Халисә Ширмән

# ЯЗМЫШЛАРДАН ЮК ЛА УЗМЫШЫМ

Повестьлар



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-31
ББК 84(2Рос=Тат)-44
Ш56

**Ширмән, Х.Х.**

Ш56 Язмышлардан юк ла узмышым : повестьлар / Халисә Ширмән. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 287 б.

ISBN 978-6-298-01820-3

Яшь язучының беренче китабы яшьлек һәм мәхәббәт турында. Тик яшьлек янәшәсендә гыйлемле һәм тәҗрибәле дөнья, мәхәббәт янәшәсендә нәфрәт бар. Язучы шул хакта уйланырга мәҗбүр итә.

УДК 821.512.145-31
ББК 84(2Рос=Тат)-44

ISBN 978-6-298-01820-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Ширмән Х.Х., 2009


ЯШӘҮ
МОҢЫ

# ЯШӘҮ МОҢЫ

*Хәтеремдә мәңге яшь булып*
*калган хезмәттәшләрем*
*Ләйләгөл һәм Айратның*
*якты истәлегенә багышлыйм*

## *Беренче кисәк*

## Алинә

Алинә, күз яшьләренә буыла-буыла, тыны беткәнче йөгерде дә йөгерде. Гамьсез узгынчылар кызый артыннан сәерсенеп карап калдылар. Берсе хәтта нәрсәдер кычкырды да бугай. Инде шәһәр гөрелтесе – артта, зәңгәр күк астында җәйрәп яткан иген кыры ямь-яшел төсе белән Алинәнең күзләрен чагылдырды. Алда урман күренде. «Йа Хода, – дип уйлады Алинә, – көч бир миңа, куәт бир! Әнә шунда гына барып җитәм дә онытам, барысын да онытам! Моның булуы мөмкин түгел, болай булырга тиеш түгел!» Ләкин урман шактый ерак иде әле. Бу кадәр авырлыкны күрмәгән тән кызның таләпләренә карыша башлады – аяклары кинәт кенә тыңламас хәлгә килде, тыны капланды. Җитмәсә, реаль дөнья үзенең бар тавышлары белән Алинәнең баш миенә үтеп керде, нәрсәдер уйларга мәҗбүр итте; күңеле эчке ярсудан арынып, ниндидер гамьсез битарафлык барлыкка килде. Гүя Алинә түгел, ә дөнья Алинә яныннан йөгерә. Ара-тирә машиналар кычкыртып узалар – аны үртиләрме?! Арыды бит инде Алинә, бик арыды. Йөгерүе әкренәйгәннән-әкренәйде, менә аяклары да бутала башлады – исерек кешедәй, әле бер якка, әле икенче якка чайкалып алды, сөрлегеп китте, бер-ике адым атлады да тагын сөрлекте, тагын алга талпынды, ләкин ерак китә алмый, тузанлы чирәмгә йөзтүбән капланды. Янына чыелдатып машина килеп туктады. «Нәрсә булды? – диде бугай янына тезләнгән ир кеше. – Үзегезне начар хис итәсезме әллә?» Начар хис итәсезме, имеш... «Әйе, бик начар хис итәм!» – дип кычкырасы килде Алинәнең. Тик тәненең бер күзәнәге дә селкенмәде. Гомумән, үзе белән булган вакыйгаларга аның үзенең бернинди катнашы юк кебек тоела башлаган иде. Әйтерсең ул бу вакыйгаларга өстән карап тора. Менә ир кеше тагын нидер дәште. Җавап ишетмәгәч, Алинәнең калтыранган иңнәреннән тотып, сак кына чалкан әйләндерде. Бер мәлгә кызның күз алдына ап-ак чаткылар сибелде. Гүя зәңгәр күк кинәт кенә җиргә сикерде дә Алинәнең күзләреннән

үпте. Яңадан – биек-биек зәңгәр күк. Шул күктә коңгырт-кара күзләр. Беркадәр усал, беркадәр таләпчән карыйлар. Үзләрендә борчылу да бар кебек. «Кай төшегез авырта?» Кай төшем авырта? Бер җирем дә авыртмый. Юк, бар җирем дә авырта. «Пычрангансыз». Пычранганмын? Шулайдыр. Йөгердем ич. Еладым. Инде менә елый да алмыйм. «Хәзер сөртәм». Сөртәм?.. Ир-атның тавышы яңгырап чыга да колагында кайтаваз булып чыңлый. Менә ул, кесәсеннән кулъяулык алып, Алинәнең битләрен ышкыды. Шушы буламы сөртү. Идән юамыни?! Җитмәсә, күңел болгандырырлык куе, затлы ир-ат хушбуе исе борынга, үпкәләргә тулды. Алинәнең уйларына, жужылдап, ниндидер сүз килеп кергәндәй булды. Пижон. Пиж-жон. Ж-ж-ж... Нәрсә жужылдый бу кадәр?! Башында, чәч араларында нәрсәдер жужылдый. Умарта күч аера. Алинә, кулларын күтәреп, башын кысып тотарга теләде. Хәлсез куллары күкрәк турысына кадәр күтәрелде дә бер мизгелгә һавада асылынып калды. Күз күреме тарая башлады. Керфекләрен тырышып-тырышып ачарга теләсә дә, һәр тарафтан һөҗүм иткән караңгылык нәрсәдер пышылдаган ир-атның йөзен дә үзенә йомып алды... Күтәрелгән куллары шап итеп кире үз урыннарына салынып төштеләр.

...Йөзенә салкынча җил бәрелә. Беркадәр дымлы, салкын караңгылык. Юк, эңгер-меңгер икән. Колагында тигез генә йөгергән машина тәгәрмәчләре тавышы яңгырый. Ул ятып тора, ахрысы. Шулай да кул-аяклары үзенә буйсыналар. Менә уң кулы кымшанды, менә башы да борыла. Коңгырт-кара күзләр. Алинәнең аларны кайдадыр күргәне бар кебек.

– Аллага шөкер, аңга килдегез. Хәзер килеп җитәбез, кымшанмыйча гына ятыгыз.

Машинада баралар икән. Кондиционердан бәргән салкын җил Алинәнең битен өшетә. Караңгылатылган тәрәзә пыялалары көн яктысын яшерәләр. Хәер, кич җитеп килә бугай инде.

– Кая?

– Хастаханәгә барабыз. Берәр җирегез авыртамы?

– Юк.

Кечкенәдән үк яратмый ул дару исен. Аның хастаханәгә барасы килми.

– Башыгыз да авыртмыймы?

– Юк.

– Алайса торып карагыз әле.

Алинә, әкрен генә кузгалып, машинаның утыргычына туры итеп утырырга тырышты. Тәне, майламаган иске

караваt пружиналары кебек, аның һәр хәрәкәтенә сызлану-әрнү белән җавап бирде. Янындагы ир-ат, күзләрен юлдан аермый гына, бер кулы белән рульне тоткан хәлдә, кызның утыргычын җайлап, турайтып куйды.

– Рәхмәт. Гафу итегез... Мин... сезне танымыйм. Сез кем?

– Безнең заманда сирәк очрый торган бер җүләр. Егылып имгәндегез дип уйлап туктаган идем, сезнең хәл катлаулырак булып чыкты. Әгәр машинада үлеп китсәгез, гомеремнең берничә көне, гаепсезлегемне раслап, билгеле урында үтәсе иде.

Бу юлы ир-атның тавышы шактый кырыс яңгырады.

– Нәрсә булды соң сезгә? Исемегез ничек?

Алинә, исемен әйтергә теләп, авызын ачты, ләкин дерелдәгән иреннәре таныш авазларны көтеп җиткерә алмыйча, күңел түреннән чыккан аһылдау белән җавап бирделәр. Кызның миен электр тогы кисеп үткәндәй булды. Йөрәге жу итеп китте. Исемегез ничек? Исемем ничек?! Ничек соң? Йа Хода, ул үз исемен белми. Юк, моның булуы мөмкин түгел – ничек инде үз исемеңне хәтерләмәскә кирәк? Кыз, бик тырышып, үз-үзен нәрсәдер уйларга мәҗбүр итте, ләкин баш мие бары тышкы мәгълүматны гына кабул итә иде. Менә ул машинада бара, янында таныш түгел ир-ат. Күз алдында офыкка җәелеп киткән юл. Кичә ул кайда иде соң? Ә өченчекөн? Юк, исенә төшерә алмый. Ходаем, үткән тормышы ак кәгазь кебек – кем ул?! Шул мизгелдә кызның күңелен курку басты, йөзенә мәет төсе керде – нишләргә дә белми, ап-ак булып катып калды, аннан, ир-атның котын алып, алга талпынды, башы машина тәрәзәсенә килеп бәрелде. Күзләре шар ачылдылар. Мондый хәрәкәтне көтмәгән ир-ат инстинктив рәвештә тормоз педальләренә китереп басты, Алинә яңадан алга сөрлекте, машина исә барган җиреннән капылт кына туктап калды.

– Ну, беләсезме, – диде ир-ат, күкле-зәңгәрле тавыш белән, – ниндидер бер... «белмим кем» аркасында минем проблемаларга чумасым килми. Чыгыгыз хәзер үк! Хушлашабыз!

Алинә тораташ хәлендә утыруын дәвам итте. Аның мие үзенең төп вазифасы – уйлаудан баш тарта иде. Ир-ат кызның көл кебек агарынган чыраена, тузгыган чәчләренә, куркынган күзләренә карады да, «Әләктем соң! Дивана!» – дип, үз-үзен битәрли башлады. «Ахмак! Туган көн мәҗлесендә кәеф сөрәсе урынга! Йөр инде бер тилемсәк белән!» Шулай да кызның тилемсә карашында

ниндидер фаҗига күрепме, бәлагә тарыганын сизенепме, йөрәгендә кызгану хисе кымшанып куйды. Кыз дигәннән, кызның яше шактый бугай инде. Унҗиде яшьлек иләсмиләс җилбәзәккә охшамаган. Салырга яратучы да, наркоман-фәлән дә түгел бугай. Уң кулының атсыз бармагында кыйммәтле балдак күренә. Димәк, кияүдә. Хәер, кем белсен аларны?!

– Да-а, – дип сузды ир-ат, битәрләвеннән туктап. – Йә, чыгасызмы, юкмы?

Алинәнең бер мизгелгә йөзенә нур кунгандай булды. Кулы белән уң як бил турысын капшый башлады.

– Сумкам! – диде ул ир-атка. – Минем сумкам булырга тиеш. Анда минем документым бар.

– Туташ! – Ир-атның коңгырт-кара күзләре ачулы ялтырап алдылар. – Мин сине машинага утыртканда, кулыңда бернинди дә сумка юк иде. Йөгереп килгән җиреңнән абынып егылдың син.

Алдашканга охшамаган кебек бу ир-ат. Кыйммәтле чит ил машинасында җилә торган ир-егеткә синең сумкаң хаҗәт түгелдер. Йөгереп килгән җирдән... Әйе шул, йөгерде ул. Бик кызу, елый-елый йөгерде. Егылды. Нигә йөгерде соң әле? Ә аңа кадәр, аңа кадәр кайда булды?! Кем ул?! Урманга барып җитәм дә онытам, диде. Анысын да хәтерли. Тик... нәрсәне? Нәрсәне онытмакчы иде ул?

Алинәнең бу кадәр билгесез, бу кадәр мескен хәлгә калганы юк иде. Күзләреннән яшь коела башлады. Ир-ат, үксеп елаган кызга карап торды-торды да, «Әйдә, ярый, ачыкларлар» дип, машинасын яңадан кабызып, кузгалып китте.

...Хастаханәгә бик тиз барып җиттеләр. Ир-ат, Алинәнең иңнәреннән сак кына тоткан хәлдә, кабул итү бүлмәсенә алып керде. Яраланган кош баласыныкы кебек тибә иде кызның йөрәге. «Зинһар, карагыз әле, – дип эндәште ир пульт артында утыручы шәфкать туташына. – Менә бу кыз үзен бик начар хис итә. Урамда егылган. Кем икәнен дә хәтерләми. Зинһар, булышыгыз инде үзенә».

Шәфкать туташының әллә ни исе китмәде. Кырын күз белән Алинәнең тузанланган өс-башына, ир-атның соңгы модалы галстугына карап алды да, мыскыллы көлемсерәп: «Шулаймыни?!» – дип сузды. Ир-ат аның карашын бик яхшы аңлады. Булсын. Барыбер.

– Карале, гүзәлем, – диде ул, тавышына беркадәр ялагайлык чыгарып. – Бары син генә булыша аласың. Беләсеңме, хәзер мин китәргә тиеш. Ләкин мин сиңа телефон номерымны калдырам. Иртәгә килгәч, бу кыз турында

иркенләп сөйләшер идек. – Ир-ат, куен кесәсеннән алып, туташның журнал эченә ниндидер кәгазьләр тыгып куйды. – Табибны чакырт инде, яме?!

Туташ журналдагы кирәкле битне бик тиз тапты. Бөгәрләнмәгән дә йөзлекләр ак халатның шактый тирән кесәсенә төшеп утырдылар.

– Хәзер. – Бу юлы туташның елмаюы Алинәгә төбәлгән иде. – Менә биредә утырып торыгыз. Мин биш минуттан әйләнеп килермен.

Моңа кадәр тыныч кына көтеп торган Алинә каршысына килеп баскан ир-атка ялварулы күзләрен төбәде.

– Сеңлем! – Йомшак баритонда аклану төсмерләре чагылып китте, әмма озакка түгел. – Мине көтәләр. Мин инде болай да синең белән йөреп соңга калдым. Китәргә кирәк. Хәзер яныңа табиб килер, ул сине дәвалар, син гаиләң, якыннарың янына кайтырсың. Сау бул, яме?! Тизрәк терелеп чык. Бәлки, берәр вакыт очрашырбыз да әле.

Ир-ат Алинәнең калтыранган салкын бармакларын учларына алды. Тәрәзәдән кергән кечке нурлар кызның яшькелт-зәңгәрсу күзләрендә чагылдылар. Сөйли торган күзләр. Алардан бөркелгән чиксез өметсезлек, инәлү иратны тетрәтте, күзләрен кызның күзләреннән ала алмый, беренче күргәндәй, матурлыкка таң калып, берара текәлеп карап торды, күңелендә, йөрәгенең әллә кайсы өлешендә ниндидер татлы хис кымшанып куйды. «Юк, – дип башын чайкады ул бераздан, – юк! Җүләрлек бу. Китәргә кирәк. Китәргә».

Кичке тынлыкта машина тавышы аерата моңсу ишетелде. Бу дөньяда Алинәне белгән, Алинә белгән бердәнбер зат эңгер-меңгер кочагына чумды.

Шәфкать туташы бик җитез генә ак ишек артына кереп югалганнан соң, озак та үтмәде, бүлмәгә күзлекле табиб килеп керде.

– Йә, нәрсә булды? Кайсы төшегез авырта?

Алинә җавап бирмәде.

– Башыгыз авыртамы?

– ...

– Исемегез? Фамилиягез? Кайда яшисез? Туганнарыгыз сезнең монда икәнне беләме?

Кургашындай авыр сораулар. Их, Алинә белсә иде икән. Монда утырыр идемени ул?! Гаҗәп кеше бу табиб.

– Розана, бу кызны сигезенче палатага билгелә әле. Иртәгә Хәмит Ризванович килгәч ачыкларбыз.

– Сигезенче палатада урын юк шул, Таһир Бариевич.

– Алайса, дүртенчегә.

– Анда милиционерлар дежур тора ич, һөҗүмдә яраланган банкирны саклыйлар.

– Кайда да булса урын бардыр бит инде? Булмаса, унтугызынчы хастаханәгә озатыйк.

Розананың «керемле пациентканы» югалтасы килмәде.

– Уникенче палата буш та инде... «югары»дан берәрсе килеп чыгуы мөмкин... Коридорга яткырсак ничек булыр?

– Әйдә, үзең хәл ит. Иртәгә Хәмит Ризвановичка әйтергә онытма. Минем кизү вакыты бетә, өйгә ашыгам.

Табиб чыгып китте. Шәфкать туташы, бик артык кайгыртучанлык күрсәтми генә, журналга нәрсәдер язганнан соң, Алинә ягына борылып сорап куйды:

– Тәнең чистамы?

Кыз, аңламыйча, башын иеп, өс-киемнәренә күз төшерде. Тузанланган инде. Егылды ич ул.

– Бетләрең юкмы, дим мин.

Кызның һаман аңламаган кыяфәт белән карап торуын күреп, шәфкать туташы кул селтәде:

– Ярый, «санобработка»га барырсың. Әнә коридор буйлап бар да, борылгач, уңнан икенче бүлмәгә кер. «Санобработка»га, диген. Менә бу кәгазьне күрсәтерсең. Икенче этаж коридорының дүртенче караваты синеке. Урын-җир әйберләрен шундагы туташлардан сорарсың. Мин хәзер шалтыратам аларга. Аңладыңмы? Бар инде, бар...

Алинә шәфкать туташы төртеп җибәргән озын коридор буйлап алга атлады. Ул арада кабул итү бүлмәсенә юл һәлакәтендә яраланган ике ир-атны китерделәр. Андамонда йөгерешкән шәфкать туташлары күренде. Берничә минутка хастаханә өчен гадәти ыгы-зыгы туып алды.

Алинә озын коридор буйлап бара да бара. Шәфкать туташы биргән язуны ике куллап күкрәгенә кысып тоткан. Ничәнче бүлмә диде әле? Кайбер ишекләрдән шәмәхә яктылык бөркелә, кайберләрендә инде ут сүнгән. Шактый баргач, коридор сулга борылды, Алинә баскыч төбенә килеп чыкты, баскыч буйлап өскә күтәрелде, тагы тар коридор буйлап атлады, ахырда, тәмам хәлдән таеп, стена янындагы эскәмиягә барып утырды. Ара-тирә әкрен, кыштырдавык адымнар белән авырулар үтеп китә, алар башын тотып утырган кызга сәерсенеп карыйлар. Дару исеннән Алинәнең күңеле болгана. Юк, чыгарга кирәк моннан. Шактый хәл җыеп утырганнан соң, Алинә кузгалып китте, тагы озын коридорларда буталып йөреп, баскыч буенча киредән аска төште. Менә пыяла ишекле зур гына залга килеп чыкты. Монда һава чистарак. Тавыш-тын да юк, утларны да сүндергәннәр. Кыз, пыяла ишекләр янына барып, тартып карады. Бикле.

– Нәрсә йөрисең төне буена? Көн генә җитмәдеме әллә? Әйттемме мин сиңа соңга калсаң чыгармыйм дип? Әйттемме?

Алинә кинәт яңгыраган бу тавышка сискәнеп китте, кызу-кызу башын чайкый башлады. Нәрсәдер әйтергә теләп, тотлыгып калды. Күзләренә көчле яктылык китереп бәрде.

Вахтер хатынның гайрәте яман иде.

– Свиданҗә йорты дип беләсезме әллә? Ачмыйм ишекне, уйлама да!

Тәмам каушап калган Алинә, ни әйтергә белми, кысып торткан кәгазен яктылык чыганагына сузды. Моны күреп, хатын бераз тынычланды, нәрсә икәнен аңламаса да, гайрәте бераз кимеде. Шул вакыт ишекне урам ягыннан шакый башладылар. Хатын, авызыннан утлар чәчә-чәчә, фонарь яктысын шул якка юнәлтте. Пыяла ишеккә унбиш-уналты яшьләрдәге ике юеш борын терәлгән, ерылган авызлары янәшәсенә, пыялага илле сум акча ябыштырганнар.

– Апакай, сезнеке төшеп калган, ахры, – үзләре шырык-шырык көлешәләр. – Менә ишек яныннан таптык.

Хатын, ачуланган кыяфәт чыгарып, йозак бикләрен шалтыратты. Ике яшүсмер, ачык ишектән җитез генә кереп, юк булдылар.

– Нәрсә катып калдың? – Алинәгә карап җикерде хатын. – Бар, күземнән югал тизрәк! Башка чыгарыр дип уйлама да. Сәгать җидедән соң ни туда, ни сюда, бел аны!

...Төн Алинәне үз кочагына алды.

Вакыт инде шактый соң булса да, шәһәр урамнарында узгынчылар җитәрлек. Кемнәрдер гаиләләре, балалары белән һава суларга чыккан, кемнәрдер парлашып мәхәббәт диңгезендә йөзә, әлегә үз парын тапмаган яшь-җилкенчәк төркем-төркем булып җыелып утыра, кычкырып көлешәләр. Алинә, боларның берсенә дә игътибар итмичә, кая барганын үзе дә сизми, аяклары тыңлаганчы барды да барды. Әйтерсең ул – робот. Курчак. Бернәрсә уйлый алмый, бернәрсәгә исе китми. Күңелен ниндидер аңлатып бетерә алмаслык ваемсызлык, гамьсезлек биләп алган. Уңга, сулга борылды, юл аркылы чыкты, ниһаять, арып, барган җиреннән туктап калды. Төн уртасы җиткән, талчыккан гәүдә ял сорый иде. Ләкин кая барырга? Йокларлык, төн кунып чыгарлык урынны каян табарга? Алинә, баш миен эшләтергә теләп, маңгаен сыпырды, күзләрен учлары белән кысып-кысып алды. «Йа Аллам, кем соң мин, минем бит торган җирем, туганнарым бардыр. Ничекләр итеп искә төшерим икән?! Өйгә кайтасым

килә, өйгә...» «Өй» диюгә, Алинәнең күз алдында яшел чирәмле, карт тал астындагы авыл өе гәүдәләнгәндәй булды. Әнә, тал янындагы утыргычта таягы белән җирне чокыштыргалап, ак яулыклы бер әби утыра. Менә ул, кулларын каш өстенә күтәреп, юлдан килүчене күзәтә... Ә юлдан... юлдан бит Алинә бара! Ул өенә кайта! Алинә, каушаудан тешләрен кысып, ыңгырашып куйды. Күз алдындагы сурәт ничек барлыкка килгән булса, шулай ук тиз юкка да чыкты, башы сулыгып-сулыгып авырта башлады. Алай да кызның аңында бер факт теркәлеп калды: аның өе авылда. Шулай булгач, монда – шәһәрдә – нишләп йөри соң ул?! Кырмыска өе кебек кайнап торган шәһәр уртасында ни калган аңа? Кунакка килде микән әллә? Тормышындагы тагын берәр вакыйганы исенә төшерергә теләп, Алинә янәшәдәге агач астына барып утырды, яңадан хәтеренә баягы әби сурәтен кайтарырга тырышты. Ләкин юкка. Әби дә, өй сурәте дә тоныклана төшеп ерагайдылар, аксыл томанга уралып, бөтенләй юкка чыктылар. Кызның керфекләре кушылды, тәне тәмам изрәп, утырган килеш җиргә ауды да шул мизгелдә үк газаплы йокыга чумды...

...Үзен төрткәләгәннән уянып китсә, тирә-як инде яктырган, җиргә иртәнге салкын һава иңгән, ләкин кояш чыкмаган иде әле. Бөтен тәне сызлый, җитмәсә, салкын җирдә ятканлыктанмы, ачытып тамагы авырта, авыз эче берни тоймас булып кипкән. Берничә яшүсмер, көлешә-көлешә, кызның аякларыннан, итәкләреннән тоткалыйлар, өскәрәк үреләләр иде.

– Нәрсә, уяндыңмы, чибәркәй?! Кичә күбрәк эчелгәнме әллә?

Алинә баштарак боларның авыз еруларының мәгънәсен дә, үзенең кайда, нишләп ятуын да аңламады. Бары тик каршында буйга җитеп килгән, җитмәсә, шактый салып алган ир-ат яшүсмерләрнең өелешеп торуы һәм бөтен тәненең сызлап-сыкрап әрнүе аны бу дөньяга кайтырга мәҗбүр итте. Кызның күңелен курку биләп алды, итәкләрен җыйнап, аягына басарга тырышты.

– Әһә, кызый тиз генә ычкынмакчы икән. Ну, егетләр, ычкындырабызмы кошны, кулга бер эләккәч?!

Моны озын буйлы, сары чәчлесе әйтте. Калганнары ихахайлап көлештеләр, берсе кызның тузгыган чәчләреннән сыйпаган булды.

– Егетләр, мин бик авырыйм, – диде Алинә, телен чак әйләндереп. Үз тавышы үзенә дә ишетелмәде. – Зинһар, ярдәм итегез миңа.

– Нәрсә, «авырыйм» диме?! Нәрсә белән авырыйсың

соң, чибәркәй?! СПИД белән авырыйсыңмы әллә? У-у, алайсак җибәрәбез инде сине... Соңрак, яме?!

Егетләр тирә-якны яңгыратып шаркылдаштылар. Теге сары чәчлесе җирдә утырган Алинәнең каршысына чүгәләде. Икесе кызның артына елыштылар. Алинә, куркыныч сизенеп, тормакчы булды, ул да булмый, арттагы икесе, кызның кулларын борып, җиргә егып салдылар, алдагысы «әһ» дигәнче кызның итәкләрен өскә күтәрде.

– О-о!

Егетләрнең тавышы ихлас иде.

– Чибәрсең үзең, чибәркәй. Мондый аякларны телевизордан гына күрсәтәләр. Ярар инде, тузанланган дип тормыйбыз, безгә болай да ярый, шулай бит, ә?!

Алинәнең әзмәвердәй егетләргә карышырлык мөмкинлеге юк иде. Аның күзләрен чытырдатып йомып, суга баткан чебеш кебек тыпырчынуыннан көлештеләр генә. «Раббым, Аллам, – диде Алинә, эченнән Ходайга ялварып, – коткар мине бу хурлыктан! Җибәр миңа үлем фәрештәсен, җибәр, газаплама!»

Алинәне кысып тоткан куллар кинәт бушады, шаркылдашкан тавышлар тынды. Алар урынына каядыр еракта икенчерәк тавышлар барлыкка килде. Беришләре – калын, түбән, икенчеләре – югары, нәзек тавышлар. Менә Алинәгә якынайдылар, уратып алдылар, ниндидер куллар кызның өске киемен тәртипкә китерде.

– Әллә инде явызлар үлекне мәсхәрә итәргә җыенганнар?!

– Юк, тере бугай. Менә пульсы бар. Сулый да үзе.

– Шушы хәлгә җиткәнче нигә эчәргә диген син?! Эх, нинди замана җитте хәзер, ә?! Хатын-кыз шушы буламы?!

– Туктале, үзеннән аракы исе дә килми бит.

– Айнык булса, монда ятмас иде. Йә наркоманфәләндер.

– Нишләтик соң? «Скорый» чакырырга кирәк, шалтыратырга. Монда калдырып булмый лабаса. Йә милиция алып китсен.

– Берәр квартирага кереп шалтыратсаң гына инде. Урамда төзек телефонны каян табасың.

– Әһе, кертерләр квартирага. Пожар кычкырсаң да кертмәячәкләр.

– Соң, болай калдырып булмый бит инде адәм баласын. Өйдә якыннары көтәдер, кайгыралардыр. Әйдә, селкетеп карыйк әле.

Берничә кул Алинәнең чигәләрен уды, яңакларыннан чәбәкләде. Кызның башка ачылмаска дип чытырдатып йомылган керфекләре калтыранып куйды, озын кер-

фекләр астыннан яшькелт-зәңгәрсу күзләре дөньяга рәнҗеп ачылдылар. Аны кулларына себерке тоткан, урам себерүче киеме кигән бер төркем кешеләр уратып алган иде.

– Уянды. Хәерле иртә, чибәркәй!

– Өйгә кайтырга вакыт түгелме сиңа?

– Нәрсә, такси килеп алганын көтәсеңме әллә?!

– Туктагыз, алай кычкырмагыз! Бәлки, авырудыр ул, нигә бәйләнәсез әле аңа? Торсын, сөйләсен. Исемегез ничек сезнең, кайда яшисез?

Исемегез ничек, имеш. Юк, бу төш. Алинәнең уянасы килә. Алинәнең уянасы килә, шайтан алгыры! Китсен, югалсын бу өрәкләр, Алинә башка чыдый алмый. Алинә башка бу саташуга түзә алмый. Китегез, убырлар! Лә хәүлә вә лә куәтә!

Ләкин өрәкләр югалмады. Алинә саташулы төшеннән уянмады. Сызланып кымшанган тән әрнүдән арына алмады. Торган җирен, гаиләсен, якыннарын, исемен, фамилиясен югалткан кыз, урам себерүче кешеләрнең айһайлы карашлары астында яткан җиреннән көч-хәл белән торып, чайкала-сөрлегә атлап китте. Алга таба, чыгып килүче кояшка таба атлады...

* * *

...Кояш инде төшлектән узган. Алинә, кояшта ялтыраган су тамчыларының уенын күзәтеп, фонтан янында утыра. Чигә чәчләреннән тамчылар тама. Керфекләре чыланган. Әллә күз яше чылаткан аларны, әллә чәчләрен чылаткан кебек, керфекләрен дә Алинә үзе чылаткан?! Менә инде битләре буйлап та агып төшәләр. Алинә аларга игътибар итми – аның ашыйсы килә. Ике көн инде – әллә күбрәк тә микән? – авызында ризык тәме тойганы юк. Баштарак арыганлык, талчыкканлыктан интексә, хәзер тән сызлануы сизелми диярлек. Ә ашыйсы килү аның саен көчәя, аның саен пәрәмәчләр, бөккәннәр, пилмәннәр, өчпочмаклар күз алдына килеп газаплыйлар. Күңелендәге горурлыгын җиңеп, юлчылардан сорап карады – кешеләр өсте-башы тузгыган, күз карашы тилергән кызыйдан, куркынып, читкә тайпылдылар. Кайберсе әшәке сүз әйтте. Кайберсе кесәдәге вак бакырларын ыргытып китте. Алинә уч төбендәге бу бакырларны тотып, кибет киштәләрендәге икмәккә карап торды да, бер кыерчыкка да җитмәгәнен аңлап, башын иеп китеп барды. Үзе кебек йорт-җирсез, кызыл борынлы пычрак урам агайларының кул сузып утыруларыннан йә булмаса

чүплек савытларында казынуларыннан күңеле белән җирәнеп, үзенең андый түбәнлеккә төшүеннән куркып, бертуктаусыз Ходайдан үлем сорады. Ләкин үлгәндә дә ашап үләсе килә икән. Берничә мәртәбә, кибеткә бәреп кереп, ризык урлап чыгудан үзен көч-хәл белән тыеп калды. Менә хәзер дә, уттай янган башын су белән чылатып, кояшта уйнаган тамчыларны күзәтә, үзенең күз алдында токмачлы шулпа белән кара арыш ипие. Шул вакыт колагына пышылдаган таныш тавыш яңгырап киткәндәй булды. Алинә, сискәнеп, корт чаккандай урыныннан сикереп торды, тирә-якка каранды. Анда-монда кешеләр йөргәләп тора, ләкин берсе дә аның ягына борылып эндәшми иде. Ә тавыш тагы кабатланды. «Өзелепләр ашыйсым килә, кызым...» Тагын, тагын... «Өзелепләр ашыйсым килә...» Тавыш Алинәнең колагыннан китәргә җыенмый да иде. Кыз, шашынып, куллары белән колакларын томалады. «И-их, кызым... Ризыкның кадерен белмибез икән... Өзелепләр ашыйсым килә шул...» Тукталe, бу бит аның әбисе. Әбисенең тавышы бу, әбисенең! Алинә, куллары белән башын тоткан килеш, шапылдап артына утырды, йөрәге ярсып-ярсып тибә башлады, хәтерендә шактый күптәнге вакыйга яңарды...

...Аның әбисе инде олы яшьтә булып, күп гарасатлар күргән, сугышлар кичергән, шулай да күңел җорлыгын югалтмаган ачык йөзле гадәти бер татар карчыгы иде. Кечкенәдән ятим калып, кеше өстендә үскән, ашау, карау җитмәгәнгәме, буе да бик кечкенә, чандыр гәүдәле булса да, йөзне тутырып бара. Яше турында тел шартлатучыларга ул: «Мин туганнарым өчен дә яшәргә тиеш, алар шулай әманәт әйтеп калдырдылар», – дип шаярта иде. Ә туганнары, чыннан да, туу белән берәм-берәм бу дөньядан китә барганнар. Тугыз балалы оядан әбисе – баш бала – берүзе яшәп калган. Шуңадыр инде Ходай үзеннән сәламәтлекне кызганмаган – туксанга кадәр бакчада чүп утады, чебеш-бәбкә белән мәшгуль булды, көтүдән кайткан малларны үз урынына кертеп яба, хәтта өй эчендә дә кул җиткән чаклы савыт-саба юа иде. Алинәне дә ул карап үстерде. Тик соңгы вакытта әбисенең хәле китеп тора. Менә ике атна инде ашаган ризыгы кире чыга. Алинә шәһәрдән көчле чит ил дарулары да алып кайтып карады, табиблар белән дә киңәште. Тик барысы да көрсенеп баш чайкадылар. Алинәнең ышанасы килмәде. «Вакыт җиткәндер инде, яшәмәдем түгел, яшәдем, – диде әбисе. – Ансат үлем бирсен Ходай». Ходай Тәгаләнең нигәдер ансат үлем бирәсе килмәде – әллә әбисе үзе китәргә теләмичә үчләштеме икән? Тагы бер атна буе кар-

чыкның төрле ризыклар ашыйсы килде. Гел пешеренеп кенә торды Алинә – яшь әтәч итен дә, өчпочмагын да, бәлешен дә, шулпасын да. Тик йөзьяшәр әбинең ашказаны берсен дә кабул итәргә теләмәде. Ашыйсы килүдән бик интеккәндә, ризыклардан сыгылып торган өстәл янына килер иде дә, һәрберсен кулына тотып, иснәп карар, ахырдан ике-өч бөртек ипи валчыгын авызында җебетер иде. Менә инде бөтенләй урыныннан тора алмас булды, капкан су да кире чыкты. Шул хәлдә тагы атна үтте. Урынында интегеп яткан әбисе иреннәрен чак кыймылдатып Алинәне чакырды. «Өзелеп ашыйсым килә бит, кызым... Өз-зелепләр ашыйсым килә». Алинәнең үзәге өзелде. Бәгыре телгәләнде. Тау кадәр өелеп торган ризык янында әбисе ачтан үлә бит, никадәр гаделсезлек! Аерылуны бу кадәр авыр булыр дип уйламаган иде. Баш очында ясин укып утыручы абыстай үлеп бетмәгән әбисенең күзләрен йомдыра, карчык, аның саен үҗәтләнеп, керфекләрен ача... Алинәнең суларга тыны җитми, күз яшьләренә буылып, әбисенең кулын кыса... Ниһаять, соңгы сулышына кадәр үлем белән тартышып, әбисе якты дөньяны калдырып китеп барды. Аның пышылдап әйткән сүзләре Алинәнең колагында озак, бик озак чыңладылар...

Алинә Нурлыҗиһан әбисенең тавышын ишеткәнгә шатлана да, кайгыра да алмады. Әйе, әбисенең исемен дә хәтерләде, йөзе дә күз алдында, хәтта балачак елларыннан кайбер истәлекләр дә хәтерендә яңардылар. Ләкин шуннан ары барысы да томан артында калды. Бу аңа үзенең кем икәнен ачыкларга да, кайда торуын белергә дә ярдәм итмәде. Тагы чигәләрен кысып, башы гөжләргә тотынды. Ашыйсы килү тойгысы шулкадәр көчле иде, Алинә торып китте. Барып, фонтаннан су эчте, битләрен юды, өстен-башын су белән сөрткәләгәннән соң, беркадәр тынычлангандай, хәл кереп киткәндәй булды. «Үләргә соң түгел. Беркайчан да соң түгел». Әбисе гел шулай дия иде. Ризык турында уйламаска кирәк. Болай шәһәр урамнарында йөреп тә булмый. Әбисен искә төшерүнең үзенә никадәр файда китергәнен кыз әле аңлап та бетермәде. Иң мөһиме – аның фикерләре бер ноктага туплана башлаган иде. Болай йөреп булмый. Кемнәндер ярдәм сорарга кирәк. Алда тагы төн. Кая барыр ул? Алдагы төннәрдәге кебек җирдә йә подъезд идәнендә йоклап булмый. Ярдәм сорарга кирәк, ярдәм... Әнә каршыга ике милиционер килә. Алар ярдәм итәргә тиеш.

Кыз, рәсми кием кигән кешеләргә якынлашкач, нәрсә әйтергә белми, аптырап туктап калды. Нәрсәдән башларга?

– Гафу итегез, сездән сорарга мөмкинме?

Милиционерлар бу сәер кызга сәерсенеп карадылар. Берсе, Алинәнең өс-башын күздән кичергәннән соң, икенчесенә мәгънәле генә карап алды да:

– Соң, тыңлыйбыз. Нәрсә сорарга телисез? – дип, кызга төбәлде.

– Мин кыен хәлгә калдым... адресымны, кайда торганымны белмим...

– Исем-фамилиягез ничек? Документларыгыз бармы?

– Белмим... бернәрсә дә хәтерләмим...Үзем белән бер әйберем дә юк.

– Нәрсә, эчкән идегезмени?

– Белмим... Юктыр дип уйлыйм. Ләкин бернәрсә дә хәтерләмим. Минем ашыйсым килә, башым авырта... Кая барырга да белмим.

Кыз яшьле күзләрен күтәреп карарга да курыкты.

Милиционерлар бер-берсенә карашып алдылар.

– Ә сез бу шәһәрнекеме соң?

– Белмим... Бу урын миңа таныш түгел... Мин берни хәтерләмим, аңлыйсызмы?!

Погонлыларның берсе икенчесенә гамьсез генә: «Нәрсә, аңлашыла инде. Гадәти хәл. Әйдә, машина чакыртыйк», – диюдән узмады. Икенчесе, бераз уйланып торганнан соң:

– Без сезгә конкрет берничек тә ярдәм итә алмыйбыз. Әгәр урамда кунасыгыз килмәсә, хәзер машина чакыртабыз. Сезне тиешле урынга озатырлар, ә анда инде барын да ачыкларлар, – диде.

Алинә, «тиешле урын»ның нәрсә икәнен күз алдына китермәсә дә, урамда төн кунудан куркынычрак түгелдер дип уйлап, шунда ук риза булды. «Бәлки, чынлап та, кемдер ярдәм итәр» дигән уй беркадәр күңелен җылытып җибәрде, кәефен күтәрде.

Милиционерлар чакырткан патруль машинасы шактый көттерде. Алинә тыныч кына фонтан янында утыра иде, милиционерлар ерак түгел әрле-бирле йөренеп торалар. Башының гөжләп авыртуын исәпкә алмаганда, кызның хәле ярыйсы. Күңелендә калыккан өмет чаткысы ачлык тойгысын да бераз киметте. Менә чатта зәңгәр «уазик» күренде. Милиционерлар үзара нәрсәдер сөйләшкәннән соң, берсе Алинәгә таба атлады.

– Әйдәгез, утырыгыз.

Машинадан төшкән милиционерның тавышы артык сүз әйтергә курыккан кешенекедәй кырыс яңгырады. Кызның башына каяндыр «алар барысы да шулай кырыслар инде» дигән уй килде, ләкин мәгънәсенә төшенеп торырга вакыт юк иде. Алинә машинада тагы ике кыз барлыгын абайлап алды. Күрәсең, бу дөньяда аңардан башка да бәлагә

тарыган кешеләр бар. Ә син үзең генә шундый хәлгә төштем дип уйлыйсың, үләргә җыенасың. И-их, син... Әмма машинадагы кызларның хәле бәлагә тарыган кешеләрнекенә охшамаган – бертуктаусыз лач-лоч сагыз чәйниләр, алда утырган милиционерларга ниндидер шаян сүзләр әйтәләр, ихахайлап көлешәләр. «Танышларыдыр, күрәсең», – дип уйлады Алинә, аптырагач. Каядыр килеп җиттеләр бугай, машина туктап калды. Шыгырдап капка ачылганы ишетелде. Машина, кузгалып, иркен ишегалдына керде, милиционерлар, төшеп, кызлар утырган ишекне ачтылар.

– Йә, күгәрченкәйләр, төшегез, килеп җиттек, – диде аларны озата килгәне.

Кызлар чытлыклана-чытлыклана машинадан төштеләр. Алинә дә аларга иярде.

Кизү торучы милиционер, бераз вакыт Алинәгә текәлеп карап торганнан соң:

– Нәрсә, яңа чибәркәй эләктеме әллә? Кая билгеләргә? – дип сорады.

Алып килүчесе:

– Әйдә, рәсмиләштер шунда бергә, аннары ачыкларлар. Безнең смена бетте, кайтабыз, – дип китеп барды.

Алинәне башка кызлар белән бергә кысынкы гына тимер рәшәткәле читлеккә кертеп яптылар. Бүлмә дип атап булмый иде бу урынны. Җитмәсә, бирегә инде төрле яшьләрдәге берничә хатын-кыз җыйналган. Яңа килүчеләрне төксе генә каршы алдылар.

– Ә-ә, син дә эләктеңмени, Розочка, – диде сәкедә ятып торган кара хатын, кызларның берсенә карап. – Нәрсә, «клиент» «тапшырды»мы сине дә? У-ух, әшәке!

Хатын ямьсез итеп сүгенде. Икенче кыз да мондагыларны белә иде, күрәсең, күңелле генә күрешеп чыкты.

– Ә бусы кем тагын? – Кара хатын усал карашын Алинәгә төбәде. – Сезнең белән мәллә, Розочка? Яңамы?

– Юк, каяндыр юлдан алдылар аны. Белмим, кемдер.

Розочка Алинәгә гамьсез караш ташлады. Ләкин кара хатынның ачуы басылмаган иде, шуңа Алинәне тиз генә җибәрәсе итмәде.

– Нәрсә, «ялгызак» мәллә? Кем син? Безнең «клиентларны» чүплисеңме?

Алинә боларның сөйләшүен, гомумән, аңламыйча басып тора бирде. Үзенең монда эләгүен ул бөтенләй ялгыш дип уйлый иде. Аңа бит «ярдәм итәбез» диделәр. «Төн кунып чыгарга урын булыр» диделәр. Монда, бу усал хатыннар янында төн кунасын Алинә башына да китермәде. Менә хәзер кererләр дә болар яныннан алып чыгып китәрләр дип уйлап, рәшәткәгә сөялде.

– Әй, мин синең белән сөйләшәм! Ишетәсеңме? Әллә чукрак инде. Китерегез әле монда үзен.

Камерадагы кызлар бу хатыннан куркалар иде булса кирәк. Шунда ук берничәсе торып, Алинәне хатынга йөзе белән бордылар, аркасына төрттеләр. Алинә, сөрлегеп, хатын алдына тезләнде.

– Менә шулай. Беренче мәртәбә күрәм сине. Кызлар, таныйсызмы?

Алинәне танучы булмады.

– Нәрсә, «ялгызак»мы? Куптәнме бу шәһәрдә? Нигә дәшмисең?

Хатын, кулы белән каты гына кизәнеп, Алинәнең йөзенә китереп сукты. Йодрык борын турысына килеп тиде, шунда ук гөрләп кан китте. Кан күргә, Алинәнең коты очты, күзләре акайды, куллары белән башын тотып, гөрселдәп идәнгә ауды. Камерада аһылдаган тавышлар ишетелде. Хатын яңадан каты итеп сугенде. Кызны күтәреп сәкегә салдылар, башын артка ташлатып, борынына чылатылган кулъяулык капладылар. Бераздан Алинә күзләрен ачты.

– Ну, кызый, кара аны. Тагын бер шундый комедия күрсәтсәң, манчыйбыз үзеңне.

Кара хатын усал итеп сүгенсә дә, кызый яныннан китмәде. Кулъяулыгын алыштыртты, башына каяндыр табып сулы сөлге уратты. Бераз ятканнан соң, Алинәгә хәл керде, сөйләшә башлады.

– Мин сезне аңламыйм. Каннан куркам мин, шуңа егылганмындыр. «Ялгызакларның» да, «клиентларның» да кем икәнен белмим.

– Ну, сыптыра! – диде кызлардан берәү:

Кара хатын шунда ук аңа:

– Тик тор! – дип җикерде.

– Алайса, кем соң син? Ничек монда эләктең?

– Белмим... Мин үземнең кем икәнемне белмим. Миңа «ярдәм итәбез» диделәр, монда алып килделәр. Мин бернәрсә-ә хәтерләмим, минем ашыйсым килә-ә...

Алинә кара хатынның күзләренә мөлдерәп карады да кычкырып елап җибәрде. Хатын дөнья таный торган кеше, ахры, яшькелт күзләрдәге фаҗигане күреп имәнеп китте. Соңгы көннәрдә кызның күңелендә шулкадәр хәсрәт җыелган иде ки, күз яшьләре, ташкын булып, тышка ыргылдылар. Мөлдерәмә күңел ташыды да ташыды. Кара хатын да, башкалар да дәшмичә тын гына Алинәнең бушануына карап утырдылар. Ахырдан кара хатын түзмәде, кызның чәчләреннән сыйпап, тынычландыра башлады, Алинәнең башын күкрәгенә кысып сөйде.

– Йә, булды инде, булды. Ярсыма алай. Тынычлан. Без белмәдек бит. Үзең әйтмисең.

Алинәнең бу наздан яңадан күңеле тулды. Күз яшьләре елга булып актылар да актылар... Озак, бик озак елады Алинә. Ахырдан, соңгы үксүләр тынгач кына, кара хатын:

– Сөйлә инде, нәрсә булды сиңа? Нинди бәлагә тарыдың? – дип, Алинәнең башыннан үткәннәрен барысын да берәм-берәм сөйләтте. Милициягә мөрәҗәгать иткәнен әйткәч, хатын ухылдап куйды, исе китеп, Алинәгә:

– Әй җүләр, үз башыңнан күрәләтә аларның кулына барып керәләрмени, тиле! – дип әрләп алды. – Ничек чыгарсың моннан, беләсеңме соң?

– Алар «ярдәм итәбез» диделәр бит...

Камерада көлешеп алдылар.

– Әй җүләр, күрәсеңме инде ничек ярдәм иткәннәрен?!

– Нишлим соң, кая барыйм?! Бернәрсә, бернәрсә хәтерләмим бит!

– Әйе, сериаллардагыдан ким булмаган хәлләрең. Ышанып та булмый хәтта. Беләсеңме, чибәрлегеңә караганда, берәр король кызыдыр әле үзең. Яисә, ким дигәндә, премьер-министрныкы. Күлмәгең әйбәт күренә. Балдагың да.

Кара хатын бу сүзләрне әйткәненә үкенде. Шунда ук берничә кул кызның бармакларына үрелде.

– Сузылма! – дип җикерде хатын. – Бүгеннән башлап бу кыз минем канат астында. Ишеттегезме?

Алинә бу сүзләрнең мәгънәсен аңлап бетермәсә дә, үзен яклаучы барын тою рәхәт иде. Шуңа да ул, батырланып:

– Ә сез кемнәр?! – дип сорады.

Кара хатын, елмаеп:

– Ничек дип әйтим икән... Э-э... Үз көнен үзе күрүчеләр, кыскасы. Мин – Эсмеральдо. Эмма дип атасаң яхшырак булыр.

– Эмма. Матур исем. Минем дә исемем бардыр инде, хәтерләмим генә...

– Исемсез кеше булмый. Син Рита булырсың. Ошыймы? Рита, Риточка, Маргарита.

Рита, Рита, Маргарита. Болай ятышлы үзе. Шундый бер изге кыз булган бугай... Чү! Нигә Алинә боларны белә, нигә үз исемен хәтерли алмый?!

– Ошый, – диде кыз, сыкрап. – Шулай да минем үз исемемне хәтерлисем килә.

– Исеңә төшкәч, үз исемеңне алырсың. Бусы мәңгелек түгел ич. Вакытлыча. Тәк, кызлар, таныш булыгыз: Рита – безнең яңа дустыбыз. Әйткәнемчә, бүгеннән минем канат астында. Мин сиңа кулымнан килгән кадәр ярдәм итәрмен. Әйдә, ятып тор аз гына.

Алинәне ипләп яткырдылар, кызлардан кайсысыдыр кофтасын салып өстенә япты. Мондый игътибардан Алинә, сабыйларча изрәп, тынычлап күзләрен йомды. Эмма, бераз уйланып торгач, яңа килгән кызга эндәште:

– Розочка! Кил әле монда, сөйләшәсе бар.

Бераз читкәрәк китеп, пышылдаша башладылар.

– Бу чибәркәйнең безнең кулга керүе шәп булды, – диде Эмма, тавышына серлелек чыгарып. – Алдый дип уйламыйм. Әгәр моннан үзебез белән әйбәт кенә алып чыга алсак, безне бәхет басты дигән сүз. Узган атнада гына югарыдан «теге якка» чыгарырга берәр кошчык сорап торалар иде, менә дигән «товар» бу! Күрдеңме күзләрен?! Кара толымлы яшькелт күзле гүзәл! Бераз таушалган инде, ләкин ял иттереп, киендереп-ясап куйсаң, тел шартлатырлык! Үзе кем икәнен дә белми! Андыйлар гел очрамый, үскәнем. Мин сиңа ышанам. Чыкканда синең ярдәмең кирәк булачак. Әгәр тырышсаң, ике «кисәк» синеке. Килештекме?

– «Яшел»ме, «агач»мы?[1]

– Син бик сикеренмә әле, кызый, – диде Эмма, йөзенә канәгатьсезлек чыгарып, – безнең «өстәл»дән булмасаң да, куллар озын, сиңа гына җитәр. «Яшел»гә башың яшьрәк, аңладыңмы?

– Шаяртам ич инде, Эмма, әлбәттә, барысы да син дигәнчә булыр! – диде Розочка, ялагайланып.

– Булмый карасын!

Ул да булмады, ишек йозакларын шалтыратып, камерага ике милиционер килеп керде.

– О-о, Эмма, кемне күрәм! – Алдан кергәннең тавышында ясалмалык сизелде. – Нәрсә, тагы эләктегезме? Ну, ярый, ярый, була инде, үзең беләсең – бүген сез, иртәгә без дигәндәй, тормыш аклы-каралы бит. Яңа чибәркәй килгән диләр, кайда соң әле үзе?

– Ох, Рустамчик, – Эмма таныш милиционерны күрүгә гадәттән тыш шат иде, – әнә авырып та ята инде. Үзең беләсең – яшь ат буразна боза. Картларда тотка, картларда өмет! Нәрсә, егетләр күңелсезләнде мәллә? Үзең кайда идең, нишләп күптәннән күренмәдең?

Рустамчик уфтанган булды, шундый ук ясалма тавыш белән көлемсерәп җавап бирде:

– Ялдан чыктым гына әле – бүген беренче көн. Хатын яныннан китеп булмады. Бераз юатсаң, зарар итмәс иде. Бер-ике чибәркәй кирәк безгә.

---

[1] «Яшел» – доллар, «агач» – сум.

– Син дигәндә, биеп тә күрсәтә алам! Ничәү кирәк дисең?

– Ике әз, дүртәү күп. Алай да, сез беркайчан да күп булмыйсыз инде, әйтергә кирәк.

– Кызлар! Ишеттегезме? Алла, Римма, Света! Җәһәт кенә! Карагыз аны, тырышыгыз! Егетләр зарланса, колагыгызны борам. Рустамчик, без дә бик ялыктык инде монда ятып. Ни диярсең икән?

– Теге смена кайтып китсен инде, Эмма. Шеф ачулы.

– Гадәттәгечә, димәк.

– Ну, беркадәр штрафтан елга саекмый, дустым. Үзең аңлыйсың хәлне.

– Килештек. Рустик, сиңа йомыш бар иде. – Кара хатын милиционерга якын ук килеп пышылдады. – Бу яңа кызга артык бәйләнмәгез инде, яме?! Кичә күбрәк кадаган, ахры, бүгенгә кадәр айнып бетә алмый.

– Нәрсә, авыруы шулмыни? – диде Рустик, көлемсерәп. – Ярар, курыкма, хәл итәрбез. Мә, исем-фамилиясен язып бир, журналга теркәп рәсмиләштерергә кирәк булыр.

– Ох, Рустик, яхшылыгыңа җавапсыз калмам, мең рәхмәт сиңа!

Милиционерлар кызларны алып чыгып киткәч, Эмма яңадан Розочканы чакырды. Хатынның күңеле күзгә күренеп күтәрелгән иде.

– Розочка, үзең күрәсең, синең ярдәмең кирәкми. Оныт сөйләшүне. Кара аны, берәрсенә тишсәң, үкенерсең!

– Янамасаң да аңлыйм инде, Эмма. Ярар, оныттым. Бетте.

Розочка йөзенә чыгармаса да, күңеленнән генә кара хатынга хәтере калды. «Карарбыз әле, – дип уйлады ул, – ничек килеп чыгар бит».

Алинә шактый вакыт изрәп ятса да, йокыга китә алмады. Соңгы вакыйгалар, берсеннән-берсе куркынычрак рәвештә күз алдына килеп, кызны тәмам йончыттылар. Җитмәсә, вакытлыча онытылып торган ачлык тойгысы яңадан кайтып, кызның эче борып-борып авырта башлады. Милиционерлар кергәч, торып утырган иде, әмма Розочка шунда ук янына килеп тормаска кушты, башынкүзен кофта белән төреп үк куйды. Камерадагы сөйләшүне яхшылап аңламаса да, пышылдашуларына караганда, сүзнең үзе турында барганлыгын чамалады. «Кызык, – дип уйлады ул, – кем икән бу Эмма? Яхшы хатынга охшаган. Ә кызлар? Барысы да Эмманы тыңлыйлар, каршы сүз әйтмиләр. Кемнәр диде әле Эмма? «Үз көнен үзе күрүчеләр» дидеме? Кемнәр була соң инде ул? Әллә...» Алинә, тел очына килгән сүзне әйтергә курыккандай, үзенең уйларында тотлыгып калды. Шунда ук, башын-

күзен ураган кофтаны бераз ачып, торып утырды, беренче күргәндәй, әйләнә-тирәгә күз салды. Кызларның өс киемнәре дә, буянулары да ерактан үзләре турында кычкырып тора иде. Ничек игътибар итмәгән ул?! Янына Эмма белән Розочка килделәр.

– Мин сезнең к-кем икәнлекне аңладым, – диде Алинә, тотлыга-тотлыга. – Сез... Сез...

– Аңласаң, бигрәк тә әйбәт, – Эмма киң итеп елмайды, – курыкма, без тешләмибез. Әйттем бит инде, син минем канат астында, ярдәм итәрбез. Беркем дә тимәс.

– Минем өйгә кайтасым килә, – диде Алинә, еламсырап, – сез миңа ничек ярдәм итә аласыз?

– Иң беренче моннан чыгарга кирәк әле, гүзәлем. Аннан соң карарбыз. Минем танышларым күп. Сорашырбыз, күзәтербез, күрсәтербез.

– Безнең кем икәнне беләсең, димәк, синең хәтерең буш түгел. – Сүзгә Розочка катнашты. – Искә төшерергә вакыт кына кирәк сиңа. Курыкма, безнең арада да яхшы кешеләр әз түгел. Эмма кебек.

Розочканың тавышында көлемсерәү яңгырап китте. Ләкин Эмма сизмәде, аның күзе кереп килүчеләргә төбәлгән иде. Йозакта ачкычлар шалтырады, чыгып киткән кызлар белән баягы ике милиционер керделәр.

– Ну, Эмма, алып чык чибәркәйләрне – начальник урынында. Хәзер хәл итәбез сезнең проблемаларны.

Кызлар шатлыктан гөрләшә-гөрләшә ишеккә өелделәр. Розочка, Алинәгә торырга булышып, арттарак калмакчы иде дә, ләкин Эмма, кызларны күздән кичереп, камерадан иң соңгы булып чыкты. Коридордан барганда, Розочка Алинәне култыклап алды, сөрлегүен күреп, иңнәреннән тотты. Шунда кабыргасына төрткәнне сизеп, Алинә Розочкага күтәрелеп караса, кыз, күзләрен түгәрәкләндереп, аңа ниндидер ымнар ясый иде. «Кач! – дип пышылдады ул, – кач моннан, яшисең килсә». Алинә берни аңламады. Ул арада арттан Эмма куып җитте, Алинәне икенче яктан култыклап, шактый озын коридор буйлап өскә күтәрелделәр.

Рустик вәгъдәсендә торды. Милиция бүлеге начальнигына бер төркем кызларны алып кереп, «материалларын» өстәлгә куйгач, елмаеп:

– Менә, иптәш майор, болар инде кичәгеләр. Тиз арада рәсмиләштерергә кирәк, – дип, кызларның исем-фамилияләрен атады.

Милиция бүлеге начальнигы яңарак кына «шеф» яныннан кайткан, шактый гына шелтә тыңлаган, шуңа күрә кәефе юк иде.

– Нәрсә, яңалармы әллә?

– Юк, иптәш майор, болар инде таныш дускайлар. Яңа урын ачканнар, шуңа бик тиз каптырганнар безнекеләр.

– ?!

– Ә-ә, клиентлары канәгатьсезлек белдергән, иптәш майор. Бу урындагы «элекке»ләр белән дә тыныша алмаганнар.

– Нәрсә, «оешкан төстәге»не чәпәп булмыймыни?!

Кызлар арасында куркулы пышылдау китте. Җинаятьләр Кодексында маддәләрнең төрлесе бар, әмма алар штраф түләп кенә котылырга өйрәнгәнлектән, мондый төрдәге кулга алуларга алай җитди карамыйлар иде. Әмма «оешкан төстәге» булгач...

– Ю-ук, иптәш майор, безнең расларлык нигез җитми. Үзләре бернинди күрсәтмә бирмиләр, беләсез бит инде...

– Беләсез, беләсез... Ә сез ни өчен монда утырасыз?! Шушы чебешләрдән дә күрсәтмә ала алмагач! Йә, кая, китер, ничәү монда?

– Тугызау, иптәш майор.

Милиция майорының чынлап та кәефе юк, ахры. Башка көн булса, кәгазьгә карамый да кул куйган булыр иде, әмма бүген нигәдер һәрбер кызны китереп исем-фамилиясен әйттерде, башка бу эш белән шөгыльләнмәскә вәгъдә алды. Рустик баскан урынында кыбырсына башлады, чөнки кәгазьләр тугыз, ә кызлар сигезәү генә. Алинәне күрше бүлмәдә калдырганнар иде.

– Тәк, сигезәү, ә кайда тугызынчысы? Волкова Маргарита Ивановна. Кайда анысы?

– Иптәш начальник, ул кыз үзен начар хис итә, шуңа күрше бүлмәдә калдырган идек.

– Нәрсә булган туташка?

– Ул әллә эчкән, әллә наркоз астында, нәрсә сөйләгәнен аңламый. Дус кызлары документларны тутырырга ярдәм иттеләр.

– Алып керегез үзен. Мин күрергә тиеш.

Рустик Эммага ашардай булып карады. «Әгәр синең аркада күңелсезлеккә юлыксам, кара аны» дигәнне аңлата иде караш. Эмма эсселе-суыклы булып китте, Розочкага төртте. Розочка «аңладым» дигән рәвештә баш какты. Ишектә торган милиционерга Алинәне алып керергә куштылар.

– Йә, кызый, – диде милиция майоры, – исемең, фамилияң? Документларың кайда?

Алинә югалып калды. Аның күңел читендә «бәлки, милиционерлар ярдәм итәрләр» дигән өмет яши иде. Шуңа ул, бераз каушабрак:

– Мин әйттем инде, бернәрсә дә хәтерләмим. Документларым да юк. Исемемне дә, фамилиямне дә, кем икәнемне дә – берсен дә белмим, – диде.

Майор күзләрен кәгазьдән күтәрде.

– Нәрсә, бер әйбер дә хәтерләмисеңмени?

– Юк.

Рустик ашыгып аның сүзен бүлде.

– Иптәш майор, менә бу тоткын... э-э... кызлардан аны белүчеләр бар.

– Мин беләм, иптәш майор, бу кыз безнең белән эшли. Исеме Маргарита, Маргарита Волкова. Ул кичә артыгын эчте, шуңа берни хәтерләми. Документларын да югалткан, күрәсең.

– Без дә беләбез аны – бергә яшибез, – диде Розочка.

Эмманың тавышы ышандырырлык чыкты. Алинә кире кагарга дип авызын гына ачкан иде, майорның тозлыборычлы итеп сүгенүен ишетеп, тотлыгып калды.

– Ну хәзерге хатын-кызлар, – диде майор, – бер ычкынсалар, туктатырмын димә. Йә, нәрсә җитми сиңа, ә? Әниең-әтиең канат астында яшисеңдер, рәхәтләнеп укырга да, эшләргә генә бит инде. Ә юк, сезгә маҗара кирәк, яшьлек гомерегез маҗара эзләп башлана, шулай ук тәгәллисез дә. Бу чибәрлегең белән яхшы гына кияүгә чыгып, балалар үстерәсе урында! Әти-әниең турында уйладыңмы? Үстергән, кеше иткән өчен рәхмәтең шулмы синең?! Ана буласы кешеләр бит сез, ... фәлән!

Майор кулларын бутый-бутый озак кычкырынды. Болай да кызыл таза йөзе шәмәхәләнеп киткәндәй булды, уң як ирен чите тартышып алды. Ахырдан кәгазьләрнең барысына да имзасын салып, Рустикка этәрде, «югалыгыз күз алдыннан» дигән кыяфәт белән кызларга кул селтәде. Кызлар тәрткәләшә-тәрткәләшә чыгып китү ягын карадылар. Баядан бирле майор каршында берсүзсез басып торган Алинәне Эмма белән Розочка икесе ике яктан култыклап алды, коридорга алып чыктылар. Арттан Рустик куып җитте.

– Фу, – диде ул, Эммага карап, – сезнең аркада харап була яздым. Ярый инде, кызкай тавышсыз икән, котылдыгыз.

Эмма, авызын түгәрәкләндереп, ишетелер-ишетелмәс «Тс-с!» дигән аваз чыгарды, күзләре белән Алинәгә ымлады. Ләкин Алинә аларны тыңламый иде.

– Шулай килеп чыкты инде, Рустик, – диде аннары, – без сиңа бурычлы, үзең беләсең. Теләгән вакытта кил, ишекләребез сиңа һәрвакыт ачык.

– Ярар, аннан соң сөйләшербез, хуш әлегә. Алдыңны-артыңны карап йөр.

– Хуш, Рустик, хуш, кадерлем!

Бу вакытта Алинә үзенең монда килеп бушка вакыт уздыруы турында уйлана иде. Майор дигән кеше кычкырды кычкыруын, әмма аның сүзләре кызга берничек тә ярдәм итмәде. Ул Алинәне дә «күбәләк»ләрнең берсе дип уйлады бугай. Кем, кем ярдәм итә ала соң Алинәгә? Кыз соңгы көннәрдә үзе белән булган вакыйгаларны күңеленнән уткәрде. Менә ир-ат аны җирдән күтәреп алды, битен сөрткәләде. Коңгырт-кара күзләр. Бераз моңсурак, әмма бик ягымлы карыйлар. Алинә аларны яхшы хәтерли. Менә машинада баралар. Кая алып барам диде әле ул? «Хастаханәгә, анда сиңа ярдәм итәрләр», – диде. Әйе шул, хастаханә! Шунда барырга кирәк Алинәгә! Тукта, ул бит инде анда булды. Нигә чыгып китте соң әле ул аннан? Вахтер хатын «башка кертмим» диде. Әллә «чыгармыйм» дидеме? Аһ, башым... Жу-жу-жжу-жжж... Алинәнең уйлары тәмам чуалды, баш мие бернәрсә кабул итмәс хәлгә килде. Кызларны инде урамга алып чыгып, алар артыннан капканы япканнар иде. Тагы урам. Тагы төн. Салкынча. Кая бара инде Алинә?! Эмма, кызның туктальп калуын күреп, җитез генә аны тагы култыклап алды:

– Рита, Риточка, кунар урының бармы соң? Юкмы? Әйдә алайса, терелгәнче миндә яшәп торырсың. Миңа кайтабыз, яме?!

Рита... Рита ул үзе бит инде. Шулкадәр рәхәт икән исемеңне тану! Шулай да... Рита түгел бит ул, түгел!

– Миңа хастаханәгә барырга кирәк, элек мине шунда илткәннәр иде, – диде Алинә, еламсырап.

– Кадерлем, бу вакытта бернинди хастаханә кабул итми инде. Үзең күрәсең, ярты төн җитә. Әйдә, бүген безгә кайтабыз, ә иртәгә хастаханәгә барырбыз.

Алинә уйлана калды. Эмма ничектер бик ялагайлана иде аның алдында, ә ул бит аның усаллыгын да татыды. Кыз, милиционерларга ышанып алданганнан соң, бераз шикләнә башлаган иде. «Мин бернәрсә хәтерләмим – кемгә кирәк мин мондый хәлдә? Эмма нәрсә тели миннән?» Эмма, Алинәнең шикле карашын тоеп, кызның кулларын ычкындырды.

– Ярар, уйлый тор алайса, минем кызлар белән сөйләшәсем бар, – диде ул, үзе сиздерми генә Розочкага төртте. – Кызлар, әйдәгез, читкәрәк китик әле.

Алинә янында Розочка калды.

– Ә мин алар «өстәл»еннән түгел, – диде ул, пышылдабрак. – Минем үземнең «түбәм» бар. «Ялгызак» мин, аңлыйсыңмы?!

Алинә, әлбәттә, аңламады. Шулай да баш кагып алды.

– Мин әйткәнне Эмма ишетмәсен, – диде кызу-кызу Розочка, бөтенләй пышылдауга күчеп. – Сине «батырырга», «төшерергә» тели ул. Аңладыңмы?!

– ?!

– Безнең кебек буласың дигән сүз, тагы да начаррак хәтта, аңладыңмы? Шуңа күрә җае чыгу белән кач, хәзер түгел тик, бераздан соң. ...Синең үзең өчен шулай әйбәтрәк бит, Рита, – Розочка монсын Эмма ишетсен өчен кычкырып әйтте. – Кунып чыгарга урының да булыр, ашау-эчү мәсьәләсе дә хәл ителер. Сиңа башка кеше мондый ярдәм кулы сузмаячак, аңлыйсыңмы?! Син Эмманың күңеленә хуш килгәнсең. Йә, ризамы инде?

Алинә Розочканың сүзләренә гаҗәпкә калды. Ничек инде безнең кебек? Теләми ул алар кебек булырга. Эмма аны мәҗбүр итә аламыни? Кинәт Алинәнең аңына барып җитте. Әйе шул, бик тә мәҗбүр итә ала, хәтта... Әгәр хәзер аларга ияреп китсә, Эмма аны беркая чыгармаячак. Хастаханәгә дә алып бармаячак. Менә шуңа ялагайлана да Эмма. Аңа ничек тә булса Алинәне өенә алып кайтырга кирәк. Әгәр хәзер үк кире какса? Боларга бәйләнмәгән ич, ул ирекле кеше. Мәҗбүр итә башласалар, кычкырыр. Тик кем ярдәм итәр соң? Розочка... Розочка ярдәм итмәячәк. Юк, Эмма аны барыбер җибәрмәс. Милицияләр дә аңа ышаналар. Әнә үзе бу якка карамаган булып кыланса да, янында торган кыз бу икенең һәр хәрәкәтен бик җентекләп күзәтә.

– Йә, кайтасыңмы инде Эмма белән? – Розочка сиздерми генә күзләрен уйнатып алды. «Ризалаш» диюе иде аның.

– Кайтам... Әгәр миңа ярдәм итсәгез.

– Ярдәм итәбез, дидем бит инде. Әйдә, кызлар янына барыйк.

Эмма, боларның якынаюын күреп, сөйләшүен туктатты, Алинәгә сораулы карашын төбәде.

– Йә, уйладыңмы?

– Мин риза... Тик иртәгә хастаханәгә барырга ярдәм итсәгез генә.

– Менә, күптән шулай кирәк иде, – Эмманың күңеле булуы йөзенә чыкты, Розочканың җилкәсеннән кагып куйды. Рәхмәт, янәсе. – Хастаханәгә дә барырбыз, зур табибларга да күрсәтербез үзеңне. Минем танышларым күп, борчылма, әнә кызлар беләләр.

Кызлар «әйе-әйе» дип баш кактылар.

– Әйдәгез алайса, юлга чыгып, «мотор» тотабыз. Кызлар, Рита белән мине озатып җибәрегез дә таралышырсыз. Розочка, син безнең якка, шулай бит?

– Шулай дип тә була. Ярый, бергә кайтырбыз.

Милиция бүлеге йортлар эчендә, күкрәп үскән сирень куаклары арасында урнашкан иде. Кайсыдыр шаяны сиреньнәрне юри утырткан диярсең. Янәсе, ирекнең һәм төрмәнең нинди исле булуын татыгыз, чагыштырыгыз. Моннан машиналар йөри торган юлга кадәр шактый ара җәяү барырга кирәк. Юл буе Эмма нәрсәдер такылдап барды, ләкин Алинә аны тыңламады. Тирә-якка сирень чәчәге исе таралган, бу ис Алинәгә таныш, бик таныш иде. Тырышып-тырышып нәрсәдер хәтерләргә теләде, әмма юкка. Аптырагач, бу төркемнән ничек котылу юлларын уйлап карады, ләкин башына яхшы дип табарлык бернинди фикер килмәде. Соңыннан «Әллә качарга инде?» дигән уйда тукталып калды. Йөгерүен яхшы йөгерә инде Алинә, аның хәтта ярышларда призлы урыннар алганы бар. Чү, нинди ярышларда? Кайчан? Гаҗәп – Алинә хәтеренә килеп төшкән вакыйганың бер җебен тотып ала да дәвамын табалмыйча гаҗизләнә. Бераздан вакыйга бөтенләй тоныкланып югала башлый. Бу юлы да шулай булды. Хәер, ул арада инде тыз-быз машиналар чабып торган юлга чыгып җиттеләр. Шактый киң урамда, төн уртасы булуга карамастан, машиналар светофор алдында берничә рәткә тезелгән.

– Безгә теге якка чыгарга, – диде Эмма. – Туктагыз, яшел утка өлгермибез инде, көтик бераз.

Менә светофорда кызыл утка туктаган машиналар сарысы янганын күреп кузгала башладылар. Кинәт Розочка Алинәнең аркасына төртте. Алинә – каян башына килгәндер! – үзе дә сизмәстән, көч белән кулын Эмманың култык астыннан тартып алды, кисәктән йөгереп, юл уртасына чыкты, кузгала башлаган машиналар алдыннан бар җәһәтеннән йөгерде. Машина тәгәрмәчләре чыелдавын күмеп, Эмманың дәһшәтле кычкыруы яңгырады. Әмма соң иде инде – юл уртасында калган кызга машиналар юл бирде, ә Эмма, ачуыннан кызарып-бүртенеп, янында торган кызларга йодрыклары белән ташланды. Йөгерде Алинә, әй йөгерде дә соң! Күзләре күргән якка, бернигә карамый, бар көченә йөгерде. Бер-ике-өч, бер-ике-өч... Менә машина тавышлары тынды, тирә-як нindidер сәер тынлыкка чумды. Кыз, туктап, бераз сулыш алды, тирә-ягына каранды. Нindidер агачлар, төннең каралыгында тагы да карасуланып, ботакларын күккә таба сузганнар. Күк йөзе тулы йолдызлар... Әнә Җидегән йолдыз, әнә Тимер Казык... Туктарга ярамый аңа. Ярамый. Марафонда йөгергәннән соң туктамыйлар. Алинә, адымнарын кызулатып, сөрлегә-сөрлегә алга атлады.

Шунда гына үзенең хәлдән таеп арыганлыгын сизде. Бераздан тирә-яктагы агачлар, Алинәне үртәп, узыша, Алинә тирәсендә түгәрәктә бөтерелә башладылар. Аларга йолдызлар кушылды. Кинәт күктәге Тимер Казык йолдызы зурайганнан-зураеп, җиргә сикергәндәй булды, аның күз камаштырырлык яктысы Алинәнең йөзенә китереп бәрде. Алинә, бу яктылыкка түзә алмый, күзләрен чытырдатып йомды, шул вакыт өстенә ниндидер авыр әйбер килеп сарылды. Һушын югалтканчы кыз машина тормозлары чыелдавын ишетергә өлгерде... Шул мизгелдә дөнья яңадан караңгылыкка чумды.

* * *

...Эзләп-эзләп тә
Табылмаган әкиятем!
Инде башка эзләмәм.
Чынга ашмас хыялларым,
Өметләрем, вәгъдәләрем!
Кайтыгыз, дип, кабат тезләнмәм!
Киләчәгем килер кара төндәй,
Мин йоклармын анда тыныч кына.
Җил дә исмәс мәңге караңгыда
Вәгъдәләрсез, өметләрсез,
Хыялларсыз кем ашкына?!
...Эзләп-эзләп тә
Табылмаган әкиятем...
Киләчәктә
Төшләремә кереп йөдәтмә.
Мин тынычлык телим кара төндә.
Сүнгән тормышымны көйрәтмә.
Көйрәтмә....

*Икенче кисәк*

## Гамир

– Фью-фью, фить-фить-фить, фью...

Каршыдагы сирень куакларында, төнге тынлыкны яңгыратып, сандугач өзгәләнә. Бу тавыш тынлыкны бозмый, киресенчә, җәйге төн караңгылыгында тынлык куера гына бара кебек. Гамирның укыганы бар, бу кадәр өздереп бары ата сандугачлар гына сайрый ала икән. Кызык.

– Әйдә, борылыйк, соң инде. Малайлар да бүген күренмиләр.

Гамир үзеннән бер башка тәбәнәгрәк Шурикка теләмичә генә җавап бирде.

– Алар аста – спорт мәйданында. Без дә шунда төшәбез хәзер.

– Нәрсә калган анда безгә? Кызлар юк та юк инде. Әйдә, борылыйк. Иртәгә килербез әле.

– Пыст! диләр сиңа! Синнән сорамыйлар. Тик тор сорамаганда!

Шурик шым булды. Бүген Памирның кәефе юк иде. Авторитет авторитет шул инде, сүз әйтеп кара син аңа. Кушаматы да туры килеп тора үзенә: Памирдай биек, кул җитмәслек – озын буйлы, атлет гәүдәле. Якын барырдай түгел. Чын исеме ничектер – тирә-якта беркем белми. Төркемдә күз артыннан Памирны «Киллер» дип атыйлар. Кавказ тауларында спецназ мәктәбе узган, пычакны уч төбендә биетергә өйрәнгән ирдән күпләр куркалар. Ул җитәкләгән төркемдәге тәртипкә кайбер генераллар кызыгырлык. Шулай да Шурик егетләрнең Памирдан шултикле куркуларын артык дип саный иде, чөнки Памирның Шурикка мөнәсәбәте бер дә начар түгел, әнә кычкырганда да тавышында явызлыктан бигрәк үз итү күбрәк ишетелә сыман... Ә акча эшләү юлларын Памирдан остарак белүче юк. Төркемдәге чыш-пышка караганда, Памир күптән түгел генә Тын океанда утрау сатып алган, имеш. Янәсе, мондагы эшләре хөрти була башласа, тиз генә шунда шыларга икән исәбе. Әйтүләренә караганда, ул инде анда әллә нинди җәнлек-җанварлар кайтарып, «зооботсад» ясаган, ди. Картлыгын ялгызы гына шул утрауда табигать кочагында үткәрергә хыяллана, ди... Шурик мондый сүзләргә ышанмый, әлбәттә, шулай да нәрсәдер бар икәнен тоя, чөнки Памир гади лидер гына түгел. Ярар, ни булса булыр, тик Шуриктан гына сорамасын акчаны.

Гамирның авыр итеп көрсенеп куюына Шурик борылып караса да, артык гаҗәпләнмәде. Мондый моңсу кичләрне ул үзе белән йөрергә бары тик Шурикны гына алып чыга. Бу ышанычның нидән икәнен егет үзе дә аңлап бетерми, ләкин бик горурлана иде. «Прогулкалар» елга ике, күп дигәндә өч тапкыр була, бу кичне Гамир аракы эчми, сөйләшми, уйга чума, әмма тел бистәсе Шурикның янында булуына мохтаҗ. Гомумән, сәер кеше ул Гамир. Җирнеке түгел. Бервакыт алар тар гына җәяүлеләр юлыннан баралар иде, Гамир кинәт, күкле-яшелле тавыш белән: «Тукта!» – дип кычкырды. Ул да булмады, күз иярмәс җитез хәрәкәт ясап, берни абайламаган Шурикның сул аягын җирдән аерып өскә күтәрде. Егет, әлбәттә, дөпелдәп, асфальтка ауды, шунда ук бил турысы чеметеп-чеметеп авырта башлады. «Тукта, – дип кабатлады Гамир, – тап-

тыйсың бит». Шурик сызлана-сызлана борылып караса, җирдән ашыгып кәбестә күбәләге корты юлны аркылы чыгып бара. Егет эченнән биш катлы итеп сүгенде, ләкин йөзенә чыгармады, Гамир белән бергәләп корт юлны аркылы чыкканчы узгынчылардан саклап тордылар. Аннан Гамир кортны, яфракка утыртып, агачка менгереп куйды...

Вакыт соң булганга, паркта йөрүчеләр күренми диярлек. Шәһәр уртасында урнашкан бу табигать почмагы соңгы елларда күзгә күренеп ямьсезләнде, ташландык бер урынга әйләнә башлады. Шулай да кешеләр, элеккеге гадәт буенча, ял көннәрен үткәрергә, яшь балалар белән саф һава суларга паркка килгәлиләр әле. Паркның иң түрендә урнашкан «Җәй» кафесы гына, тирә-юньдәге таркаулыкны танырга теләмичә, үзгәреп-купшыланып, калын кесәләрне төрле төстәге утлары белән үзенә чакырып тора.

– Әйдә, керик булмаса, берәр савыт сыра зыян итмәс. Эчәсе килә.

Шурикка шул гына кирәк тә. Башка вакыт булса, ул монда выжылдап машинада гына килеп туктар иде дә... Памир паркта машинада йөрергә рөхсәт итми. Хәтта егетләр белән җыелып барганда да, берсеннән-берсе купшы машиналарны паркка кергәнче бер рәткә тезеп куялар. Мондый сәер гадәтләрен Памир аңлатып торуны кирәк дип санамый. Шулай да, имеш-мимешкә караганда, аның балачагы шушы паркта үткән булырга кирәк.

Официант егет, боларны күрүгә үк, ресторанның уң ягында тәрәзә янында урнашкан өстәлне бушатуларын сорап, җайлы гына утырган яшь парны торгыза башлаган иде, Гамир официантка «кирәкми» дигән кыяфәттә кулын селтәде. Бар янындагы биек утыргычларга авышып, кечкенә шешәле алман сырасын чөмергәннән соң гына бераз хәл кереп киткәндәй булды, Гамирның күз карашы яктыра төште. Башка вакытта тел бетчәсе Шурик та бүген эндәшми, куе кашлары астыннан караган аксыл керфекле кечкенә тонык күзләре залда биегән яшь парны, дөресрәге, яшь кызны өтә.

– Киттек әйдә, тамаша бетте.

Шурик, Гамирның карашы җылынуын күреп, кызга ымлады:

– Чибәр нәрсә. Безнекеләргә охшамаганнар бугай. Кунак кызын алып кайтыйк мәллә?

– Тотынып кына кара. Узган гауганы оныттың мәллә?

Әйе, узган ел шундый бер кызый аркасында «Кәлтәләр» белән шактый аралар бозылып алган иде. Шуңа күрә Шурик артык чәпчемәде, тик, зал аркылы чыкканда, чибәр кызыйга күз кысарга барыбер онытмады.

Рестораннан чыккач, уңга борылдылар. Дөрес әйтә Шурик, бу вакытта спорт мәйданына төшеп йөрү ахмаклык. Малайларның анда түгеллеген Гамир үзе дә белә. Шуңа күрә Тукай һәйкәлен әйләнеп бераз баргач, кайту ягына таба борылды.

Төн. Теле ачылып киткән Шурикның бытбылдавын исәпкә алмаганда, тып-тын. Хәтта сандугач та тынган. Күктә ай йөзә. Аның яктысын кеше кулы ясаган бернинди лампа уты белән чагыштырып булмый. Гамирның яшьлектә күп тапкырлар аракы эчеп исереп йә булмаса наркотик сөременә буылып караганы булды, ләкин табигать кочагында ай яктысында гамакта тибрәлү ләззәте кебек ләззәтне аңа һичнәрсә бирә алмады. Әйтерсең ай сине йомшак челтәр белән кочып ала да йолдызлар арасында – зәңгәрсу-каралҗым күктә әкрен генә тибрәтә... Гомере буе Гамир табигатькә гашыйк булды, гомере буе табигатьне кеше аңы чишә алмаслык бер могҗиза дип саный иде. Мәктәп елларында биология укытучысы Гамирның «тозсыз» сорауларыннан башы әйләнеп, еш кына җавап бирүгә караганда журналга икеле тезүне кулайрак күрде. Ә Гамирның чын-чынлап беләсе килә: ни өчен яфрак яшел төстә? Хлорофилл эшләнгәнгә. Ә нигә хлорофилл яшел төстә, ни өчен кызыл яисә кара түгел? Димәк, әбисенең тәрәзә төбендә үскән шәмәхәле-кызыллы фикус гөле хлорофиллсыз үсәмени? Ә төсле кәбестә? Әллә аның хлорофиллы шәмәхә-кызыл төстәме? Ә гөмбәдә хлорофилл юкмы? Алайса, ул кислород бүлеп чыгармыйммы? Әгәр яфракның хлорофиллын гөмбәгә кушсаң, гөмбәләр гел яшел төстә генә булыр идеме? Ә менә җил нәрсә ул? Нигә суны төссез, иссез диләр, Казансу бит күзләрен яшькелт-зәңгәр, ә җилдән яңгыр суы исе килә? Бу сораулар, әлбәттә, укытучыны кыен хәлгә куялар, чөнки ул үзе дә белми. Ә балаларга шул гына кирәк тә – шунда ук класста көлеш башлана, дәрес тәмам бозыла. Ә Гамирның көндәлегендә тәртип буенча тагы бер икеле арта...

...Шурикның төртүеннән Гамир айнып китте, иптәше күрсәткән якка борылып карады. Алар инде парктан чыгып җитә язганнар икән. Уң якка, каерылып, машина юлы борылып китә. Алдарак, алардан бер унбиш-егерме адым ераклыгында җәяүлеләр сукмагыннан бу якка таба кемдер атлый. Адымнары буталчык, җир өстеннән барган өрәк кебек, як-якка чайкала, бутала, менә авам, менә авам дигәндәй, куллары белән һаваны кисеп ала. Менә өрәк ут яктысына – юл өстенә килеп чыкты, егетләр озын чәчләре тузгып таралган, сылу буй-сыны сизелеп торган бик килешле, ләкин таушалган күлмәк кигән кызыйны

абайладылар. Шул ук мизгелдә диярлек уң яктагы борылыштан фара уты бөркелде, шактый тизлек белән килгән машина, юлда кемдер барлыгын күреп, тәгәрмәчләрен чыелдатты. Гамир катып калды. Колагына каяндыр еоактан – балачагыннан ук «Абый!» дип кычкырган үзәк өзгеч тавыш ишетелде. «Абы-ы-й!» Күз алдында алсу күлмәк кигән, чәчләренә матур итеп бантик таккан кызчык – сеңлесе гәүдәләнде. «Абы-ы-й...» Менә кызчык, бәргәләнеп, юл өстендә ята. Алсу күлмәгенә кып-кызыл тап җәелә... «Абы-ы-й...» Кызчык инде кычкырмый, Гамирның кулларында бары бәргәләнә, ыңгыраша гына... Узгынчылар Гамирны читкә сөйриләр, ул тарткалаша, ләкин көчле куллар, күтәреп, аны юл өстендә үлеп яткан сеңлесеннән каядыр читкә алып китәләр...

...Гамир ничек сикерүен хәтерләми. Барс булып ыргылды, лачын булып очты. Фара уты күзләрен камаштырды, кызның авырлыгы сугышта алган ярасын ачты. Җиргә әүмәкләшеп аудылар, ләкин Гамирның спецназ биргән чыныгуы җуелмаган икән – секундның өчтән бер өлешен тотып, җиргә аркасын куярга өлгерде. Кыз бөтен авырлыгы белән аның өстенә килеп төште. Яннарыннан, тормозларын чыелдатып, зәңгәр буйлы, сигналлы «Эсперо» үтеп китте. Шактый баргач кына туктый алды машина. «Эсперо»дан ава-түнә ике милиция хезмәткәре килеп чыкты, берсен каты итеп очкылык тота иде. Гамир, экрен генә торып, яңадан җиргә чүгәләде, аңсыз яткан кызның пульсын тотып карады да читтәрәк кинофильм карагандай авызын ачып катып торган Шурикка: «Җибәр тегеләрне, барысы да тәртиптә» дигән кыяфәт белән кул селтәде. Шурик, ниһаять, исенә килде, ГИБДД машинасы янына барып сөйләшә башладылар. Рульдә утырган сержант, Гамирны таныгач, җиңел сулап куйды, «Ну, парень, даешь» диюдән башка сүз әйтә алмады. Озакламый алар машиналарына утырып китеп тә бардылар.

Кыз һаман аңсыз. Гамир иснәп карады – исерек түгел. Кулларында, аякларында энә эзләре дә күренми – наркоманка түгел. Киеменә караганда, фахишәгә дә охшамаган. Ләкин бик нык талчыккан бугай – аякларына урыны-урыны белән зәңгәрләнеп кан сауган, чәчләре, битләре, күлмәге пычрак, тузан гына. Йөрәге сизелер-сизелмәс тибә. Кем бу? Каян килеп чыкты бу кыз юл уртасына? Каян исенә төшерде күп елгы фаҗигане? Гамир, авызында тоз тәме сизеп, төкеренә башлады. Егылганда сугышта алган ярасы ачылган, ахры. Хәзер бер-ике айсыз рәтләнмәячәк инде.

– Әйдә, күтәр кызыйны, – диде, янында кызга карап катып торган Шурикка. – Алып кайтабыз. Өйгә.

Гамир әйткәнен ике кабатламый, бәхәсләшергә дә ирек бирми. Шуңа күрә Шурикка, аһ-ваһ килеп, кызны күтәреп машинага кадәр алып барудан башка чара калмады. Ярый әле Шурикның бәхетенә машиналары ерак түгел иде.

Алгы утыргычны җәеп, кызны кертеп салдылар. Ул әүвәлгечә аңсыз иде, шулай да яткырганда каты итеп ыңгырашып куйды. Гамир, шикләнеп, яңадан кызның тәнендәге һәрбер сөяген капшап, тикшереп чыкты. Юк, сынган, яньчелгән, кан саркыган урыннарны тапмады.

– Әйдә, син рульгә утыр, – диде Шурикка, – мин артта караштыргалап барырмын.

– Кая кайтабыз? – Шурик машина йөртергә үлеп ярата иде. Бигрәк тә мондый затлыны. – Сарайгамы, квартирагамы?

Гамир бер мәлгә уйланып калды. Сарай дигәне ике катлы зур гына таш йорт булып, күбрәк кунаклар кабул итәргә җайлап төзелгән. Бассейны, саунасы бар. Квартирасы да иркен, әмма анда үзе яши, чит-ятларны кертмәскә тырыша иде.

– Әйдә квартирага, анда уңайлырак булыр.

Гамирның бу җавабына Шурик шаккатты. Бу соравын ул юри генә, җавабын алдан ук белеп бирәм дип уйлаган иде. Ничә ел инде аның Памир белән танышлыгына, ә квартирасында моңа кадәр булганы юк. Әллә башка квартира турында сүз барамы?!

– Кайсысына?!

– Менә тинтәк! Ничә квартирам бар дип белдең минем?! Шунда инде, бердәнберенә! Үзәккә каер әйдә, зәңгәр йортларга.

– Аңлашылды, иптәш капитан. Хәзер. Ну-ка, гүзәлем, әйдә, тыңла хуҗаңның... э-э... машина йөртүчесен!

Өр-яңа ялтырап торган «Ауди» тавышсыз гына кузгалды, чатта борылып, шәһәр уртасына элдерде. Шурик музыка көйләп куймакчы иде дә, Памирның йөзенә карагач, бу уеннан кире кайтты.

Кыз һаман аңсыз. Бәлки, шулай яхшырактыр да. Үзе дә аңламастан, Гамирның кыздан аерыласы килмәде. Бу кыз бер мизгелдә бөтерелеп аның тормышына килеп керде, күңел түрендә җиде йозакка бикләп куйган хисләрен актарып чыгарды. Моннан егерме еллар элек машина астында һәлак булган сеңлесен хәтерләтте. Әгәр ул вакытта Гамир сеңлесенең кулын ычкындырмаган булса... Әгәр артыннан йөгереп куып тотса, читкә сөйрәп кала алган булса... Әгәр катып калмаган булса... Бу һәлакәт-

не ул энәсеннән җебенә кадәр күрде, сеңлесенең һәрбер хәрәкәте, һәрбер ыңгырашуы ташка чокылган кебек аңында уелып калды, төшләренә кереп газаплады. Бала күңеле олылар гаебен үз өстенә алды, бу авыр йөкне гомере буе үз иңнәрендә күтәрде. Шуңа да бүгенге хәл Гамирны тетрәткән, шуңа да кем икәнен белмичә бу кызны тиз генә җибәрәсе килми иде.

Ә кыз аңына килергә уйламады да. Менә инде Гамирның өченче каттагы квартирасына күтәрелделәр, тимер ишекләрне ачкач, Гамир кызны йокы бүлмәсендәге киң караватка салырга кушты. Шурик, бу квартирага әлегү бәхетенә ышана алмыйча, күзләре белән әйләнә-тирәне капшый башлады, тапкан мәгълүматны җәһәт кенә хәтер кесәсенә сала барды. Әһә! Памирның кызы бар икән, чөнки стеналардан аңа дүрт-биш яшьләр тирәсендәге матур итеп елмайган кызчык рәсемнәре карап тора. Менә ул таган атына, менә асфалька сурәт төшерә. Ә монда ниндидер малай белән. Анысы да Памир улы микән? Алай дисәң, рәсемнәр төссез, иске күренәләр. Әллә Памир үзе инде? Шурик рәсемдә таныш чалымнар табып Памирга борылган иде, тегесе тиз генә чакырылмаган кунакны квартирасыннан озата башлады, төрткәләп диярлек чыгарып җибәрде.

Табиб чакырсаң әйбәт булыр иде. Гамирның танышлары арасында табиблар бар да барын, тик шулай да... Соңрак. Әгәр үзенең кулыннан килмәсә, чакырыр. Беренче ярдәм дә күрсәтә алмагач, нинди спецназ буласың соң инде син, Шурик әйтмешли, иптәш капитан?! Үзе белән «кирәк булыр» дип алып кергән машина аптечкасын ачып, мамык белән нашатырь спиртын тапты, ачы истән борынын җыера-җыера, кызга нашатырь иснәтте. Менә озын кара керфекләр дерелдәп куйдылар, кыз тирән итеп сулыш алды, башын икенче якка борып, ыңгырашыпбәргәләнеп куйды. Шулай да күзләре ачылмады. Гамир тагы нашатырь сузган иде дә, кызның күкрәге күтәрелгәнен чамалап, кулын кире алды. Кыз әкрен генә, тирән итеп сулый башлаган иде. Пульсы сизелер-сизелмәс, әмма тотрыклы. Йоклый. Үлем йокысы белән йоклый. Ниләр кичте икән синең баштан, кызкай?! Кем син? Нишләп мондый хәлгә төштең? Гамир, куллары белән иягенә таянып, бик озак кызга карап утырды. Коңгырт-кара чәчләр мендәргә сибелгән. Озын кара керфекләр, матур итеп сызылган кашлар. Әгәр үлмәсә, аның сеңлесе дә шулай чибәр булыр иде...

...Ул кымшанганда инде таң аткан, урамда кешеләр йөрештерә башлаган иде. Тагы бер тапкыр кызның пуль-

сын санап, йоклаганына ышангач, Гамир икенче бүлмәгә чыгып ятты. Төшендә сеңлесен күрде. «Рәхмәт, абый, – диде кызчык, кинәт озын керфекле, коңгырт-кара чәчле дәү кызга әйләнеп, – бүген син мине коткардың. Башка елама инде, яме?!» Гамир исә елады. Кычкырып-кычкырып, ирләргә хас булмаганча сыкранып елады. Күз яшьләре агып беткәч, тынычланып, җиңеләеп калды. «Әйдә, очабыз, – диде сеңлесе, – бир миңа кулыңны». Болытлар, елга-күлләр өстеннән бик озак очтылар, соңыннан сеңлесе аны яңадан җиргә төшереп куйды. «Мин китәм инде, абый, тик син елама, тиздән без бергә булырбыз, яме». Сеңлесе, болытларга уралып, күздән югалды. Ә Гамир, төшендәге бу җиңеллектән, рәхәтлектән аерыла алмыйча, әле шактый озак изрәп ятты. Уянып киткәндә, мендәре лычма су булган, әмма тәненә шулкадәр җиңеллек иңгән иде.

...Кояшка караган тәрәзәләрдә нур балкый. Шаян, озын уклар, үтә күренмәле тәрәзә челтәре аркылы җиңел генә үтсәләр дә, өчпочмаклап куелган калын пәрдәләрдә тукталып калалар. Алинә, йомшак урын-җирдә ятуына куанып, рәхәт итеп киерелеп куйды, башы мендәргә чумып-чумып китте. «Шундый рәхәт, – дип уйлады ул, – тәнем дә авыртмый, башым да гөжләми». Үлеп эчәсе килә тик. Шулай да... кайда ята соң әле ул? Бу бүлмә аңа таныш түгел. Бу бүлмә аныкы түгел. Хастаханә бүлмәсе дә түгел бу. Кыз, күңеленә курку үрмәләгәнен тоеп, үзе белән булган соңгы вакыйгаларны хәтерләргә тырышты. Аңа милиция майоры кычкырды. «Син җилбәзәк» диде. Кинәт Алинәнең эче жу итеп китте. Эмма! Эмма аны үзенең өенә алып кайтам диде. Күрәсең, бу Эмма өе. Тик Алинә аңардан качты бит. Йөгерде. Аннан соң нәрсә булды әле? Ниндидер яктылык йөзенә бәрде, һәм ул күзләрен йомды. Аннан соң ни булганын хәтерләми. Ничек монда эләкте икән ул? Күрәсең, Эмма аны куып тоткан да үз өенә алып кайткандыр инде. Әйе, бу Эмма өе. Алинә ачыргалануыннан ыңгырашып куйды. Хәзер нәрсә көтә инде аны алда? Розочка язмышымы? «Бездән дә түбәнрәк буласың» диде бит Розочка. Анысы ни дигән сүз? Юк, ул моңа бармаячак. Үлгәндә дә. Дөресрәге, үлү алай түбәнлеккә төшүдән яхшырактыр да әле. Кинәт аңа бу урын-җир әйберләре җирәнгеч булып тоелды – кизәнеп, өстеннән мамык кебек йомшак җәймәне алып атты. Шәрә аяклары ачылдылар. Шул вакыт артында ир-ат тавышы яңгырады.

– Исәнмесез! Хәерле иртә! Ничек йокладыгыз?!

Алинә борылып караса, каршында озын буйлы, өстенә

кара майка белән киң чалбар кигән мөлаем гына ир-ат басып тора иде. Иреннәре елмая елмаюын, тик каш астында ук урнашкан карасу-зәңгәр күзләре ничектер бик кискен карыйлар. Алинә тиз генә урыныннан сикереп торды, җәймәсен алып, шәрә өс-башын каплады да тәрәзәгә таба чигенде.

– Әгәр якын киләсез икән, мин тәрәзәдән сикерәм. Эммага әйтегез: мин үлгәндә дә фахишә булмаячакмын!

Ир-ат башта бераз аптырап, хәтта югалып калды. Аннан кычкырып көлеп җибәрде.

– Менә нәрсәдә икән эш! Менә кемнәрдән качкансыз икән! Әйтәм бит, нәрсәдер булган бу кызый белән дип! Курыкмагыз, зинһар, мин көчләүче дә, фахишәләр тотучы да түгел. Ышанмасагыз, карагыз әнә: мин хәтта сезнең өстегезне дә алыштырдым инде, ләкин сезгә бармак белән дә кагылмадым!

– Әйттем бит, якын килсәгез, тәрәзәдән сикерәм! Чыгып китегез!

– Ну, беренчедән, бу тәрәзә балконга карый, сикерсәгез дә ерак китмәссез дип уйлыйм. Икенчедән, минем сезгә якын килергә бернинди теләгем дә юк – күрәсен мин болай да күрдем инде. Өченчедән, әгәр үзегезне тәртипкә китерәсегез килсә, ванна бүлмәдән чыккач, сул якта. Анда мин сезнең күлмәгегезне юып куйган идем, кипкәндер инде. Минем өйдә хатын-кыз күлмәкләре юк, шуңа күрә искесен тәкъдим иткән өчен гафу итәсез. Теләсәгез, халат кия аласыз, ирләрнеке, әлбәттә, ләкин чиста, юылган, эленеп тора. Чиста сөлгеләр дә шунда, күрерсез.

Ир-ат чыгып китте. Инде Алинә аптырап калды. Нәрсә ди? «Күрәсен болай да күрдем» диме! У-ух, оятсыз! Җир бит! Алинәнең аңсызлыгыннан файдаланган, димәк! Кинәт Алинә каршыдагы кием шкафына эленгән көзгедә үз шәүләсен күреп шаккатты. Аңа чәчләре чуалып беткән, күз төпләре шешенгән бер өрәк карап тора иде. Менә өрәк көзгегә якынрак килде, өстеннән җәймәсен төшерде. Күлмәге юк, аның урынына ирләр майкасы киеп алган. Күкрәкләре тырпаеп чыккан, аякларында кара янган урыннар күзгә бәрелеп тора. Тезләре сыдырылып төшкән. Йөзе агарганмы, саргайганмы, әллә күгәргәнме – аңлап та булмый хәтта. Әйе, мондый кыяфәттә аңа ир-ат түгел, шайтан да якын килмәячәк! «Юк, бу мин түгел, – дип коты очты Алинәнең, – бу өрәк мин булырга мөмкин түгел!» Ләкин Алинә кулын күтәрсә, өрәк тә кулын күтәрде, төшерсә, өрәк тә төшерде. «Кайда диде ваннаны? Чыккач, сул якта. Ходаем, сакла мине, үзеңә тапшыр-

дым!» Хатын-кызлык үзенекен итте – әле генә үләргә җыенган кыз, көзгедә үзенең ямьсез кыяфәтен күреп, һушсыз кала язды. Тиз генә җәймәне яңадан өстенә бөркәнде дә курка-курка гына бүлмәдән чыкты. Ир-ат күренмәде. Ванна бүлмәсен тиз тапты, керү белән эчтән ишекне бикләп алды. Юынырга дип борылган гына иде, аксыл пәрдә артында кемнеңдер шәүләсен күреп, аһ итеп куйды, куркуыннан хәле китте, тез буыннары калтырый башлады, артына чүгәләде. «Эләктем! Явызның кулына үземне-үзем илтеп бирдем! Беркатлы мин, тинтәк!» Шәүлә селкенмәде. Алинә дә утырган җирендә утыра бирде. Ниһаять, бераз утырганнан соң, кыюлыгын җыеп, пәрдәне ачып җибәрсә, иңсәгә эленеп куелган үз күлмәген күреп шаккатты. Кинәт күңелле булып китте, ирексездән үзалдына елмаеп куйды. Үлеп эчәсе килә иде. Кыз, боргычларны ачып, йотлыгып салкын су эчте, аннан соң гына юынырга керде. Өстән агып торган җылы су тәннәрен иркәләде, сабынлы йомшак мунчала бөтен пычракны юып алды. Дөнья матурланып китте.

...Алинә ваннадан чыкканда, ир-ат аш бүлмәсендә чәй әзерләп ята иде. Борынын ярып кергән ашамлык исен сизеп, Алинә һушын югалта язды, өстәлдәге ризыкларга үрелүдән үзен чак тыеп калды. Ничә көн ашаганы юк ла аның!

– Әһә, халат киеп бик әйбәт иткәнсез, – диде ир-ат, – сезгә килешә. Чибәр икәнегезне чамалаган идем инде, ә хәзер сез ... гүзәл дию дә аз.

Алинә, кыенсынып, чәчләрен сөрткәләде, күз алдына көзгедәге өрәк килеп басты.

– Алайса, сезне Эмма җибәрмәдемени?!

– Мин бернинди дә Эмманы белмим, исеменә караганда, белергә дә теләмим. Ә сезнең исемегез ничек?

– Рита, – диде кыз, ничектер ыңгырашыбрак, – минем исемем Рита.

– Рита. Матур исем. Сез Казаннанмы?

Алинә дәшмәде, сүзне икенчегә борасы килде.

– Мин монда ничек килеп эләктем?

– Сез төнлә паркта һушыгызны югалтып егылдыгыз. Ә мин сезгә ял кирәк дип уйлап, өйгә алып кайттым. Әйдә, утырыгыз, чәй әзерләдем. Хәзер барысын да сөйләшербез.

Алинә киң артлы йомшак утыргычка авышты. Борынын яңадан майда кыздырылган суган, колбаса исе ярып керде, кинәт өстәл өстендәге ризыклар күз алдында йөзеп киттеләр, кыз ава язып калды, чытырдатып, өстәл кырыена ябышты.

– Нәрсә булды? – Ир-ат тавышында борчылу чагылып узды. – Үзегезне начар хис итәсезме әллә?

– Мин... мин берничә көн ашамадым бугай... Башым әйләнеп китте.

– Соң, нишләп әйтмисез соң? Боларның берсен дә сезгә ашарга ярамый. Хәзер, әз генә сабыр итегез, зинһар. Менә сөт эчә торыгыз. Йотымлап кына, яме?!

Ир-ат тиз-тиз генә өстәлдән кыздырылган йомырка, колбаса, май белән икра ягылган икмәк кисәкләрен алып, барысын бергә чүп чиләгенә томырды. Кыз аһ итте. Ул арада ир-ат суыткычтан эремчек алып, сөт белән бутап сыеклады да кыз алдына куйды.

– Әлегә сезгә шушы җитеп тора, – диде ул.

– Сез нәрсә? – Алинә тавышында ачулану да, гаҗәпләнү дә, рәнҗү дә ишетелде. – Нигә ташладыгыз ул ризыкларны?! Күрәм, сез беркайчан да ач тормагансыз. Сез... Сез ризык кадерен белмисез!

Ир-ат бу сүзләргә үпкәләмәде. Бераз йөзе моңсуланыбрак китсә дә, элеккечә мөлаем елмаеп:

– Зинһар, әз генә кабып ашарга тырышыгыз, менә сөт йотыгыз, – дип, Алинәне сыйлый башлады. Алинә исә артык кыстатып та тормады. Ялт иттереп тәлинкәдәге эремчекне сыпырып куйды, сөт эчте, ярты телем икмәк тә шунда ук авызда эреп юкка чыкты.

– Ризык кадерен беләм мин, ачуланмагыз, зинһар, – диде ир-ат, Алинәнең ашаганын күзәтеп. Аннан, әйтергәме-юкмы дигәндәй, бераз уйланып торды. – Чечен тоткынлыгында бер ай диярлек үз канымны суырып тукландым... хәзер искә төшерүе дә кыен хәтта. – Ир-ат көчәнеп елмайды. – Ләкин ризыктан культ ясамыйм. Сезнең күз алдыгызда ул ризыклар торса, үзегезне тыю авыр булыр иде. Беләсезме, сез күпме йокладыгыз? Ике тәүлек! Сезгә ризыкның күплеге аның булмавы кебек үк куркыныч. Туендыгызмы?

– Юк, – диде Алинә, үҗәтлек белән.

– Нишлисең, димәк, тагы әзрәк ач торырга туры килер. Ярты сәгатьтән ботка пешерермен үзегезгә, армиядәгечә итеп. Ә хәзер ял итегез, ләкин утырып кына, ярыймы.

Кыз теләмичә генә урыныннан кузгалды. Тик бүлмәгә кереп киткәнче үзе ашаган савытларны чайкап куярга онытмады.

Гамир өстәл янында уйларына чумып утыра бирде. Соңгы берничә елда ул бүген беренче мәртәбә иртәнге чәйне ялгызы гына эчмәде. Беренче мәртәбә бүген хатын-кызга чын күңеленнән, үзе теләп елмайды. Беренче мәртәбә көлмәк юды. Хатын-кыз күлмәге. Кыз үлем йо-

кысы белән йоклаганда аның өс-башын алыштырды, сәгать саен пульсын санады. Әгәр кыз рөхсәт итсә, ул аны, яшь баладай, калактан ашатырга да әзер. Күңелендә күтәрелгән ниндидер яңа тойгыга ияләшү әлегә авыр иде. Юк, бу җенескә бәйле сөю тойгысы түгел. Бу – якын кешең, туганың барын тою, аның турында кайгырта алу мөмкинлеген тою. Бу кыз аның өчен сер йомгагы. Кем ул, өе, гаиләсе, туганнары кайда? Рита. И-их, Рита, белсәң иде, Гамирның бу турыда синнән сорарга ничек курыкканын! Юк, сорамаячак ул. Сорамаячак. Син китеп барсаң, аның кояшы сүнәчәк. Китмә, Рита, китмә әлегә, зинһар!

Гамир үз-үзеннән моны көтмәгән иде. Ул беркайчан да үзен хисле кеше дип уйламады, беркайчан үзен дә, башкаларны да кызганмады. Ә бүген... күз яшьләре төштә генә түгел, өндә дә тамарга гына торалар. Кинәт Гамирга һич кенә дә көтелмәгән бер яңалык ачылды: бүгеннән башлап Памир дигән кеше дөньяда яшәми. Памир – горур, кырыс, куркыныч Памир, «авторитет» Памир яшәүдән туктады. Чөнки ул Памирның йөрәгенә курку хисе үтеп керде. Якыны, якын кешесе өчен курка Памир. Памирның үлеме – шушы кызда. Булсын. Памир үлсә, Гамир яши башлар. Үз исеме бар ич аның!

...Гамир, көрсенеп, өстәл артыннан торды, кесә телефонын алып, кибеткә шалтыратты. Ритага ашар өчен җиләк-җимеш кирәк. Көч кайтарырга тавык шулпасы кирәк. Витаминнар, дарулар, халат, күлмәк, туфлиләр – барысы да кирәк. Кирәк, кирәк... хатын-кызга тагы ниләр кирәк икән?! Каян белсен аны Гамир?

Бу вакытта Алинә үзен тәртипкә китерергә маташа иде. Әйе, шактый тырышырга туры киләчәк аңа: шушы берничә көн эчендә кыз үзен ун елга картайган кебек хис итте. Күз төпләренә, гомердә булмаганны, кара-кучкыл капчыклар эленгән, бәбәкләр шешенгән, йөзе көл төсендә. Ә бит ул үзен бит урталары янып торган шат күңелле тормышка гашыйк кеше итеп хәтерли! Нәрсә булды соң аңа, нәрсә булды?! Әгәр ул беркайчан да үзенең кем икәнен хәтерләмәсә? Әгәр гаиләсен, туганнарын тапмаса? Нишләр ул чагында Алинә, нишләр, кемгә барып егылыр?! Юк, хәтерләргә кирәк, хәтерләргә. Болай булмый. Болай ярамый. Ир-ат әйтүенчә, ул ике көн йоклаган. Икеөч көн урамда үтте. Димәк, әгәр аның туганнары булса, Алинәне эзли чыгарга тиешләр. Милициягә аның югалуы турында хәбәр итәргә тиешләр. Милициядә ул инде булды. Анда аны Волкова Маргарита дип яздылар. Ләкин ул бит Волкова түгел! Маргарита да түгел! Әгәр яңадан милициягә барса? Аны тагы «төнге күбәләкләр» белән

бикләп куярлармы икән? Юк, йә тагы ябып ук куярлар. Хастаханәгә барса? Ул анда да булды инде. Аннан соң ул бит үзенең кем икәнен белми. Аның документлары юк. Хастаханәдә дә, милициядә дә документ сорадылар. Аһ, нишләргә соң инде. Әгәр бу ир-атка үзе турында сөйләп бирсә? Ир-ат аңа ярдәм итә алыр микән? Юк, Алинә аңа да ышана алмый. Кем ул? Алинә хәтта аның исемен дә белми. Нишләп әле ул аны үз өенә алып кайткан? Нигә хастаханәгә илтмәгән? ...Алинәнең башында мең төрле сорау бөтерелде, ләкин берсенә дә кыз җавап таба алмады.

Бераздан ишек кыңгыравы шалтырады. Алинә үз бүлмәсен бикләп ук куйган иде, шуңа күрә ир-атның кемнәр белән сөйләшүен аңлый алмады. Хәер, ир-ат озак сөйләшеп тормады, тышкы ишекне япкан гына иде, шунда ук диярлек тагы кыңгырау шалтырады. Тагы кемнеңдер тавышы яңгырады. Бераздан тагы кыңгырау. Кыз, шикләнеп, бүлмә ишегенә колагын куйды, ул арада тышкы яктан бүлмә ишеген шакыдылар. «Рита, гафу итегез, әгәр йокламасагыз, сезгә үтенечем бар иде». Алинә, корт чаккандай, читкә сикерде.

– Юк, йокламыйм, керегез, – диде ул, тыныч булырга тырышып, ишекнең келәсен күтәрде. Бусагада купшы гына киенгән, кулына берничә төргәк тоткан йорт хуҗасы күренде.

– Менә, сезгә башка кием кирәк булыр дип, кибеткә заказ биргән идем. – Гамирның тавышы ничектер гаепле яңгырады. – Үлчәмегезне белмим инде, чамалап кына әйттем. Ярамаса, кире кайтарырга мөмкин.

Ир-ат төргәкләрне кызга сузды. Алинә, алыргамы, юкмы дигәндәй, аптырап калды, күтәрелеп ир-атның күзләренә карады. Ир-ат бик уңайсызлана шикелле, алмаса, елап җибәрер баладай бер кыяфәттә басып тора иде. Шулай да Алинәнең күңелендә баягы «Эмма җибәргәндер» дигән шик калган, таныш түгел ир-атның мондый җылы мөнәсәбәтенә бик ышанып бетмәде.

– Мин бит сездән бернәрсә дә сорамадым, – диде, беркадәр сүзсез торгач.

– Зинһар, ышаныгыз, минем сезгә нинди дә булса начарлык эшләү уемда да юк. Минем аңлавымча, сез ниндидер бәлагә тарыгансыз яки күңелсез хәлгә юлыккансызмы – белмим, ләкин нәрсәдер булган, шулай бит? Әгәр үзегез сөйләмәсәгез, мин бернәрсә дә сорамаячакмын. Шулай да минем ярдәм итәсем килә. Сез... минем сеңлемә охшагансыз.

Ир-ат соңгы сүзләрен сыкранып диярлек әйтте, стенадагы сурәткә күтәрелеп карады. Кечкенә шаян кызчык

һәрвакыттагыча күзләреннән очкын чәчеп елмая иде. Алинә бу сурәтләрне күргән, ләкин ул да Шурик кебек ир-атның кызы дип уйлады. Күрәсең, ир-ат сеңлесен бик яратадыр.

– Рәхмәт... гафу итегез, мин сезнең исемегезне белмим, – диде Алинә, төргәкләрне ир-ат кулыннан алып.

– Гамир. Минем исемем Гамир.

– Рәхмәт, Гамир.

Бер мәлгә сүзсез калдылар. Алинә Гамирның чыгып киткәнен көтә, ә Гамир исә, нәрсәдер әйтергә теләп тә, әйтә алмыйча интеккән кеше кебек, борсалана иде. Ниһаять, телгә килде.

– Беләсезме... Мин... Миңа китәргә кирәк. Мин... Үзегезне генә ялгыз калдырырга... теләмәс идем.

Алинә бу сүзләрне көтмәгән иде. Димәк, Гамир аның ялгызын гына үз өендә калдырырга курка. Әлбәттә инде, чит-ят кызны... нишләп әле ул үзенең кыйммәтле җиһазлар белән тулы квартирасында калдырсын ди?!

– Алайса, мин хәзер... киенәм дә... китәрмен. Тик бу киемнәр миңа кирәкми.

– Юк, сез аңламадыгыз, – диде Гамир, ашыга-ашыга. – Киресенчә, мин сезнең бу өйдә калуыгызны телим. Мин сезнең... чыгып китүегездән... э-э... югалуыгыздан куркам. Әгәр мөмкин булса, беразга булса да... монда яшәп торсагыз иде.

Алинә моны да көтмәгән иде. Дөрес, аның барыр урыны юк, шулай да әзрәк хәл алгач, бүген үк үзенең туганнарын эзли башларга дигән фикергә килде. Монда яшәргәме?

– Сезнең туганнарыгыз... бу өйнең хуҗабикәсе ни әйтер соң?

– Мин буйдак. Һәм ятим. Әгәр сез калсагыз... туганым булыр идегез.

Алинә тиз генә җавап бирә алмады.

– Мин уйлармын, – диде ул, бераз каушап. «Туганым» ди. Ә сеңлесе?

Гамир көрсенеп куйды. Әллә ничек шунда... сөйләшә алмый ул бу кыз белән. Әйтәсен әйтә алмый. Аңлата алмый. Ул инде ике көн беркая чыкмады – телефонның берөзлексез шалтыравыннан туйгач, ычкындырып куйган иде. Ләкин өйдә бикләнеп ятып та булмый – эшлисе эшләре, хәл итәсе мәсьәләләре җитәрлек. Ә чыгып китсә, кыз да китеп югалыр дип курка. Каравыл куеп булмый ич инде. Хәер, Гамирның мондый хәлдә калганы беренче тапкыр гына түгел. Иң яхшысы – кырт кисәргә кирәк. Нишлисең, бәйләп куеп булмый – язмыштан узмыш юк

диләрме әле? Тормыш әфәнде үзе бик тиз хәл итә ул. Бу бәхетле ике көнне оныттырга туры килер. Кирәк була икән инде, ул кызыйны җир астыннан да эзләп табачак.

– Ярар алайса. – Бу юлы Гамирның тавышы ничектер кырыс һәм катгый яңгырады. Яңа гына уңайсызланып, тотлыгыбрак сөйләшкән егеттән әйтерсең җилләр исте. – Шулай да, әгәр калырга уйласагыз, аш бүлмәсендәге өстәлгә сезнең өчен җиләк-җимеш юып куйдым. Ә, әйе, онытып торам икән, ботка да әзер. Кайнар килеш ашагыз. Үзегез чәй куеп эчәрсез. Әз-әзләп ашарга тырышыгыз, зинһар.

Гамир, чыгып китәргә җыенып, ишек тоткасына кулын куйды. Әйтәсе сүзе бетмәгән иде, ләкин борылып кызның күзләренә карарга йөрәге җитмәде.

– Рита... Әгәр китәргә уйласагыз, ишек тышкы яктан ачкычсыз гына бикләнә. Өегезгә кайтырга акча кирәк булыр... аш бүлмәсендә уң яктан беренче аскы тартмада. Кирәк кадәрле алырсыз.

Юк, Гамир барыбер кызга борылып карамыйча чыгып китә алмады. Алинә бүлмә уртасында дәшми генә басып тора иде. Күз карашыннан берни аңлап булмый. Яшькелт-зәңгәрсу күзләр бары сынап, бераз шикләнеп карыйлар.

– Сау бул, Рита. Мин кич кайтам, бик соңга калмаска тырышырмын.

– Сау булыгыз, Гамир.

Гамир чыгып китте. Ишек йозаклары ябылганын ишеткәч, Алинә яңадан караватка барып ятты. Тик шунда ук, күңеле болгануын тоеп, торып утырды. Гамир аңа «ятарга ярамый» диде ич. Дөрес әйткән икән. Кыз, авыр сулап, тирә-ягын күзәтә башлады. Стенадан таныш кызчык елмая иде. Бу баланың елмаюы шулкадәр самими, шулкадәр нурлы, әйтерсең дөньяда аңардан да бәхетле кеше юк. Алинә үзалдына елмаеп куйды. Караган саен карыйсы, җавап итеп елмаясы килә. Күңелдә нindидер хисләр кузгала, кемнедер сагыну, өзелеп юксыну хисе барлыкка килә... Кайда икән хәзер Гамирның сеңлесе? Сорамады да. Сеңлесе булгач, ятим түгел инде ул. Ә Алинә чын ятим менә хәзер. Беркеме юк. Кинәт моңсу булып китте, басылып торган ашыйсы килү тойгысы яңадан кайтты. Җиләк-җимеш юдым, диде Гамир. Ашарга кирәк.

Бая абайламаган да, аш бүлмәсе шундый зур һәм якты икән. Тәрәзә буенда почмакка турылап куелган ике озынча таррак өстәлдә ямь-яшел булып гөлләр үсә. Арада чәчәк атканнары да бар, шулай да күбесе яшел, яфраклы гөлләр. Гамир үзе үстермидер инде, димәк, өйдә тагы кемдер яши

яисә килеп йөридер. Әлбәттә, сеңлесе. Уртада түгәрәк өстәл өстендә ак эскәтердә табагы белән җиләк-җимеш тора. Ниләр генә юк монда! Бу кадәр кирәкми иде, Гамир артык кыланган. Алинә табактан банан алып әрчеде. Туклыклы җимеш, әмма ипи барыбер тәмлерәк. Кайда икән ипи? Алинә, тартмаларны ачып, ипи эзли башлады. Суыткыч консервалар белән тулы. Ит, бавыр, балык, икра, кальмар, краб, төрле компот консервалары, тагы Алинә белмәгән әллә ниләр. Ипи юк. Шкаф тартмаларында да ипи күренмәде. Менә бит, иң кирәкле ризыкны аскы тартмаларга яшергән. Алинәнең, ипине күргәч, авыз сулары килде. Шулай да Гамирның «әз-әзләп аша» дигәнен искә төшереп, бер телем кисеп алды да калган икмәкне урынына куйды. Янәшәдәге тартманы ачып караса, аһ итте. Бу Гамир әйткән тартма иде, тартмага яртылаш диярлек акча тутырылган иде. Җаныңа нindие кирәк – үзебезнең ил акчалары да, чит илнеке дә – әйтерсең кухня өстәле түгел, дәүләт банкы. Алинәнең гомерендә дә бу кадәр акча күргәне юк, ул төгәл белә. Ничек диде әле Гамир? «Күпме кирәк, шуның кадәр ал» диде. Юк, булуы мөмкин түгел. Мөгаен, кайдадыр ерак түгел генә саклап торадыр. Янәсе, хәзер Алинә бу өйдән акчаны алып чыгып кача, ә Гамир аны шунда ук эләктереп ала да «карак» дип төрмәгә озата! Ләкин Гамирга бу нигә кирәк? Әмма үчеме әллә? Юк, әллә ничек, бәйләнеш юк. Кем бу Гамир? Гадәти кеше түгел, анысы билгеле. Гадәти кеше бу кадәр акчаны аш бүлмәсе өстәлендә сакламый. Банкир, эшмәкәрме?! Ә эшмәкәр акчаны монда саклар идеме? Юк, аңлашылмый. Йа Ходаем, Гамир – үтерүче. Кеше үтереп табылган акчалар бу. Алинә, җирәнеп, тартманы шатырдатып ябып куйды. Ә юылган күлмәк? Ә гөлләр? Ә «гафу итегез», «зинһар», «әгәр мөмкин булса»? Үтерүче шулай сөйләшер идеме? Үтерүче ботка пешерә беләме?! Алинә тәмам буталды... Яхшы чакта ычкынырга кирәк моннан. Ә Гамир ишек артында сагалап торса?

Кызның йөрәге дөп-дөп итеп, калтыранып типте. Чигәләрендә кан шаулады. Нindидер карарга килергә кирәк иде. Йә калырга, йә китәргә. Китеп кая барыр? Калып нәрсә эшләр?! Алинә чарасызлыктан гаҗиз булды, аптырагач, тәлинкә алып, плитә өстендә торган кәстрүлдән ботка салды, өстәл артына ашарга утырды. Гамир, кич белән кайтам, диде. Димәк, әле вакыт бар. «Соңрак уйлармын, – диде ул үз-үзенә, – әлегә уйлый алмыйм. Ашыйсым килә».

Тамагын туйдыргач, Алинәгә дөнья яңадан ямьләнеп киткәндәй булды. «Нишләп әле мин кеше акчасын са-

ныйм? Бәлки, бу кешенең гадәте шундыйдыр. Бәлки, ул өендә күп акча тотарга яратадыр. Үтерүче, имеш. Әгәр үтерүче булса, үтергән булыр иде инде. Аннан соң, «теләсәң, китә аласың» диде. Ә минем барыбер барыр урыным юк. Калам. Әллә шулай да... китәргәме?».

Бераздан соң Алинә үзе яшәгән өй белән таныша башлады. Ул йоклаган бүлмәдән тыш, тагы бер зур гына бүлмә – зал ягы бар икән. Әйе, муллык бу йортта күзгә күренеп, кычкырып тора иде. Бер караганда, барысы да гади, артык әйбер юк сыман. Ләкин җентекләбрәк күзәтә башласаң, стенага ябыштырылган кәгазьнең үтә зифа, зәвыклы икәнен күрәсең, идәнгә җәелгән келәмгә аяклар яртылаш батып китә. Түшәмгә эленгән люстра да артык күзгә ташланмый, ләкин кояш нуры бер таш-тамчысына эләксә, калган барлык ташларын балкытып уйнаклый. Сул як стена буеннан-буена тезелгән китап киштәләре калын томнардан сыгылып тора. Кызык, Гамир укыймы икән аларны, әллә матурлык өчен генә тезеп куйганмы? Башка өйләрдә гадәти булган зур шкаф – стенка да юк биредә. Аның урынына стеллажда берничә зур-зур аквариум, алар каршында бер-берсенә борып каратып куелган ике йомшак кәнәфи, тәбәнәк өстәл. Стеллажның бер баскычында кыйбатлы телевизор, икенче ягында музыкаль үзәк. Уртадагы баскычта кыйммәтле ташлар белән бизәп эшләнгән кечерәк кенә өстәл лампасы. Алинә аның төймәсенә баскан иде, аквариумнар өстендәге көн яктысы бирә торган лампалар кабынды, якты нурлар өстәл лампасының ташларында уйный башлады. Моңа кадәр тыныч кына су өстендәге күбекләрне җыеп йөргән балыклар җитез хәрәкәткә килде, тәңкәләрен ялтыратып, куыша башладылар. Алинә каршыдагы йомшак кәнәфигә барып утырды, мавыгып, су асты дөньясын күзәтә башлады...

...Гамир көне буе ары чапты, бире чапты. Дөресрәге, машинада җилдерде. Әле берсе белән очрашты, әле икенчесенә җикеренде, өченчесенә сырпаланды. Бүген ул теләсә нәрсә эшләргә әзер иде – бары тик өйдә калган Рита турында гына уйламасын. Бары «Рита киткәндер» дигән газаплы уй гына аның баш миен бораламасын. Ул бүген теләсә нәрсә эшләргә әзер. Ләкин көн кичкә якынлашты, эшчеләрнең эш сәгатьләре чыкты, һәркем ашыга-ашыга үзенең торган урынына, якыннары янына юл алды. Гамир элек тә көннең нәкъ шушы вакытын яратмый иде, ә бүген исә кояшның офыкка якынлашуын күралмас хәлгә җитте. Аның сагынып көтеп торган кешесе юк, аның, дөресен генә әйткәндә, кайтыр урыны да

юк – бүлмәсенең буш стеналары күңел кайтаргыч. Нишләп әле башка вакытта бу турыда уйланылмаган? Әллә берәрсенә кунакка барыргамы?! Кемгә?! Гамир хәтта югалып калды. Кемгә генә барсаң да, «нигә килдең» дигән сораулы караш белән каршы алачаклар. Чөнки Гамир дигән әфәнде юктан гына кунакка йөрми. Беркайчан да. Йөздән артык танышы, дус-ише бар – ә ул барыбер ялгыз. Өенә кеше кертмәгән кебек, күңелен дә кешеләрдән яшереп, бикләп куйды – димәк, сиңа хыянәт итмәячәкләр. Шулай дип уйлады Ританы очратканга кадәр. Ә Рита сорап тормады, аның тормышына бәрде дә керде. Менә йөр инде хәзер кайтыргамы, кайтмаскамы дип каңгырап.

...Ниһаять, Гамир машинасын кайтыр якка борды. Кояш, аның хәленә кергәндәй, офыкка килеп җиткәч тә әле бераз күк читендә эленеп торды да әкрен генә аска тәгәри башлады. Машинасын гаражга куйганнан соң, егет үз өенең тәрәзәләре каршындагы утыргычка килеп утырды. Кайбер йортларда инде ут алганнар – Гамирның тәрәзәләре караңгы. Егетнең күңеле упкынга очкандай булды. Димәк, Рита киткән. Киткән. Син нәрсә көткән идең соң, егеткәй? Күктән төшкән шаһинә түгел ич Рита, ул – җир кешесе. Аның үз өе бардыр. Үз туганнары бардыр. Бәлки, сөйгән кешесе, ире дә бардыр... Ә син «миндә яшә», имеш. Ничек яшәсен ул синең белән, кем булып яшәсен? Дөрес, син булыштың аңа, ләкин иң беренче чиратта син үзең ярдәмгә мохтаҗ идең. Ул кыз сиңа бурычлы түгел. Гамир, бераз уйланып утыргач, үзенең беркатлылыгына шаккатты. Әйе, күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе ботак тишеге, диләр бит. Әкрен генә утыргычтан кузгалып торып китте. Гадәттә өч кенә сикергән баскычларның бүген саны-исәбе юк сыман иде. Менә инде синең буш өең, егеткәй. Кер дә ят үзеңнең мәгарәңә. Ә мәгарәдән нишләптер аш исе килә. Зал ягыннан кызгылт яктылык бөрки – камин яна. Әллә өйдә кемдер бармы? Бар шул, бар. Рита өйдә, Рита!

– Рита, – Гамирның тавышы беркадәр калтыранып чыкты, – сез өйдәме?

Зал ягыннан шәүлә калыкты. Адымнар тавышсыз, тыенкы.

– Исәнмесез, Гамир энем. Хәерле кич!

Юк, бу Рита тавышы түгел. Гамир өенең ачкычлары тагы бер генә кешедә бар – өй караучысы Камилә апада. Гамир ашыгып ут яндырды. Каршысында Камиләттәй басып тора иде.

– Исәнмесез, Камилә апа. Сезнең бүген киләсегезне белмәдем.

– Гамир энем, кичә көн буе шалтыраттым сиңа, бүген иртән шалтыраттым – өйдәге телефоның да җавапсыз, эшеңдә дә синең кайда икәнне белмиләр, үз телефоныңны да алмыйсың. Аптырап, бер-бер хәл булмады микән дип килгән идем дә, монда бер кыз бала яши икән.

Димәк, КамиләттәйРитаны күргән.

– Кайчан китте соң ул?

– Кем китте?

– Соң... теге кыз бала. – Гамир гамьсез күренергә тырышты. Костюмын салып элеп куйды, залга узды. Камиләттәй аның артыннан иярде. – Рита исемле иде ул. Рита... күптән киттеме?

Камиләттәй җавап бирергә өлгерми калды, балкон ишекләре ачылдылар, залга зур-зур чәчәкле халат киеп алган Рита килеп чыкты. Рита. Рита калган, Рита бирелә!

– Хәерле кичләр, Гамир.

– Рита... исәнмесез. Э-э... сезне күрүемә бик шатмын.

– Мин балконга чыккан идем әле генә. Камилә апа белән сөйләшеп утырдык бераз. Аның минем белән калуын үтенгән идем.

Камиләттәй «әйе, әйе» дигәндәй баш какты.

– И-и, искә төшереп утырдык яшь чакларны. Рита учак ярата икән. Электр мичен учакка охшаган, ди. Балыкларны җәлли. Авыл баласының шул инде, иркенлеккә тартыла күңеле. Әйдә, Гамир энем, ашап ал. Рита мин килгәндә аш пешереп куйган иде инде, үзе дә ашамаган әле. Бергәләшеп ашарсыз, әйдәгез.

Рита аш бүлмәсендә Камиләттәйгә табын әзерләргә булышып калды, Гамир юынырга кереп китте. Рита калган, Рита бирелә, трат-та-та, трат-та-та! Гамирның шатлыгы йөрәгенә сыешмый, җыр булып тышка атылырга әзер. Бүген юына торган су күбектәй йомшак, сөлге ефәктәй назлы, бүген дөнья матур, бүген... Гамир бәхетле!

Өстәл әзерләү белән, Камиләттәй китү ягын карады. Алинә бу мөлаем тел бистәсе хатынның төнгелеккә дә монда калуын теләгән иде дә, хатын көлде генә. «Иртәгә килермен алайса», – дип, тиз-тиз китеп барды. Гамир юынып чыкканчы, Камиләттәйдән җилләр искән иде инде.

– Сезнең ялгызыгызны калдырып китүем өчен гафу итегез, зинһар. – Гамир өстәл артына утырды. – Үзегезне ничек хис итәсез?

– Хәзер барысы да әйбәт. – Алинә туп-туры Гамирга күтәрелеп карады. – Сезгә бик зур рәхмәт. Сез булмасагыз, мин... белмим, нишләгән булыр идем.

– Алайса, миннән башка шикләнмисез инде?

– Мин сезнең кем икәнегезне белмим бит. Камилә апа әйтүе буенча, сез бик яхшы кеше.Ләкин ул да кем икәнегезне белми.

– Мин дә сезнең кемлегегезне белмим. Сез дә яхшы кешегә охшагансыз.

Тынып калдылар. Алинә тәлинкәләргә буы чыгып торган кайнар тавык шулпасы бүлде.

– Кичке ашка шулпа пешерергә кирәк булмагандыр бәлки, тик мин ярмаларны тапмадым.

– Юк, киресенчә, мин бик ачыгып кайттым. Бик тәмле аш пешергәнсез. Үзегез дә ашагыз, сезгә бигрәк тә файдалы тавык шулпасы.

Алинәнең күңеле булды. Таныш түгел аш бүлмәсендә кирәкле азык яки савыт-саба табуы кыенга туры килсә дә, шулпаны ул бик яратып, җиренә җиткереп пешергән иде. Яшелчәләр белән ит кыздырды, хәтта матурлап бизәп тә куйды. «Бәлки, мин элек пешекче булганмындыр?» Югалган тормышын май кайнаган табадан, чынаяк-кәстрүлдән күзалларга тырышты. Юк, хәтер катламнарына кат-кат юшкын утыргандай, берни күренми, кәстрүл-табалар Алинәгә ярдәм итә алмый...

Сүзсез диярлек ашадылар. Алинә чәй әзерләргә керешкән иде дә, Гамир аны туктатты.

– Юк, юк, – диде ул, – чәйне мин үзем әзерлим. Әйдәгез, сез залда утырып ял итә торыгыз. Чәйне шунда гына, камин каршында эчәрбез.

– Алайса, сез чәй әзерләгән арада, мин савыт-сабаны юып куям.

Гамир, хатын-кыз белән бәхәсләшеп булмый инде дигәндәй, елмаеп ризалашты. Ә Алинәнең күңелен һаман корт кимерә: янәсе, чәйгә берәр нәрсә салып бутамыймы? Йоклатып алдарга уйламыймы? Савыт-саба юганда, Гамирның кулларыннан күзен алмады. Юк, егетнең андыймондый уе юк, ахры, икесенә дә бер үк чәйнектән чәй ясады, икесенә дә җимешләр салды, кечкенә тәгәрмәчле арбага конфет, шикәр, кайнатмалар тезеп куйды. Шулай ук елмаеп, Алинәгә борылды.

– Ягез, киттек чәй эчәргә.

Камин, залның уң як стенасына киртләп, борынгы венециан рухында ясалган. Гамир кәнәфиләрне мич алдына күчереп куйды, өстәлне якынрак китерде. Каминны кабызып, бүлмә утын сүндерде. Алинә сискәнеп китте.

– Зинһар, утны калдырсагыз икән.

– Яктыда каминдагы учак телләре күренмәячәк. Ясал-

ма булсалар да, караңгыда матуррак алар. Теләсәгез, өстәл лампасын кабызырга мөмкин.

Лампаны кабызуга, аквариумнар өстендәге утлар да кабындылар. Бүлмә яктырып китте.

– Рәхим итегез, җайлап утырыгыз, зинһар. Чәйдән авыз итегез.

Мич эчендә катып калгандай ясалма учак телләре, җемелдәп, талгын кызыл ут белән балкыйлар. Җылысы сизелми диярлек, күрәсең, Гамир каминны җәйге төнгә яраклаштырып куйган. Алинә, егет сузган чынаякны алмыйча, Гамирныкына үрелде. Янәсе, йокы даруы салырга өлгергән булса, үзе эчсен әле менә. Гамир көлеп җибәрде.

– Әһә, димәк, һаман ышанмыйсыз әле миңа. Әйтәм аны, аш бүлмәсендә миннән күзегезне алмадыгыз. Ярый, бик дөрес эшлисез. Сезнең урында булсам, мин дә ышанмас идем.

– Гафу итегез, мин сезгә ышанырга бик теләр идем дә... сезнең турында бернәрсә дә белмим.

– Әгәр мин үзем турында сөйләсәм, сез ышанып идегезме?

– Бәлки...

– Ләкин мин бик җиңел сезне алдый алам бит. Сезгә теләсә нинди сюжет уйлап чыгара алам. Әйтик, мин инженер, заводта эшлим, буйдак. Эчмим, тартмыйм.

– Сез инженер түгел.

– Каян беләсез?

– Инженер кеше болай яшәми.

– Ничек – болай?

– Болай... бай.

– Ә минем әти-әнием бай кешеләр.

– Ялган. Сез иртән «мин – ятим» дидегез.

– Әйе, сезне тиз генә алдап булмый, күрәсең. – Гамирны кызның матур йөзендә балкыган кызгылт яктылык әсир итте. Рита бик җитди, беркадәр дәрвишләрчә утка карап утыра иде. Менә ул Гамирның карашына җавап итеп күзләрен күтәрде, егеткә туп-туры, сынап карады.

– Кем соң сез?

Гамир кызның карашын курыкмыйча күтәрде, шулай да, сүзне кайдан башларга белми, беркадәр уйланып калды.

– Мин Казанда туып үстем. Сез егылган урыннан ерак түгел генә, Казансу буенда, кечкенә авыл бар иде. Хәзер дә әле анда кешеләр яши, ләкин ул элеккеге кебек төзек, матур авыл түгел инде. Гаҗәп хәл, шундый зур шәһәрнең нәкъ уртасында, тып-тыныч бер урында тезелеп киткән

авыл өйләрен күз алдына китерәсезме?! Шунда ук балалар бакчасы, мәктәбе дә бар. Теләсәң, ун минуттан гөрелтеле шәһәргә килеп чыгасың. Әтине мин хәтерләмим диярлек, әни әйтүе буенча, ниндидер авырудан вафат булган, без әни һәм сеңлем белән өчәү яши идек. Әни эштә, ә без үзебезгә үзебез хуҗа. Җәй көннәре бигрәк тә. Теләгәнчә су керәбез, агачларга үрмәлибез, паркта таган атынабыз.

Гамир көрсенеп куйды. Егеткә бу истәлекләрне кабат күңеленнән уткәрү катлаулы булса кирәк. «Менә сәер кеше, – дип уйлап куйды Алинә, – сөйләргә хатирәләре бар, ә ул көрсенеп утыра!»

– Айгөл – сеңлемнең исеме шулай иде – бик шук, тере кызчык. Бәлки, минем белән, малайлар арасында үскәнгәдер, бер дә тик тормас, агачларга менә, тауларга үрмәли, бер сүз белән әйткәндә, малайлардан да уздыра иде. Менә... шул сеңлемне саклап кала алмадым... Берк-өнне паркта уйнаганда, кулыннан ычкынып киткән туп артыннан йөгереп, машина астына барып керде... Мин янында идем, куркудан катып калганмын... Хәзергә кадәр үз-үземне кичерә алмыйм.

Гамир соңгы җөмләләрне сызланып, әрнеп әйтте. Үкенеп, гасабиланып әйтте. Юк, Гамир боларны уйлап чыгара алмас иде, Алинә аңа ышана. Менә кем икән аның сеңлесе! Күзеннән чаткылар чәчрәтеп көлгән кызчык – Айгөл – Гамирның гомерлек җан сызлануы икән. Синең үзеңә ничә яшь иде соң ул вакытта, егеткәй?

– Бу хәбәрне ишетүгә, әни йөрәге белән егылды. Бик ярата иде ул Айгөлне. Икебез дә ярата идек. Аны яратмый мөмкин түгел иде. Айгөлне күмеп, бер ай үтүгә, әни үлеп китте. Күтәрә алмады йөрәге. Бер ел элек кенә әбине җирләгән идек. Башка туганнар булмагач, мине балалар йортына бирделәр. Андагы тормышны үзең беләсең инде – усаллашырга туры килде. Аннан соң армия еллары. Кавказга эләктем. Кайтыр вакыт җитүгә, беренче чечен сугышы башланды. Үзем теләп спецназга язылдым. Тагы ике ел анда үтте. Аннан – әсирлек... Качтым. Кайткач, монда яңа тормыш башладым. Хәзер инде ныклап аякка бастым дияргә була – үземнең кибетләрем бар. Менә шундый инде инженер язмышы.

Гамир тынып калды, суынган чәен йотты. Хәзер күңел бушатырга Алинәнең чираты. Сөйләрме, юкмы кыз үзе турында?

– Димәк, «мин ятим» диюегез аңлашыла. Гамир, миңа бик кызганыч. Мин сеңлегезне исән-сау дип уйлаган идем.

– Ул минем дөньядагы бердәнбер якын кешем. Бик еш төшләремә керә. Казанга кайткач та, иң беренче аның фотоларын күрше кызыннан эзләп табып, зурайтып ясаттым. Башка туганнарымның барлыгын мин белмим.

– Гамир, әгәр мин сезгә үзем турында сөйләсәм, сез миңа начарлык эшләмәскә вәгъдә итәсезме?

– Димәк, сез миңа һаман ышанмыйсыз.

– Юк, эш анда түгел. Минем язмыш сезнекеннән аерыла. Дөресрәге, минем киләчәк язмышым бүгенге көннән, бәлки, күпмедер дәрәҗәдә сездән дә торадыр.

Гамирның карашында беркадәр сәерсенү чагылып китте. Бер тын белән чәен йотып бетерде дә, чынаягын куйгач, кызга борылыбрак тураеп утырды.

– Мин бернәрсә аңламадым, шулай да вәгъдә бирәм: сезгә үзегез теләмәгән бернинди эш тәкъдим итмәячәкмен, бернинди начарлык эшләмәячәкмен, сеңлем истәлеге белән ант итәм. Әгәр сөйләргә теләмисез икән, үзегезне мәҗбүр итмәгез. Сез янымда булсагыз, миңа шул җитә. Бераз вакытка булса да.

Алинә Гамирга тагы сынап карады. Аллага тапшырды, бу кеше начар уйлыга охшамаган. Бәлки, ул аңа ярдәм итә алыр.

– Беләсезме, бөтен эш тә шунда шул. Мин сезгә үзем турында бернәрсә дә сөйли алмыйм, чөнки мин үземнең кем икәнемне үзем дә белмим. Мин Рита түгел.

Гамир бернәрсә аңламады. Ничек инде Рита түгел? Кем алайса?

– Ничек инде белмисез?

– Мин үземнең кем икәнемне, кайда торганымны, исемемне, фамилиямне – берсен дә белмим. Кайчандыр мин кемдер булганмындыр – ә хәзер мин беркем түгел. Мин хәтеремне югалттым. Әллә югалтканмын – мин инде үзем дә буталдым.

Алинә үзе белән булган хәлләрне сөйләп бирде. Аның бөтен тарихы үзе хәтерләгән өч-дүрт көнгә сыйды – ләкин нинди тарих иде бу?!

– Күрәсезме инде, сез миннән бәхетлерәк – сезнең сагынып сөйләргә истәлекләрегез бар, ә минем үткәнем – караңгы төн кебек, киләчәгем томанлы. Шуңа да мин сезгә баштан ук сөйләргә батырчылык итмәдем. Хәзер дә куркам – теләсәгез, сез мине кол итеп тә сата аласыз бит.

Гамир дәшмәде. Дәшмичә бик озак утырды. Һәрхәлдә, Алинәгә шулай тоелды. Егетнең нәрсә уйлавын белү мөмкин түгел – күзләрен түбән төшергән, йөзе тораташтай катып калган. Ниһаять, ул Алинәгә борылды.

– Әгәр чыгып китсәгез, кая барыр идегез?

Бу юлы Алинә тынып калды. Кая барсын инде ул?

– Сезнең барыр урыныгыз юк. Шулай да, әгәр кайчан да булса чыгып китсәгез, үзегез турында беркемгә сөйләмәгез. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанмагыз. Сезгә үзегездән башка беркем ярдәм итә алмый. Бәлки, кайчан да булса барысын да исегезгә төшерерсез – ләкин моны бары үзегез генә эшли аласыз. Сезгә ярдәм итә торган бер генә табиб бар – ул да булса вакыт. Вакыт кына дәвалый алыр сезне.

– Әгәр ул вакыт дәвасы ун елга, утыз елга сузылса? Әгәр мин аны көтеп җиткерә алмасам?

– Димәк, сезгә яңа тормыш башларга кала дигән сүз. Әлегә сезнең күңелдә туганнарыгызга ышаныч бар, шулай бит? Сез хәтерли алмасагыз, бәлки, алар сезне эзли чыкканнардыр. Менә шул ышаныч сүнгән мизгелдән алып, сез яңа тормыш башларга тиеш буласыз.

– Нишләп әле сез шулай катгый сөйлисез? Сез табибмы әллә?

– Юк, профессия буенча мин табиб түгел. Ләкин тормыш дигән «әфәнде» мине күп нәрсәләргә өйрәтте. Мин кабатлап әйтәм: сезгә бернинди начарлык эшләмәячәкмен.

Гамир, тавышының кырыс тонга күчүен сизеп, уңайсызланып калды. Юк, кырыслыктан түгел иде бу – бик тә җаваплы берәр эш алдыннан Гамир шулай кырысланган шикелле була. Бөтен энергиясен бер йодрыкка җыеп, алга сикерергә әзерләнгән барс шикелле, йомыла, кечерәя, көч туплый. Ул инде эченнән кызга булышу юлларын эзли башлады – хәтерендә таныш-белешләрен барлады, нәрсә эшләргә кирәклеген, план төзегән шикелле, билгеләп куйды. Әлбәттә, күп нәрсәРитаның үзеннән тора.

– Рита, мин сезгә якыннарыгызны табарга булышырмын. Миңа кайбер нәрсәләрне ачыкларга кирәк булачак. Әйтегез әле, сез «юл буеннан йөгердем» дидегез. «Урманга җитә яздым» дисез. Димәк, шәһәр читенә чыгып йөгергәнсез. Кайсы юл буеннан, дөресрәге, шәһәрнең кайсы ягыннан йөгердегез икән?

– Белмим. Миңа калса, хастаханә дә шул ук юл буенда диярлек иде. Әйе... анда тагын мәчет күзгә чалынды.

– Һ-мм. РКБ тирәсе булуы мөмкин. Күрдегезме, инде бу үзе күп нәрсә турында сөйли. Ә теге сезне хастаханәгә илткән ир-атны таныр идегезме? Машинасы нинди иде, хәтерләмисезме?

Хәтерли Алинә ул ир-атны. Коңгырт-кара күзләр Алинәгә шундый якын итеп карадылар ки, Алинә аларның искиткеч тирәнлегенә кереп баткандай булды. Тик

соңыннан ул ир-ат барыбер Алинәне ташлап китте ич. Каядыр барасым бар, диде. Ә машинасы?

– Күрсәм, таныр идем шикелле. Машинасын белмим, чит ил машинасы икәне истә калган. Салкын җил өргәнен хәтерлим.

– Бәлки, тагы нәрсә булса да хәтерлисездер?

Алинә уйланып тын калды. Күңеленнән әлеге бәхетсез көнгә кайтты, кинофильмдагы кадрларны кире чигергәндәй, үзе белән булган һәр мизгелне хәтеренә төшерергә тырышты. Менә ул соңгы кадр – Алинә йөгерә. Ашыгып, ярсып-ярсып йөгерә.

– Юк... барысы да томанлы. Мин бары бик кызу йөгергәнемне генә хәтерлим. Кешеләр нәрсәдер кычкырдылар хәтта.

– Нәрсә, нәрсә кычкырдылар?

– Белмим...

Әйе, каршыга килгән зур гына гәүдәле хатын-кыз нәрсәдер кычкырды. Кулы белән күрсәтеп, кат-кат кычкырды. Алинәнең күз алдына әлеге хатынның таза йөзе килеп басты. Тавышын хәтерләми, ә менә иреннәре кыймылдыйлар. Кинәт Алинәнең эче жу итеп киткәндәй булды.

– Сумкам! Минем сумкам бар иде. Мин аны төшереп калдырганмын! Әйе, теге хатын миңа шул турыда кычкырды!

– Тынычланыгыз, зинһар. – Гамирга хәзер үк чыгып китәргә җыенгандай талпынган кызны тынычландыруы җиңел булмады. – Бу бик кирәкле деталь, ләкин аңа да ышаныч аз. Сумкагызны тапкан кеше аны шунда ук тиешле җиргә илтеп биргәндер дип уйламыйм. Акчагыз булса бигрәк тә. Мин иртәгә үк сораштыра башлармын.

– Сумкада минем документларым бар иде. Табылган әйберләрне кая илтәләр, милициягәме?

– Рита, сез бигрәк беркатлы инде. Әйтәм бит, ышаныч аз, дип.

– Сез юри мине тоткарларга тырышасыз! Мин иртәгә үк үзем эзли чыгам! Минем сезнең белән бу йортта торырга исәбем юк!

Гамир дәшмәде. Нишлисең, дөрес сүзгә җавап юк. УлРитаның монда озаккарак калуын тели. Шул ук вакытта аңа чын күңелдән ярдәм итәргә әзер.

Алинә дә, ярсыганын сизеп, беркадәр уңайсызлана калды. Үзеңә ярдәм итәм дип торган кешегә болай кычкырырга ярамый. Нишлисең, тизрәк үзенең кем икәнен ачыклау шатлыгы кызны дулкынландырды, күңелендә өмет уятты.

– Гафу итегез, зинһар... беләсезме, миңа бик авыр. Нәрсә эшләргә, кая барып бәрелергә белмим. Коточкыч хәл бу, аңлыйсызмы?!

Кызның зур күзләре томанланды, кызгылт шәүләләр икешәргә аерылып дерелди башладылар.

– Рита... Еламагыз, үтенәм сездән! Сез ялгыз түгел хәзер, бергәләп ничек тә җаен табарбыз.

Озын керфекләр, яшь тамчыларының авырлыгын күтәрә алмый, сыгылып килделәр. Егет, кайнарланып, кызның дерелдәгән кулларыннан алды.

– Рита, елама... Елама, зинһар. Миңа да синең ярдәмең кирәк... Бик кирәк!

– Гамир... Мин бик куркам! Башта мин нәрсә булганны аңламадым диярлек. Ә аннан соң... мин... минем хәтта үләсем килде... Беләсеңме, бу дөньяда япа-ялгыз, урынҗирсез, исемсез калдым бит! Акылдан язам дип торам. Кайчакта хәтеремә ниндидер вакыйгалар, сурәтләр килеп төшә, тик берсенең дә ни башы, ни азагы юк. Коточкыч! Әгәр мин беркайчан да терелә алмасам?! Нишләрмен мин, нишләрмен?!

– Рита, мин сине бик яхшы аңлыйм. Әни белән сеңлем үлгәч, мин дә япа-ялгыз калдым. Мин аларны беркайчан да кайтара алмаячакмын. Мин мәңгегә ялгыз. Ә синең хәл башкача, син үткән тормышыңны бөтенләй югалтмагансың. Тик әлегә син бик хәлсез, үз-үзеңне кулда тота алмыйсың. Менә күрерсең, бераз вакыттан соң тынычланырсың, уйларың да тәртипкә килер. Шунда инде киләчәк тормышыңны хәл итәрсең.

– Миннән гел документ сорадылар, ә минем бернинди документым юк, аңлыйсыңмы?! Әйтерсең мин бөтенләй кеше дә түгел! Мин хәтта эшкә дә урнаша алмаячакмын. Үземә ничә яшь икәнен дә, хәтта бүген нинди көн икәнен дә белмим бит!

– Рита, кадерлем, мин сиңа ярдәм итәргә әзер. Беләм, ышанып бетмисең, тик ант итәм: миңа синнән бернәрсә дә кирәкми – наз да, иркә дә, мәхәббәт тә – ишетәсеңме?! Мин сине сеңлем дип кабул итәм һәм мондый горур, гүзәл сеңлем табылуга бик шатмын! Ә син? Теләр идеңме минем шикелле абыең булуын?! Әллә миңа мондый кырынмаган бандит кирәкми дисеңме?! Сеңелләр бик усал булалар алар!

Алинә, Гамирның тавышында шаян төсмерләр сизеп, яшь аралаш елмаерга тырышты. Ирен читләре тартышып куйды, бераздан, чыннан да, йөзенә елмаю галәмәте чыкты.

– Гамир, мин сиңа тормышым белән бурычлы. Әгәр син очрамаган булсаң...

– Ю-ук, тик күңелсез вакыйгаларны искә төшерергә генә кирәкми! Беләсеңме, миңа бер аксакал тау карты нәрсә дигән иде? «Син монда, димәк, син башка урында булмаганга күрә монда» диде. Нинди акыллы сүзләр, ә?! Кем әйткән бит әле аны!

Гамир кычкырып көлеп җибәрде. Әйтерсең шүрәлеләр кытыклап тора үзен – шундый ялкынлы, ымсындырып көлә – күзләреннән очкыннар чәчри. Әйе, сеңлесе белән бик якын булганнардыр болар – стенада да шундый очкынлы елмаюлы сурәт балкый бит... Алинә Гамирга ияреп яшь аркылы елмайганын сизми дә калды...

* * *

...Йорт ишегалды балалар тавышыннан яңгырап тора. Төрле яшьләрдәге эреле-ваклы малай-шалайлар, кыз-кыркыннар бер-берсе белән йөгерешәләр, куышалар, кычкырышалар, елашалар. Ара-тирә өлкәннәр тавышы ишетелеп китә. Соңгы арада көннәр шактый кызу тора, берничә тапкыр күкрәүле-яшенле яңгыр явып китте. Бу вакытта Алинә сәер тойгылар кичерде: өерелеп, тузан-туфрак күтәреп, җилнең кузгалуы да, биткә китереп бәргән эре тамчылар да, сулыш юлларын ярып кергән яңгыр исе дә – барысы да әйтеп бетергесез якын, бик якын иде. Алинә упкын алдында торган кеше сыман, менә искә төшерәм, менә искә төшерәм дип, үз-үзен газаплады, балкон тәрәзәсеннән очып китәрдәй булып талпынды, каядыр чыгып йөгерәсе килде. Ләкин могҗиза булмады: Алинәнең үткәне элек ничек булса, шулай томанлы килеш кала бирде. Аның бу өйдә яшәвенә инде ике атнадан артык вакыт үтте. Аяк-кулларындагы зәңгәрләнеп кан сауган урыннар саркып юкка чыкты, тәне дә, үзе дә беркадәр сәламәтләнеп, тынычланып китте. Тик күңел ярасы гына тынгы бирми иде. Гамир кулыннан килгәнчә ярдәм итә кебек; һәрхәлдә, эштән кайткач, һәр кичне Алинәгә кайларда булганын, кемнәрдән сорашканын – барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирә, сүзләрен раслаучы язулар күрсәтә. Ләкин аларның берсе дә әлегә Алинә язмышын ачыкларга ярдәм итмәде. Ике тапкыр инде Гамир табиб алып килде. Беренчесе – алтын кысалы күзлек кигән, үз дәрәҗәсен белеп кенә сөйләшүче табибә Алинәнең авызын ачтырып, тешләрен барлап чыкты, чишендереп йөрәген тыңлады, хатын-кыз мәсьәләләрен сораштырды, кирәкле анализлар алды. Ахырдан «Сау-сәламәт» дигән диагнозын ишек артында көтеп торган Гамирга җиткерде. Алинәнең моңа исе китмәде. Сәламәт икәнен

ул үзе дә белә. Тик табибә Гамир белән пышылдашканнан соң, Алинәне тетрәндергән яңалык әйтте. «Беләсезме, туташ, – диде ул, сүзсез генә Алинәгә карап торганнан соң, – хәер, сез туташ түгел, сез – ханым. Сез көмәнле булгансыз, бала тапкансыз. Бу турыда белә идегезме?» Алинә тораташтай катып калды. Ничек инде... Ул ана булганмы?! Аның кечкенәсе, бердәнбере, газизе бармы?! Һәм Алинә аны хәтерләмиме? Йа Ходай, булуы мөмкин түгел. Юк, бу дөрес түгел. Алинә, күзләрен тутырып, Гамирга борылды. Нишләсен Гамир, фаҗигале, тетрәнүле әлеге караштан бөрешеп килде. Дөньяның тоткасы булса, кубарырдай булды. Табибәгә әйтергә рөхсәт биргәненә мең тапкыр үкенде, мизгел эчендә мең тәмугны гизеп чыкты. Тик ни генә булмасын, әлеге карашка җавап итеп күзләрен төшермәде, киресенчә, иреннәрен кысып: «Без аны табарбыз. Менә күрерсең», – дип пышылдады. Шул көннән башлап Алинә төннәрен бала елаган тавышка уянып китә торган булды. Икенче табиб тәбәнәк буйлы, тезләре ялтырап чыгып торган чалбардан, үтүкләнмәгән кыска зәңгәр халаттан, пеләш башлы юантык кына бер ир-ат иде. Гамир аны «невропатолог, үзе үк психотерапевт, хөрмәтле профессор» дип таныштырды. Невропатолог шактый озак Алинәнең башыннан үткәннәрен сөйләтте, тозсыз, кабатлаулы сораулар биреп башын әйләндереп бетерде, кечкенә чүкеч белән тез башларына чүкеде, кулларын, аякларын күтәртте, башын як-якка боргалатты, чүгәләтте, торгызды, әледән-әле кан басымын үлчәде, тамырларын тыңлады. Алинәгә баштарак болар кызык тоелса да, соңыннан ачуы килә башлады, киреләнергә уйлаган иде дә, баласы турында исенә төшеп, табибның һәр әмерен тиешенчә үтәргә тырышты. Табиб булгач, ярдәм итми калмас дип уйлады. Тик бу табибның да ярдәме Алинә көткәнчә булмады. Дөрес, табиб Алинәгә эчәргә дип билгеләнгән ниндидер дару рецептлары калдырып китте, «әгәр үзгәреш булмаса, бераз вакыттан гипноз кулланып карарбыз» дигәнрәк киңәш тәкъдим итте. Күрәсең, Гамир әйткәннәр дөрес булып чыга – Алинәгә беркем ярдәм итә алмый. Үзеннән башка. Ничек диде әле Гамир? «Вакыт – иң яхшы табиб». Тик күпме көтәргә кирәк Алинәгә?! Ул монда кул кушырып ятса, аның баласын кем карый, кем үстерә, кемнәр сөяр соң?! Шулай уйлый да хәзер үк чыгып йөгерәсе килә Алинәнең. Ул инде бу турыда күп тапкырлар Гамир белән сөйләште. Гамир аның берүзен генә чыгарып җибәрми, хәер, Алинә үзе дә чыгып китеп әллә ни кыра алмасын акылы белән аңлый. Тик күңеле гел икенчене тәкърарлый. Баласы

турында белгәннән бирле дарусыз йокыга да китә алмый башлады. Ахырда Гамир, кызның газаплануын башка кабул итә алмас дәрәҗәгә җитеп, бүген кичке якта шәһәрне бергә урап кайтырга вәгъдә биргән иде. Шуңа да бүген Алинә кич җиткәнен дүрт күз белән көтә.

Менә ишектә кыңгырау шалтырый. Кем булыр бу? Гамир кайтырга иртәрәк әле. Алинә иңнәренә канат куелгандай йөгерә генә. Кем булсын инде – Камиләттәйнең бу йортта башка күренгәне дә юк; әлбәттә, Гамир кайткан. Үзенә ишек ачкан кызның түземсезләнеп янган күзләрен күреп, Гамир кыенсынып куйды. Юк, бикләп тотмый ул Ританы, тик әлегә кадәр үзе белән алып чыкканы да юк иде. Танышлары аркылы милиция бүлекләрен дә белеште: кызны эзләмиләр. Гамир үзен ике ут арасында калган кеше кебек хис итә – бердән, Ританы югалтасы килми, ә туганнары табылса,Ританың монда калмаячагы көн кебек ачык; икенчедән, кызның газаплануын да күрәсе килми. Баласы турында ишеткәннән бирле, Рита бөтенләй икенче кешегә әйләнде дә куйды. Әлбәттә, Гамир кыз тормышындагы бу фактны яшереп кала алган булыр иде – тик соңыннан Рита аны кичерерме?! Кайчан да булса кызның хәтере яңадан үзенә кайтыр. Нәрсә уйлар ул Гамир турында? Элек кызның күзләре чарасызлыктан сүнгән, өметсезлек аның һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә чагылган кебек иде. Ә хәзер исә Рита урынында тик кенә утырып тора алмый, боргалана, Гамирдан әледән-әле кайда булганы, нәрсә эшләгәне турында сораштыра, җавап таләп итә. Тагын берничә көн – һәм кыз баласын эзләргә үзе чыгып китәчәк. Гамир моны бик яхшы аңлый, шуңа күрә Рита нинди дә булса уйланылмаган адым ясаганчы, аны үзе белән шәһәргә алып чыгуны кулайрак дип тапты.

Алинә, гадәттәгечә, тәмле итеп кичке аш пешергән иде, Гамир юынганда, ул алып кайткан җиләк-җимешләрне юып өстәлгә куйды. Ашаган арада Гамир телестудиядә булуын, югалган кешеләр турында белешмәләр алуын сөйләде.Ританың фотосы телестудиядә юк икәнен әйтте, димәк, аны эзләүчеләр булмаган. Кыз көрсенеп куйды. Нишләп соң әле аны эзләмиләр, ул дөньяда беркемгә дә кирәкми микәнни? Әллә ул да Гамир кебек ятим микән?!

– Беләсеңме, мин нәрсә уйладым, – диде Гамир, кызның күңелсезләнүен күреп, – безгә синең фотоны телевидение аша күрсәтергә кирәк. Син бу шәһәрдә яшәсәң, бәлки, сине танучылар булыр...

Әйе шул. Нишләп бу турыда уйламадылар соң әле алар?

– Алайса, миңа сурәт ясатырга кирәк булачак.

– Бүген соң инде, фотосалонга иртәгә кереп чыгарбыз. Ә-ә, әйе, әйтергә онытып торам, иртәгә мин көне буе өйдә. Шулай булгач, шәһәрне көндез дә әйләнербез.

Кызның шатлыгы йөзенә чыкты. Әйтерсең бүген-иртәгә аның туганнары табылырга тиеш. Әйтерсең ул урамга чыгу белән барысын да исенә төшерәчәк. Аһ, соңыннан күңеле кайтса, бик кыен булыр инде үзенә. Шулай да Гамир кызның кәефен төшерәсе килмәде.

– Ну, киттек алайса?! – диде ул, ашап-эчеп туйганнан соң. – Мин хәзер савытларны юып куям, ә син киенә тор.

Алинә ике кабатлатмады. Тиз генә бүлмәсенә кереп, кием шкафыннан кич кияргә дип әзерләп куйган күлмәген алды, озын чәчләрен тарап, калын толымга үреп куйды. Гамир кызга берничә төрле кием алган булса да, Алинә бүген үзенең күлмәген киясе итте – бәлки, бу күлмәгендә аны берәрсе таныр?! Аннан соң үз күлмәге ничектер якынрак сыман. Бераздан Алинә көзгегә карап торды-торды да толымга үргән чәчләрен киредән сүтте. Юк, ул урамда чәчләрен үреп йөрмәгәндер кебек. Алайса таратты микән? Кыз дулкын сыман куе коңгырт-кара чәчләрен аркасына сипте. Юк, болай иткәч, ничектер бик вульгарлаша кебек. Бу кыяфәттә аны танымаслар. Ахырда, бер үреп, бер сүтеп тәмам гаҗиз булганнан соң, чигә чәчләрен артка җибәреп кечерәк толымга үреп куйды да калганнарын туздырды. Булды бугай. Тик барыбер Алинә нәрсәдер җитмәгәнен сизеп, көзгегә кат-кат каранды. Әлбәттә, хатын-кыз беркайчан да урамга сумкасыз чыкмый инде. Аның сумкасы юк шул. Их, табылса иде ул сумка...

Гамир каршысына чыгып баскан кызга беркадәр гаҗәпләнеп карады. Ританы өй халатыннан күреп өйрәнгәнгәме, әллә аны тәмам сеңлесе итеп күзаллагангамы, мондый кисәк үзгәрешне көтмәгән иде. Бит урталары кызарып киткән, коңгырт чәч көлтәсен аркасына салган бу сылу кызның түземсезләнеп елмаюыннан Гамир читенсенеп китте, күңелендә ниндидер ят тойгының баш калкытуын сиземләде. «Юк, – диде ул шунда ук бу яңа хискә, – юк, юк, юк. Ул минем сеңлем. Сеңлем!»

...Менә машина әкрен генә шәһәр читеннән бара. Алинә иреннәрен кыскан хәлдә бик җентекләп тирә-юньне күзәтә. Кояш офыктан дүрт бармак биеклеге генә өстәрәк, әледән-әле биек йортлар, агачлар артында югалып тора да тагы күзгә күренеп ала, еракгагы урман башларын алтынсу төскә манчый; юл читендәге иген басуы бер караңгыланып китә, бер ямь-яшел төсе белән күзләрне чагылдыра.

– Гамир, шушында туктале, зинһар.

Машинадан чыгуга, Алинә ерактагы урманны күздән кичерде, тирә-ягына каранды.

– Әйе, һичнинди шик юк. – Кыз бик җитди иде, тавышында тимер ныклыгы чыңлап китте. – Мин шушы юл буенча йөгердем. Кайдадыр шушы тирәдә егылдым. Димәк, мине шушы урыннан кире шәһәр эченә алып киттеләр. Безгә борылып шәһәргә керергә кирәк. Анда юл тирәсендә генә хастаханә булырга тиеш, ир-ат мине шунда калдырды. Хастаханәдә мине журналга теркәделәр, димәк, без ул язуларны таба алабыз.

Гамир кызның ихтыяр көченә, үз-үзен тотышына таң калды. Ул аны йә шатланыр, йә, киресенчә, елый башлар дип көткән иде, ә кыз исә, гадәти хатын-кыз законнарына каршы килеп, ныклык күрсәтә. Әйтерсең чит бер кешенең чуалган язмыш йомгагын сүтә. Тик Гамир тәҗрибәлерәк шул, юкка гына тормыш мәктәбе узмаган.

– Рита, синең бу урынны хәтерләвең бик әйбәт. Безгә нәкъ шушы урыннан эзли башларга кирәк булыр. Тик ахырга таба түгел, ә алга таба эзләргә кирәк. Аңлыйсыңмы? Әгәр без ахырга таба эзләсәк, шушы мизгелдә басып торган урынга килеп чыгачакбыз. Һәм бу безгә синең үткәнең турында бернинди мәгълүмат бирмәячәк.

Кыз, моңсуланып, урман өстендә уйнаган кояш нурларына карап тора иде, борылып Гамирга текәлде. Уйчан күзләрендә үҗәтлек чагылып китте, тик озакка түгел.

– Әйе шул, син дөрес әйтәсең. Эскерттән энә эзләгән кебек булып чыга инде бу. Мин бит алга таба берни хәтерләмим.

– Ә син тырышып кара. Шәһәргә кергәч, бераз җәяү барырбыз. Бәлки, таныш йортлар, урамнар очрар? Бәлки, нәрсә булса да исеңә төшәр?..

...Таныш йортлар, таныш урамнар... Менә ул йортлар, урамнар, кибетләр, трамвайлар, автобуслар, кешеләр – тик берсе дә таныш түгел. Берсендә дә Алинә үзенең үткәнен чамалый алмый. Бара-бара аяклары арыды инде, узгынчыларның йөзләренә текәлеп карап, күзләре алҗыды, тик күңелендәге үҗәтлеге барыбер кимемәде. Киресенчә, эңгер-меңгер төшеп, күз бәйләнү белән, Гамирны иртәгә шушында ук килергә ризалаштырып куйды. Машина ерак калган иде, шуңа Гамир аңа кадәр трамвайда барырга тәкъдим итте. Трамвай исә көтмәгәндә Алинәнең күңелен кытыклап куйды: шыгыр-шыгыр килеп, аһ-ваһлап баруымы, мичкәдәге балыклар сыман тыгызланган кешеләрдән аңкыган тир исеме – һичшиксез, нәрсәдер таныш иде. Нәрсә икәнен Алинә аңлый алмады. Әйтерсең

аның үткәне белән бүгенгесен нindидер күзгә күренмәс пәрдә, бик юка җеп аерып тора. Менә шул пәрдәне селтәп төшерсә, җепне өзеп атса, үткән тормышы аңа кире кайтачак. Өзгәләнә Алинә, күңеленнән бик ымсына, омтыла, нәрсәнедер селкетәсе, үз урынына урнашсын өчен дөмбердәтәсе килә, тик ахыр чиктә чарасыз булып күңел читендә өметсезлек баш калкыта башлый. Юк, бирелергә ярамый. Әгәр бу хәтер дигәнең чиләк булса, барысы да исенә төшкәнче, урынына утырганчы селкер иде Алинә аны, куллары тыңлаганчы, күз аллары караңгыланганчы берөзлексез селкер иде...

Гамир үз районының күршесендә урнашкан ресторан каршысына килеп туктады. Дөрес, соңгы арада ресторанны «контроль»дә тоткан «лидер» белән беркадәр аралар сүрелеп, хәтта бер-берсенә «сугыш» белән янаулар да булып алган иде. Гамир мондый «селкенеп алулар»га әллә ни зур игътибар итмәсә дә, саклык турында онытмады. Әлеге сәгатьтә әлеге урында аңа куркыныч янамый, югыйсә ул Ританы монда алып килмәс иде. Казандагы «төркемнәр» арасында эреләнү тәмамланып килә, кечкенәрәк, көчсезрәк төркемнәрне «зурлар» күптән йотып бетерделәр диярлек. Гамир төркеме шул диңгез арасында бер ялгыз утрауга охшап калды, чөнки аңарда «дисциплина, тәртип» дигән көч хәрби югарылыкта куелган иде. Әйе, сәясәт аларга да үтеп керде, «лидер»лар, «автор»лар әкрен генә югарыга, властька таба үрмәли башладылар. Гамирны соңгы вакытта шәхси сәүдә борчулары да, үз тормышында булган вакыйгалар да «төркем» эшләреннән беркадәр читләштерде, ничектер яңалыкларны да бик сүлпән кабул итә башлады бугай. Һәрхәлдә, «күрше»ләргә туктавының сәбәбе дә мондагыларга үзенең алардан курыкмавын күрсәтергә бер сылтау гына иде.

Әкрен генә җемелдәгән лампалар яктысында берничә пар бөтерелә. Залны тутырып, сиксәненче еллар көе агыла: әле Юрий Антонов яшьлек язлары турында моңлана, әле София Ротару торналар тавышының сагышын чыңлата, әле төрле инструменталь ансамбль көйләре яңгырый. Әлбәттә, ресторан җырлаучылары үзләре Антонов та, Ротару да түгел, тик бик тә аларга охшарга тырышып, чын күңелдән җырлыйлар. Алинә музыканы бик ярата, өйдә берүзе чакта көне буе музыкаль үзәкне сүндермичә диярлек җырлар тыңлый. Җыр аны юата, кайчакта сагышка күмә, кайчакта исә күңеленә көч бирә. Нинди генә телдә яңгырамасын – татарча да, русча да, инглиз телендә дә – әгәр җырчы йөрәгеннән алып җырлый икән, ул тыңлаучыны битараф калдыра алмый. Дөрес, арада төссез-

тәмсез, иләмсез җырлар да ишетелгәли. Андыйлар Алинәнең күңелен кузгата алмый, бернинди җылы хис тудырмый, киресенчә, ярсыта гына – Алинә тизрәк икенче дулкынга борып куя.

Гамир да рәхәт кенә җыр көенә оеп утыра иде, кинәт залның икенче ягындагы өстәл артында таныш чалымнар күреп сискәнеп китте. Караңгырак почмакта тәмәке төтененә күмелеп, берсе яхшы гына, икенчесе кайтышрак киенгән ике ир-ат серләшә. Гамир сүзнең җитди икәнен шунда ук аңлады: мондый сөйләшүләрдә, гадәттә, чакырыла торган «түтәй»ләр катнашмый, ир-атлар иркен итеп, җәелеп, ләкин бер-берсеннән читкәрәк утырганнар; димәк, сүз күбрәк иреннәр кыймылдавыннан аңлашыла. Иреннәр бик әкрен һәм сирәк, озын паузалар тотып кыймылдыйлар, күрәсең, сөйләшер сүзләре аз, ләкин әһәмиятле. Гамир ир-атларның икесен дә таныды: залга арты белән борылып утырганы Шурик, ә аның алдындагысы – күрше төркем «лидер»ы Раджа иде. Гамир Шурикны бернинди дә «стрелка»га җибәрмәде – ә мондый эшләр төркемдә тик аның аша гына уза. Димәк, Шурик биредә үз йомышы белән. Тик «күрше»ләргә нинди йомышы булырга мөмкин бу вак «алтылык»ның? Бигрәк тә мондый зур даирәдә? Гамир аны эче пошканда гына, дөресрәге, йөрәген ачыттырып, якын кешегә, туганына мохтаҗлык хисе баш калкытканда гына үзенә якынайта иде, еш кына бергә булалар, ләкин бервакытта да аңа җитди эшләр кушканы булмады. Дөрес, Шурикка карата һәрвакыт яхшы мөгаләмәдә булды, берничә тапкыр кыен хәлдән йолып калды. Гамир Шурикны күпмедер дәрәҗәдә туганы итеп кабул итә иде, чөнки бу малайның абыйсы белән сабый чакта бергә уйнап үстеләр, Гамир балалар йортына озатылгач кына юллары аерылды. Шурик сөйләве буенча, абыйсы хәзер Себердә яши, Казанга кайтып күренгәне юк икән. Гамир беркайчан да Шурикка абыйсын белүе турында әйткәне булмады. Кызык. Күрәсең, Шурик та, Раджа да Гамирның мондалыгын абайламаганнар, югыйсә болай җәелеп утырмаслар иде. Бик яхшы. Тизрәк югалырга кирәк.

Ашык-пошык кына Ритадан гафу үтенеп, Гамир өстәлдә аш өчен акча калдырды да чыгышлый ук телефоннан такси чакырды. Такси көткән арада тиз генә үз машинасын каршыдагы ишегалдына кертеп куйды. Алинә берни аңламады. Гамирның үз-үзен тотышы бик сәер, кинәт кенә егет як-ягына карана башлады, ничектер җиргә сеңгәндәй булды, әйтерсең кемнәндер кача. Такси килү белән үк, Алинәне төрткәләп диярлек маши-

нага утыртты, берни дәшмичә, аңлатмыйча, рестораннан чыккан кешеләрне күзәтә башлады. Бераз утырганнан соң «О! Менә нинди ихтирам! Озата чыга, кара син аны!» дип, үзалдына сөйләнеп куйды, такси йөртүчегә рестораннан кузгалып киткән соры төстәге «тугызлы» машинасы артыннан барырга кушты. Бераз калышып, шәһәрне урадылар. «Тугызлы» хуҗасы машинасын төнгелеккә куеп, каршыдагы йортка кереп киткәннән соң гына, Гамир таксисттан үзләрен кире ресторанга илтеп куюын үтенде.

Ниһаять, Гамир үзенең машинасына кереп утыргач, берни дәшми, йомылып утырган Алинәгә карап алды да, кызның сораулы, хәтта бераз үпкәләүле карашын күреп, гадәттәгечә, кычкырып көлеп җибәрде.

– Ох, Рита, гафу ит, зинһар. Менә, минем белән чыксаң, шундый шпион уеннарын уйнап аласың инде. Курыктыңмы бик?

– Курыкмадым дияргә була. Тик сиңа бер сорау бирсәм, төгәл генә җавап бирерсеңме?

– Нинди сорау икән, карап карыйк. Хатыным юк, балаларым юк, кәләшем дә юк. Кызларны тагы нинди сорау кызыксындырырга мөмкин?

– Син һаман шаяртасың, Гамир.

– Елыйммыни соң инде? Бик күңелсез күренештер ул минем кебек буйга җиткән ир-ат еласа, ә? Йә, ярый, үпкәләмә. Алайса, тантаналы төстә вәгъдә бирәм: ни генә сорасаң да, төгәл һәм ачык итеп җавап бирергә әзермен!

Гамир күпме тырышса да, Алинәне елмайта алмады. Кыз кич буе бик җитди иде.

– Гамир... син кем?

Гамир нәкъ менә шундыйрак сорауны көткән иде.

– Без бервакытны бу турыда сөйләшкән идек бит инде. Беләсең ич, мин – кибет хуҗасы.

– Гамир, миңа чын дөресе кирәк.

Әйе, күрәсең, шулай кирәктер – Рита белергә тиеш. Әгәр Гамир аны үзенең сеңлесе дип таный икән, туганыннан моны яшерүнең кирәге юк.

– Ничек кенә аңлатыйм икән... Беләсеңме, Казанда үз-үзләрен кая куярга һәм ничек итеп акча табарга белмәгән яшь-җилкенчәк күп. Төркем-төркем булып оешалар да аерым «эшләр» белән шөгыльләнә башлыйлар. Яшьрәкләр җитди зурлар төркеме – «бригада»ларга буйсына. Араларыннан берәү яки берничә «лидер» шул «бригада»ларны җитәкли. Менә мин шундый бер иптәш булам инде. Кушаматым – Памир.

– Җитәкли торганымы?

– Нәкъ үзе.

– Ә «аерым эшләр» дигәнең ул кешеләрне талаумы инде?

– Ну, син бигрәк тагы. Бәлки, кайчандыр шулай булгандыр, тик заманалар үзгәрде бит. Талый торган төркемнәр дә очрый – тик алары башка. Алар күбесенчә йә яшь-җилкенчәкләрдән, яисә төрмәдә утырып кайткан берничә кешедән тора. Аннан соң хәзер кеше талап кына акча эшләп булмый. Әлбәттә, кемне талыйсың – анысы да бар. Ә кемнеңдер үзен «талатасы» килә – андыйлар да очрый. Хәзер төркемнәр «бизнес» белән шөгыльләнә, күбесенең үз эчендә уртак кибетләре бар, кемдер наркотиклар яисә корал сата, кемдер башкаларга «түбә» ясый – ягъни, бер сүз белән әйткәндә, кем ничек булдыра ала, шулай акча эшли. Беркем дә бу төркемнәргә мәҗбүри кабул ителми – бездә керү-чыгу ирекле. Өметсез наркоманнар, алкоголиклар гына төркемнән мәҗбүри читләштерелә. Эшмәкәрләрнең күбесе шул төркемнәрдән үсеп чыкты да инде. Исән калганнары, әлбәттә.

– Димәк, син – бизнесмен – эшмәкәр?!

– Менә, үзең шунда ук тотып аласың тагы. Бу сүз минем күңелгә ята. Алайса, талау да талау. Безне «дәүләт» дигән эшмәкәр күбрәк талый әле, беләсең килсә...

Алинәнең күз алдында аш өстәле тартмасында яткан төргәк-төргәк акчалар бөтерелгәндәй булды. Әйе, теге вакытта иң беренче чиратта «кеше үтереп тапкан акча» дип уйлады бит ул...

– Гамир, ә синең кеше үтергәнең булдымы?!

– Рита, төркемдәге һәрбер кеше үтерүче дигән сүз түгел, аңлыйсыңмы?! Әгәр кем беләндер исәп-хисапны өзәргә туры килә икән, моны аерым кешеләр башкара, чөнки һәрбер кеше сугыш уены уйнарга сәләтле түгел. Бездә катгый бүленеш бар. Ә миңа килгәндә, әйткән идем бугай – мин Кавказда берничә ел сугыштым, ә сугышка ипи ашарга җибәрмиләр.

– Куркынычтыр ул... сугыш дигән нәрсә.

– Анда курку турында уйларга вакыт калмый. Гадәти хәл инде – әйтик, урам тулы тыз-быз чапкан машиналарга карап торганда, юлны аркылы чыгарга курыккан кебек буласың. Тик шул юлга кергәч, курку бетә, тизрәк каршы якка чыгу теләге генә кала, шулай бит? Менә... сугыш та шуның кебегрәк. Аннан соң сугышка карт бабайларны җибәрмиләр ич – барысы да егерме тирәсендәге яшьләр. Ә кайда яшьләр, шунда уен-көлке.

– Гамир, син гаҗәп кеше.

– Шулай булыр дип уйлаган идем аны.

– Ничек булыр дип?

– Минем турында фикерең үзгәрер дип.

– Юк, минем фикерем үзгәрмәде... дияргә була. Тик барыбер кайбер нәрсәләр аңлашылмый. Мәсәлән, ни өчен син өйдә шуның кадәр күп акча тотасың?

Гамир, Алинәгә карап, бераз моңсурак итеп елмаеп куйды.

– Курыкма, төркем акчасы түгел алар. Төркем акчасы – «общак» – беркайчан да «үле йөк» булып ятмый, ул бизнеска салына. Ә болар... Ничек дип аңлатырга... Беләсеңме, балалар йортында үскәндә минем кулда тотарлык акчам булмады. Акча гынамы соң! Туйганчы ашаганым булмады дисәм дөрес булыр. Кайсыдыр бала бөтенләй ач йөри, чөнки аннан зурраклар, көчлерәкләр талап ала! Син таламасаң, синнән талыйлар. Син кыйнамасаң, сине кыйныйлар. Мине хәзер дә кайбер зур җитәкчеләрнең балалар йортына торт белән берничә уенчык күтәреп килүләре ярсыта. Комедия! Бер йөз кило тавык ите китереп, күз алдында пешерттереп, балаларга туйганчы ашатсалар, аларга гомергә онытылмаслык бәйрәм булыр иде!

Гамирның тавышы күтәрелде, руль тоткан кулының бармаклары агарып китте, ярсынып, рульне бәргәли башладылар... Алинә акча турында сүз кузгатканына үкенеп куйды.

– Акча дигәннән, мин шул вакытта үз-үземә сүз бирдем: кайчан да булса минем өемдә бер ел кайгысыз яшәрлек акча запасы торачак! Нәкъ менә акчалата! Әлек тә, хәзер дә акча кешегә ирек биргән – моны кайсыдыр бер бөек кеше күптән язып калдырган. Ә без «акча ул – начарлык» дип өйрәндек!

Кызыл утка туктап торган «Ауди», тәгәрмәчләрен чыелдатып, зур тизлек белән кузгалып китте. Алинә Гамирны бу кадәр ярсыган килеш беренче күрә иде, шуңа чынчынлап шүрли башлады. Гамир исә, бер башлагач, тауташны җимереп аккан ташкындай, күңелендәгесен әйтеп бетерергә ашыкты.

– Беләсеңме, парадокс килеп чыга: акчасы юк кеше акча булсын өчен – димәк, ирекле булсын өчен – дөньяның астын-өскә китерергә, үтерергә, җимерергә, таркатырга әзер! Ә акчасы җитәрлек дәрәҗәдә күп булган кеше шул таркаулыктан котылырга омтыла, матурлык, гүзәллек, гаделлек эзли башлый! Чөнки инде ул үзе эшләми, аның акчасы эшли. Син мине эшли дип уйлыйсыңмы?! Юк! Мин – шарлар уйнаткан фокусчы кебек: шарларны бер кулдан икенчесенә күчерәм, һавага чөям – менә инде

шарлар өчәү түгел, ә тугызау! Шуның кебек, акча акчага ята, ә кеше тынычлана, дөньяны икенче югарылыктан өйрәнә башлый. Моны ничек аңларга соң?! Акча булмау яхшымы, әллә аның булуы яхшымы?! Әлбәттә, булуы, диярләр миллионнар. Ләкин ул булсын өчен нәрсәнедер җимерергә кирәк ләбаса! Җимергәнне кемдер яңадан җимерсен өчен торгызырга кирәк! Башка юл юк! Менә сиңа диалектика! Менә сиңа Гегель!

Гамир шаркылдап көлеп җибәрде. Аның бу көлүе һич кенә дә Алинә белгән көлү түгел иде, бераз җүләрләрчә, беркадәр ачынулы, ярсулы – куркыныч көлү иде. Алинә Гамирның бу сүз ташкынын җүнләп аңламады да, тик егет күңеленең авырткан, әрнегән урынына кагылганын гына чамалады. Югыйсә әллә ни сорамады да бит инде...

Берничә минуттан Гамир элекке халәтенә кайтты, Алинәнең утыргычка сеңеп бетеп диярлек утыруын күреп, гаепле елмайды.

– Гафу ит, Рита, сине куркыттым бугай. Шулай инде менә – үткәннәр тынгылык бирми. Шулай булгач, үткәнеңне белмәвең белән син күпмедер дәрәҗәдә бәхетле дә әле...

Калган юлны тын гына, сөйләшмичә кайттылар. Һәркем үз уена чумган иде. Гамирның күз алдыннан Шурикның ялагай елмаюы китмәде. Раджаны белә Гамир, Шурик кебекләр белән чәй эчә торган кеше түгел. Әгәр аралаша икән, димәк, җитди сәбәбе бар. Ләкин нинди?! Иртәгә үк ачыкларга кирәк. Шурикның үзеннән соравы, әлбәттә, вакытны бушка уздыру гына булачак. Егетләрне эшкә җигәргә булыр.

Вакыт соң булуга карамастан, өйгә кайткач та, тиз генә йокларга ятарга ашыкмадылар. Гамир ваннадан юынып чыкканда, Алинә, гадәттәгечә, камин каршында мәҗүси караш белән утка текәлеп утыра иде.

– Гамир, бәлки... мин гел дә бу шәһәрдә яшәмимдер?!

Күрәсең, Алинә һаман бүгенге кичерешләреннән арына алмый. Шәһәргә чыгудан ул күбрәкне көтте, нәрсәгәдер өметләнде, могҗиза булыр кебек тоелды. Нәтиҗәдә исә хәтере кичәге кебек үк буш.

– Нигә алай дисең, Рита?

– Беләсеңме, үземнең балачагымнан, үсмер еллардан кайбер вакыйгаларны хәтерлим бит. Мин авылда яшәдем. Минем әбием бар иде. Аны да хәтерлим. Әтиемне дә төсмерлим сыман. Тик кайсы авылда, кайда яшәгәнемне һич хәтерли алмыйм.

Алинәнең тавышы калтыранып чыкты. Ничек юатырга бу кызны? Кирәкме икән аңа юату сүзләре?

– Ә бу йортлар, урамнар миңа һич таныш түгел. Әгәр мин монда яшәгән булсам, мин аларны таныр идем, шулай бит? Һич булмаса, нәрсәдер искә төшәр иде, мин бу кибетләргә кергәнмендер, бу юллар буйлап йөргәнмендер, алар миңа нәрсә дә булса сөйләргә тиешләр, шулай бит? Шулаймы?

Гамир Алинә янәшәсендәге кәнәфигә утырды. Мең тапкыр юатты инде ул кызны, файдасы юк. Тик Гамирга мең дә беренче тапкыр да юату сүзләре табуы кыен түгел.

– Рита, син ашыгасың. Беләсеңме, синең авыруың, бәлки, мизгел эчендә барлыкка килгәндер, ләкин теләсә кайсы авыруны дәвалау вакыт таләп итә. Ә синеке кебеге бигрәк тә. Зинһар, дип әйтәм, үзеңне болай газаплама. Бер авыртуны тагы да көчлерәк авырту белән басып була, ләкин аңардан котылып булмый. Бераз уйларыңнан тыелып тор, баш миең ял итсен, нервларың тынычлансын. Менә син инде ничәмә-ничә көннәр үткәнең турында уйлыйсың, минут саен, секунд саен нәрсәдер искә төшерергә тырышасың. Нәтиҗәсе бармы? Юк. Шулай бит? Димәк, синең бу тырышуларың ярдәм итми.

– Нишлим соң? Мин бит кеше, мин уйлый торган итеп яратылган зат – уйламый яши алмыйм. Син дә уйламыйча гына яшәмисеңдер.

– Минем хәл башкачарак. Ә сиңа икенче төрле эшләп карарга кирәк.

– Ничек инде – икенче төрле?

– Әгәр уйлау ярдәм итми икән, уйламыйча кара. Бәлки, уйламау ярдәм итәр.

– Син тагы көләсеңме?

– Рита, мин чынлап сөйлим. Әйдә, болай эшлибез. Син ике атна буена үткәнең турында уйламаска вәгъдә бир. Әгәр мондый уйлар башыңа килә икән – шунда ук икенче әйбер турында уйла, теләсә нәрсә турында, тик үткәнең турында гына түгел.

– Нәрсә турында гына уйлый алам соң мин? Минем көнем үткәнемне эзләп үтә – аш пешерсәм дә, кер юсам да, җыештырсам да – мин гел узган тормышым, югалган балам турында гына уйлый алам. Минем бүгенгем дә юк ич, ә киләчәк турында уйларга куркам!

– Рита, үткән белән яшәгән кеше алга таба үсә алмый. Хәтта кешелек җәмгыяте дә ничә гасырлар буе узганга табынып яшәүдән туктаганнан соң гына прогресска ирешкән!

– Юк, моңа мин һич кенә дә ышанмыйм. Узган тарихын белмәгән халык – киләчәксез халык!

Алинә бу сүзләрне әйтте дә тотлыгып калды. Баш

миендә нәрсәдер кымшанып куйгандай булды, чәч араларыннан, йөгереп, кырмыска үтте... Тик мизгел үтүгә, тойгы ничек барлыкка килгән булса, шулай ук югалды да. Кызып бәхәс куерткан Гамир Алинәнең бу халәтен сизмәде.

– Ә мин белмәскә димим ич, тик узганнан культ ясарга ярамый. Узганга таянып кына бүгенге көнне дә, киләчәкне дә корып булмый дип әйтәм. Әгәр югалып калырга теләмисең икән – киләчәккә карап яшә, планнар кор, максат билгелә – яшәргә кирәк, Рита! Мин башка синең берүзеңне генә өйдә калдырмаячакмын. Теләсәң, берәр җиргә ял итәргә барырга була!

Алинә ачынып көлемсерәде. Ял итәргә, имеш... Ә Гамир исә кинәт башына килгән бу фикергә үзе дә гаҗәпләнде. Чыннан да, аның күптән инде диңгез буенда булганы юк. Әгәр Рита белән бер-ике атнага, әйтик, Кара диңгез буена сәяхәт итсә, ничек булыр? Бик әйбәт булыр. Мондагы эшләрне генә җайларга да китеп барырга. Хәзер җәйнең кызу көннәре башланды, күпләр болай да ял итәргә әзерләнә. Бу турыда чынлап та уйларга кирәк.

– Рита, бу бик яхшы фикер. Мин дә бераз ял итәр идем, син дә онытылып торыр идең. Чынлап та, әйдә берәр җиргә – әйтик, диңгез буена барып кайтабыз, ә? Әллә чит илгә чыгабызмы?

Алинә беркадәр вакытка тынып калды, гадәттәгечә, сынаулы карашын Гамирга төбәде. Бу ир-атка ышанып җир читенә чыгып китәргәме? Әгәр алдаса? Әгәр ташлап калдырса яисә тагы да яманрак бер-бер начарлык күрсәтсә? Күңел читендә ниндидер ятсыну хисе кымшанып куйды. Ул бит Алинәгә беркем дә түгел... Шулай да Алинә үз гомерен аңа ышанып тапшырды ич инде. Хәзер нәрсә дә булса үзгәртүнең кирәге бармы икән?

– Гамир, син бу турыда шундый җиңел сөйлисең, әйтерсең диңгезгә бару ипи кибетенә чыгып керү кебек кенә. Алай гына түгелдер инде.

– Ә нәрсә кирәк безгә? Самолетка утырабыз да очабыз, иртәгә диңгездә коеначакбыз, – диде Гамир, көлеп.

– Минем бернинди документым юк лабаса, оныттыңмыни?

Гамир уйга калды.

– Әйе шул. Бу турыда уйламаганмын. Чит илгә чыгып булмаячак. Самолетка ярардай документ әзерләү кыенрак инде ул. Поезд шактый озак бара, аннан соң юлда да күңелсез. Теләсәң, машинада барырга була.

– Машинада?!

– Ә нигә? Бик күп кешеләр диңгезгә шулай баралар. Юлда очраган шәһәрләрне карарбыз.

– Белмим шул... Әллә ничек, кинәт кенә җавап бирүе кыен.

– Ярар алайса, уйла да иртән җавап бирерсең. Әгәр ризалашсаң, планнар үзгәрә – мин иртәгә үк барлык эшләрне, карап чыгып, тиешле кешеләргә тапшырам. Хәзер соң инде, әйдә, йокларга ятыйк.

– Хәерле төннәр, Гамир.

– Тыныч йокы, Рита.

Гамир идәнгә кабартмалы түшәген җәя калды, Алинә исә йокы бүлмәсенә кереп бикләнде. Йомшак юрган астына чумгач та, кызның күзенә йокы эленмәде. Гадәттәгечә, хәтерен кайтарырга теләп, күзләрен авыртканчы кысып-кысып йомгалады, уч төбе белән чигәләрен ышкыды, уе белән кабат-кабат үткәнгә әйләнеп кайтырга теләде. Тик сукыр кеше кебек нindидер тоташ караңгы соргылт диварга гына төртелде. Юк, кайтмаячак, күрәсең, хәтере. Болай җәфаланудан ни файда. Дөрес әйтә Гамир, әгәр уйлау ярдәм итми икән, уйламыйча карарга кирәк. Уйламаска. Үрелеп, өстәл лампасын кабызды, тартмадан йокы даруы алды, озын муенлы нәфис пыяла вазадан су салып эчеп җибәрде. Уйламаска. Яңадан юрганына төренеп йокларга ятты. Уйламаска. Чалкан яткан җиреннән уң якка борылды, бераз кыбырсынгач, сул якка авышты. Уйламаска, уйламаска, уйламаска... бераздан, ачу белән юрганын ыргытып, яңадан торып утырды. Йа Ходa, ничек соң уйламыйча гына йокыга китәргә?! Мөмкинмени бу?! Мөмкин. Шулай кирәк. Тагы төренеп ятты. Эченнән генә «у-у-й-ла-а-маас-ка-а» дип, бишек җыры көйли башлады. У-у-й-ла-а-маас-ка-а... У-у-й-ла-а-маас-ка-а... а-аа-а... Менә кулында нindидер озынча төргәк... Ачып караса, аяк-куллары белән тыпырчынып, яшь бала елмаеп ята... Менә сүтелеп төшеп тә китте, кай арада җиргә басып, Алинәнең кулыннан җитәкләде дә соргылт дивар янына алып килде. «Әни, мин әти янына чыгам, ә син?!» Алинә җавап кайтарырга тели, тик авызы, ярга ташланган балыкныкы кебек, ачыла да йомыла, тавышы чыкмый... Бала исә үрмәләп диварга менеп тә китте, бөтенләй күздән югалды. Алинә бала артыннан үрмәли, тик менеп җитә алмый, шуа да төшә, шуа да төшә... куллары канап бетте... Ә бала инде диварның икенче ягыннан «Әни! Әни!..» дип кычкыра... «Әни! Әти дә монда, әйдә, чык инде!»...

* * *

Әкияттәге серле йомгак кебек,
Ник чуалды болай язмышлар?!
Гомер китабының һәр битендә
Ятлар белми торган сагыш бар...
Адаштыммы әллә сукмак эзләп,
Ник яктыра әле бу таңым?
Риза идем мәңге караңгыга,
Чыгып киләм Җиргә мин тагын...

*Өченче кисәк*

## Шурик

Шурик яткан җиреннән рәхәт итеп озаклап киерелде. Бүген ял көне, торып, каядыр чыгып чабасы юк. Дөресен генә әйткәндә, болай да иртәләрен бик еш чыгып чапмый ул, ләкин бүген барыбер хәл башка төрлерәк. Бүген кояш ягымлы елмая, бүген бүлмәсе дә яктырак, бүген... Шурик үзалдына елмаеп куйды. Әйе, көтмәгәндә-уйламаганда күктән аңа бәхет иңде. Дөресрәге, иңәчәк. Барыбер түгелмени – беренче адым ясалган, сөйләшенгән, килешенгән. Бераз көтәсе генә калды. Шурикның түземлеге җитәрлек, болай да бик озак көтте инде ул, калганын гына көтеп җиткерә алыр. Егет рәхәтләнеп күзләрен йомды. Менә тәрәзәләре дә, үзе дә кап-кара ялтырап торган затлы машина... Нинди марка икән? «Мерседес»? «Линкольн»? Машинадан төсен-төскә китереп зәвыклы киенгән Шурик чыгып килә... Юк, Шурик түгел – Александр Михайлович. Тузанланмаганмы дип, ялтыравыклы кап-кара ботинка башларына күз төшереп ала... Ул керүгә, ресторан ишекләрен ачык тоткан кызыл формалы мыеклы швейцар карт иелә-бөгелә киң елмая: «Хәерле кич, Александр Михайлович! Рәхим итегез, Александр Михайлович!» Шурик җавап бирмичә генә эчкә уза. Менә аны киенгән-ясанган яшь чибәркәйләр уратып ала... Шурик аларга да игътибар итми, түргә – пыяла өстәл артында утыручы кара костюмлы ир-ат янына уза. Кем бу? Шәһәр башлыгымы? Әллә... президент?!

Шурик, арттырганын үзе дә сизеп, тагы киерелеп куйды. Ә нигә... Белмәссең. Бәлки, президент белән дә очрашыр әле. Хәзер акчалы кешегә һәр якка керү юлы җәелгән. Ә Шурикның тиздән акчасы бик күп булачак. Дөрес, башлангыч капиталны берәр уңайлы, табышлы сәүдәгә саласы булыр, ләкин, әйтелгәнчә, Шурикның

түземлеге җитәрлек. Иң әһәмиятлесе – башлангыч капитал булсын.

Шурик эченнән санап «өч!» диюгә сикереп торды, кухняга чыкты. Сеңлесе таба чыжлата.

– Ә-ә, тордыңмыни, йокы чүлмәге, – диде ул, ваемсыз гына. – Әни кичә сине «соң кайтты» диде, тагы теге сөйрәлчек белән буталгансыңдыр инде, шулаймы?

Сеңлесе класскташ кызының Шурик белән аралашуын өнәми, шуңа күрә төртмәләнә. Әмма бүген Шурик, гадәттәгечә, кычкырынмады, плитә янында торган сеңлесенә арттан якынлашып, көтмәгәндә кытыклый башлады. Кыз, аһ-ваһ килеп, кычкырып җибәрде, табасын кулыннан ычкындырып, Шурикка аш сөлгесе белән чәпәде. Шурик көлә-көлә ваннага юынырга кереп китте.

Иртәнге чәйне эчкәндә дә төрле мәзәкләр сөйләп сеңлесен көлдереп бетерде. Шурикның болай шат күңелле вакыты сирәк булганга, Ксюша башта сагаеп калган иде, соңыннан исә үзе дә сизмәстән абыйсының шаяртуларына шундый ук шаярту белән җавап бирә башлады. Көтмәгәндә Шурик җитдиләнеп китте, һәм кызның күзләренә туп-туры карап:

– Йә, Раджа белән мөнәсәбәтләр ничек? – дип сорады.

Сеңлесе аһ! итте. Әлбәттә, Раджа белән очрашуы хакында кайчан да булса Шурикның беләсе көн кебек ачык иде, ләкин бу кадәр тиз түгел ич инде. Раджа – күрше төркем лидеры, андый егет белән теләсә кемнең чуала алмаганын Ксюша бик яхшы аңлый. Шурик каян белгән соң әле аны?

– Нинди Раджа белән?

– Йә, кыланма инде. Молодец, шундый егетне эләктерә алгансың. Һәркемнең дә кулыннан килә торган эш түгел. Хуплыйм.

– Ә син каян беләсең?

– Һе, абыең бөтен нәрсәне дә белә ул.

Ксюша, ни әйтергә белми, тотлыгып калды. Күрәсең, абыйсына җиткергәннәр. Аларны бергә күрүче дә булмады кебек югыйсә...

– Ну, без бит болай гына... Берничә тапкыр очраштык шунда.

– Шулай дәвам ит. Бик яхшы кандидатура, тик ычкындырма гына. Үзеңә бәйли алсаң, бигрәк тә әйбәт.

– Туктале, сез бит... э-э... бик дус түгел, ахрысы. Мин сине хупламассың дип уйлаган идем, хәтта син белсәң, дуларсың дип курыккан да идем.

– Дөнья бу, сеңлем, ач күзеңне.

– Раджа әйбәт егет... Акча да кызганмый. Артык

бәйләнми дә үзе. Тик сиңа... э-э... дусларың ничек карарлар соң?

– Бусы минем проблема. Йә, ярар, әни кайчан кайтам диде?

– Гадәттәгечәдер, сорамадым. Бик соңга калма инде, соңгы арада әнинең кәефе юк, авырып тора.

– Озакламый барысы да үзгәрер, менә күрерсең.

Сеңлесенең сораулы карашына серле кыяфәт белән күз кысып, Шурик балконга чыгып басты, тәмәке төтәтә башлады. Бүген Памир янына барасы булыр. Кичә Раджа аңа бик төпле киңәшләр бирде: «воркуннар»[1] һәр җирдә, безнең очрашканны барыбер күрерләр, тиешле кешегә җиткерерләр, диде. Син аңа кадәр үзең ирештер, черки борын тыга алмаслык булсын, диде. «Академик»[2] шул Раджа. Шурик Памирга нәрсәләр әйтәсен сүзен-сүзгә алдан уйлап куярга теләгән иде, тик әллә күңеле очынганга, әллә, гомумән, аңа алдан уйлау дигән әйбер ят булганга, башына бер юньле фикер килмәде. Памирның үтәли күрә торган күзләрен җиңел генә алдармын димә. Шулай да тәвәккәлләргә кирәк булыр – ятып калганчы атып калуың хәерлерәк.

Юыну бүлмәсенә кереп, башын яңадан салкын су белән чылатып чыккач, Шурик Памирның кесә телефоны номерын җыйды.

– Шурик, синме? Ни кирәк? – Тавышына караганда, Памирның, күрәсең, кәефе бер дә Шурикныкы кебек күтәренке түгел.

– Очрашасы иде, Памир. Син белергә тиешле информация бар.

Гамир исә Шурикның тавышында ниндидер борчылу сизде. Кем-кем, ә Гамир күпне күргән кеше. Ул инде үзенең егетләренә Шурикны «көтәргә»[3] кушты, тиешле кешеләр тәрәзә төбендә аның чыкканын сагалап утыралардыр. Нәрсә, шуларны сизгән мәллә?

– Нәрсә булды? Ашыгыч түгелдер бит, офиска килгәнне көт.

– Үзеңә генә әйтәсе информация бар иде, Памир. Алайса, мин сине офиста көтәрмен.

– Ярар, ярты сәгатьтән килеп җитәм, анда бул.

Гамир Шурикның «информация» сүзенә басым ясап, кабатлап әйтүенә игътибар итте. Кичәге очрашу хакын-

---

[1] «Воркун» – әләкче (арго).

[2] «Академик» – берничә тапкыр төрмәдә утырып кайткан «авторитет» (арго).

[3] «Көтәргә» *(рус. «пасти»)* – күзәтергә, сакларга (арго).

да әйтергә телиме икән әллә? Бәлки, Шурик бер дә сатлык түгелдер, Гамир аның турыда кызулык белән генә начар уйлагандыр? Ярар, ачыклар, хәзер Гамир күбрәк алда торган сәяхәт белән мәшгуль иде. Бүген иртән Рита ял итәргә барырга ризалашты, шуңа да җайга саласы эшләре, күрәсе кешеләре бихисап. Җитмәсә, үзенең проблемалары белән Шурик барлыкка килде.

Ярты сәгатьтән килеп җитәм дисә дә, Памир тиз генә бушый алмады. Егетләр Шурикның өйдән чыгып офиска килгәнен, тыныч кына көтеп утырганын җиткерә тордылар. Ниһаять, эшләрен бертөрле җайга салып, офисларына килеп җиткәндә, өч сәгатьтән артык вакыт узган иде инде.

– Йә, нәрсә әйтергә теләгән идең? – диде Памир, бүлмәдә үзләре генә калгач. – Тыңлыйм, сөйлә.

Әллә Памирның бүлмәгә язгы ташкын булып кинәт бәреп керүеннән, әллә кырыс тавышыннан, әллә үзенә төбәлгән үткен карасу-зәңгәр күзләрдән Шурик бер мәлгә телсез калгандай булды, коелып төште. Югыйсә монда утырган вакытта ул инде нәрсәләр әйтәсен алдан уйлап куярга өлгергән иде. Кирәкле мизгелдә бөтен сүзләр җилгә очкандай юк булдылар, Шурик ык-мык килде, күз карашы белән идәнне тишәрдәй булып, аска текәлде, тирләп пеште. Әгәр шушы минутта Памир кичә аны Раджа белән күрүен әйтсә, Шурик ике дә уйламый, бар дөресен сөйләп бирер иде.

– Нәрсә мыгырданасың инде? Әйтәсең булса – әйт, әйтмәсәң – сузма, югал. Болай да эшләрем җитәрлек.

Ниһаять, Шурик аңга килгәндәй булды, күз карашын күтәрде. Памир исә, аның бу кадәр җебегәнлеген күреп, мыскыллы көлемсерәде. Кара инде, кем белән эш йөртмәкче була Раджа.

– Беләсеңме, Памир... Ксюша... Миңа әйтергә дә кыен...

– Нәрсәне әйтергә кыен? Нинди Ксюша?

– Ксюша, минем сеңлем... Рр-раджа белән буталган.

Уф, ниһаять, Шурик җиңел сулап куйды. Памир әлегә бернәрсә аңламаса да, төп фикерне әйтте бугай. Алга таба уйнавы җиңелрәк булыр.

– Ничек буталган? Рәтләп сөйли аласыңмы, юкмы?

– Минем сеңлем бар, Ксюша исемле. Вәт... Раджа, беләсең бит инде, э-э... белмим, ничектер танышканнар, шуннан... йөреп тә киткәннәр. Мин моны белгәч, Ксюшаны өйдән чыгармый тоттым хәтта – елый, яратам, ди... Беләсең бит инде – бездә.. мондый эшләр... ни... хупланмый. Шуннан... Раджа янына бардым. Ансы да... гаҗәп

инде... Ксюшадан беркайчан да... ну, баш тартмыйм, ди... Яратам, ди...

– Кайчан бардың Раджа янына?

– Кичә. Ресторанда очраштык.

Менә нәрсәдә икән эш. Әйе, Ксюшаны белә Гамир. Чибәр, сөйкемле кыз, теләсә кемнең күзе төшәрлек. Тик мәктәп укучысы гына түгелме соң әле ул?

– Нигә миңа башта ук әйтмәдең бу турыда?

– Әйтергә җыенган идем... Синнән очрашу хакында сорадым да әле. Хәтерлисеңме, өченчекөн? Аннан соң... гаилә эше бит, бәлки, болай да узар, дидем.

Әйе, нәрсәдер сорады шул Шурик, хәтерли Гамир. Бу көннәрдә уйлары тулысынча Рита тирәсендә бөтерелгәнгә, игътибарга алмаган иде. Аласы калган икән.

– Ну... Әгәр синнән рөхсәт булмаса, үзең беләсең инде... Тик җәл беркадәр... чыннан да, яраталар, ахры.

Ксюшаның яратуына шикләнми Гамир. Яшьлеге – җүләрлегедер. Тик Раджа иләс-миләс йөрүдән күптән узган кеше. Шунысы сагайта.

– Нәрсә диде Раджа?

– Яратам, ди...

Гамир сүгенмәкче иде дә, тыелып калды.

– Миңа нәрсә дип әйтергә кушты?

– Ә-ә. Әгәр Памир каршы килсә, Ксюша укып бетергәннән соң сеңлең белән башка шәһәргә күченеп китәргә риза, диде.

Гамир, эченнән бәреп чыккан ачуны басып, гаҗәпләнгән булды:

– Нәрсә, Раджа «китәм» дидемени?

– Шулай диде инде...

– Нигә минем янга үзе килмәде?

– Ну... беләсең бит инде. Үзләрендә дә күпләр аңа каршы.

Гамир бер мәлгә уйлана калды. Төркемнәр арасында алыш-биреш уены хупланмый. Андый очраклар йөзгә бер булса да, гадәттә, яшь парларны төркемнән читләштерәләр йә булмаса парлар үзләре үк башка урынга күченеп китәләр иде. Ә үзара конкурентлар булган төркемнәрдән парлар алышу турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Җитмәсә, югары даирәдә. Әйе. Нишләргә соң? Гамир, уйларыннан арынып, Шурикка беркадәр текәлебрәк карады. Күңел түрендә шикләнү бетү түгел, киресенчә, кабарды гына. Күз алдына ресторандагы очрашу күренеше килеп басты. Җәелеп, кунакка килгәндәй утырган Шурик, әкрен генә кыймылдаган иреннәр... Ялганламый микән бу иптәш?

– Сеңлең безнең эшләрне ни дәрәҗәдә белә?

– Ну... минем аңа бернәрсә дә сөйләгәнем юк диярлек. Ул безнең малайлар белән дә аралаша бит... Алар аша берәр нәрсә белсә генә.

– Әйт сеңлеңә: әгәр Раджа белән алга таба да очрашасы килсә, авызын җиде йозакка яхшы бикләсен. Аңладыңмы? Әгәр үзләрен яхшы тоталар икән, нигездә, мин мәхәббәткә каршы түгел. Сөешсеннәр туйганчы. Тик синең урында мин Раджага мәктәп укучысы булган сеңлемне ышанып тапшырмас идем. Бу инде синең үз эшең. Тагы нәрсә? Шушы гынамы?

– Шул гына, Памир.

Шурик киткәннән соң да, Гамир берара уйланып утырды. Әйе, бик матур аңлатты егет кичәге очрашуны, ләкин Гамир Кавказ тауларында сугышып йөргәндә җирле егетләрдән бер әйбергә өйрәнде: кешенең күңелендәме, йөрәгендәме, әллә юкса баш миендәме һәрвакыт сагайта торган, шикләндерә торган бер күзәнәге булырга тиеш. Интуиция дип атыйлар аны галимнәр. Ничә гасырлар буе сугыштан өзелмәгән тау лачыннары әйтте: әгәр синең әнә шул күзәнәгең тиешле вакытта эшкә җигелми икән, син – сугышчы түгел, син – беренче очракка кадәр исән йөрүче мәет. Тере мәет. Андыйлар беркайчан да чын сугышчы була алмый. Моңа Гамир үз тәҗрибәсендә ышанды. Сугышның икенче елы бара иде. Гамир белән бергә хезмәткә чакырылганнар инде үз срокларын тутырып кайтырга җыеналар. Гамирның исә (көтеп торучысы булмаганга күрәдер инде) күңеле туган якларга бик ашыкмый. Ә егетләр тулысынча иреккә чыккан кебек хис итәләр үзләрен: теләгән вакытларында рөхсәтсез диярлек кышлакка чыгып йөриләр, бөтен тирә-якка бер булган кибеткә баргалыйлар. Кайчакта Гамир да аларга иярә. Язгы матур көн иде. Гамир, тирә-якка карана-карана, әкрен генә юлдан атлый. Алдан. Берүзе. Бераз арттарак калып, өч иптәше бара. Соңгы вакытларда тыныч, шикләнерлек урын юк та кебек, ләкин барыбер саклык дигән нәрсә солдатларның канына сеңгән. Юл кырыйлары ачык, тик анда-монда гына язын калкып чыккан чүп-чар күренгәли. Күктә – тургай. Кәҗә бәтие кебек йөгерәсе, сикерәсе, узышасы килгән гамьсез чак бит бу! Менә юл өстендә диярлек сырадан бушаган калай банка ята. Кибеттән кайткан уңайда егетләр ташлап калдырган инде. Гамир, беренче баручы буларак, банканы ераккарак тибеп җибәрү теләге белән адымнарын кызулатты, тик банка янына барып җитәрәк алда аунап яткан шундый ук тагы бер банка күренде. «Әйдә, тегесе минеке булыр!» – дип уйла-

ды ул, арттагы егетләргә күз төшереп. Тик ун-унбиш адым атларга өлгерде микән – йөрәгендә ниндидер шөбһә кымшанып куйды, эченә салкын йөгерде. «Типмә!» – бырылып, җан ачысы белән кычкырды Гамир. Соң иде – һавада селтәнгән аякны гына күрергә өлгерде һәм шул мизгелдә үк колак тондыргыч шартлау тавышы белән килгән һава агымы аны бәреп екты. Аңына килгәндә, «Кайтабыз!» дип туган якларына хатлар язган өч иптәше кан эчендә яталар иде...

...Менә шул интуиция дигән әйбер хәзер дә баш калкытты. Хәер, интуиция генә түгел, Гамирның тәҗрибәсе дә җитәрлек инде. Раджаның ниндидер мәхәббәт уены уйнап төркемне ташлавы – тузга язмаган хәл. Беркайчан да булмаячак бу. Ксюша жәл... Беренче тормыш тәҗрибәсе канатларын киссә, алга таба югалуы да бар. Ә Шурик нәрсәдер яшерә. Нәрсә? Раджа Шуриктан нәрсә тели? Информация дисәң, Шурик төркем эшләрендә пассив башкаручы гына, тулы информацияне хәтта Гамирның уң кулы Кактус та белеп бетерми. Димәк, Раджа төркемне эчтән кимерергә тели?! Тә-әк. Шурикка «көтүчедән» тыш, «үрдәк»[1] тә куярга кирәк булыр. Кинәт куркытырга гына ярамый егетне.

Гамир Ритага ял итәргә бару турында кызулык белән әйтеп ташлаганына үкенеп тә куйды. Хәзер соң инде... Бу кадәр эшне калдырып китүне ул элек күз алдына да китерә алмый иде. Ә монда – җиңел генә, имеш, ял итәргә бара... Туктале, ул бит Рита белән бара! Нәрсә, әллә аңа рәхәтләнеп көньяк кояшында бер-ике атна кызыну ярамасмы? Нәрсә югалта соң әле ул?

Бу уйлар Гамирның башыннан бөтерелеп диярлек уздылар. Бүлмәгә Шурик артыннан ук килеп кергән Кактус кына аның йөзендә ниндидер борчылу галәмәте сизде, ләкин берничә секундтан өстәл артында элекке кырыс кыяфәтле Памир утыра иде инде.

– Ну, яшьти, бөтен җаваплылык синең өстә кала. Кара аны, мине хурлыкка калдырасы булма. Миннән башка яңа эшкә керешмә. Хисап – телефоннан – атна саен. Мин сиңа координаталарымны калдырырмын.

Кактуска тиешле күрсәтмәләрне калдырганнан соң, Гамир беркадәр тынычланып калды. Көн кичкә авышкан, Рита янына кайтырга кирәк.

...Алинә исә бу вакытта үзенчә юлга әзерләнеп ята

[1] «Үрдәк» – дустанә мөнәсәбәткә кереп, кешенең серен алучы әләкче (арго).

иде. Гамир бүген иртән үк аның фотосурәтен ясатты, «яңа документ өчен дә, телевидение өчен дә кирәк булыр» диде. Әлбәттә, Алинә Гамирның бу эшләренә шакката, хәтта ышанып та бетми – ничек инде бер көндә, берничә сәгать эчендә кешегә яңа паспорт алып була?! Мөмкинме бу хәл? Әгәр Гамир шундый куәтле икән, димәк, ул чыннан да аңа ярдәм итә ала? Димәк, Алинәнең бердәнбер өмете – Гамир? Әлеге сораулар кызга көн буе тынгылык бирмәде. Урамнан әйләнеп керү теләге көчле булса да, балконга чыгып басып тору белән чикләнде. Хәзер ул Гамирны югалтудан курка иде. Бу ике атнада Гамир аның бердәнбер якын кешесенә әйләнде, Гамир аркылы ул тормыш белән, дөнья белән яңадан таныша башлады. Дөресен генә әйткәндә, кичәге сәяхәттән соң ул урамга чыгарга курка да бугай. Әйтерсең тышкы дөнья белән аның арасында күзгә күренмәс киртә барлыкка килде – Гамир өендә ул тыныч, аңа бернинди куркыныч янамый, ә урамга чыкса, тагы ялгыз калыр кебек; ул андагы тормышны белми – ул тормыштагы кешеләр аны белми. Тик балконнан җәйрәп яткан шәһәр өстенә карап торганда кайдадыр шул йортларның берсендә йөрәк пәрәсе – баласы булу җәрәхәте генә аның күңел дөньясын тышкы дөнья белән тоташтыра иде. Йа Ходай, бу турыда уйлыйсы түгел. Кичә бит ул үз-үзенә карар бирде – үткәне турында уйлыйсы түгел. Әнә кара урамга – әбиләр подъезд төбендә гәп коралар, бабайлар шашка чиртәләр, кәрт сугалар... Ә комлыкта – балалар... Таганда – балалар... Балалар велосипедта узыша, балалар таш тибешле уйный, куышалар, йөгерешәләр... Шомырт төбендә коляскада бала елый... Бүлмәгә керергә кирәк.

Калган вакытны ул телевизор карап, китап укып үткәрде. Менә ишек кыңгыравы шалтырый. Гамир.

– Йә, ничек хәлләр?! – Бүген Гамирның тавышы бигрәк якын тоелды. – Юлга әзерме инде безнең команда?

– Һәрвакыт әзер! – Алинә, үзенең җавабында ниндидер таныш ноталар табып, сискәнеп китте.

– Алайса, хөрмәтле Сабирова Маргарита Гайнановна, үзегезнең паспортны рәхим итеп алыгыз!

Алинә кисәк кенә каушап калды, дулкынланып, кулына өр-яңа паспорт кенәгәсен алды. Беренче битендә үк аңа үзе карап тора. Бүгенге Рита. Сабирова Маргарита Гайнановна. Гаҗәп беркадәр. Күптән түгел генә ул Волкова Маргарита Ивановна иде. Бүген Сабирова. Нишләп Сабирова?

Алинә күзләренә эленгән яшь пәрдәсе аша Гамирга күтәрелеп карады.

– Каршы килмәссең дип уйладым. Мин – Сабиров Гамир Гайнанович. Әгәр син минем сеңлем икән, димәк, синең дә фамилияң – Сабирова, әтиең Гайнан булып чыга, шулай бит?! Аннан соң бу паспорт үзеңнең чын исемеңне белгәнчегә кадәр генә бит. Бераз гына булса да Сабирова бул инде, яме?!

Алинә нәрсә диярг дә белмәде. Күңеленә тулган рәхмәт хисе сүз белән генә белдерерлек түгел иде. Яшьле күзләрен күтәреп карарга кыенсынып, ул Гамирга елышты, соң дәрәҗәдә оялып, егетнең колач җитмәс иңнәреннән кочып алды, башын Гамирның күкрәгенә салды да үксеп елап җибәрде. Ниһаять, ул – кеше. Урамга чыкса да, хәзер инде курыкмас, чөнки аның кеше булуын раслаучы кәгазе бар. Әйе, туганнары юк, торыр урыны юк, ләкин ул – кеше. Әлеге минутта Алинә моннан да зур сөенечнең булуын күз алдына да китерә алмый иде.

– Ну болай ярамый инде, сеңелкәш, син нәрсә?! – Гамир кызның чәчләреннән сыйпады, башын күтәреп, күзләрендәге яшьләрен сөртте. – Елама, зинһар, Рита. Менә күрерсең, барысы да әйбәт булыр. Мин синең сурәтне телевидениедә калдырдым, җомга көн кичке тапшыруларның берсендә күрсәтәбез, диделәр. Шулай булгач, насыйп булса, без тиздән синең чын исемеңне дә белербез. Ә бу паспортның бик үк чын түгеллеген аңлыйсыңдыр инде.

– Гамир, шушы кәгазьдән башка мин беркемгә дә кирәк түгел икән бит...

– Ну, Рита, мин әйтер идем, син бу кәгазь белән дә беркемгә кирәк түгел. Миннән башка, әлбәттә. Дәүләт өчен без – кешеләр – статистика гына.

Алинә, беркадәр тынычланып, яшьләрен сөртте, яңадан кулындагы кәгазьгә текәлде. Чынмы, түгелме – аның өчен әлеге минутта моннан да кадерлерәк бүләк юк иде. Хәзер ул югалмас, теләсә, урамга чыгып йөрер, теләсә, эшкә урнаша алыр – һәрхәлдә, билгесез хәлдә калган ише түгел. Йа Хода, ничек инде шулай – кеше кадәр кешенең гомере, тормышы шушындый уч төбенә сыярлык кәгазь кисәгенә бәйле?! Алай булырга тиеш түгел бит, түгел...

– Яшәү урының шушы квартира дип күрсәтелгән. Кирәк була калса дип әйтәм инде. Чын йортыңны искә төшерсәң дә, минем адресны онытмассың бит?

– Аһ, Гамир, синең яхшылыгыңны мәңге онытмамын... Мең рәхмәт яусын!

– Ну, ярар, әйдә, кибеткә чыгып, сиңа кирәкле киемсалым алып кайтабыз. Миңа да кайбер әйберләр карыйсы булыр. Диңгез буена костюмнан барып булмас.

– Бәлки, башта ашап алырсың?

– Юк, рәхмәт. Эшне бетерик инде, аннан иркенләп кичке ашны ашарбыз. Теләсәң, соңрак кафега йә ресторанга барырга була.

– Гамир, ә диңгез буена без самолетта очабызмы?

– Әлбәттә, самолетта. Алайса, паспорт нигә кирәк соң? Тик минем сиңа мәшһүр Каф тауларын, үзем хезмәт иткән кайбер урыннарны күрсәтәсем килә, шуңа күрә баргач машинада да шактый йөрергә туры килер.

Алинә тиз җыенды. Бер-ике сәгатьтән соң инде алар, бер кочак кием-салым күтәреп, кибеттән чыгып киләләр иде. Гамир һәрвакыттагыча, төрле көлкеләр сөйләп, Алинәнең күңелен табарга тырыша. Алинәнең дә оныталасы килә, бик килә! Тик булдыра алмый... Шулай да Гамирның күңеле булсын өчен генә булса да шат йөзле күренергә тырыша иде.

...Кич булып, шәһәр өстенә сибелгән меңләгән кечкенә йолдызлар яктысы күктәге илаһи йолдызлар утын каплады. Июнь төненең җиләс җиле, ачык калган тәрәзәләргә кереп, төн сәламен тапшырып чыкты да, шәһәр читендәге урман итәгенә ятып, таңгача гамьсез йокыга талды. Көне буе кояшта кызынып арыган күп катлы зур-зур йортлар, җир өстенә салкынча тынлык йөгерүен сизеп, рәхәтлектән киерелеп куйгандай булдылар. Төн агай балконда моңсуланып басып торган Алинәнең битенә үзенең кара ефәктәй кулы белән кагылып алды, чәчләреннән сыйпады. Алинәнең күңеле моңсу, бик моңсу иде. Бүген бу шәһәрдә аның соңгы төне. Ул тагы билгесезлек алдында басып тора, тагы күңелендә кешеләргә ышану-ышанмау тойгысы бил алыша. Ышанган очракта да, бүгенге төн – аның үткәне һәм киләчәге арасындагы чик. Үткәне – билгесез, үткәне – караңгы, шушы төн карасыдай, эчкәрәк кергән саен куера бара. Киләчәге нинди? Алинә әлегә үзе дә белми – кулына паспорт алган мизгелдән башлап, аның үз-үзенә ышанычы артты: Гамир белән юллары аерылса да, хәзер ул югалмас кебек. Тик Алинәнең Гамирдан аерыласы килми... Янында көчле терәк, яклаучың барын тою хатын-кыз өчен бик кирәк икән. Гамир Алинә өчен үзе бер сер дөньясы. Кем ул? Нинди ул? Йә көләч, йә бик җитди. Бер карасаң, йомшак, ягымлы, тик кайчакта күзләреннән усал чаткылар чәчрәп китә... Төнге караңгы күктә Гамирның күзләре барлыкка килде. Куе кара кашлар астыннан карасу-зәңгәр күзләр шаян чаткылар чәчрәтеп көләләр дә көләләр... Кыңгырау шулай чыңлый... ярны ялаган дулкыннарны узып йөгергән шук малай артыннан су тамчылары шулай си-

белеп-чәчрәп калалар... Дым көткән асфальтка яңгыр тамчылары шулай бәреләләр... Тик бу күзләрнең зәңгәрлеге артында, тирәндә-тирәндә сискәндерә торган, үзенә буйсындыра торган ниндидер салкынлык яшеренгән кебек... Әнә шул шом Алинәгә тынгылык бирми, әнә шул шом ятсыну тойгысын уята. Юк, бу хистән качарга кирәк. Алинә төнге күктәге күзләрне озын кара керфекләр артына яшерде. Яңадан ачылганда, әлеге күзләр бары шаян очкыннар гына сибәләр иде...

* * *

Еракта, калын кара урман артында, гөрселдәп күк күкрәде. Кинәт китереп бәргән көчле, дымлы җилгә йөзьяшәр наратлар сыкрану белән җавап бирделәр, иелми-сыгылмый гына, бер-берсенә кагылып алдылар, әйтерсең җилгә каршы иңгә-иң торырга сөйләшкәннәр. Корыган ботаклар, сынып, җиргә төште. Каршы яктагы каеннар гына, бер-берсенә әрнү салырга теләгәндәй, җил бәргән саен зифа кәүсәләрен әле бер якка, әле икенче якка селкетәделәр. Ниһаять, агач башларын талап-туздырып йөргәннән соң, котырынган җил җиргә ятты. Шунда ук тирәяк караңгыланып китте. Озакламый яңгыр коеп түгәчәк иде.

– Ярар, җитәр бүгенгә. Җыегыз кораллрны.

Раджа, машина ишегенә сөялгән килеш, урман каравылчысы, аның малае һәм Шурикның йөгерә-атлый җиргә сибелгән тартмаларны, нарат кәүсәләренә кадакланган калын кәгазь мишеньнәрне җыюларын күзәтте, яшен ялтыраган саен Шурикның куркынып күккә каравына, күкрәгән тавышка сискәнүенә игътибар итте. Ул инде бу пешмәгән авызны шундый зур эшкә тартуына үкенә дә башлады, ләкин күңелендә «нәкъ менә шушы кеше кирәк сиңа» дигән уй нык урнашкан булганга, әлегә артык борчылмый иде.

Әйберләрне җыеп, машинага кереп утырдылар. Раджа Шурикны үз янына утыртты.

– Ну, ияләшәсеңме инде «дускай»га? Сезнекеләр сиңа бик тоттырмыйлар, ахры. – Раджаның ачыктан-ачык көлемсерәү белән әйтелгән сүзләренә Шурик сискәнеп китте, эчендә кимсенү тойгысы кымшанып алды.

– Үзең беләсең... Бездә башкачарак.

– Ярар, күрәм, эшләр уңайга бара. Бик әйбәт. Мә, тот бишне.

Раджа костюм кесәсеннән урталай бөкләнгән берничә америка акчасы чыгарып Шурикка сузды.

– Кирәк-яракка тотарсың. Бусы сөйләшенгән суммага керми.

...Машинадан төшкәч тә, Шурик кесәсен яндырып торган яшел кәгазьләрне көн яктысына чыгарып, күзләрен кыса-кыса, яңгырдан соң чистарып калган кояшка таба сузды. Чын акчалар. Чын долларлар. Әлбәттә, ул доллар күрмәгән кеше түгел, доллар еш кына иптәшләре арасында да әйләнә, үзенә дә килеп эләгә иде, тик болары башка төрле. Болары зур, бәхетле тормышның беренче карлыгачлары. Шуңа күрә дә Шурикның кәефе күтәрелеп китте, асфальтта җыелып калган күлдәвекләргә чупырдатып баса-баса, уйга чумган хәлдә өенә таба атлады.

Уйлары исә алда торган зур «эш» тирәсендә бөтерелделәр. Памирның инде ике атнадан артык күренгәне юк. Малайлар аның бу чаклы озак югалып торуына гаҗәпләнсәләр дә, артык төпченмиләр. Кактус исә Памирга караганда да каты куллы булып чыкты. Тик кенә өйдә ятармын димә. Егетләрне әле бер урынга, әле икенчегә товар озатучы итеп тә җибәрде, складларга каравылны арттырды, бер-бер артлы машиналарны ремонтка кертте. Боерыкларны үтәргә теләмәгәннәр белән сөйләшү кыска булды. Шурикка да эләкте. Әйе, Памир белән эш икенчерәк иде. Ул башкаларга каты куллы булса да, ни өчендер Шурикка алай каты бәрелми. Нигә икәнен егет үзе дә аңлап бетерми, ләкин бу факт аның өчен кулай түгел. Ул аның ачуын чыгарырга тиеш, ул аны ярсытырга тиеш! Шурик Памирны күрә алмаска тиеш! Бу ялыктыргыч уй инде күптәннән аның теңкәсенә тия, Памирның кара бәрхет тавышы төшләренә кереп йөдәтә... Тизрәк кайтсын иде инде, соңгы мизгелдә күңелендәгесен Памирның йөзенә бәреп әйтер иде – бернидән курыкмыйча, каршысына басып, икәүдән-икәү генә калып! Соңыннан ихахайлап көләр дә иде әле... Татлы уйларына чумып, Шурик өйгә кайтып җиткәнен сизми дә калды.

Тагы берничә көн үтте. Шурикка вакыт тәгәрмәче бик акрын тәгәри сыман, көннәрен үткәрә алмый интегә, зарыгып диярлек Гамирның кайтуын көтә иде. Гамир исә һәрвакыттагыча һичкем көтмәгәндә кич белән кайтып төште. Офиста компьютер артында утырган Кактус та бер мәлгә югалып калды хәтта.

– Сәлам! – Ишектән кергән эре рәсемле юка җәйге күлмәктән, тезгә кадәр генә шортик кигән ир-атта элекке костюм-чалбарлы, кырыс Памирны тануы, чыннан да, кыен иде. Өстәл артында гәпләшеп утыручы ике хисапчы егет аһ! итте, Кактусның да гаҗәпсенүе йөзенә чыкты.

– Йә, нинди проблемалар, нинди яңалыклар?– Памир-

ның тавышы да көрәеп киткән кебек, көньяк кояшында каралган йөзендә элеккеге кырыслык эзләре дә кимегән төсле. Шулай да нәрсәгәдер борчылган кеше кебек, авыр елмая. – Эшләр барамы?

– Сәлам, – Кактус кул сузып күрешкәндә дә көтмәгәндәге каушаудан арына алмады. – Эшләр бара, тик бүген инде сине көтмәгән идек. Үзгәргәнсең, танып та булмый хәтта.

Гамир көлеп җибәрде. Егетләр дә җанландылар, Гамирдан кайда булуы турында сораштыра башладылар. Ләкин бу турыда сөйләү аның планына керми иде булса кирәк, шуңа күрә егетләр белән тиз-тиз генә саубуллашырга тотынды.

– Иртәгә сөйләшербез, – диде ул, ләкин йөзендәге елмаюы югалмады. – Бүген соң инде, кайтыгыз.

Егетләр артыннан ишек ябылганда, Гамир Кактус утырган компьютер янында иде инде. Шактый вакыт сәүдә эшләрен сораштырды, исәп-хисапка күз йөгертеп чыкты, артык төпченмичә генә керем-чыгымны барлады.

– Болары бик әйбәт. – Гамирның тавышы җитдиләнеп китте, күз карашы стенадагы сәгатькә текәлде. Вакыт, чыннан да, шактый соң икән инде. Тәрәзә артында да караңгылык куера төшкән сыман. – Мин белмәгән башка яңалыклар бармы?

– Күршеләр депутатлыкка кандидат тәкъдим итәләр, әгәр бездән башка кандидатлар булмаса, территорияне кулланырга сорадылар. Синсез хәл итмәдек.

– Уйларга кирәк булыр. Сәясәт – керемле нәрсә, әгәр күршеләр кымшанганнар икән, безгә кул кушырып яту килешмәс. Сорамасалар да билгеле.

– Мин дә нәкъ шулай уйлыйм, Памир. Аннан соң Капитан бригададан чыгарга тели, ахры. Тел төбеннән шул аңлашылды.

– Нәрсә калдыра?

– Күпер янындагы ноктаны булса кирәк. Балыкчылар киоскын.

– Минем янга килсен, сөйләшербез. Проблема булмас дип уйлыйм. Тагы?

– Башка яңалыклар юк инде... Шурик турында әйтсәм генә.

Гамир бер мәлгә аңламыйча торды, бераздан соң гына сүзнең кем турында барганлыгын чамалап, ресторандагы очрашуны искә төшерде. Ул бу турыда гел оныткан иде. Әйе шул, китәр алдыннан Шурикны күзәтергә кушкан иде ләбаса.

– Ничек тотты иптәш үзен?

– Алай артык шикләнерлек урын юк сыман. Тик... бер урман каравылчысына барып йөри, ауга чыгалар, диләр.

Гамир тәрәзә артындагы караңгылыкка текәлеп утыра иде, гаҗәпләнеп Кактуска борылды.

– Кем, Шурикмы?

– Мин дә бераз шикләнгән идем, тик ул карт, чыннан да, Шурикның туганы булып чыкты. Әнисенең абыйсы. Информация дөрес. Анда ул әнисе, сеңлесе белән барып йөри. Кайчакта берүзе генә. Шурикның сеңлесе Раджа белән күренгәләп алган, диләр.

– Анысын беләм. Шурик карт белән элек аралашканмы, ачыкладыгызмы?

– Әлбәттә. Элек тә аралашканнар, тик соңгы арада ешлаган. Картлачны урманда очратып сыйлаганнар егетләр, бер-ике рюмкадан соң үзе үк барысын сөйләп биргән. Шурикны куян атарга өйрәтә, ди. Дөресен генә әйткәндә, Шурик кемнәндер бик курка икән, шуңа күрә, янәсе, сакланыр өчен аңа коралга ияләшергә кирәк дип аңлаткан.

Гамир берара үз уйларына чумып, дәшми торды. Төркемдә корал йөртү һәркемнең үз иркендә. Булдыра алсаң – бишне тагып чыксаң да була. Алай шикләнер әйбер юк та сыман, шулай да... Кемнән курка Шурик?! Раджаданмы?! Егетнең уенда нәрсәдер бар, димәк. Тик нәрсә? Вендетта уйнарга – сеңлесе өчен үч алырга җыенамы әллә? Ярар, алга таба күренер.

– Ну, Кактус, – Гамир, урыныннан торып, Кактусның кулын кысты. – Рәхмәт үзеңә. Молодец! Ышанычлы кеше син.

– Тырышабыз инде, Памир. Шулай да, минем теләгемне хәтерлисеңме? Мин өметләнә аламмы?

– Беләсеңме, Кактус. – Гамир берара тәрәзә төбендәге гөлләрнең туфрагын йомшарткалады. Дымлы. – Мин Мәскәү аркылы кайттым бит. Имеш-мимешләр дөрес – анда инде бик күпләр бер-берсен кырганнар. Безнең кебекләр хәтта Мәскәүдә дә бармак белән санарлык. Озакламый бөтенләй таркалачаклар. Казанга да килеп җитәр бу. Безнең «бригада»ларга яшүсмерләрнең «тяп-ляп» төркемнәре алмашка килә. Тарих кабатлана, Кактус. Шуңа күрә, киткән очракта да, бергә китәрбез дип уйлыйм.

Памир Кактуска борылды, күзләре очраштылар. Кактусның карашында ачу да, үпкә дә юк иде, коңгырт-кара күзләрдән ничектер бик якын итеп тугрылык саркый иде. Памирга уңайсыз булып китте.

– Мин сине көчләп үз янымда тотасым килми. Тик шулай да мин тагын бер елга калуыңны үтенәм. Синең кебек якын, тугры дустым юк минем.

– Мин сине аңлыйм, Памир. Мин үзем сиңа бик рәхмәтле.

– Алайса килештек.

Офисны бикләп, сакка тапшырып чыктылар. Төн җиткән икән инде. Гамир якында гына торган машинасына күз ташлады, беркадәр уйланып торганнан соң, яңадан борылып, китәргә җыенган Кактуска дәште:

– Рөстәм... Әйдә, берәр җиргә кереп утырыйк, ә? Мин нишләптер арыдым әле бүген...

Кактус беренче карашка үз кушаматының нәкъ киресе иде. Тыныч, басынкы, беркайчан тавышын күтәрмәс, ләкин әйткән һәрбер сүзе, төбәлгән кешесенә барып җитәрдәй булып, үтемле итеп чыга. Кайчак Гамир аның шулай сеңдереп сөйләшә белүенә көнләшеп тә куя. Ике институт бетергән югары белемле бу егетнең Памир төркеменә кушылып китүе дә кызык кына булды. Моннан берничә еллар элек Гамир, өр-яңа машинасына утырып, беренче тапкыр шәһәр әйләнергә чыккан иде. Затлы чит ил машинасының тузан да кунарга өлгермәгән панелендәге хисапсыз кнопкаларны тикшерә-тикшерә, йомшак кәнәфигә чумып, машина йөртүдән ләззәтләнеп дәртле көйләр тыңлап барганда, алдагы чаттан шактый тизлек белән «Ока» машинасы килеп тә чыкты, Гамир машинасының уң як канатын каерып та атты. Бу шулкадәр тиз булды ки, Гамир, мөгаен, үз гомерендә беренче мәртәбә чарасызлыктан хәтта югалып калды. Җитмәсә, битенә панельдән чәчрәгән куркынычсызлык мендәре китереп бәргәч, бөтенләй миңгерәүләнеп киткәндәй булды. «Ока»дан таушалганрак өс-башлы, озын буйлы, коңгырт-кара чәчле егет килеп чыкты да, Гамир машинасына игътибар итеп тә тормастан, шактый яньчелгән үз машинасы янында бөтерелә башлады. Гамир да машинадан чыкты, тын гына егетнең хәрәкәтләрен күзәтеп, машинасына сөялеп басып торды. Әлбәттә, яңа машина кызганыч, бик кызганыч иде. Шушында ук тавыш кубарасы, бар тавышка кычкырасы, әлеге егетне селтәп атасы килә иде. Ләкин егетнең дә, үз машинасының һәрбер яньчелгән детален сыйпап, аһ-ваһ килүен күргәч, нигәдер күңеле йомшады. Ниһаять, егет Гамирга борылды.

– Кимендә ун мең, – ачыргаланып, Гамирга кулын сузды. – Рөстәм.

– Кимендә синең машина. – Гамир, тәмам тынычланып, машинасының уң канатына ишарәләде. – Памир.

Шунда гына егет Гамирның машинасына күз салды. Ялтырап торган соңгы модель «Ауди»ның уң канаты тәмам изелеп, егетне мәсхәрәләгәндәй, ыржаеп тора. Моны күргәч, егет, җиргә сеңгәндәй булып, кечерәеп калды.

– Йә, чакырабызмы милиция? Кызыл утны күргән идеңме соң? – Гамир моны болай гына әйтте. Күренеп тора, егетнең машина йөртү таныклыгы булса да, кичә генә алгандыр. Тәҗрибәсезлеге йөзенә чыккан.

– Беләсеңме... – Егет ык-мык килде. – Тормоз урынына газга басканмын, ахры... Үзем дә аңлап бетермәдем. Бүген рульдә... Үзем генә беренче тапкыр.

Гамирның бертуктаусыз елмаясы килде. Бер ун елдан бу сүзләреңә үзең дә шаккатырсың әле, егеткәй. Мондый кешеләр тормышта йә гений, йә шыр тиле булалар. Син кем икән, иптәш өйрәнчек?

– Әйдә алайса, машиналарны юлдан алыйк та якыннанрак танышырбыз.

Егетнең машинасы йөрерлек түгел иде, машина янына җыелган ачык авызлар этеп юл кырыена чыгардылар. Гамир да үз машинасын җәяүлеләр сукмагы янына ук кертеп куйганнан соң, каршыдагы җәйге кафега барып утырдылар. Егет сырадан баш тартты. «Бөтенләй үк җүләр түгел, монысы әйбәт», – дип уйлады Гамир, егеттән үзе турында сораштырган арада. Бераздан Рөстәмнең ике институт – биология һәм экономика факультетларын быел гына тәмамлап, эшкә урнаша алмый йөрүче икәне ачыкланды, машинасын сугыш ветераны буларак, бабасына бүләк иткәннәр икән. «Биология» диюгә, Гамирның күзләре ялтырап китте.

– Беләсеңме, – диде ул, ике дә уйламый, – безгә экономист кирәк бит. – Әйдә, мин сине үз яныма эшкә чакырам.

Шулай итеп, Рөстәм кибетләр челтәре буенча эшли башлады. Бераздан кая эләккәнен аңлады бугай, тик китәргә чамалап бер-ике талпынып караганнан соң, тәмам ияләште, тиз арада Гамирның уң кулына әйләнде. Беренче эш көнендә үк офиска кактус гөле күтәреп килгәнгә, үзенә Кактус дип кушамат тактылар. Кактус Гамирга күп нәрсә бирде – һәрхәлдә, үзенең генә башы җитмәгән катлаулы икътисад операцияләрен чикләвек урынына ватканын күреп, Гамирның егеткә хөрмәте арткannan-арта барды. Егетнең кулы да туры иде, ә Гамир андыйларның кадерен белә. Хәзер инде Кактус – шактый тәҗрибәле ир-егет, төркем эшләре белән шөгыльләнсә дә, үзенең дә яхшы гына табыш китерә торган кибете бар, киләчәктә кечерәк банк ачып җибәрергә хыяллана. Иртәме-соңмы,

аларның юллары аерылачак. Хәер, Гамирның да монда көннәре санаулы. Яңа заман килә, Гамир моны аңламаслык җүләр түгел.

...Машиналарын янәшәдәге төнге каравылга биреп, такси белән шәһәрнең икенче читенә диярлек чыктылар. Гамир тыныч, аулак ресторанны сайлады. Биредә аларны йөзгә-биткә танучы юк иде, ахры, шуңа күрә килеп эндәшүче, комачаулаучы да булмады. Кактусның гаҗәпсенүен күрмәмешкә салышып, Гамир каты коньяк китертте, эһ тә итми, бер-бер артлы ике рюмканы салып куйдылар. Кактус карышмады. Памирның эчмәгәнен ул белә, бик сирәк очракларда гына егетне кәефле килеш күрергә була. Коньяк затлы, каты иде, ашамаган егетләрне бик тиз кулга алды, кан тамырлары буенча йөгерде, җылы рәхәтлектә изрәтте. Сөйләшүнең җитди буласын сизенеп, Кактус дәшмәде, Памирның сүз башлавын көтте.

– Рөстәм, – Памир бертуктаусыз кулындагы рюмканы әйләндерде. – Минем исемем Гамир. Моны синнән башка тагы бер кеше генә белә.

Кактуска Памирдан үз исемен ишетү никадәр сәер тоелса да, Памирның чын исеме барлыгын белү тагы да көтелмәгәнрәк булды.

– Балалар йортында ук миңа Памир дип дәшәләр иде. Гамир – Памир. Охшаган ич. Пленнан котылгач, паспортка яздырдым. Военкоматта Гайнанов Гамир хәбәрсез югалганнар исемлегендә. Ә Гайнанов Памир – синең каршыңда. Менә шулай.

– Да-а, – дип сузды Кактус, нәрсә әйтергә белмәгәнлектән. Ул сүзнең кайсы якка борыласын аңлый алмый интегә иде.

– Рөстәм, синең якын кешең бармы?

– Әтинең вафатыннан соң иң якын кешем – әни. Абый белән сеңлем үз тормышлары белән яшиләр. Мин – әни янында.

Гамир кисәк кенә Кактуска күтәрелеп карады.

– Димәк, синең сеңлең бар?

– Әйе, миннән ике яшькә генә кече. Абый бездән күпкә зур, шуңа күрә кечкенәдән сеңлем белән бергә уйнап үстек.

– Рөстәм, син бик бәхетле кеше, сеңлең булгач. Беләсеңме, минем дә сеңлем бар бит.

Гамир тынып калды. Кулында аунаткан рюмкасына яңадан коньяк агызды, Кактусныкына да койды.

– Әйдә, сеңелләр өчен.

Ниһаять, ашарга китерделәр. Кактус ачыккан иде, бик теләп кайнар ашка ябырылды. Гамир исә эчемлекнең кан

тамырлары буенча йөгергәнен, баш миен кыздырганын сизә, ләкин шулай да ашка исе китмәде, калак белән болгатып утыруын белде.

– Минем сеңлем авырый, – диде ул, бераз утыргач.

– Кызганыч. – Кактус, тәлинкәдән күтәрелеп, Гамирга текәлде. Күрәсең, егетнең кайгысы бар. – Терелергә өмет бармы соң? Бәлки, мин ярдәм итә аламдыр? Минем абый – хирург.

– Бар... Тик мин аның терелүен теләмим.

Кактус чәйнәгән ипиенә тончыга язды. Стаканга салып, су эчеп куйгач, ашавын бөтенләй онытып, Гамирга дәште:

– Гамир... Күрәм, нәрсәдер әйтергә телисең. Аңлатып сөйлә әле, юкса мин бернәрсә дә аңламыйм.

Гамир һаман икеләнә иде. Аның үзе турында яисә якыннары турында кешегә сөйләгәне юк, гомумән, шәхси проблемаларны кеше үзе генә хәл итәргә тиеш дип уйлый, авыз күтәреп, адым саен сөйләп йөрүчеләргә түбәнсетеп карый иде. Кыен икән кешегә хәлеңне сөйләү.

– Ярар, башлаганмын икән – бетерермен дә, – Гамир бераз башы әйләнүен тойды. – Күптән түгел мин сеңлемне очраттым. Бертуган сеңлем түгел, шулай да... сеңлем. Ул хәзер минем белән яши. Аның авыруы гадәти түгел. Ул... хәтерен югалткан. Үзенең элекке тормышы турында бернәрсә хәтерләми.

Кактус утырган урынында кыбырсып куйды, нәрсәдер әйтергә теләп, авызын ачты, тик Гамир «бүлдермә!» дигәнрәк кыяфәт белән кул селтәде.

– Мин аңа ял булыр дип, диңгез буена алып бардым. Бу турыда беләсең. Кичә кайттык. Бүген мин аның кем икәнен, кайда торганын – гомумән, элекке тормышын ачыкладым. Мин барысын да беләм. Ул зур фаҗига кичергән. Тик мин аңа бу турыда әйтә алмыйм.

Кактус бу сүзләр ташкынында бер әйберне аңлап калды – Памирның сеңлесе хәтерен югалткан. Тик... нишләп әле Памир үз сеңлесенең тормышын ачыклап йөри? Белмәгәнмени?!

– Ә син элек сеңлең турында белми идеңмени?!

– Юк. Мин аны күптән түгел генә очраттым. Тик бу әһәмиятле түгел. Мин аңа дөресен әйтә алмыйм, чөнки мин аның терелүен теләмим, аңлыйсыңмы?!

Кактус аңламый иде. Әллә коньяк башын бутадымы? Ничек инде, ничек терелүен теләми?

– Аңламыйм, Гамир.

Гамир үзе дә буталды. Эчемлек бераз күңелендәге ташны эретер, күкрәген авырттырган хисне җиңеләйтер дигән

иде, булмады. Киресенчә, проблема аның алдына катлауланып, куерып кына килеп басты.

– Ярар, әһәмиятле түгел. Мин синнән икенче мәсьәлә турында үтенмәкче идем.

Гамир алдындагы ашны болгатып утыруын белде. Инде икенчегә ризык китерделәр, ә ул әле бер чеметем валчык та капмады. Тамагыннан ризык үтми иде.

– Гамир, син беләсең, кулдан килгәннең барысын да эшләрмен.

– Рәхмәт. Мин...

Гамир сүз табалмый интегә, ахры, ашын болгатып утыруын дәвам итте. Кактус, үтенечне көтеп җиткерә алмый, үзе үк рюмкаларга яңадан коньяк койды.

– Гамир, эчик әле, әйдә.

Сүзсез генә эчеп куйдылар.

– Тыңлыйм, Гамир.

– Мин үземнең барлык мөлкәтемне – квартираны, коттеджны, машиналарны, кибетләрне – барысын да сеңлем исеменә яздырырга телим. Шуңа күрә аларның кыйммәтен бәяләп, исәп-хисап эшләрен эшләп, рәсми рәвештә беркетергә кирәк. Никадәр тизрәк, шулкадәр яхшырак.

Кактус шаккатты. Дөрес ишеттемме дигәндәй, кашларын җыерып, күзләрен кысып, сузып салды:

– Бөтенесен?.. Сеңлеңә?!

– Әйе, мин хәл иттем инде.

– Син яхшы уйладыңмы?! Күптән түгел очраттым дисең ич, кем икәнен беләсеңме соң? Бәлки, ул аферисткадыр? Синең туганлык хисләреңдә уйнап, бөтен малыңны тартып алу турында хыяллангандыр?!

– Кактус! – Гамирның тавышында тимер чыңлап китте, күзләреннән утлар чәчрәде. – Башка алай сөйлисе булма! Мин синнән киңәш сорамадым!

Кактус, Гамирдан күзләрен алмыйча, туп-туры карап утыруын белде, тик иреннәре генә нидер пышылдый иде.

– Беләм, синең өчен көтелмәгәнрәк бераз, тик мин күптән хәл иттем инде. Шулай кирәк. Юридик яктан проблемалар булмас дип уйлыйм. Идарә минем кулда кала, тик барысына да сеңлем хуҗа булуын телим.

– ...Уйлап караганда, яхшы фикер бу. – Кактусның башы әйләнә башлады, сәбәпсез елмаясы килә иде. Тик елмаюның урынлы булмаганын аңлап, үзен тыйды. – Дөресен генә әйткәндә, мал-мөлкәтне беркем дә үз исеменә яздырмый... Мин үзем дә Казан ятиме кебек ялангач... Тик барыбер сеңлең ышанычлы булса ярый инде. Калганын эшләрбез.

– Ышанычлы. – Гамир яңадан рюмкаларга эчемлек

койды. – Әйдә, бусы соңгысы. Тик эчкәнче минем сиңа тагы бер үтенечем бар.

– Гамир. – «Көньяктан үтенечләр капчыгы белән кайткансың» дип әйтәсе килде Кактусның, тик тагын үзен тыйды. – Мин яртылаш исерек. Бәлки, иртәгә калдырырбыз?

– Юк. Мин көн саен сиңа җанымны ачып салырга җыенмыйм. Тыңлыйсыңмы?! – Гамир үзе дә исерә башлаган иде.

– Тыңлыйм, Гамир.

– Синең якын кешең бармы?

– Әйттем ич инде – әни, туганнарым.

– Юк, мин башка мәгънәдә сорыйм. Буйдак икәнеңне беләм. Синең яраткан хатын-кызың бармы?

Кактус ачы көлемсерәде. Бер өйләнеп карады инде ул. Яши алмадылар. Яраткан кызың, имеш... Кактусның күз алдында ялварулы яшькелт-зәңгәр күзләр төсмерләнде. Күпме эзләде ул аларны. Тапмады.

– Юк, Гамир.

– Мин сине сеңлем белән таныштырасым килә. Мин аны үзем дә бик яратам... Тик ул – минем сеңлем. Үтенечем шул – син миңа сеңлем турында гомерең буе кайгыртырга, аны бәла-казадан сакларга вәгъдә ит.

– Гамир! Бу нәрсә дигән сүзең? Аңламыйм. Ә син үзең кая китәргә җыенасың?

– Шул сүзем, мин кайгырта алмасам, син минем сеңлем турында кайгыртырга тиеш.

– Гамир, мин аңа өйләнә алмыйм, әлбәттә, ләкин ярдәм кирәк булса – һәрвакыт.

– Нишләп өйләнә алмыйсың?

– Мин өйләнергә җыенмыйм!

– Өйләнәсең. Минем сеңлемне күрсәң – өйләнәсең.

– Гафу ит, ләкин мин яратмаган килеш башка мәңге дә өйләнмәячәкмен. Хәтта синең сеңлеңә дә.

– Миңа синең холкың ошый. Син – минем кебек. Тик барыбер өйләнәсең.

– Гамир, әйдә иртәгә сөйләшәбез.

– Юк, вәгъдә бир миңа.

Егетләрнең икесенең дә теле бәйләнде. Җыенырга вакыт иде.

– Ярар, синең сеңлең турында гомерем буе кайгыртырга, булышырга, күз-колак булырга вәгъдә бирәм. Тик өйләнү мәҗбүри түгел.

– Рәхмәт, Кактус. Тагы. Монда сөйләшкәннәр ике арада гына, аңладыңмы?

– Әйтмәсәң дә билгеле, Памир.

Урамга чыккач, такси килгәнне көтеп, беркадәр ресторан каршындагы чәчәкләр түтәле янында утырдылар. Төн искиткеч матур, җылы. Бераз израп утыргач, Гамир телефонын алып, квартира номерын җыйды.

– Хәерле кич, Рита! – Егет булдыра алган кадәр тавышын тигез тотарга тырышты. – Бүген мин еракта, өйгә кунарга кайтып җитә алмыйм, ярыймы?.. – Нишләп әле Гамирның колак очлары кызыша?! Мәктәп укучысы түгел ич инде ул. – Үзең генә кунарга курыкмыйсыңмы? Теләсәң, Камиләттәйне китертәм. Курыкмыйсың? Юк, барысы да әйбәт. Иртәгә күрешкәнче, яме. Әйе, хәл итәсе проблемалар бар. Ярар, сау бул.

– Мондый кыяфәттә сеңлем күзенә күренә алмыйм. – Гамир Кактуска борылды. – Әйдә, коттеджка кайтабыз, «түтәй»ләр чакырабыз.

– Юк, Памир. Мин кайтмасам, әни кайгыра. Мин кайтканчы йокламый ул. Мин өйгә кайтам.

– Теләгәнең, алайса.

Кактус белән хушлашканнан соң, Гамир танышына шалтыратты. Изрәгән ир-ат тәне бушануны таләп итә иде. «Озын чәчлесе бармы «түтәй»нең?» Гамир бу сүзләрне авырлык белән әйтте, ләкин әйтте. Озын коңгырт чәчләргә чумасы килә аның... Ир-ат лабаса ул, таза-сәламәт ир-ат...

* * *

...Тәмле кичке аш исе баскыч төбенә үк чыккан. Гамир бер мәлгә тукталып калды. Ничек кенә каушамыйча, берни дә белдермичә Ритага сөйләп бирергә? Гамир моны күз алдына да китерә алмый иде. Кулын яңадан звоноктан алды. Нәрсә дияргә соң? Ничек кенә Ритадан барысын да белүен яшерергә?! Әлегә ул дөресен әйтә алмый, чөнки сеңлесенең үзе белән бергә яшәвен тели. Аннан соң... шулкадәр авыр хәбәрне ничек җиткермәк кирәк? Юк, әлеге хәлдә ялган – иң әйбәт чара. Рита үзе искә төшерсә генә... Әйе, Рита үзе искә төшерергә тиеш! Ә ул аңа ярдәм итәр, бәлки, хастаханәгә урнаштырырга да мөмкин булыр. Тик хәзергесе кыен... Аптырап, ишек төбендә шактый басып торганнан соң, әйтәсе җөмләләрен төзеп карады, тик алар ничектер бик купшы килеп чыктылар. Шунда исенә чечен карты әйткән сүзләр килеп төште. Гамирга тоткынлыктан качарга булышкан карт бик зирәк иде, аның ярдәме белән ул туган якларына кайтты, гәрчә карт үзе үк Гамирның хуҗасы – ул аны «боевик»лардан коллыкка сатып алды. Мөселман икә-

нен белгәч, җибәрергә вәгъдә итте, шулай да аның ихатасында торкын егет шактый тир түкте әле. «Әгәр юлда кемне дә булса алдарга туры килә икән, иң элек ялганыңа үзең ышан». Ялганга ышанырга. УлРитаның кем икәнен белми. Әлбәттә, белми. Беркем дә белми. Телестудиядә белмиләр, аның фотосын беркем дә танымаган. Алинәне беркем дә эзләмәгән. Дөресрәге, Ританы беркем дә эзләмәгән. Кулы үзеннән-үзе кыңгырау төймәсенә үрелде.

...Алинәнең күзләрендә түземсезлек, сорау, өмет ярылып ята, йөзе агарып киткән. Ишек ачылу белән, ул Гамирга текәлде. Егет бу караш астында бер мәлгә каушап калды, тик шунда ук үзен кулга алып, өметсез кыяфәт белән башын чайкады. Алинәгә башка сүзләр кирәк тә түгел иде. Әйтерсең мизгел эчендә үзе корган хыял сарайлары җимерелеп төште. Әйтерсең җир әйләнүдән туктады.

– Димәк, мине беркем танымаган, беркем эзләмәгән, – диде ул, калтыранган тавыш белән. – Димәк, бу шәһәрдә мине белүче юк.

Гамир баш какты. Ләкин шунда ук кызның сүнгән карашында үҗәтлек чагылып китте.

– Гамир, бу шәһәрдә белүче юк, чөнки мин бу шәһәрдә яшәмимдер! Башка шәһәрләрдән, авыллардан эзләргә кирәк! Ул канал республикага чыгамы?

Гамир гаҗәпләнүдән нәрсә әйтергә белмәгәнлектән, үзалдына «әйе, әлбәттә, шулай» диебрәк мыгырданды да тизрәк юыну бүлмәсенә узды.

Ниһаять, юынып, әзрәк хәл алгач, аш бүлмәсендә өстәл артында үзен көтеп утырган Алинә янына керде.

– Рита, гафу ит, зинһар. Юлда арылды... Синең көткәнеңне беләм, тик кичә кайталмадым.

Алинә, әлбәттә инде, кичә Гамирның бик үк «тотрыклы» түгеллеген аңлаган иде.

– Борчылма. Фирмада барысы да тәртиптәме соң?

Алинәнең тавышы тонык, кыяфәте урман кисеп кайткан кешенеке төсле. Гамирны вөҗдан уты телгәләде.

– Әйе... Барысы да әйбәт дияргә була.

– Ярар алайса, аш бүләм.

Сөйләшми генә ашадылар. Алинә үз уйларына чумган иде. Чәй артында җавабын алдан белгән кебек сорап куйды:

– Телестудиядә нәрсә диделәр соң? Беркем дә шалтыратмаганмы?

– Юк, Рита, шалтыратмаган...

– Мин шулай дип уйлаган идем инде. Әгәр син нәрсә

дә булса белгән булсаң, кичә үк миңа хәбәр иткән булыр идең, шулай бит?!

– Әйе... Шулай.

Нишләп бу кадәр авыр соң Гамирга. Теле шомырт ашаган кебек көрмәкләнгән. Авыз ачып сүз әйтер хәл юк. Алинә дә аның бу халәтен сизде.

– Гамир, авырмыйсыңдыр бит?

– Әллә нәрсә шунда... Климат үзгәртү ярамады, ахры, үземне начар хис итәм.

– Ятып тор бераз. Температураң бармы әллә?

Кыз, урыныннан кузгалып, Гамир янына килде, кулын аның башына куйды. Назлы кулның ефәктәй йомшаклыгыннан, Алинәнең шулкадәр якынлыгыннан Гамирның башы әйләнгәндәй булды. Йа Хода, ул бит үзе Алинәгә малайларча муеннан гашыйк, ничек итеп кичә Кактустан тузга язмаган вәгъдәләр алды ул!

– Юк, башың кайнар түгел. Шулай да дару эчмисеңме соң?

– Миндә дару-фәлән юк инде ул.

– Алайса, чәеңне катырак ясыйм әле.

Гамир Алинәнең чәй янында кыбырсып утыруыннан сүзе бетмәгәнлеген сизде, ләкин үзе авыз ачып дәшәргә җөрьәт итмәде. Ниһаfive, кыз Гамирга туп-туры карады да:

– Гамир, хәтерлисеңме, син миңа беренче көнне нәрсә дигән идең? – диде. Шунда ук Гамирның җавабын көтеп тормыйча, үзе үк әйтеп бирде. – «Сиңа иң яхшы дәва – вакыт. Бары вакыт кына ярдәм итә ала сиңа» дигән идең. Син дөрес әйткәнсең, Гамир. Мин хәзер шул вакытның тизрәк үтүен телим. Тагы син әйткән идең: «Синең күңелеңдә туганнарыңа ышаныч бар. Әгәр син хәтерли алмасаң, бәлки, алар сине эзлиләрдер дип уйлыйсың. Менә шул ышаныч сүнгәннән соң син яңа тормыш башларга тиеш буласың» дидең. Хәтерлисеңме? Гамир... Күрәсең, миңа яңа тормыш башларга вакыт җитте. Мин эшкә урнашырга телим.

Гамир үзен томанда адашкан кешене күзәтеп утырган кебек хис итте. Менә ул кеше, кулларын сузып, тырмаша-тырмаша юл эзли, ә Гамир юлның кайда икәнен белә торып, аңа әйтми... Бөтен күкрәге белән авыр итеп көрсенеп куйды.

– Яхшы, Рита. Мин бик шат. Безнең офиста сиңа эш табылыр дип уйлыйм.

Чәй эчкәннән соң, сөйләшми генә телевизор карадылар. Гамир күрде: кызның күзе экранда булса да, уйлары әллә кайларда йөзә иде. Үзен бик, бик гаепле итеп сизде егет, шулай да дәшмәде. Төн җиткән иде инде.

Һәркем, үз уена чумып, йокларга ятты. Гамир күрше бүлмәдәге Алинәнең йокыга китә алмый борсалануын ишетеп торды, үзенә дә «Дөрес эшләдемме?» дигән уй озак, бик озак тынгылык бирмәде...

* * *

...Бер-бер артлы көннәр – Алинәнең көннәре үтте. Кайберләре бик тиз, күз ачып йомганчы, кайберләре көзге тымызык яңгыр кебек сүлпән генә Вакыт елгасына тамдылар. Җәй иленә көздән илче булып, Җил әфәнде килде, бераздан бакчаларга кереп, эсселектән әлсерәгән, кояш нурларында изрәгән алмагачларны җәйге татлы оюдан уята башлады, алмаларын алсу буяуга манарга киңәш биреп китте. Кояшның күп эшләп кызарган битен болытлар белән каплаштырып йөрде. Яфракларга көз сәламен җиткерде, китәсе кошларның мамыкларын кабартып, ерак юлга әзерләште, басу-кырларга күпләп сары буяу ташыды. Арып-талып, иртәнге томаннарга уралып, Көзнең аягына барып егылды. Ниһаять, җиһанга Көз галиҗәнап үзе аяк басты.

Алинә «эшкә урнашам» дисә дә, Гамир аңа бераз хастаханәдә дәваланырга тәкъдим итте. Кыз үзе дә бу турыда уйлый иде, шуңа күрә карышмый гына атна-ун көн вакытын урамга палата тәрәзәсеннән карап, китаплар укып үткәрде. Әлбәттә, Гамир тырышты: ап-ак, чиста палатада Алинә берүзе, телевизор, суыткыч – барысы да Алинә карамагында, шәфкать туташлары, табиблар да, ягымлы елмаеп, нәрсә теләсәң, шуны үтәргә әзер булып тордылар. Туташларның ялагай карашын күрсә, Алинә, ачыргаланып, коңгырт күзле ир-атның үзен хастаханәгә китерүен искә төшерә иде... Һава суларга чыкканда да, башка авыруларның үзенә көнләшеп карауларын сизде, шуңа күрә ачылып сөйләшердәй иптәш тә табалмады. Әйе, дөнья үзгәргән, һәм бу кырыс дөньяда Алинә үзен танымый. Вакытын күбрәк китап укып үткәрде. Китапларның да тарих турындагыларын сорады. Гамир исә тарих буенча бер кочак мәктәп дәреслекләре күтәреп килде. Күрәсең, даруларның да ярдәме тигәндер: кайбер вакыйгаларны ул укый башлау белән искә төшерә; кайберләрен алдан ук белеп тора, һәрбер искә төшкән хатирәгә сабыйларча чын күңелдән шатлана. Ләкин шул Җир шарындагы миллиард тарихлар, миллиард язмышлар арасында үз язмышы гына табылмады. Гүя ул бу Җир шарында бөтенләй яшәмәгән дә. Гүя кемдер аның хатирәләрен җиде кат сандыкка җиде кат йозак белән

бикләп куйган. Шулай да хастаханәдән чыкканда, кызның күңеле көр иде: ул дөнья тарихындагы күп вакыйгаларны искә төшерде, хәтер катламнарын эшкә җикте – шулай булгач, кайчан да булса аның үз тарихы да кайтачак, әлбәттә, кайтачак!

* * *

Ниһаять, Шурикның хыялы тормышка ашты: шактый сузганнан соң, Раджа «операция» үткәрергә рөхсәт бирде. «Операция»нең бөтен детальләрен урынга чыгып нечкәләп сөйләштеләр – билгеләнгән планнан тайпылыш булырга тиеш түгел иде. Менә ул көтелгән минутлар! Берьюлы үзен дә сынап карар. Бу инде сиңа куян куып йөрү генә түгел. Шурик, әнисенең урман каравылчысы булып эшләгән абыйсын искә төшереп, елмаеп куйды. Кем уйлаган бит картлачның кирәге чыгар дип! Шулай да бераз каушата. Төнлә дә йоклый алмады. Раджаның ерак түгел генә үзен көтеп торуы көч бирә, әлбәттә. Тик... Шурикның кулы калтыраса, соңгы мизгелдә үзен аклый алмаса? Алга таба нишләр? Ул бу турыда уйламаска тырыша. Билгеле: алда аны бәхетле, мул тормыш көтә. «Александр Михайлович!.. Нәрсә телисез?!» Менә шуның турында уйларга кирәк. Тизрәк, тизрәк, тизрәк... Үч иткән кебек, минутлар акрын узалар. Аны бит беркем күрергә тиеш түгел. Ярый әле, Раджа вакытны белеп сайлады, бу вакытта инде подъездда кеше йөрми, барысы да эшкә китеп беткәннәр. Әби-бабайларның йә телевизор карап, йә булмаса, намазларын укып, оеп утырган вакыты. Әһе, менә ишек ачыла бугай... Шурик читкәрәк елышты, кесәсендәге пистолетын кулына алды, артка яшерде. Ишектән башта хатын-кыз чыкты, аннан, ачкычларын шалтыратып, Гамир күренде. Шурик бер мәлгә катып калды, чөнки план буенча Гамир берүзе булырга тиеш иде! Каян килеп чыкты бу хатын-кыз?! Менә ул Шурикны күреп алды, Гамирга эндәшә... Шурикның тез буыннары сыгылып килде, аяклары камырдай йомшады. Шулай да көч җыеп, бер адым алга атлады, стена буеннан баскыч төбенә чыкты. Гамир, борылып, йөзе көл төсле агарынган, иреннәре күгәргән Шурикны танып алды, җәһәт кенә аның янына килде.

– Шурик?! Нәрсә булды? Нишләп монда торасың? – Гамирның тавышында, гадәттәгечә, борчылу катыш таләп чагылып китте, тик шунда ул Шурикның кулы артка яшеренгәнен күреп алды. Күзләре очраштылар. Шурикның күз карашы тилергән кешенекедәй томанлы иде.

– Нигә тораммы?! Нигә тораммы?! – Шурик, үз-үзен белештермичә, кычкырына башлады. – Ә менә нигә!

Гамир шул ук мизгелдә егетнең кулы күтәрелгәнен күрде, күкрәгенә пистолет көпшәсе төбәлде, ату тавышы яңгырады. Әйтерсең күзгә күренмәс күсәк белән китереп бәрделәр, Гамирны ниндидер көч артка сөйрәде. Күкрәктән башланган коточкыч авырту бөтен тәнен биләп алды, колакларында су шаулаганы ишетелде. «Алинә! Алинәне сакла!» Тәне буйлап тагын бер тапкыр түзә алмаслык авырту дулкыны узды. Тагы... Күз алдында, дер-дер килеп, Шурикның кулы калтырады, менә пистолет көпшәсе Алинәгә борылды. «Юк! Ю-у-к!» Гамир, бар көчен җыеп, алга омтылды, аягы белән Шурикның пистолет тоткан кулына китереп типте. Ату тавышы таш йортның стеналарына килеп бәрелде, кайтаваз булып Гамирның колагында яңгырады. Шунда ук тимер коралның баскыч буенча шакы-шокы бәрелеп төшеп китүе ишетелде. Шурик бөтен тәне белән калтырый иде. Менә ул артка чигенде, гәүдәсе белән Алинәне каплап, таш идәнгә егыла башлаган Гамирдан күзен алмый, баскычның бер катына төште, аннан борылып, җан-фәрманга урамга чыгып чапты. Гамирның күз күреме тарайганнан-тарайды, колакларында бертуктаусыз су шаулады, котып салкыны бөтен тәнен биләп алды. «Алинә... Алинә...». Үз тавышы үзенә дә ишетелмәде. Бик биектә Алинәнең йөзе барлыкка килде, кызның күзләреннән бертуктаусыз яшь ага, бите канга буялып беткән, күз карашы шашынган иде. «Гамир!.. Гамир!.. Ишетәсеңме мине, Гамир?!» Гамир канга тончыга башлады. Иреннәрен чак ачып, кызга эндәште: «Алинә... Синең исемең Алинә... Гафу ит, Алинә...» Егетнең иреннәре, тагы нәрсәдер пышылдап, ярым ачык килеш катып калдылар. Менә ул үзенең әкрен генә һавага күтәрелгәнен сизде. Таш идәндә кан эчендә егылып яткан үзе дә, шашынып елаган Алинә дә томанга уралды. Тирә-ягын ап-ак нур биләп алды, искиткеч җиңеллек, күңелендә күптән көтелгән тынычлык барлыкка килде. Ниндидер илаһи көч аны алга этәрде. Ак нур эчендә сеңлесе яралды. «Килдеңме, абый. Әйдә, әниләр сине көтә. Без сине барыбыз да көттек». Бала чактагы кебек кулга кул тотынышып, Гамир сеңлесе белән ап-ак нур эченә очты...

...Шурик бер машинадан төшеп, икенчесенә кереп утырды. Машина шунда ук урыныннан кузгалып китте.

– Йә, нәрсә әйтерсең? – дип, Раджа теше-тешкә тими, дер-дер калтыранган Шурикка кечкенә фляга белән аракы сузды.

Аракы Шурикның ирен читләреннән акты, бугазыннан үтмичә, тончыктыра язды. Йотылып-йотылып, тәмен сизми, суга сусаган кеше кебек кинәнеп эчте Шурик. Ниһаять, флягадан аерылып, җиңе белән иренен сөртте, бушап калган савытны Раджага сузды. Калтыравы беркадәр басылган кебек булды.

– Ул хатын-кыз белән чыкты.

Раджаның күзләре түгәрәкләнде, бер кулы белән Шурикның изүенә ябышты. Руль артында утырган егет арткы көзгедән боларга карап-карап алды.

– Сөйлә!

Шурик тотлыга-тотлыга нәрсә булганын сөйләп бирде. Аракы әкрен генә үзенекен итә иде, егет салкыннан җылыга кергән кеше сыман изрәде. Шулай да кулыннан коралын Гамир бәреп төшерүен әйтмәде.

– Аттыңмы икесенә дә?

– Аттым, дим ич. Икесе дә егылды.

– Контрольгә аттыңмы, дим мин?!

– Башларынамы? Үлделәр, дим ич, икесе дә...

Раджа әшәке итеп сүгенде. Аның кәефе киткән иде.

– Кайда тимерең?

– Ыргыттым шунда, этаждагы чүплек савытына.

Раджа теш арасыннан кысып чыгарды:

– Анда чүп төшерә торган урын юк. Мин сиңа нәрсә дигән идем? Кая ыргыттың?

Шурик буталды, авыз эченнән нәрсәдер мыгырдады. Әлеге минутта аны «гонорардан» башка бер әйбер дә кызыксындырмый иде.

– Раджа... Мин барысын да эшләдем. Гамир...

Шурик кулы белән муен тирәсен кысып алды.

– Раджа... Мин кайчан бүләкләнәм инде? Ыйк...

Егет кикерә башлады. Раджа, шулай ук тешен кыскан килеш:

– Хәзер, – диде.

– Хәзер үкме?! Ыйк...

– Хәзер үк.

Машина, шәһәрдән чыгып, урман юлына борылды.

– Кая барабыз? – Шурик аракыдан томанланган карашын тәрәзәгә төбәде, юл кырыенда үскән агач ботаклары машина тәрәзәсенә килеп бәрелә иде.

– Миңа кайтабыз, Шурик. Мондый вакыйганы юарга кирәк ич инде!

Раджа дустанә итеп Шурикның җилкәсеннән какты. Егет аңлаган кыяфәт белән баш селкеде, тынычланып, күзләрен йомды. Шул секундта ук гырлап йокыга талды.

Машина алан кырыенда туктады. Раджа, машинадан чыгып, тирә-якка карангач, Шурик утырган якның ишеген ачты, йөртүче егет исә Шурикны сөйрәп җиргә төшерде. Исерек йокысыннан уянмады да. Раджа югарыдан Шурикка бераз карап торганнан соң, кесәсеннән пистолетын чыгарып, егетнең маңгаена төбәде.

– Менә ничек итеп аталар контрольгә. – Урманны яңгыратып, ату тавышы яңгырады, янәшәдә үсеп утырган агачтан куркынган кош күтәрелеп очып китте. Шурикның гәүдәсе тартышып куйды. – Өйрәттем-өйрәттем, тәки өйрәнмәгәнсең.

– Үзебезнекеләргә кушсаң, яхшырак булыр иде. Бу салага белән проблемалар гына. Үзеңне дә пычратуы бар.

– Гамирдагы кебек «спец»лар юк шул миндә. Кайсыгызның моның урынында буласы килә? – Раджаның күз карашын күтәрә алмый, машина йөртүче егет Шурикка төбәлде.

– Шул шул менә. Ярар, телгә салынма, сөйрә.

Егет Шурик гәүдәсен алдан казып куелган чокыр янына сөйрәп килде, этеп төшереп җибәрде. Туфрак белән күмеп, кисеп алынган үлән кәсләре белән тигезләп каплады. Бу урында кеше гәүдәсе ятуын күрсәткән бер дәлил дә калмады.

Раджа, канәгать йөзен күккә күтәреп, гамьсез генә йөзгән аксыл болытларга эндәште:

– Менә шулай, Гамир. Бер казанга ике депутат башы сыймый. Хәзер инде минем юлда тормассың.

* * *

Күкләрдән соң күпне сорадыммы?
Кулларымда – бәхет тузаны...
Кайгылардан кем дә азат түгел,
Куанычлар көтеп сыкрый күңел –
Гомеркәйләр шулай узамы?

Галиҗәнап вакыт якты микән
Язмышларның кайнар учагын?!
Әй болгатыр идем күмерләрне,
Озынайтыр идем гомерләрне,
Булса тәндә җаным, сау чагым...

Язмыш учагында дөрли күңелем,
Яна яшьлек, яна тормышым.
Бу дөньяга миннән сәлам кала,
Әнкәемнең күз яшьләре анда,
Язмышлардан юк ла узмышым...

*Дүртенче кисәк*

## Рөстәм

...Алинә, күз кабакларына кадәр сызлаганын тоеп, уянып китте. Карашы ап-ак түшәмгә барып төртелде. Нәрсәдер суларга комачаулаган кебек иде, Алинә, борынына, авызына җайлап куелган сулау аппаратын тоеп, хәлсез куллары белән аны алып атты. Шунда ук хлор катыш дару исе борынын ярып керде, куллары үзен уратып алган ниндидер чыбыклар арасында буталды. Янында урындык сыкрап куйды, кемдер аның кулын кысып тотты. Һәрбер хәрәкәткә баш түбәсенең, чигәләренең сызлану белән җавап бирүен җиңеп, Алинә тавыш килгән якка борылды. Үзенә төбәлгән коңгырт-кара күзләрдә борчылу чагыла иде.

– Аллага шөкер, аңга килдегез. Исәнмесез, Алинә. Сез мине таныйсызмы?

Коңгырт-кара күзләрне Алинәнең кайдадыр күргәне бар кебек. Әйе-әйе... Менә ул йөгерә... Егылды... Ә бу ир-ат аның битләреннән тузанны сөртә... Менә хастаханә, дару исеннән кызның күңеле болгана... Тукта әле, ни соң бу?! Бу вакыйгалар Алинәнең тормышында бер тапкыр булды лабаса, тагы кабатланамы? Әллә ул төш күрәме? Йа Хода, нинди газап соң бу?! Алинә шактый вакыт ир-атның нәрсә әйткәнен ишетми-аңламый, хәтерендәге вакыйларны барлап, аның йөзенә текәлеп карап ятты. Кинәт кызның чырае агарынды, күзләре шашынып ачылдылар.

– Гамир... – диде ул, телен көч-хәл белән әйләндереп, – Гамир исәнме?

Егет тынып калды, куллары Алинәнең кулын ныграк кыстылар. Алинә соравын кабатлады. Тик ир-егет җавап бирергә өлгермәде, кыз яткан урыныннан күтәрелде, ачыргаланып кычкырып җибәрде.

– Алмаз! Йа Ходаем, минем ирем! Балам! Йа, Ходаем... Алар да үлделәр бит, үлделәр!..

Кыз яңадан түшәккә ауды, күкрәгеннән газаплы ыңгырашу ташып чыкты, яткан килеш иңнәре белән калтырап үкси башлады. Ир-егет шунда ук янәшәдә торган телефоннан кемнедер чакырды, ул да булмый бүлмәгә табиб килеп керде, мендәрдә бәргәләнеп яткан Алинәнең кулындагы кан тамырын табып, укол кадады. Бераздан кыз тынды, дару сөременә буылып ятса да, күзләре йо-

мылмады. Ап-ак төшәмдә, кинофильм кадрлары кебек, үз тормышы сурәтләнде...

...Алинә авылда, әбисе янында үсте. Әнисен ул бөтенләй диярлек хәтерләми, ә менә әтисен бик тә, бик тә ярата иде. Дөрес, әтисенең айнык чагы сирәк була, тик ул Алинәне беркайчан какмады-сукмады, ачуланмады, булдыра алган кадәр матур киендерде, тәмле ашатты. Эштән һәрвакыт кызмача кайтыр иде, кызын, тезләренә утыртып, аркасыннан сөяр, чәчләрен үрер иде. Алинә дә аны һәрвакыт шундый хәлдә күрергә өйрәнгәнлектән, «Әтиең исерек» диючеләргә исе китмәде. Тик «Әти, әни кайда?» дип сорагач кына, әтисенең күз карашы караңгыланып китә, кызын алдыннан төшереп, «Башка сорама дип әйттем бит инде мин сиңа. Бар, әнә иптәшләрең көтә» дип, җаваптан кача иде. Бары бер тапкыр гына, читкә карап: «Әниең еракта, кызым. Тиз генә кайта алмый әле ул», – дип җавап бирде. «Әллә ул корабта йөзәме?» «Әйе, кызым, корабта йөзә...» – «Ә нигә ул безгә хат язмый? Рафис абый яза бит». – «Рафис абыең шәһәрдә генә яши, анда почта бар, ә диңгездә почта юк шул, кызым, анда хат йөрми». – «Алайса, без әни янына барыйк. Минем диңгезне күрәсем килә». – «Барырбыз, кызым, барырбыз. Тик сиңа үсәргә кирәк башта. Кечкенә балаларны корабка кертмиләр». Шул көннән Алинәнең тизрәк үсәсе, зур буласы килде. Ә менә әбисе әнисе турында сорашканны бөтенләй яратмый иде. Мәктәпкә укырга кергәч тә, классташлары аны: «Син начар кыз, сине әниең ташлап киткән», – дип үрти башладылар. Алинә күз яшьләре аша: «Минем әнием еракта, диңгездә йөзә», – дип кычкыра иде... Бераз зурая башлагач, әнисенең кайтмаячагын акылы белән аңлады, тик ышанасы килмәде. Көннәрдән бер көнне әтисе лаякыл булып исереп, пычранып кайтып керде, йөзе болыттан да кара иде. Кич җитүгә карамастан, Алинәне уйнарга чыгарып җибәрде, үзе калтырана-калтырана әбисенә нәрсәдер сөйләп калды. Алинә, икенче көнне иртән әбисенең шешенеп беткән йөзен күреп, ниндидер куркыныч хәл булганын сизенде, тик сорарга курыкты. Ул көнне барысы да аңа төбәлеп карыйлар сыман тоелды, шуңа күрә мәктәптән дә «авыруйм» дип, иртә кайтып китте. Гаҗәпкә каршы, әтисе өйдә, айнык иде, кызын, алдына утыртып, бик озак сөйде, чәчләрен сүтеп үрде, дәфтәрләрен, көндәлеген карады, кызын мактады. Алинә, тәмам тынычланып, бераздан

урамга уйнарга чыгып чапты. Әкич кайтканда, әтисе тагы исерек, тик барыбер кызын тагы сөеп-яратып, йокларга озатты... Иртән ишегалдында халык шаулашкан тавышка уянып, торырга куркып ятты Алинә. Бераздан әбисе, кереп, Алинәне күрше апасы белән авылның икенче очында торган туганнарына кунакка җибәрде. Туган апасы исә «Әй, сабыем, ятимкәем, бигрәк хәсрәтле бала булып тугансың бит» дия-дия каршы алды, өенә алып кереп, тәм-том белән тулы өстәл янына утыртты. Алинә берни аңламады, балаларча самимилек белән, өстәлдәге кәнфит-прәнеккә үрелде. Шунда туган апасының Алинәдән әз генә кечерәк кызы «Синең әтиең үлгән бит, нигә еламыйсың?» дип сорамасынмы?! Алинә апасын ничек бәреп чыгып чапканын да хәтерләми, тыны кабып, өйгә кайтып кергәндә, берничә ир-ат йөзе күгәргән, авыз читләрендә, колак кырыйларында кара кан укмашып каткан, теле салынган әтисенең үле гәүдәсен урынга салып маташалар иде. Алинә катып калды, куркып-кычкырып, аңын югалтып егылды...

Ул вакыйгалардан соң инде күп вакытлар узды, Алинә зур кыз булды. Әнисенең бер хәрби офицерга ияреп, үзен имчәк баласы чагында ук ташлап китүен, шуннан соң хәбәре-хәтере булмавын, әтисенең эчүгә сабышуын, исерек килеш трактор белән күпер өстеннән суга төшеп китүен, үзе котылса да, трактор батканга күрә озакка төрмәгә утыртуларыннан куркып, асылынып үлүен белде. Алар әбисе белән икесе генә яшәделәр. Ике бөртек кешегә күп кирәкми иде, ләкин әбисе кечерәк мал-туар, тавык-чебеш асрады, артканны күрше-күләнгә сатты йә колхозга тапшырды – шуңа күрә Алинә балачактан ук эшкә, хуҗалыкка өйрәнеп үсте, яхшы укыды, өсте-башы да кешенекеннән ким булмады. Әбисенә бик рәхмәтле иде Алинә, югары уку йортына укырга керү теләге булса да, әбисен ташлап китәсе итмәде. Әбисе исә, көчләп диярлек чемоданнарын тутыртып, Алинәне юлга озатты. «Укы, кызым, кеше бул» диде... Тик шуннан соң озак яшәмәде – Алинәне тетрәндереп, озак кына үлем белән тартышып ятканнан соң, якты дөньядан китеп барды. Алинә берүзе калды. Күңелендә әнисен эзләп табу теләге бик көчле булса да, шул ук вакытта аңа кире хис – рәнҗү хисе дә калкып чыгып, Алинәне туктата иде. Бераздан исә Алмазны очратты. Күзләре янып торган егеткә Алинә бер күрүдә үк гашыйк булды, бераз вакыт дуслашып йөргәннән соң,

өйләнешеп тә куйдылар. Бу вакытта илдә авыр заманнар кузгалды, яшь гаиләгә вакыт-вакыт бик кыенга туры килә иде. Кызлары туган елны икесе дә укып бетерделәр, Алмаз яхшы гына урынга эшкә урнашты. Алинә дә, кызы белән ике ел өйдә торганнан соң, укытучы булып эшли башлады. Дөнья түгәрәкләнеп киткән иде...

Алинә, шуннан соңгы сурәтләрне күрмәс өчен, күзләрен чытырдатып йомды, битен яндырып, тагы яшьләр агып төште. Юк, күпме генә «оныттам» дисә дә, онытылмаган ул фаҗига, онытылмаган...

...Якшәмбе көн иде. Алмазның көтеп алынган ялы башланды. Алинәнең дә, иртә таңнан торып, мәктәпкә чыгып чабасы юк. Кечкенә кызлары Айсылуны дә балалар бакчасына кем илтәсен бүлешәсе түгел. Тик шаян кызчык барысыннан да иртәрәк уянган да, түшәктән торырга теләмичә, йокы кочагында иркәләнеп яткан әтиәнисенең юрган итәгеннән тарткалый.

– Әти! Әти! Әни! Толыгыс инде! Миңа күңелсес! Әни! Әни!

– Кызым, йоклыйк инде аз гына, әле бик иртә бит.

Айсылу бирешми, әтисенең колакларын уа, борынын кыскалый, чәченнән тарта.

– Әти! Тол инде! Син миңа кисә нәлсә тигән идең?!

Алмаз авыз эченнән нәрсәдер мыгырдана да башыннан ук бөркәнеп ята. Айсылуның бар өмете – әнисе. Әнисенең мендәргә сибелгән коңгырт-кара чәчләрен җыя, кечкенә бармаклары белән күзләрен ачмакчы итә.

– Әни! Әти кисә улманга балабыс тиде! Әни! Әйдә толыгыс инде, сәй эсәсем килә! Әни!

Ниһаять, Алинә кызының кулларын әләктереп ала, кечкенә бармакларын үбә-үбә, яткан килеш Айсылуны күкрәгенә кыса.

– Әйдә, тагы әзрәк йоклыйбыз, кызым. Аннан соң торырбыз.

Айсылу, тыпырчына-тыпырчына, әнисенең кочагыннан ычкына, карават очына барып, юрганны сөйри башлый. Ниһаять, Алинә торып утыра, халатын бөркәнә, ул да булмый, кызы, кулыннан тотып, үзләре яшәгән тулай торакның коридорына алып чыгып китә...

...Бөҗәкләр безелдәвеннән, чикерткә, кошлар сайравыннан урман яңгырап тора. Табигатьнең кышкы торараташ хәленнән җанлану вакыты һәр күзәнәктә чагыла, һәрбер үсемлек, һәрбер бөҗәк, һәрбер җан иясе кояшның

җылы нурларыннан көч алып, нәселен дәвам итәргә юл эзли. Яфракларның үтә яшел төсе әле дөнья тузаны белән пычранырга өлгермәгән, әле яңа яралган тереклек иясе алдагы тормышның куркыныч борылышларын татымаган... Әле җәйнең дә таң вакыты гына... Алинә, болында күбәләк куып йөргән кызын күзәтә-күзәтә, җай гына Алмаз итәгендә кырын ята, Алмазның көлә-көлә нәрсәдер сөйләгәнен дә тыңламыйча, җан тынычлыгы рәхәтенә чумган... Иртәгә мәктәпләрдә соңгы уку көне, аны идеалларын, кыйбласын югалткан укучылар мәхшәре көтә, ул аларга киләсе елда да белем-тәрбия бирергә тиеш... Дөресрәге, белем бирергә тиеш... Тәрбияләүне хәзер мәктәп үз өстеннән төшерде, тик бу укытучының эшен шулкадәр кыенлаштырды гына... Иртәгә эш хакы бирәсе көн, тик аны инде өч ай бирмиләр... Иртәгә бирерләр дигән өмет юк. Иртәгә аны тулай торакның кысан бүлмәсе каршы алачак, тик бу әһәмиятлемени?! Алинәнең дөньясы түгәрәк, бүген Алинә бәхетле! Зәп-зәңгәр биек күккә борылды да, эченнән генә: «Йа Рабби, Ходаем, мәңге тынычлык, мәңгелек бәхет бир! Булган бәхетемне күпсенмә миннән! Күпсенмә! Мин аны бик көтеп алдым! Йа Рабби, Ходаем!», – диде. Тик нишләптер шул мизгелдә үк күңеленә салкын йөгергәндәй булды, әбисенең әйткән сүзләре искә төште: «Кызым, теләк теләсәң, Ходайдан үзеңә генә сорама, бар тереклек иясенә бирсен Ходай, дип әйт. Шөкер кылырга онытма!»

– Әни, бу сәсәкләлне мин сиңа сыйдым!

Алинә чәчәкләре белән кызын кочып алды, эченнән генә әбисе артыннан кабатлады: «Бар тереклек иясенә бәхет бирсен Ходай! Амин!»

...Шәһәргә төштән соң гына кайттылар. Инде кайтып җитәргә дә күп калмады, тик һаман аларга кирәк трамвай күренми. Айсылу көне буе чәчәк җыеп, күбәләк куып арыган-талган, кайтканда ук йоклап китте, хәтта автобустан төшкәч тә уянмады. Хәзер дә әтисенең җилкәсенә башын салган килеш кымшанмый да. Алмаз үзе дә арыган инде, кызын күтәргән хәлдә трамвай тукталышында җиргә чүгәләгән. Трамвай күренми.

– Алинә, киосктан су алып кил әле, зинһар. Эчәсе килә. Уянгач, Айсылу да сорар.

Алинә, елмаеп, баш какты. Үзләре белән алган суларын, ашамлыкларын күптән ашап-эчеп бетерделәр шул.

– Хәзер.

Тукталыш юл уртасында урнашкан иде, машиналар узып киткәнен көтеп, Алинә каршы якка киоскка таба атлады. Су сатып алды, Айсылуга кечкенә генә шоколад та аласы килде. Бәйрәм бәйрәм булсын инде, шоколадны еш ала алмыйлар кызларына. Кинәт артында гына, машиналар шавын басып, шомлы, үзәк өзгеч тавыш белән кемдер кычкырды. Алинә ялт итеп борылды. Тукталышта трамвай көткән кешеләр, ниндидер ташкыннан өркегән җәнлекләр шикелле, тирә-якка сибелә башладылар, кайсыберләре Алинәнең күз алдында, юлдан барган машиналар астына килеп кереп, һавага чөелделәр, асфальт буенча тәгәрәделәр. Тукталышның икенче башыннан, берни абайламаган кешеләрне сыта-изә, коточкыч тизлектә «Волга» машинасы якыная иде.

– Алмаз! Ал-ма-ааз!

Алмаз күрми, ул икенче якка борылып чүгәләгән. Шуннан соң Алинәнең секундлары сәгать булып сузылды. Дөнья тавышы тынды, суы төшеп китте, куллары үзеннән-үзе иренә таба сузылды. Аның күз алдында җиргә чүгәләгән Алмаз белән Айсылуга тимер машина килеп бәрелде, җиргә сылап, өсләреннән узып китте. Тагы берничә кеше машина астында калды. Яртылаш бөгәрләнеп җирдә аунаган ире белән кызы канлы тап булып Алинәнең күз алдында бөтерелә башлады...

...Дөнья ыңгырашкан, ярдәм сорап кычкырган тавышлар белән тулы. Тирә-якта машиналар кычкырта. Алинә, яралы кешеләр өстеннән атлый-атлый, Алмаз белән Айсылу яткан урынга якынлаша. Юк, ул һавадан оча бугай. Тик күкрәк турысы, таш тутырган капчык кебек, җиргә сөйри. Ул бит курка, каннан курка. Алмаз, Айсылуны кочаклаган килеш, тынсыз калган. Менә санитарлар Алмазны да, Айсылуны да, носилкаларга салып, машинага кертәләр. Алинә дә аларга иярмәкче була, тик аңа нәрсәдер әйтәләр, кертмиләр. Алинә баш чайкый: бу – аның ире белән кызы, ул алар белән булырга тиеш! Яшел халатлы врач берара Алинәгә карап торгач, кызның кулын табып, ниндидер укол ясый. Шуннан машина эченә күрсәтә: урын юк. Больницага башка транспорт белән барырга кирәк. Больницага. Шуннан соңгысын Алинә начар хәтерли: өенә кайтуын да, өстен-башын алыштырып, ак халат алып, хастаханәгә килүе дә ничектер әллә булган, әллә булмаган... Кабул итү бүлмәсендә үзе кебек үк бәлагә тарыган кешеләр җыелган. Менә врач, чыгып, үлүчеләр

исемлеген укый. Кемдер елый башлый, кемдер аһылдый. Кемнедер әле өйдә көтәләр – билгесезләр шактый. «Галимов Алмаз». Алмаз. Галимов. Үлгән. Юк, моның булуы мөмкин түгел. Алар бит көндез генә бергә иделәр, чәчәк җыйдылар. Алинә башка түзә алмый, юлында торган кешеләрне бәргәләп, урамга чыгып чаба... Мөмкин түгел. Бу – төш. Онытырга кирәк бу төшне. Онытырга. Ул көндез генә зәңгәр күккә ялварды, «Йа Ходаем, бәхет бир!» диде. «Бөтен кешеләргә дә бир!» диде... Шулай булгач, моның булуы мөмкин түгел. Урманга йөгерергә кирәк, Алмаз белән Айсылу калган болынга. Йөгерергә. Тизрәк. Тизрәк...

* * *

...Нәрсә өчен, кем өчен яши инде ул хәзер?! Әти-әнисе юк, әбисе мәрхүм, ире, кызы – барысы да кеше аңы барып җиталмас урында. Хәтта Гамир булып Гамир да аны калдырып китте. Нигә кирәк бу дөнья?! Нәрсә күрде ул яшәү дәверендә?! Кирәкми аңа бу тормыш. «Йа Хода, мин ирекле рәвештә тормыштан баш тартам. Кемгәдер, бик кирәк җан иясенә бир минем гомеремне. Мин арыдым...»

Алинәнең күзләрендә яшьләр кипте, күңеле ничектер урынына утырган кебек булды. Ул катгый карарга килгән иде. Тик башта ире белән кызының каберен эзләп табып, алар белән сөйләшеп кайтасы бар. Эчәсе килә икән. Урыннан кымшануга, янындагы урындык тагы шыгырдап куйды, ягымлы гына ир-ат тавышы ишетелде:

– Алинә... Үзегезне ничек хис итәсез?

Оныткан да икән, аның янында теге вакытта очраган ир-ат утыра ич. Кем икән ул?

– Сез кем?

Ир-ат, кечкенә өстәл өстендә торган графиннан әзрәк су салып, стаканны Алинәгә сузды.

– Рөстәм. Кушаматым Кактус. Бәлки, Гамирдан ишеткәнсездер минем турында?!

Кактус... Әйе, Гамир сөйләде аның турында. Бик яхшы егет, минем иң ышанычлы кешем, диде. Эшкә чыккач, таныштырырмын сезне, диде. Бүген Алинә беренче мәртәбә офиска эшкә чыгасы иде... Аһ, Гамир...

Алинә көрсенеп куйды. Ул инде кем турында кайгырырга да белми. Шуңа тонык, ваемсыз тавыш белән Кактустан сорап куйды:

– Гамирны кайчан күмәләр?!

– Гамирны җирләдек, Алинә. Сез ике атна аңга килми яттыгыз.

Димәк, Гамирны да соңгы юлга озата алмый калды. Ике атна... Ире белән кызын кемнәр җирләде икән инде?! Казанда туганнары да юк бит. Алмазның әнисе Төрекмәнстанда яши, чикләр ябылгач, Алинә дә, Алмаз үзе дә кайта алмадылар. Әнисе хәбәр алды микән, килде микән улын күмәргә?!

– Бүген нинди көн?

– Октябрьнең бише. Урамда матур һава, икенче әбиләр чуагы җитте. Сезгә тизрәк терелергә кирәк, күңелегезне төшермәгез, Алинә.

Димәк, мәктәптә дә укулар башланган. Алинәне эзләделәр микән?! Кинәт кызның хәтерендә Гамирның үләр алдыннан пышылдаган сүзләре яңардылар. «Алинә... Синең исемең Алинә... Гафу ит, Алинә...». Гамир белгән, Алинәнең кем икәнен белгән. Шулай булгач, кемдер Алинәне эзләгән. Яисә таныган. Нигә Гамир әйтмәде икән?! Аһ, Гамир... Күрәсең, Алинәгә авыр хәбәр әйтәсе килмәгән инде. Алинәнең әлегә кадәр ышанасы килми...

Кактус Алинәнең күзләрендә чагылган кайгыны яртылаш үзенә алырдай булды. Язмыш аларны юл буенда бик гаҗәп рәвештә очраштырганнан соң, Алинә егетнең күңеленә кереп калды, кич буе, төне буе кызның ялварулы яшькелт-зәңгәр карашы Рөстәмнең күз алдыннан китмәде. Икенче көнне үк кызны калдырган больницага барып эзләде, тик кыз суга төшкәндәй юкка чыккан иде. Шуннан бирле Кактус гел яшькелт күзле кызларга игътибар итә торган булып китте. Инде кызның төсе-кыяфәте егетнең хәтереннән җуела да башлаган бер мәлдә (кем уйлаган бит!), язмыш аларны якын дустының мәете өстендә кабат очраштырды... Менә кем турында сөйләгән икән Памир! Ул бит Кактустан Алинә турында гомере буе кайгыртырга, ярдәм итәргә сүз алды. Күрәсең, Памир үлем якынлашуын сизгән. Кактус үзе дә ерак йөрми ул ак киемле агайдан. Тик Алинә өчен аның белән бил алышырга да әзер. Ә менә кызның күзләре сүнгән, өметсезлек, чиксез кайгы керфекләренең һәр бөртеге арасына яшеренгән.

– Алинә... Бүген хәл җыегыз, тынычланырга тырышыгыз. Сезнең белән бик җитди мәсьәләләр турында сөйләшәсе бар. Үз-үзегезне саклагыз, зинһар, сез әле бу дөньядагы кайбер кешеләргә бик кирәк. Сау булыгыз, Алинә.

Кактус чыгып киту белән, палатага шәфкать туташы килеп керде, Алинәнең төшәгән күтәребрәк, мендәрен утырырга җайлап куйды. Сөялеп утырырга теләсә дә, Алинә үзе генә урыныннан күтәрелә алмады, шәфкать туташы белән бергәләп, ничек кирәк алай түшәктән бераз күтәрелделәр. Алинәнең бертуктаусыз башы әйләнде, тәненең һәрбер күзәнәге сыкрап авырта, кычыта иде. Су сорады, тик күпләп эчәргә туташ рөхсәт итмәде.

– Сез бит ике атна ашамаган-эчмәгән килеш, аңлагыз инде, – диде ул. – Әкренләп күнегергә кирәк. Тормышны тәэмин итү аппаратына тоташтырылган идегез, бик зәгыйфь әле сез. Шундый туганыгыз булу зур бәхет инде, сезнең өчен бик тырышты Рөстәм Исламович.

– Нинди туганым? – Алинә, аңламыйча, шәфкать туташына борылды.

– Яңа гына чыгып киткән туганыгыз. Сез яткан көннән башлап, һәр көн бер-ике сәгать сезнең янда утырып китте ул... Ашыйсыгыз киләдер, беләм, тик бүген сезгә ашау булмаячак. Кичке якта җылы сөт алып керермен.

Бераздан палатага санитарлар кереп, Алинә караваты янында торган зур аппаратны алып чыгып киттеләр. Шәфкать туташы да, «кирәк булсам, менә бу төймәгә басарсыз» дип, палатадан чыкты. Кыз үз уйлары тоткынында калды...

...Алинә аякка басканчы шактый вакыт үтте әле. Күрәсең, тәненең бик талчыккан булуыннанмы, әллә тормышта гаме калмагангамы – һәрбер адым, һәрбер сулыш Алинәгә авырлык белән бирелде. Кактус – Рөстәм – көн саен килеп йөрде, әйтер сүзе булмаганда да, тын гына Алинә янында утыра иде. Кайчагында Алинә аны күрми дә сыман, күзләрен түшәмнән алмыйча, үз дөньясында йөзә. Эндәшми, зарланмый, еламый, ләкин шәфкать туташлары сорауларына да бик авырдан кубып җавап бирә. Рөстәм аның бу халәте алдында чарасыз калды. Әлбәттә, кызның фаҗигале язмышын белә, тик күңел юатырдай сүзләр таба алмый, гомумән, бу турыда сүз башларга курка. Нәрсә дип юатсын инде ул аны? «Мин сиңа үлеп гашыйк, Алинә, тизрәк терел» дисенме? Яисә «Сине кибетләрең, акцияләрең, коттеджың, квартираң көтә» дисенме? Алинәне бу дөньядагы байлык та, бу дөньяның кешеләре дә кызыксындырмый, аның дөньясы, аның сөйгән кешеләре – барысы да яшәешнең икенче ягына күчтеләр. Бу дөньяда Алинә ялгызы. Рөстәм моны бик

яхшы аңлый, шуңа чарасызлыктан нишләргә дә белми аптырый иде...

Менә Алинә хастаханәдән чыгасы көн җитте. Соңгы кәгазьләрне шәфкать туташыннан алгач, Алинә, киенеп, үзен көтеп торучы Рөстәм янына төште. Сак кына кулыннан тотып, егет кызга машинага утырырга булышты, әкрен генә кузгалып киттеләр. Рөстәм, нәрсәдер әйтергә теләгән кеше кебек, Алинәгә карап-карап ала, тик әйтә алмый, кызның сүз башлаганын көтә. Алинә исә тәрәзә янында йомылып утыра бирә. Ниһаять, машинаның тулай торак урнашкан урамга керми узып китүен чамалап эндәште:

– Безгә уңга борылырга кирәк иде, Рөстәм. Узып барабыз бугай.

Рөстәм машинаны юл читенә чыгарып туктатты да Алинәгә таба борылды.

– Алинә, беләсезме... Мин сез яшәгән тулай торакта булдым инде. Сез хәбәрсез югалганнан соң, әйберләрегезне бүлмәдән чыгарганнар. Сакланып калган кайбер шәхси истәлекләрне, кайбер киемнәрегезне тартмага тутырып, саклау бүлмәсенә төшергәннәр. Мин аларны табып, Гамир квартирасына кайтарып куйдым.

Рөстәм көрсенеп алды, Алинәнең күзләренә туп-туры карап, катгый итеп әйтте:

– Сезнең бүлмәдә хәзер башка кешеләр яши, Алинә. Анда хәтта стена кәгазьләре дә башка. Күршеләрегезне күрү сезгә бу минутта кирәктер дип уйламыйм. Әйдәгез, Гамир квартирасына кайтыйк.

Алинә баш какты. Их, елый алса иде икән. Юк шул, тамак төбенә ком утыргандай, авыз ачып эндәшергә, сулыш алырга да ирек бирми, күкрәкне кыса...

Алинә буш квартирага кайтып керүдән бик курыккан иде. Ярый әле, Рөстәм Камиләттәйне чакырган.

– Кайттыгызмы, балакайлар, – диде ул, ишек ачылу белән. – Әйдә, кызым, уз. Хәзер чәйне яңартам.

Җәһәт кенә атлый-атлый, Камиләттәй аш бүлмәсенә кереп китте, шунда ук чынаяк-чәйнек шалтыратканы ишетелде. Алинә Рөстәмгә мең-мең рәхмәтле иде. Гамирның юклыгы ук булып кадалмасын дигәндер инде. Йа Алла, каминда шулай ук ут яна, аквариумдагы балыклар да исән-сау, дөньяда бер гамьнәре юк сыман, су өстендәге күбекләрне җыеп йөриләр... Йокы бүлмәсендә берничә зур-зур тартма тора. Димәк, Алмаз белән Алинәнең тор-

мышы шушы тартмаларга сыеп беткән. Ә стенадагы кечкенә кызчык, күзләреннән чаткылар чәчрәтеп, көлә дә көлә... Алинә, йөрәгенә ут капканын сизеп, тизрәк бүлмәдән чыкты.

Чәй янында күбрәк Гамирның җеназасы турында сөйләштеләр. Үтерүчене тапмаганнарын белеп, Алинә шаккатты.

– Ничек инде тапмаганнар?! – диде ул. – Мин аны күрдем. Аны минем элек тә күргәнем бар иде – Гамирның альбомында. Үзегезнең кеше ул!

Рөстәм агарынып китте. Алинә шунда ук, залга чыгып, калын гына альбом алып керде. Берничә битне ачкач, Гамир белән иңгә-иң тотынып төшкән җирән чәчле егеткә күрсәтте.

– Менә ул!

– Шурик?! – Рөстәмнең гаҗәпләнүе йөзенә чыкты. – Алинә, сез ялгышмыйсызмы?! Бу бик әһәмиятле бит!

– Юк, Рөстәм, ялгышмыйм. Нәкъ үзе. Хәтта киемнәре дә шул ук иде.

Рөстәм бераз тын утырды. Димәк, шик-шөбһәләр дөрескә чыга – Раджа. Шурик, күрәсең, күптән инде җир куенында. Ә өендә «командировкада» дип көтәләр. Ә бит Гамир сизгән – Шурикның ниндидер кырын эш йөрткәнен белеп, күзәтү куйдырды ул. Үзенә каршы булуы мөмкин дип уйламагандыр инде. Якын күрә иде ич Шурикны. Аһ, Шурик...

– Нишләп тикшерүче минем янга килмәде икән соң? Мин шунда ук күрсәткән булыр идем. – Алинә, аптырап, Рөстәмгә борылды.

– Чөнки сез үлдегез, Рита. Гамир белән бергә сезне дә атып үтерделәр. – Рөстәм, кутәрелеп, Алинәгә текәлде. – Сабирова Маргарита Гайнановна – Гамирның сеңлесе – үле.

Камиләттәй эченнән укынып алды. Алинә авыр сулап куйды.

– Курыкмагыз, зинһар, Алинә. Хәзер сез үзегезнең исемегезне белгәч, ул уйдырма шәхеснең кирәге калмады, шулай бит?! Ә менә сезнең иминлек куркыныч астында иде. Үтерүче йә булмаса үтертүче тиешле җәзасын алыр, Гамир истәлеге белән ант итәм!

Рөстәмнең бармаклары йодрыкка җыелдылар, йөзе нәфрәт уты белән янды. Шактый вакыт һәркем үз уена чумып, дәшмичә утырды. Бераздан Рөстәм Камиләттәйдән

гафу үтенеп, Алинә белән икесен генә калдыруын сорады. Камиләттәй шунда ук аңлаган кыяфәт белән: «Әлбәттә, улым, хәзер», – дия-дия, залга чыгып, телевизор кабызды.

Рөстәм, бераз дәшми утырганнан соң, Алинәгә күтәрелеп карады:

– Алинә... Сез беләсе тагы кайбер нәрсәләр бар.

Алинә, үз уйларына чумып, мөкиббән китеп утыра иде. Сискәнеп куйды, беркадәр шикләнеп, Рөстәмгә текәлде. Тагы нәрсә булырга мөмкин?!

– Беләсезме, Алинә, сез Памир квартирасына түгел, сез үзегезнең квартирагызга кайттыгыз. Бу квартира сезнеке.

Алинә аңламады, шуңа сораулы карашы белән Рөстәмгә текәлгән килеш тын гына утыра бирде.

– Үләр алдыннан Памир үзенең булган бар мал-мөлкәтен сезнең исемгә яздырды. Хәтерлисезме, Памир сездән кайбер кәгазьләргә кул куйдырган иде?

Әйе, хәтерли Алинә. Тик Гамир бит аны «эшкә чыгу өчен кирәкле документлар» дип аңлатты. Димәк...

– Сез бу квартираның тулы хуҗабикәсе. Ләкин алай гына да түгел. – Рөстәм, бик әһәмиятле сүз әйткәнен аңлаган кыяфәттә, дәвам итте. – Сезнең карамакта тагы шәһәр читендәге коттедж, янындагы гаражда джип машинасы һәм инде сез күргән «Киа Кларус» бар. Тагы Памир карамагындагы берничә кибетне әйтергә була. Ләкин болар барысы да аның акцияләре һәм кыйммәтле кәгазьләре янында бернәрсә дә түгел. Памир безнең һәрберебездән акыллырак, алдан күрүчән иде. Шуңа күрә аның төп байлыгы – алмаз һәм нефть табу компанияләренә салынган акцияләрдә, кыйммәтле кәгазьләрдә. Сез хәзер шәһәребезнең иң бай ханымнарының берсе, Алинә.

Алинәнең күз алдына Гамирның елмаюлы йөзе килеп басты. «Мин бизнесмен – эшмәкәр». «Мин эшләмим, минем өчен акча эшли». Аһ, Гамир, син, әлбәттә, гомереңне кеше булуга – ирекле булуга багышлагансың, тик бушка... Әгәр нәселең калмый икән, бу байлыкны үзең белән алып китеп булмый. Нигә, нигә өйләнеп балалар үстермәдең икән син, кадерле абыем?!

Алинә көрсенеп куйды, башын чайкады. Рөстәм бу турыда сүз башлавының иртәрәк икәнен аңлап алды. Ярар, әйтеп бетерсен инде. Барыбер кайчан да булса Алинә белергә тиеш.

– Алинә, Гамир боларның барысын да үзенең сеңлесенә яздырды. Мин хәтта каршы да килгән идем. Тик ул үзенчә хәл итте. Бу – аның үләр алдыннан әйткән соңгы сүзе, әманәте. Сез шулай кабул итәргә тиешсез.

Алинә, нәрсә әйтергә белми, тукталып калды. Аһ, Гамир... Дөньяның бар байлыгы да синең очкыннар чәчеп елмаюыңа тормый бит, Гамир! Әгәр шул байлык бәрабәренә синең үзеңне, ирем белән кызымны кайтарып булса иде... Соңгы юлга чыкканда Алинәгә байлык кирәкми.

– Рөстәм, мин эшмәкәр түгел бит, мин – укытучы. Шул хәлемдә үлгәнче калырмын дип уйлыйм. Аннан соң бу байлык миңа бәхетемне кире кайтармаячак. Гамирны да байлык бәхетле иткәндер дип уйламыйм. Шуңа күрә Гамирның мөлкәтен балалар йортына тапшырсагыз әйбәтрәк булыр. Минем абыем моны аңлар дип уйлыйм. Күрәсез – үзем тапкан мал түгел – димәк, мин аның кадерен дә белмим.

– Юк, юк, Алинә, әлегә бернәрсә хәл итмәгез! Мин сезгә бары информация рәвешендә генә әйттем. Балалар йортына килгәндә, Гамир анда әз акча күчермәде, тик ул акча кайбер тирән кесәләргә генә кереп ята. Гамир бу проблеманы бер кеше иганәлегеннән чыгып кына хәл итеп булмаганлыгын аңлады, Алинә. Бу – дәүләт проблемасы. Ә сез үзегез турында, үзегезнең киләчәгегез турында уйларга тиеш! Гамирның әманәтен аяк астына салмагыз, зинһар. Аның эшен дәвам итәргә тиешсез. Сез әле яшь, сезнең гаиләгез, балаларыгыз булыр...

Юк, Рөстәм ялгышты. Болай әйтергә ярамый иде. Шунда ук кызның күзләре томанланды, керфекләре аска төште. Менә бит сөйләшә белмәү нишләтә, их! Рөстәм тизрәк сүзне икенчегә борырга ашыкты.

– Алинә, Гамир миңа да абыем кебек якын иде. Шулай булгач, сез дә миңа үз сеңлем кебек. Мин сезгә гомерем буе хезмәт итәргә әзер. Әгәр сезгә нинди дә булса ярдәм кирәк булса, мин минут эчендә килеп җитәрмен. Камиләттәй әлегә сезнең янда торыр, бу турыда сөйләшенгән. Мин хәзер китәрмен инде, кайбер ашыгыч эшләр көтә.

– Рәхмәт, Рөстәм. Сез болай да миңа бик күп ярдәм иттегез – мин сезгә бик рәхмәтлемен.

Чыгып китәр алдыннан Рөстәм Алинәгә тагы киңәшләр бирде:

– Алинә, зинһар өчен, беразга булса да, квартирадан үзегез генә чыгып йөрмәгез. Подъездны егетләр саклыйлар, шулай да үзегез дә саклык турында онытмасагыз иде. Әгәр ишеккә шалтыратсалар, ачмагыз. Мин килер алдыннан – ишек төбеннән башта телефонга шалтыратырмын. Камиләттәй дә шулай итәр. Әгәр шикләнерлек хәл сизәсез икән – шунда ук миңа шалтыратыгыз. Ярыймы?

– Ярый. – Алинә бу кадәр саклыкны һич кирәксез дип саный иде, шулай да бәхәсләшмәде.

Рөстәм артыннан ишек ябылгач, Камиләттәй белән өстәлне җыештырып, савыт-сабаны юдылар. Алинә бу җор күңелле хатынның монда булуына куанса да, бүген аңа ялгызы гына калырга кирәк.

– Камиләттәй, ачуланмагыз инде, – диде ул, гаеплерәк тавыш белән, – бүген мин берүзем генә калырга телим. Кайбер әйберләрне карыйсы бар. Аңлагыз инде.

– Мин аңлыйм, кызым, аңламаган кая инде, балакай! Нишлим соң, Рөстәмнән сорамый китә алмыйм бит. Монда бул, диде ләбаса!

– Алайса, хәзер мин үзем аңа шалтыратып сорыйм.

Рөстәмне күндергәч, Камиләттәй китте. Алинә өс-башын алышты, Гамир бүләк иткән өй халатын киеп алды да тартмалар янына килде...

* * *

...Хастаханә, прокуратура һәм суд арасында йөреп, Алинә хәлдән таеп бетте. Гамир квартирасына кайтканның икенче көнендә үк ул Алмаз белән кызы калган хастаханәгә барды, ләкин хастаханәдә Алмазның җәсәден үлем йортына – моргка – озатылганын әйттеләр, ә кызы турында, гомумән, бернинди мәгълүмат та юк иде. Алинә, тешен кысып, үлем йортына юнәлде. Тик анда ире һәм кызының мәете турында мәгълүмат бирүдән баш тарттылар, «моның өчен судтан яисә прокуратура тикшерүчесеннән рөхсәт кәгазе кирәк» диделәр. Судья Алинәгә прокуратурага мөрәҗәгать итәргә кирәклеген аңлатты. Прокуратура тикшерүчесе Алинәнең кем икәнен ачыклаганнан соң, Алмазның үлеме буенча кузгатылган җинаять эше төгәлләнеп, судта каралганын әйтте, машина йөртүченең исерек хәлдә кеше үтерүдә гаепле танылганын һәм төрмәгә утыртылуын аңлатты. Алмазның кайда күмелүе

турындагы мәгълүматны тикшерүче берничә көннән соң гына, Алинәнең гаризасы буенча тиешле күрсәтмәләр җибәреп, аларны алганнан соң гына хәбәр итәчәген белдерде. Алинә моңа әзер түгел иде. Ниһаять, шактый вакыт үтенеп-үтенеп сораганнан соң, тикшерүче үлем йортына җибәреләсе кәгазьләрне Алинәнең үзенә бирде, «шулар буенча сезгә җавап бирергә тиешләр» дип аңлатты. Кыз яңадан моргка юнәлде. Анда Алинәне тагы да тетрәткән яңалык көтә иде. Иренең җәсәде өч ай буе үлем йортында яткан, аны күмәргә теләк белдерүче булмагач, иренең исем-фамилиясе билгеле булуга карамастан, аерым номер белән билгесезләр каберлегенә күмәргә карар чыгарганнар. Шунда эшләүче җыештыручы хатын, исем-фамилиясе буенча Алмазның мөселман икәнен ишетеп, мәчеткә хәбәр иткән, мәчет әһелләре Алмазны мөселман кануннары буенча татар зиратына җирләгәннәр... Ә кызының җәсәде үлем йортына бөтенләй кабул ителмәгән...

Алинә өйгә көч-хәл белән кайтып егылды. Авыр, бик авыр булды аның көне. Таш тутыргандай, күкрәк читлеге торараш булып катты, суларга һава җитмәде. Камиләттәйнең сораулы карашына да җавап бирмәде, мөлаем карчыкның юату сүзләре дә ярдәм итмәде, Алинә гүя аларны бөтенләй ишетми иде. Аякларын көч-хәл белән кыймылдатып, аш бүлмәсенә чыкты, кара итеп ясалган бер чынаяк чәйне эчте дә яңадан йокы бүлмәсенә кереп бикләнде. Камиләттәй курка калды, Рөстәмгә шалтыратты. Ярты сәгатьтән Рөстәм өстәл артында утыра иде инде.

– Улым, нәрсәдер булган Алинәгә, – диде Камиләттәй, – тавышында эчкерсез борчылу ишетелде. Күрәсең, ул да эченнән өзгәләнә. – Нәрсәдер ишеткән, ахры. Бик куркам, балам, сөйләшми-эндәшми дә, үз-үзенә кул салмаса ярар иде...

Рөстәм сак кына йокы бүлмәсенең ишеген шакыды, җавап ишетелмәгәч, Алинәгә эндәшеп, тагы ныграк шакырга тотынды, ишекне этеп карады. Ишек эчтән бикле иде. Алинә җавап бирмәде. Рөстәмнең эченә шом йөгерде. Бар көче белән ишекне берничә тапкыр бәреп, эчке келәсен ватып, бүлмәгә атылып керде. Артыннан Камиләттәй иярде. Кыз юрган белән томаланган, киң караватта җан әсәре сизелми дә. Рөстәм тиз генә баш турысыннан юрганны ачып җибәрде. Алинә, күкрәгенә ире һәм кызы белән төшкән рәсемне кысып, тын гына, сыкрап-өзгәләнеп елый иде, әйтерсең ул аларны күрми дә.

Бөтен бите, мендәре күз яшенә манчылган. Рөстәм җиңел сулап куйды. Юк, Алинәнең берүзен калдырмаячак ул башка. Ә менә елавы әйбәт, ичмасам аз гына булса да күңеле йомшарыр. Шулай да табиб чакырырга кирәк. Рөстәм, куен кесәсеннән телефон кенәгәсен алып, кирәкле номерны тапты, ишарәләп, Камиләттәйгә шалтыратырга кушты. Үзе Алинә караваты читенә барып утырды.

– Алинә, – катгый итеп әйтергә тырышса да, Рөстәмнең тавышы йомшак ишетелде. – Алинә, мине тыңлагыз әле, зинһар.

Алинәгә күз яшьләрен яшерүнең кирәге юк иде. Башын борып, тоньк карашын Рөстәмгә текәде.

– Алинә, минем аңлавымча, сез бүген ирегезнең каберен эзләгәнсез. Халәтегезгә караганда, тапкансыз булса кирәк. Шулаймы?!

Алинә эндәшмәде. Рөстәмнең тавышы ничектер ерактан, торба эченнән яңгыраган сыман ишетелә.

– Ирегезнең җәсәде, озак кына үлем йортында билгесез хәлдә ятканнан соң, татар зиратына мәчет тарафыннан күмелгән.

Алинәнең күзләрендә сорау чагылды. «Сез беләсезмени?» дия иде кызның карашы.

– Әйе, беләм, Алинә. Мин сезгә дә әйтмәкче идем, тик һич кенә дә сезне бүген үк эзләргә чыгып китәрсез дип уйламадым. Әгәр мине көткән булсагыз яки миңа хәбәр итсәгез, сез күп кенә кыенлыкларны читләтеп үткән булыр идегез.

Алинә авыр сулады, күзләреннән тагы яшьләр коелды. Читенсенеп, башын борды, кулындагы сурәтне күзләренә каплады.

– Алинә, үлгән артыннан үлеп булмый. Мин сезгә әле барысын да әйтмәдем.

Рөстәм, кирәкле сүзләр эзләгәндәй, берара тукталып калды, фикер туплады.

– Алинә, сезгә ирегезнең күмелү урынын әйткәннәрдер, бәлки, сез инде анда булгансыздыр да. Ә менә кызыгыз турында бернинди хәбәр дә юк, шулай бит?!

Алинә, кулларын күтәреп, сурәтне күзләренә китерде. Аһ, Айсылуым, балам... Иртәгә аның каберен эзли чыгасы булыр. Аннан соң алар кушылырлар. Алинә хәл итте.

– Алинә... Ничек дип әйтергә икән... Алинә, зинһар, тыңлагыз әле.

Рөстәм Алинәнең кулын учына алды, кысып тотты. Кызның яшьле күзләрендә яңадан шул ук сорау чагылды.

– Алинә, сезнең кызыгызның кабере билгеле түгел, чөнки ул авариядән соң хастаханәгә китерелгәндә исән булган. Бик авыр яраланган, ләкин исән калган. Аны аңсыз хәлдә башка хастаханәгә озатканнар. Бераз вакыттан соң тагы башка хастаханәгә күчергәннәр. Алинә, мин әлегә кызыгызны тапмадым – аны исән-сау дип әйтә алмыйм. Тик шулай да үле дигән хәбәре дә юк, аңлыйсызмы?

Берара Алинәнең күзләре, Рөстәмгә текәлгән килеш, бернинди хис белдерми ачылып калдылар. Ниһаять, егет көткән мизгел туды. Рөстәм әлеге диңгез өстенә эленгән рәшә төсле яшькелт-зәңгәр тирәнлектә ниндидер чаткы яралганын күрде, диңгез дулкыннары кузгалып куйгандай булдылар, тонык караштa җан төсмере чалымланды. Шул ук минутта күзләре яшь белән тулды, ярларына сыеша алмый, күз яшьләре чигә чәчләренә агып төште.

– Рөстәм... – Рөстәм әлеге зәгыйфь тавышка да бик шат иде. – Сез чынлап та... минем кызым исән дип уйлыйсызмы?

Егет үзен кулында үлем һәм тормыш даруы тотып торучы табиб итеп хис итте. Әгәр «Әйе, кызыгыз исән» дисә, Алинә яшәячәк. «Юк, белмим» дисә, Алинә үләчәк. Ләкин ул бит дөресен белми. Шулай да әлеге мизгелдә Алинәнең яшәве кирәк.

– Әгәр үле хәбәре юк икән, димәк, ул исән, Алинә. Безгә аны эзләп табарга гына кирәк. Ә моның өчен сез терелергә тиеш.

Бүлмәдәге киемнәр шкафы да, кечкенә өстәл дә, янында утырган Рөстәм дә аксыл томанга уралып йөзеп киттеләр, бер мизгелгә күзеннән югалып, ачыклагычка салынган фотосурәт шикелле, яңадан барлыкка килделәр. «Үләргә беркайчан да соң түгел, кызым». Белә иде бит Алинә, белә иде – иң соңгы мизгелдә дә әбисе кебек тормышка ябышырга, теш-тырнагың белән яшәү өчен көрәшергә кирәк. Ясин укучы синең күзләреңне йомдырганда да, Газраил айбалтасын күтәргәндә дә ышанырга кирәк – Ходай Тәгалә синең газапларыңны күрә, бу дөньядагы һәрбер сулыш, һәр вакыйга Аның кодрәтеннән башка эшләнми, димәк, син дә бу дөньяны үз белдегең белән ташлый алмыйсың. Нишләп буталды соң Алинә? Юк, алай тиз генә калдырмаячак әле ул бу дөньяны. Аның эшлисе

эшләре, сулыйсы һавасы бетмәгән. Аның әле кызын, алдына утыртып, чәчләреннән сыйпыйсы, назлап сөясе бар. Караңгы төннән соң һәрвакыт илаһи иртәләр туа...

Ишек кыңгыравы шалтырады. Камиләттәй чакырган табиб килеп тә җиткән иде. Рөстәм, Алинәне табиб кулына тапшырып, бүлмәдән чыкты...

* * *

Үләм, дисең.
Ә менә син
Үлмичә кара яшәп.
Мамык мендәр урынына
Булса да салам түшәк,
Кемдер каймак ашаганда,
Син каты кимерсәң дә,
Берәү шәраб чөмергәндә,
Син суга тилмерсәң дә,
Кузгалак диеп капканың
Булса да яшел әрем,
Үртәлүнең соң чигендә
Тамса да күз яшьләрең,
«Булганына – рәхмәт!» диеп,
Ходайга әйтеп кара.
Яшәвеңнең бер мәгънәсез
Көннәре үтеп бара...
Булдырырсыңмы син шуны?
Булдырырсыңмы, Кеше?
Әллә инде «үләм» диеп
Бетерергәме эшне?!
...Үләм, дисең.
Ә менә син
Үлмичә кара яшәп.
Мең газаптан мең терелеп,
Бер гади булып, яшьнәп,
Сызланып кара яшәп...

# ЭПИЛОГ

...Яфраклар коела. Җил агайның өрфия канатларын аз гына кымшатуы була – җир өстенә яфраклар коела. Көзнең салкынча талгын тыныч һавасында төнге күбәләкләрдәй уйнап алалар да сары келәм җәелгән урман юлына, тын сукмакларга, кабер өсләренә коелалар. Яфраклар бу көздә соңгы вальсларын бииләр...

Алинә зиратка ире белән, Гамир исемле абыйсы белән серләшергә килгән. Өстендә килешле кара пальто, матур итеп артка җыеп куелган коңгырт дулкын чәчләренә апак үтә күренмәле шарф бөркәгән. Уң кулы янәшәдән атлаган кызының кечкенә учын кысып тоткан, сул кулында кып-кызыл чәчәкләр. Өстән яуган сары яфраклар көенә зират сукмагыннан тын гына атлыйлар... Тирә-якта кемнәрнеңдер язмышлары – шатлык-куанычлары, кайгыхәсрәтләре, ваемсыз тормыш мизгелләре – соңгы ноктага тупланган. Тирә-яктан Алинәгә әле мәрмәр сыннар, әле кәгазь сурәтләр, әле гади язулар текәлгән. Әйтерсең Алинә кызы белән Мәңгелек аша уза. Юк, курыкмый ул. Кайдадыр шул тирәнлектә аның якын кешеләре әйләнә. Менә мәрмәр ташта Алмаз елмая. Алинә, туктап, Айсылуны кабер янына алып керә, дәшми генә утыргычка иңәләр. Алинә күңеленнән генә ире белән сөйләшә.

– Алмаз, без синең янга килдек, – ишетәсеңме мине?

Талгын җил Алинә бөркәнгән шарф очын тибрәтә, коңгырт чәчләреннән сыйпый.

— Айсылу ничек зур үсте. Кызыбызга биш яшь тулды бүген, Алмаз. Хәзер елмая да башлады, нәкъ элеккеге кебек, хәтерлисеңме?

Алинәнең күз алдында болында күбәләк куып йөргән кечкенә Айсылу гәүдәләнә. «Әни, бу сәсәкләлне мин сиңа сыйдым!» Рөстәм белән балалар йортыннан эзләп тапканда, ябык йөзендә зур күзләре генә утырып калган, култык таякларына таянган, чәче кыркып алынган Айсылу элеккеге кебек елмая башлар дигән өмете калмаган иде Алинәнең...

– Безгә бергә булырга насыйп булмаган, күрәсең. Язмыштан узмышлар юк. Тик без сине беркайчан да онытмабыз, Алмаз.

Дуамал җил Алинәнең шарфын башыннан йолкып ук ташлый, чәчләрен туздырмакчы була, куенына үтеп керә.

– Кызым, монда синең әтиең йоклый. Эчеңнән генә «тыныч йокла, әтием» дип әйт.

– Ә ул мине ишетәме?

– Ишетә, кызым.

Айсылу берара тын тора, аннан, утыргычтан кузгалып, ташка куелган сурәткә учлары белән кагыла.

– Бигрәк салкын, әни. Әтигә дә салкын микән?

Алинә күз яшьләренә буылганын сизеп дәшми.

– Әни, әтине өйгә алып кайтырга кирәк. Монда салкын.

Тамакка утырган таш, бераздан соң гына йомшарып, түбәнгә тәгәри. Алинә кызының учларын кулына ала, өреп җылыта.

– Әтиеңне өйгә алып кайтып булмый, кызым. Беркайчан да. Ул монда йокларга тиеш. Әгәр без аны онытмасак, аңа беркайчан да салкын булмаячак.

Айсылу аңлаган кыяфәт белән баш кага, тик күзләрендә килешмәгәнлек кычкырып тора. Алинә кулындагы чәчәкләр бәйләменең берсен кабер өстенә куя, тагы бераз тын гына утыргач, Алмаз белән саубуллаша.

– Сау бул, Алмаз. Авыр туфрагың җиңел булсын...

...Яфраклар моңы астында зират сукмагыннан алга атлыйлар. Менә мәрмәр ташта икенче очкынлы елмаю эленгән. Алинә, таныш чалымнарны ерактан ук шәйләп, сискәнеп китә... Яфраклар ана белән кызны кабер рәшәткәсенә кадәр озата баралар, сукмакка бәхилләшү көе булып яталар... Алинә рәшәткәгә уеп ясалган кечкенә капканы ачып керә, кызын кочып, утыргычка иңә...

– Мин килдем, Гамир. Сеңлең синең белән серләшергә тели, – тыңларсыңмы мине?!

Моңсу җил, Алинәгә ияреп, монда да килеп җиткән, кабер янына куелган, өшеп саргайган чәчәкләрнең таҗларын йолкый, җиргә сибә. Кабер башына утыртылган кечкенә генә агач үсентесенең соңгы яфрагын өзә дә һавага чөя. Яфрак, соңгы вальста бөтерелгәннән соң, Алинәнең алдына килеп төшә.

– Син миңа бик кирәк, Гамир. Син минем бу дөньядагы бердәнбер туганым идең.

Еламсак җил тына, җирдән шуышып, каядыр китеп сызгыра. Алинә дәшми, кызын кочып, тын гына Гамирның очкынлы күзләренә кереп югала... Бераздан сукмакларда йокларга яткан сары яфраклар сөйләшә башлыйлар, рәшәткә ачыла. Алинәнең янәшәсенә Рөстәм иңә. Һавада бөтерелгән яфраклар сукмакларга гына түгел, Алинәнең иңнәренә төшкән ап-ак шарфына, Айсылуның береткасына, Рөстәмнең кара чәчләренә урала... Айсылу кулын сузуга, кечкенә учка кечкенә сары яфрак төшеп утыра.

– Монда да салкын, әни. Кем йоклый бу урында?

– Минем абыем – Гамир йоклый, кызым.

– Ул да әти кебек өши микән?

– Юк, кызым, өшеми. Без сөйләштек бит инде – алар безнең хәтеребездә вакытта беркайчан да өшемәсләр.

– Минем монда йоклыйсым килми.

Алинә сискәнеп китә, кызын ныграк коча.

– Без монда йокламабыз, Айсылу. Җирдә йөргәннәр монда йоклый алмый.

Айсылу әнисенең кочагыннан ычкына, күтәрелеп, Рөстәмгә карый.

– Әни, минем әти монда йокламаска тиеш. Әти өйдә, минем янда торсын.

Алинә дәшми. Айсылу киреләнеп дәвам итә.

– Мин беләм: әтисез балаларны «детдом»га бирәләр. Әгәр чын әтине моннан алып кайтып булмаса, өйдә җирдә йөри торган әти булсын. Минем «детдом»га барасым килми.

Алинә кызының сүзләрен аңлап та өлгерми, тик озын керфекләр урап алган зәңгәр тамчыларда беркадәр үҗәтлек, беркадәр үпкә сизеп сагаеп кала. Айсылу әнисенең кулындагы чәчәкләрне кабер өстенә куя да тиз генә Рөстәмгә борыла.

– Рөстәм абый, син минем җирдә йөри торган әтием булырсыңмы?

...Яфраклар коела. Җил агай өрфия канатларын аз гына кымшатуы була – җир өстенә яфраклар коела. Көзнең салкынча талгын тыныч һавасында төнге күбәләкләрдәй уйнап алалар да сары келәм җәелгән урман юлына, шул юлдан әтисе белән әнисенең кулларына тотынып, тын гына атлаган Айсылу өстенә, тар сукмакларга, кабер өсләренә коелалар. Яфраклар бу көздә соңгы вальсларын бииләр...

*2002*


АСЫЛЪЯР

# АСЫЛЪЯР

Илаһидан мәҗүсигә – бары бер мизгел.
Юктан бар булуга – бары бер мизгел.
Сакла, кадерен бел, – уйлан бер мизгел.
Яшәү – аз да, күп тә түгел, – бары бер мизгел!

*Гомәр Хәйям*

*Беренче бүлек*

## Гөлкәй

– Кызл-а-ар, монда ничек яшәрбез инде без, ә?

Ишек йозагыннан ачкычны көч-хәл белән тартып алып, тулай торакның бишенче каттагы бүлмәсенә биш ел яшәргә дип кергән биш кызның күз алдында бик мескен манзара ачылды. Кысан бүлмәдәге ялангач пружиналарын ыржайтып елмайган караватлар, стеналардан урыны-урыны белән кубып төшкән акшар буяу, тапталудан буявы кубып беткән җир төсле идән, түшәмнән ялангач тимер чыбыкка эленгән тонык лампочка – барысы да студентның нәкъ менә тулай торакта яшәвен кисәтеп торырга сөйләшкән пейзаж күренешләре сыман иде.

– Ничек яшибез – гөрләтеп яшибез аны! Өстәл – бар, карават – бар, шкаф – бар. Тагы ни кирәк? – Беркайчан да күңел җорлыгын югалтмаган Гөлүсә зур сары чемоданын тәрәзә буенда урнашкан уң як караватка китереп аударды. – Кызлар, бусы – минеке. Кояшны күрмәсәм, шиләм мин!

– Карарбыз, кыш көне ни диярсең икән. Мондый тәрәзә буенда йоклавы Котыпта йоклау белән бер булмагае. – Ишек артындагы караватка килеп утырган Фаягөлнең укытучылар сөйләгән киләчәк якты тормышка өмете калмаган иде. Нишлисең, эти-әнисе янында гына үскән шәһәр кызының ялангач сиртмәле караватка мөнәсәбәте, әлбәттә, тискәре.

Тәрәзә буендагы икенче караватны Гөлкәй яулады, Зөлфия белән Рәмилә ян-як стена буендагы караватларга елыштылар. Хәзер кастелянша янына түшәк-юрганнар алырга төшәсе иде.

– Кызлар, кастелянша качмас, әйдәгез, танышыйк, булмаса. Мин –Гөлүсә, гел үсәм, иртә үсәм, кич үсәм. – Кыскарак киселгән саргылт-алтынсу чәчле, борын очларына мәхәббәт сипкелләре сибелгән кызның очкынлы күзләреннән шаян нурлар балкыды. – Кукмарадан.

– Ә мин – Чаллының үзеннән. Исемем – Фаягөл.

– Тәк, Фаягөл, син дә гөл, мин дә гөл, тагы кемнәр гел дә гөл?

– Мин – Гөлкәй. – Озын толымнары билдән түбән төшкән зур кара күзле кыз, бераз оялгандай, читенсенеп җавап бирде. – Ерактан мин, Себердән үк.

– Үләм икән! Гел гөлләр җыелганбыз лабаса! Безнең бүлмә шау чәчкәдә утырачак болай булса! – Гөлүсә шунда ук кеткелди башлады. – Әллә барыбыз да гөлләрме?

– Гөлләр үк булмасак та, гөлдән ким түгелбез. Рәмилә. – Зур күзлекле, каратут йөзле чандыр гына кыз, сүзләрен раслагандай, кулы белән һаваны кистереп алды. – Әлмәттән.

– Ә мин – Зөлфия. Арчадан.

– Җәмәгать, танышу тәмам. «Общага» белән танышуны тәрәзәдән карап дәвам итәбез!

Кызлар, Гөлүсәнең шаян сүзләренә җавап итеп, берберсенә карап елмаештылар, тәрәзә янына килделәр. Алар бүлмәсе йорт ишегалдына карый икән. Бер яктарак зур гына трансформатор корылмасы, янында ук диярлек асфальт җәелгән кечкенә генә мәйданчык. Уртадарак спорт мәйданы. Гөлкәйнең күзләре уң якта, бераз читтәрәк үсеп утырган мәһабәт чыршыга төште. Шунда ук күкрәк читлегендә нәрсәдер сулкылдап куйды, сагыну хисе йөрәген өздереп алды. Туган як билгесе иде бу чыршы...

– Гөлкәй, әйдә, без киттек!

Гөлкәй, онытылып, тәрәзә янында берүзе басып калган икән. Кызларның чыгарга җыенганнарын ишетеп, бүлмәгә борылды.

– Т-сс! Шаулашмагыз!

Ишекне ачып чыгарга җыенган Гөлүсә, берара тукталып, нәрсәдер ишеткән кешедәй, колакларын торгызды.

– Нәрсә бар?

– Т-ссс!

Кызлар, баскан урыннарыннан кымшанмыйча, тынып калдылар. Тавыш-тын юк. Тик шунда ук ишек төбендәге почмакта урнашкан иске кием шкафы ягыннан кыштырдаган тавыш килде. Кайдадыр эчтәрәк, әллә шкафның астында ук, һичшиксез, нәрсәдер кыштырдый иде.

– Тә-әк, җәмәгать, комендант ничәү яшисез дип сораса, алтау дияргә кирәк. Монда безгә кадәр торучы бар икән инде.

– Син кем турында әйтәсең?

– Тычкан иптәш яши безнең белән, хөрмәтле кызлар! Тычкан! Димәк, без – алтау!

Кызлар, чыелдашып, бүлмә эченәрәк сибелделәр.

– Ә миңа калса, без тагы да күбрәк. – Фаягөл баядан бирле үзенең караваты янәшәсендәге чынаяк куяр өчен ясалган шкафка текәлеп тора иде. – Безне санарга бармаклар гына җитмәячәк – карагыз әле монда!

Менә шкафның кырый почмагыннан антенналар кебек тырпайган мыеклар күренде, аннан тараканның ярты гәүдәсе чыкты, бераздан бөтенләй кыюланып, бармак буыны озынлыгындагы шактый симергән таракан кызларның күз алдында киштә буенча бер баштан икенче башка йөгереп кенә сәяхәт итеп алды. Иптәшләренең кыюлыгыннан дәртләнеп киткән тагы берничә таракан яшеренгән урыннарыннан башларын суздылар.

– О! Яшәсеннәр тараканнар! Буш вакытларда дрессировка белән шөгыльләнербез! Беләсегез килсә, тараканнарны өйрәтү бик җиңел диләр, шулай булгач, бүлмәдә таракан чабышы оештырсак та була!

Кызлар Гөлүсәнең сүзләреннән көлешеп алдылар.

– Алайса, тычканны да фокус күрсәтү һөнәренә өйрәтергә булыр – эшсез ятмасын.

– Фу! Нинди ямьсез сүз – тычкан, имеш! Безнең белән яшәгәч, тычкан булмый инде ул! Исем кушарга кирәк!

– Васька!

– Моська!

– Гошка!

– Җәмәгать, безнең тычкан милләте буенча – татар. Шулай булгач, татарча исемнәр генә кабул ителә!

– Хәйрүшкә!

– Габдуллашка!

– Гали!

– Вәли!

– Кызлар, сез әллә нәрсә сөйлисез. Җүнлерәк исем табыгыз инде.

– Монда без – кунаклар. Ә ул безгә кадәр яшәгән, бездән соң да яшәр; бүлмәнең хуҗасы – ул. Без югында күзколак булып торыр. Димәк, Хуҗа агай булсын!

– Ай-һай, Рәмилә, акыллы да инде үзең! – Гөлүсә, тавышын калынайтып, мәктәп укытучысының мактау интонациясен кыланып күрсәтте. – Димәк, Хуҗа агай. Хуҗа агай! Без хәзер кайтабыз, учакны сүндермә!

Кызлар, көлешә-көлешә, түшәк-юрган алырга кастелянша янына төшеп киттеләр. Тынып калган бүлмәдә бераздан кыштырдау ишетелде, кечкенә генә соры йомгак идән уртасына йөгереп чыкты да, караватларга якын килеп, борыны белән һаваны иснәштергәләде. «Димәк, яңалар, – дип уйлады Хуҗа агай. – Болай ярыйсы күренәләр. Төтен исе дә килми үзләреннән. Дуслашырга

кирәк булыр». Кеше юклыктан файдаланып, өстәл буенча йөгерешкән тараканнарга куркыныч итеп чыелдап алды да Хуҗа агай үзенең өненә кереп юк булды...

...Караватларга түшәкләр, япмалар җәйгәч, сатып алып, чүпрәк чаршаулар, арзанлы гына тәрәзә пәрдәләре коргач, бүлмә бераз ямьләнеп киткәндәй булды. Стена акшарлары кубып төшкән урыннарга кызлар календарьлар, журналдан кисеп алынган рәсемнәр ябыштырдылар. Чаршаудан калган чүпрәкне кисеп, өстәл япмасы ясадылар, пыяла кефир шешәсенә саргайган яфракларын кайнар үтүк белән үтүкләп, каен, чаган, миләш ботакларын утыртып куйдылар. Ике проблема гына калды: берсе – кырылып беткән идән, икенчесе – тараканнар. Идәнне әллә ничә тапкыр агачына кадәр кырып-кырып юсалар да, әллә ни яхшы нәтиҗә бирмәде – бүлмәгә кергән кешенең күзе иң элек ала-кола идәнгә төшә. Инде моңа кул селтәгәннәр генә иде – Чаллыдан Фаягөлнең ничек урнашуын карарга килеп төшкән әти-әнисе искерәк, әмма чиста идән паласы калдырып киттеләр. Бу кызларга көтелмәгән куаныч булды. Тараканнарга каршы көрәш исә бик кискен куелды. Һәр кешенең бүлмә алдындагы изге бурычы – көнгә биш тараканны юк итү дип игълан ителде. Әмма мәлгуньнәр әллә кайдан чыгалар – әйтерсең әкиятләрдәге Һарун патша капчыгыннан коелалар. Бераздан карават сиртмәләренә кадәр һәрнәрсәнең тараканнардан торганлыгы ачыкланды. Төнлә йоклап яткан кызларның битләре буйлап йөгерергә дә тайчынмадылар тараканнар. Хуҗа агай һәр төн үзенең чистарып киткән биләмәләрен йөреп чыга, почмагы алдына кечкенә консерва савытына салып калдырылган сөтне эчә, ипи кыерчыгын кимерә дә йомышларын үтәргә идән астыннан гына күршеләргә чыгып чаба иде. Изгелеккә изгелек белән җавап кайтарырга өйрәнгән шул Хуҗа агай...

Кызлар укыган экономика факультетында дәресләр бер атнага соңга калып башланды. Быел уку бинасын җәйгелеккә ремонтка япканнар икән, шуңа күрә яңартылып буялган, буяу исе аңкып торган аудиторияләрдә беренче сентябрь көнне көне буе утырган кызларның дәрестән чыкканда күз алларында әлҗе-мөлҗе томаннар уйный башлады, укучылар да, укытучылар да буяу исенә беркадәр исереп, озын коридорлардан сөрлегәсөрлегә атладылар. Икенче көнне «дәресләр бер атнага кичектерелә» дип игълан ителде. Кызлар куанычының чиге булмады. Әле Казан белән таныша гына башлаганнар иде, кирәкле трамвай номерларын да белеп бетермиләр, ә истәлекле урыннарда йөрергә вакытлары

бөтенләй булмады. Шуңа күрә атна буе Кремль, Болак, Елга порты, Казансу буйлары, Кабан күле, Бауман урамы белән танышып йөрделәр, хәтта акчаларын кыса-кыса, кинога барырга җөрьәт иттеләр. Рәмилә икенче көнне үк милли китапханәгә язылды, тулай торакка үзе белән бер кочак китап күтәреп кайтты. Кызлар һәрнәрсәдә ямь табалар, һәрнәрсә алар өчен кызык, көтелгән иде. Шулай булмыйча – Казан кадәр Казанның үзендә югары уку йортында укып карале! Бу инде сиңа ниндидер авыл гына түгел, хәтта провинциаль шәһәр дә түгел: бу – Казан! Ямьләнеп, үзләренеке булып киткән тулай торакта да никадәр яңа танышлар, яңа дуслар! Ә төннәрен... Ә төннәрен кызлар туктый алмый, эчләре катканчы, күзләреннән яшь атылганчы көлешәләр. Һәрвакыт нәрсәгәдер канәгатьсезлек белдергән Фаягөл дә кызлардан ким кеткелдәми иде. Нәрсәдән көләләрме?! Бөтен нәрсәдән! Хәтта тәрәзәдән караган моңсу айдан да эчләре катып көләләр иде кызлар...

Атна үтте, ниһаять, дәресләр җанланып, һәрнәрсә үз урынына төшеп утырды. Икенче курс студентлары, укулар башлангач та, колхозга бәрәңге алырга кайтып киткәннәр. Югарырак курслар сирәк күренәләр, очраганда да, беренче курслар кебек төркем-төркем түгел, ә ялгыз яисә кечерәк төркемнәр белән йөриләр иде. Беренче курсларга исә барысы да кызык: әле алар имтиханнарның нәрсә икәнен белмиләр, зачет тапшыра алмыйча, укытучы артыннан ялынып йөрү газабын татымаганнар – аларның дөньясы түгәрәк. Укыган фәннәре дә унынчы класс математикасын кабатлау гына. Әле барысы да алда аларның...

Гөрләтеп беренче курска кабул итү бәйрәме узды. Беренче курс студентлары өлкән курсларга үзләренең нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәттеләр: биеделәр, җырладылар, шигырь укыдылар, мәзәк сөйләделәр. Гөлкәй дә концертта катнашты: ул җырлаганда, бөтен зал, тын калып, моңга чумды. Әнисенең яраткан җырын – «Кыр казлары артыннан»ны җырлады Гөлкәй. Туган ягын, әнисен өзелеп сагынуын җырга салды. Җырның моңы йөрәкләргә үтеп керсә, зал Гөлкәй тавышының көченә, матурлыгына хәйран калды. Әйе, мондый тавыш сирәк кешегә насыйп була шул...

Шулай итеп, бәйрәмнәр дә узды, студентларның гадәти уку атналары башланды. Төп укыган фәннәре – математика. Фәлсәфә дәресе була дигәч, кайбер студентлар җиңел сулап куйгандай булды. Монда укучыларның күбесе математикага гашыйк кешеләр булса да, гел

математика гына ялыктыра башлаган иде. Күз алдына китерү мөмкинме – иртәдән кичкә кадәр сине саннар уратып ала. Саннар синең башыңда, саннар синең күз алдында, өстәлдәге китапта, дәфтәргә син саннардан челтәр төзеп язасың, укытучының авызыннан сүзләр түгел, саннар очып чыга шикелле... Менә янында теоремалар очып йөри, син аларның чишелешен тотып алырга тиешсең, менә мәсьәләләр – ике билгесезле, күп билгесезле, ә менә алга Аксиома агай килеп баса – чишелешен аңлатмый, дәлилләми генә кабул ит, дускай, кунакка чакыр... Ә фәлсәфә!..

...Аудиториягә озын буйлы, сылу ыспай гәүдәле, кулына зур гына портфель тоткан утыз биш тирәләрендәге укытучы ир-ат килеп керде. Керде дә, аудиториягә карамый гына, портфелен өстәл янындагы утыргычка куйды, ачып, язулы кәгазьләрен алды, өстәлгә салды. Баштарак бераз шаулашкан аудитория тынып калды. Укытучы һаман да аудиториягә күз салмый гына тәрәзә янына үтте, кесәсеннән тарагын чыгарып, кара чәчләрен тарады. Берара, тәрәзәдәге күренешкә карап, онытылып басып торды. Аудитория аның һәр хәрәкәтен гаҗәпләнеп күзәтә иде. Гадәттә, математика укытучылары язгы ташкын кебек ургылып аудиториягә килеп керәләр, иң беренче дәресне төркем белән танышудан башлыйлар, берәм-берәм студентларның исемнәрен әйттереп, кайдан килүләре турында сорашалар, укыган мәктәпләренең, укытучыларының исемнәрен ачыклыйлар. Дәреснең биш минуты үтте инде, ә укытучы һаман эндәшми әле. Аудиториядә чебен очканы ишетелерлек тынлык. Менә шул тынлыкны бүлеп, йомшак бәрхет баритон яңгырады. Тәрәзәгә караган килеш, укытучы шигырь сөйли иде.

Илаһидан мәҗүсигә – бары бер мизгел,
Юктан бар булуга – бары бер мизгел...

– Бу робагыйны унберенче гасырда яшәгән бөек математик, астроном, философ, шагыйрь Гомәр Хәйям язган. Аның турында беләсезме?

Укытучы, борылып, Гөлкәйгә текәлде. Әйе, әйе, туксан студент арасыннан нәкъ менә Гөлкәйгә текәлде! Чемкара күзләр Гөлкәйнең күзләреннән нәрсәдер эзләделәр, җавап көттеләр. Гөлкәйнең гәүдәсен кисәкләргә турап, астан өскә таба ниндидер кайнар дулкын йөгереп узды. Күкрәк турысында нәрсәдер парә-парә килде. Күзләрен укытучының күзләреннән ала алмый, сихерләнгән кебек, ир-атка карап утыруын белде. Тирә-якта утырган курс-

ташлары, ак томанга уралып, юкка чыктылар, аудиториядә Гөлкәй һәм Укытучы калды. Гөлкәй, Укытучы һәм Робагый. Гөлкәй, Укытучы һәм Шигырь моңы. Гөлкәй, Укытучы һәм Фәлсәфә...

...Дәрес ахырында гына Укытучы үз исемен атады. Фәлсәфә тарихын сөйләүче Казан дәүләт университетының фәлсәфә кафедрасы доценты Мансур Ибраһимович икән. Университет исемен ишетүгә, студентлар аһ итеп куйдылар, рәтләр арасында сокланулы пышылдау китте. Университет кадәр университет доценты, Ленин укыган университет укытучысы... Аларның вузлары да төшеп калганнардан түгел, ләкин университетка тиңләшә алмый инде, әлбәттә. Ә Мансур Ибраһимович исә гади генә саубуллашты да, киләсе дәрестә тикшереләчәк теманы әйтеп, аудиториядән чыкты.

– Вәт менә укытучы! – Коридордан барган Гөлүсәнең соклануы йөзенә бәреп чыккан, әсәрләнеп киткән иде. – Чибәрлеге диген син аның! Күрдегезме, гел миңа карап сөйләде!

– Нишләп сиңа карасын инде – миннән күзләрен дә алмады ич! – Фаягөл ачулы кыяфәттә Гөлкәй белән Гөлүсәне ике яктан култыклап алды. – Их, шундый берәүгә үлеп гашыйк буласы иде, кызлар!

– Ә ул бездә гамәли дәрес алып барачак! Менә шәп!

Гөлкәй дәшмәде. Дәрестән соң күңеле урынына утырмаган иде әле, аңы Укытучының серле карашыннан арынып бетә алмый иде...

Калган дәресләрдә дә Гөлкәй иләс-миләс утырды. Әллә нәрсә булды аңа: колагында робагый яңгырый, алдында – Укытучының галәм карасыдай кара күзләре... Әллә күзләре түгел, очарга талпынган кош канатыдай кара кашлары микән? Әллә юкса диңгез дулкыннарыдай куе кара чәчләреме яисә кабартып куелган мендәр кебек тулы иреннәреме?! Нишләп соң әле бу Укытучы әбисе көйләп укыган Йосыф кыйссасындагы кебек шулкадәр гүзәл?! Йөзгә якын студентлар алдында лекция укыган Укытучы болай матур булырга тиеш түгел, бу – гөнаһ... Йөзләгән студентның күбесе әле унсигезе дә тулмаган яшь кызлар лабаса, алар гашыйк булмый нишләсен? Гөлүсә, әнә «миңа карады» диде... Фаягөл дә. Ә Укытучы бит Гөлкәйгә карап кына сөйләде. Аңа гына, бары аңа гына...

Гөлкәй буталды. Калган дәресләрне янында очып йөргән саннарга бернинди әһәмият бирми, бары чәршәмбе турында гына уйлады. Чәршәмбе көнне аларга Мансур Ибраһимович яңадан дәрес бирәчәк. Гамәли дәрес үткәрәчәк. Бары аларның төркеменә генә. Бары Гөлкәйгә генә.

Ах, Гомәр Хәйям, әгәр сине Мансур Ибраһимович шулай хөрмәтли икән, нинди бәхетле кеше булгансың син...

Кызлар, әлбәттә, Гөлкәйнең бу халәтен сизделәр. Әйтерсең кызны гипнозладылар – тулай торган бүлмәсендә дә Гөлкәй йә караватка абынды, йә кулыннан әйберен төшереп җибәрде. Кичен исә, өстәлдә торучы тоз савытыннан Гөлкәйнең чәйгә тоз салып бутарга җыенганын күреп, Гөлүсә һәрвакыттагыча кычкырып көлде:

– Кызла-а-р, үләм икән, Гөлкәй гашыйк булган лабаса! Карагыз әле, кара!

Гөлкәй сискәнеп китте, калактагы тозны кире савытына бушатты. Көчәнеп елмайды.

– Йә, дустым, әйт хәзер үк, кем ул бәхетлесе? Бүген дәрестә бик иләс-миләс утырдың, әллә Мансур Ибраһимовичка гашыйк булдыңмы?

Гөлкәйнең коты очты. Юк, бервакытта да, беркемгә дә әйтмәячәк ул. Юк. Ләкин кызлар барысы да Гөлкәйгә текәлгәннәр, күзләре кызыксынып яна, яңа маҗара, сөйләр сүз эзли. Бер мизгелгә Гөлкәйнең күз алдына куркыныч күренеш килеп басты: менә бөтен факультет Гөлкәйнең мәхәббәте турында белгәннәр, менә аңа төртеп күрсәтәләр, Мансур Ибраһимович аңа кызганулы караш ташлый – нишлисең, яшь чакта була торган хәл... Юк, юк!

– Аһ, кызлар, нишләргә дә белмим инде. Гашыйк булдым, ахры, шул. – Гөлкәй, тавышының калтыравын басып, мөмкин кадәр ышанычлы сөйләргә тырышты.

– Кемгә?! Мансур Ибраһимовичкамы?

– Юк, сез нәрсә инде. Андый картаеп беткән доцент белән нишлим мин.

Кызлар тагы да көлештеләр.

– Алайса, кемгә?! Кем ул бәхетле җан иясе?!

Әйтмим дисәң, әйткәнчегә кадәр барыбер җанны ашаячаклар. Гөлкәй мизгел эчендә үзенең таныш-белешләрен барлый башлады. Юк, ул гашыйк булырдай кешеләр табылмады.

– Ну, мин аның исемен үзем дә белмим әле. Э-э... Безнең этаждагы бер егет.

– Алайса, сез таныш түгелләр?! – Фаягөл Гөлкәйне ашардай булып карап утыра иде, башка кеше турында сүз барганын аңлагач, җиңел сулап куйды.

Гөлүсә «хәзер танышабыз аны» дигәнрәк кыяфәт белән шунда ук Фаягөлгә җавап бирде:

– Бернәрсә дә тормый, дустым. Бүген үк танышабыз, Гөлкәй күрсәтсен генә. Нindирәк егет ул?

Гөлкәй авыр сулаган булды, күзләрен түгәрәкләндереп, керфекләрен уйнатып алды.

– Аһ, кызлар, куркам ла. Берәр күрсәтермен әле.

Зөлфия җаваптан канәгать калды булса кирәк, чәен болгата-болгата, сүзгә кушылды:

– Кызлар, минем дә үлеп гашыйк буласым килә... Мансур Ибраһимович кебек берәр егет табылса иде икән, ә?!

Шунда ук Гөлкәйнең күңелен көнчелек корты кимереп куйды: бер ул гына гашыйк түгел шул Укытучыга...

– Әй, таптыгыз сөйләрдәй әйбер. Мансур Ибраһимович, Мансур Ибраһимович!.. Беләсегез килсә, күптән өйләнгән инде ул сезнең Мансур Ибраһимовичыгыз! – Рәмилә кетердәтеп сохари тешләде.

Кызлар Рәмиләгә текәлделәр.

– Нәрсә барыгыз да миңа акайдыгыз? Әйтерсең хөрмәтле Мансур Ибраһимовичның кулындагы балдагын миннән башка беркем күрмәгән?

– Балдагы? Мансур Ибраһимовичның балдагы бар идеме?! – Фаягөлнең тавышы ярсып чыкты, йөзе агарынып китте. Ләкин моны бары Гөлкәй генә сизде булса кирәк.

– Соң, дустым, үзең уйлап кара: Мансур Ибраһимович кимендә утызның аръягына чыккан ир-ат. Шулаймы? Йә, әйт хәзер, кайсы җүнле ир-ат утыз-кырыкка кадәр өйләнми йөри, ә? – Рәмилә һәрвакыттагыча мәсьәләнең чишелешен әйтте дә салды. Кызлар берара үзләренең яшерен хыялларына үзләре мөкиббән китеп утырдылар.

Өйләнгән... Димәк, дөньяда Гомәр Хәйямнан да бәхетлерәк кеше бар... Мансур Ибраһимовичның хатыны бар... Шундый гаҗәп матур укытучының хатыны да матурдыр инде... Гөлкәйнең күз алдына ни өчендер унтугызынчы гасыр хатын-кыз күлмәге кигән, эшләпәле, Лев Толстойның Наташасына охшаган хатын-кыз килеп басты. Менә ул Мансур Ибраһимович каршында реверанс ясый, ә кара фрак кигән Мансур Ибраһимович, әсәрләнеп, аның кулын үбә...

– ...Ә өйләнгән кешенең, үзегез беләсез, балалары була. – Рәмилә, үзенә шаккатып караган кызларга әһәмият бирмичә, кайнар чәенә өрә-өрә, коточкыч нәтиҗәләрен җиткерә торды. – Шулай булгач, сезнең авыз суы корыткан Мансур Ибраһимовичыгыз – өйләнгән, бәлки әле, зур начальник кызына өйләнгәндер, кимендә ике, күп дигәндә дүрт балалы, кырыкка җитеп килә торган ир-ат уртасы кеше. Йә, кайсыгыз гашыйк инде Мансур Ибраһимовичка?

– ...Суйдың, Рәмилә. – Зөлфия, артык борчылмый гына, шырык-шырык көлә башлады. – Кызлар, мондый акыл иясе белән биш ел ничек яшәрбез икән, ә?!

Аңа Гөлүсә кушылды.

– Әйе-е, кызлар, биш ел буе мондый... Һи-һи-һи... акыл иясе белән торсак, без егетләргә... Һи-һи-һи... борылып та карамаячакбыз... Һи-һи-һи... карт кызлар булып гомер кичерергә кала... Һи-һи-һи... Үләм икән! – Гөлүсә, көлә-көлә, урынында сыгылып килде. Аңа карап, көлмичә түзү мөмкин түгел иде, кызлар һәммәсе, эчкән чәйләрен онытып, егылганчы көләргә тотындылар. Рәмилә, үпкәләүне исенә дә алмый, үзе эчен тота-тота, кызлар белән кеткелдәде. Гөлкәй дә көлде, күзләреннән яшьләр атылганчы көлде, эчендәге ачынуы күз яшьләре белән чыгып беткәнчегә кадәр көлде...

...Ниһаять, чәршәмбе көннең соңгы дәресе башланды. Аудиториягә кергән Мансур Ибраһимовичка күтәрелеп карарга Гөлкәйнең йөрәге җитмәде. Караса, шунда ук укытучы эшнең нәрсәдә икәнен сизәр кебек тоелды.

– Исәнмесез, коллегалар, хәерле көн. Утырыгыз, зинһар.

Кыеграк утырган студентларның аркалары тураеп киткәндәй булды. Бу юлы Мансур Ибраһимович җитез генә өстәл янына килде, башка укытучылар кебек үк, кәгазьләрен өстәлгә салганнан соң, җитди кыяфәт белән дәвам итте.

– Дәфтәрләргә бүгенге датаны һәм тикшереләчәк теманы язып куегыз. Сез узган лекциядә фәлсәфә фәне турында күп мәгълүмат алдыгыз, шулай да сезгә әйтәсе берничә фикерем калган иде. Боларны язу мәҗбүри түгел, тыңлап утырсагыз, шул җитә. Димәк, бүгенге тема...

Коллегалар... Нинди коллега булсын инде беренче курс студенты университет укытучысына? Шулай да әлеге сүз укытучы белән студент арасын бәйләде дә куйды. Коллега булгач, укытучы студент дәрәҗәсенә төшә дигән сүз түгел инде. Коллега булгач, студент укытучы дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш дигән сүз... Димәк, яхшылап укырга кирәк булачак. Коллегаң алдында белмичә кызарып утыру килешмәс...

Гөлкәй дәреснең беркадәр өлешен дәфтәргә язылган семинар темасын сырлап-бизәкләп үткәрсә дә, колаклары Мансур Ибраһимович әйткән һәр сүзне хәтеренә сала барды.

– ...Лекциядән тыш, өстәмә рәвештә минем сезгә җиткерәсе килгән мәгълүматлар менә шулар иде. Димәк, без киләсе лекциядән фәлсәфә фәнен җентекле өйрәнүне башлый алабыз. Бүген безнең семинар дәрес. Кем әйтә ала, семинар дәрес лекциядән нәрсә белән аерыла?

Берничә кул күтәрелде. Мансур Ибраһимович алда утырган егеткә мөрәҗәгать итте:

– Рәхим итегез.

– Семинар дәрес ул – лекциядә узган материалны кабатлау.

Мансур Ибраһимович, хуплап, башын иде һәм дәвам итте:

– Әйе, шулай, ләкин бу җавап тулы түгел. Әгәр без семинар дәрес вакытында лекциядә ишеткән материалны гына кабатлап утырсак, бу дәрес сезгә ятлаудан башка бернинди файда да бирмәс иде. Ләкин сез бер сүздә генә ялгыштыгыз. – Мансур Ибраһимович, тынып калган аудиториягә карап, җитди кыяфәт белән дәвам итте: – Семинар дәрес вакытында без лекциядә узган теоретик материалны анализлыйбыз. – Мансур Ибраһимович, тавышын күтәреп, бөтен аудиторияне яңгыратты. –Анализлыйбыз! – Бераз паузадан соң, алдагы сорау яңгырады: – Ә нәрсә ул анализ?

Бу юлы студентлар кул күтәрергә җөрьәт итмәделәр. Математик анализның нәрсә икәнен белсәләр дә, фәлсәфә анализының нәрсә икәнен кем белгән... Хәтта һәрнәрсәне яттан белгән Рәмиләнең дә кул күтәрергә кыюлыгы җитмәде булса кирәк. Укытучы исә дәвам итте:

– Анализ ул – һәрбер күренешне, һәрбер тәгълиматны аңларлык итеп таркату һәм аңлатма бирү дигән сүз. Бер үк күренешне төрле кеше төрлечә аңларга мөмкин. Мәсәлән...

Мансур Ибраһимович берара тынып калды, фикер тупларга теләп, тәрәзәгә борылды. Студентлар да, гипнозга буйсынгандай, барысы да укытучы артыннан тәрәзәгә текәлделәр. Тышта салмак кына көзге яңгыр сибәли иде.

– Мәсәлән, яңгыр яву күренешен кеше, әйтик, без, бик җиңел күз алдына китерәбез. Балалар исә яңгырның гади су икәнен аңламыйлар, шулай ук болытның пар хәлендәге су бөртекләреннән торганлыгын алар күз алдына китерә алмыйлар. Ләкин без яңгырның су икәнен аңлаган хәлдә дә аны гади су белән тиңләштермибез, «су ява» яисә «су коела, су түгелә» дип әйтмибез, «яңгыр ява» дибез. Шулай ук җир белән биек күк арасында меңәрләгән тонна су асылынып торуы хакында уйланмыйбыз. Табигатьне өйрәнүче галим исә бу күренешнең барлыкка килү процессын җентекле рәвештә сөйләп бирә ала. Димәк, бер үк күренешне төрлечә аңлату яки аңлау мөмкин, ләкин һәр күренешне бер тәгълимат кына дөрес итеп аңлата ала. Бу – марксистик тәгълимат.

Мансур Ибраһимович, тәрәзәгә караган килеш, яңадан тынып калды. Гөлкәй уйларында йөгереп кенә балачагына кайтып килде: менә ул, абыйсыннан калган резин

итекләрне киеп, яңгырдан соң куе чирәмдә җыелып калган күлдәвекләрне ера. Анда-монда соңга калган тамчылар күлдәвек өстендә гаҗәеп бөҗралар ясыйлар... Әлеге тамчыларның су икәнен аңладымы икән соң Гөлкәй? Күлдәвек – су, әлбәттә, ә яңгыр тамчысы – сумыни?! Кара, гомерендә дә бу турыда уйламаган икән...

Укытучының көчле бәрхет тавышы студентларны аудиториягә кайтарды.

– Марксистик тәгълимат – бердәнбер дөрес тәгълимат. Без семинар дәрестә башкарылачак анализларны әлеге тәгълиматка корачакбыз. – Мансур Ибраһимович көрсенеп куйды, тамак кырып алды. – Семинар дәресләр, гадәттә, «сорау-җавап» рәвешендә корыла, ләкин без түгәрәк өстәлләр, киңәшмәләр рәвешендә дә эшләрбез. Лекцияләр дә, семинар дәресләр дә атнага бер пар белән ике семестр – җәй көннәренә кадәр дәвам итәчәк, беренче семестр ахырында – зачет, җәй көне имтихан тапшырасыз. Күрәсез, безгә шактый вакыт бергә эшләргә кирәк булачак. Танышу өчен алдымда сезнең төркем исемлеге бар, хәзер мин фамилияләрне атыйм, ә сез, зинһар, тулы исемегезне, әтиегезнең исемен һәм кайсы мәктәпне кайчан тәмамлавыгызны әйтерсез. Староста сайладыгызмы инде?

Гөлүсә укытучы авызыннан «староста» сүзенең икенче «с» авазы чыкканчы ук торып басты, күзләренә төшкән чәчләрне артка өреп җибәреп, көр тавыш белән:

– Сайладык, Мансур Ибраһимович. Мулланурова Гөлүсә, Кукмара районы Абдулла Алиш исемендәге мәктәптән. Мең тугыз йөз алтмыш бишенче елда туганмын. Дәүләт хезмәткәрләре гаиләсеннән. Әнием – Мулланурова Әнисә Гарифовна, укытучы. Әтием – Муллануров Камил Габдрахманович, бухгалтер. Икесе дә партия әгъзалары, – дип, бер тында ярып салды.

Моңа кадәр тын гына утырган аудитория «пырх» килеп, көлеп җибәрде. Гөлүсә үзе дә аптырамады, шунда ук киң итеп елмаеп, күзенә төшкән чәчләрен бу юлы кулы белән артка сыйпады да күңелле генә әйтеп куйды:

– Тагы нинди булса да өстәмә информация кирәкме, Мансур Ибраһимович?!

Кинәт яңгыраган бу сүзләр ташкыныннан Мансур Ибраһимович беркадәр аптырап калгандай тоелса да, бик тиз үзен кулга алды, уң кулын учы белән аудиториягә каратып, тынычланырга ишарә ясады.

– Бик тулы җавап бирдегез, өстәмәләр кирәкми. Димәк, фамилиягез...

– Мулланурова, Мансур Ибраһимович.

– Мулланурова...

– Гөлүсә.

– Мулланурова Гөлүсә?

– Мулланурова Гөлүсә Камилевна, Кукмара районы Абдулла Алиш исемендәге мәктәпнең быел унынчы классын тәмамладым.

– Булды, миңа башка информация кирәкми. Ничек җавап бирәсен барыгыз да аңладыгызмы? Гөлүсә Камилевна, староста буларак, дәрес калдыруларның сәбәбен ачыклауны мин сезгә йөклим. Дәрескә йөреш йөз процент булырга тиеш. Авырып дәрес калдыручыларның кулларында справкалары булу мәҗбүри. Шулай булмаган очракта калдырылган һәр дәрескә өстәмә ике сәгать билгеләнәчәк. Комсомол җыелышында мондый укучыларның тәртипләрен тикшерүне таләп итәчәкмен. Аңлашылдымы?!

– Аңлашылды, Мансур Ибраһимович.

Студентлар үзара карашып куйдылар. Әйе, бу укытучы бик йомшак сөйләшә сөйләшүен дә, таләпләре бик кискен күренә бугай... Йомшак җәеп катыга утырта диләрме әле...

– Ярый. Димәк, башлыйбыз. Абдуллин.

– Абдуллин Вил Гыйльманович, Буа районы Яшь ленинчы исемендәге мәктәпне өч ел элек тәмамладым. Флотта хезмәт иткәннән соң укырга кайттым.

– Бик әйбәт! Арискин...

...Гөлкәй, дөп-дөп сикергән йөрәген ничек тынычландырырга белмичә, гаҗиз булды. Исемен дә әйтә алмый буталып бетәр, көлкегә калыр кебек тоелды. Әле тирләп, кызарып чыкты, әле аудитория котып салкынына төрелгәндәй, бер дә юктан калтыратты. Аның фамилиясе исемлекнең ахырында гына әле. Йа Хода, күпме газапланырга мөмкин... Аптырап аргач, исем-фамилиясен дәфтәр битенә язып куйды да шуннан гына укырга булды. Ну нәрсәсе бар инде – торасың да язганны укыйсың. Әле укытучы беркемгә дә бернинди өстәмә сорау бирмәде. Әгәр исемеңне дә әйтә алмыйсың икән, ничек дәрес сорауларына җавап бирерсең син, ә, җүләр кызкай? Шул турыда уйладыңмы? Әллә инде кире Себергә кайтып китәргәме исәбең? Әткәң әманәтен аяк астына салырга уйлыйсыңмы? Гөлкәй эсселе-суыклы булып китте, шунда ук уйлары тәртипкә килгәндәй тоелды, башы сафланды.

– Якупова.

Гөлкәй инде бу. Гөлкәй.

– Якупова Гөлкәй Салихҗановна...

Менә бернинди дәфтәргә язган язу кирәкми, болай да бик әйбәт җавап бирә ләбаса. Тавышы калтырамый, башы урынында. Тәрәзәгә караса ни... Тик укытучы алга таба исемлекне дәвам итәргә ашыкмады, ялгыш ишетмәдемме дигәндәй, кабатлап сорады:

– Себердән?!

Бу юлы инде укытучыга карамый мөмкин түгел иде. Менә ул чем-кара упкын... суыра, Гөлкәйне үзенә суыра. Гөлкәйнең йөрәге, бавыры өскә таба суырылып килә – татлы, ләззәтле хис... Тик урынсыз, кирәксез, кирәксез! Ярамый, я-ра-мый!!!

Гөлкәй ничек кирәк алай үзен кулга алды.

– Әйе, Себердән.

Укытучының кызыксынуы артты гына. Шулай да, күрәсең, төркем алдында артык төпченүне урынсыз санап, күзләрен исемлеккә төшерде, алдагы фамилияне әйткәнче бераз тукталып торды да танышуны дәвам итте.

– Ямалтдинов!

Гөлкәй тизрәк урынына авышты, кулына каләм алып, бүгенге дәрес темасын йөзенче тапкыр буйый-сырлый башлады. Ниһаять, Мансур Ибраһимович исемлекне барлап чыгып, студентлардан кирәкле мәгълүматларны алганнан соң, турыдан-туры дәрес темасына күчте. Ул шундый җиңел, иркен сөйли иде ки, студентлар хәтта танышу вакытында туган беркадәр киеренкелекне онытып, дәрес барышына актив кушылганнарын сизми дә калдылар, бераздан укытучының сорауларына урыннан гына кычкырып җавап бирә башладылар. Тик укытучыга бу ошамады. Гадәттәгечә, уң кулын учы белән аудиториягә каратып, студентларның тынычланганнарын көтеп торды да, тамак кырып, дәвам итте:

– Иптәшләр, дәрестә мин барыгыздан да тәртип таләп итәчәкмен. Әгәр болай... гафу итәсез... бака туе ясый башласагыз, ике искәрмәдән соң дәрестән чыгып китәчәксез. Тәртип – иң беренче чиратта – һәрберегездән тора.

Дәреснең калган өлеше кызыклы үтсә дә, Мансур Ибраһимович материалны бик җиңел итеп аңлатса да, студентлар үзләренең кайда, кем дәресендә утырганлыкларын онытмадылар, шуңа күрә дәрес вакытында башка дәресләрдәге кебек җанланып, шаулашып алулар булмады диярлек. Әйе, бу укытучыга коллега булу бик җиңел түгел булса кирәк. Кинәт Гөлкәй аңлап алды: әлбәттә инде, Укытучы аларны үзенең коллегалары дип санамый... Бары итагатьлек йөзеннән генә әйтелгән сүз ич... Коллега. Коллега. Бу сүзне әйткән саен, Укытучы, кире-

сенчә, Гөлкәйдән ерагая гына. Аларның арасында ниндидер күзгә күренмәс киртә барлыкка килә сыман. Юк, киртә түгел, баскыч, баскыч барлыкка килә. Мансур Ибраһимович шул баскычның иң югары басмасында, ә Гөлкәй әле баскычка аяк басарга җыена гына...

– Димәк, киләсе дәрескә өй эшен яздыгыз. Тема буенча сораулар бармы? Юк. Муллагалиева, Алмазов һәм Якупова, берничә минутка минем янда калыгыз, зинһар. Башкаларга чыгарга мөмкин. Сау булыгыз.

Гөлкәй сизмичә дә калган, дәрес беткән икән ич. Тик нишләптер Мансур Ибраһимович аны үз янына чакыра. Менә студентларның аудиториядән чыкканнарын көтеп торды да янына ук килеп баскан Гөлүсәгә эндәште:

– Гөлүсә Камилевна, сез барлау журналын башлагансыздыр дип уйлыйм.

– Әлбәттә, Мансур Ибраһимович! Менә, сезгә күрсәтә дә алам!

– Ярар, бик әйбәт. Димәк, аңладыгыз инде: дәрес калдырган һәрбер студентның кулында справкасы булырга тиеш. Әгәр сәбәпсез дәрес калдыра икән, өстәмә сәгатьләр алачак. Шул сәгатьләрен тапшырмый торып, имтиханга яисә зачетка кертелмәячәк. Аңлашылдымы?!

– Әлбәттә, Мансур Ибраһимович!

– Ярый, сезгә чыгарга мөмкин.

Гөлүсә, тагы да нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачса да, нәрсә әйтергә белми, тынып калды, әкрен генә аудиториядән чыкты. Ул арада Мансур Ибраһимович Алмазов фамилияле студент белән сөйләшә башлаган иде инде.

– Ирек Галиевич, сез Әфган сугышында катнашкансыз икән. Яралануыгыз турында да беләбез.

Кырыс каратут йөзле егет армиядәгечә кырт кисте:

– Нәкъ шулай, Мансур Ибраһимович.

– Бу турыда миңа алдан ук әйттеләр. Сез Ватан алдында изге бурычны үтәгәнсез. Без сезнең белән бик горурланабыз. Ләкин бу хәл сезнең дәресләргә булган мөнәсәбәтегезне йомшартмас дип уйлыйм. Дәрестә җавап биргәндә сез нәкъ башка студентлар кебек үк бер дәрәҗәдә һәм билгеләр дә сезгә, башкаларга куелган кебек үк, объектив куелыр дип өметләнәм. Аңлыйсызмы?

– Нәкъ шулай, Мансур Ибраһимович.

– Ярый, чыгарга мөмкин.

Ирек чыгып киткәннән соң, аудиториядә Мансур Ибраһимович белән Гөлкәй икәү генә калдылар. Гөлкәй, укытучының сүз башлавын көтеп, аның ручка тоткан кулына текәлде. Алтын балдаклы кулына...

– Гөлкәй Салихҗановна... Мин сездән үзегез турында

тулырак мәгълүмат аласым килгән иде. Димәк, сез Себердән?

Укытучы Гөлкәйгә татарча эндәште. Әйе, әйе, нәкъ менә татарча, хәтта үзләренчә, Себердәгечә, Гөлкәйнең күңеленә бик якын, иренләшмәгән ачык «а» авазлы итеп, «аласым» диде... Гөлкәй үзен домна миче янында торган кебек хис итте, эчке калтыравын басарга тырышып, баш какты. Аһ, тизрәк, тизрәк чыгып качасы иде моннан... Себергә, Арктикага, Антарктидага... Башка планетага... Тик бу бәрхет тавышны гына ишетмәсен иде дә бу кара күзләргә күтәрелеп карыйсы гына килмәсен иде...

– Гөлкәй... Шулай дип кенә эндәшсәм ярыймы?!

Гөлкәй тагы баш какты. Йа Хода, бу укытучыга нәрсә кирәк соң аннан, нәрсә кирәк?! Болай да инде бит урталары ут булып яна...

– Гөлкәй, димәк, сез N авылыннан. Бу авыл турында ишеткәнем бар. Сезнең туган авылыгызда мәчет бар иде, шулаймы?!

Гөлкәй сискәнеп китте, өстенә салкын су коелгандай булды. Ирексездән башын күтәреп, Мансур Ибраһимовичның сораулы күзләренә текәлде. Каян белгән бу укытучы?! Казанда! Бер мәлгә башында «әйтергәме, әйтмәскәме» дигән уй бөтерелде. Ниһаять, саклык канына сеңгәнгәдерме, башын чайкап:

– Белмим... Хәтерләмим, – дип куйды.

Мансур Ибраһимович, беркадәр тын торганнан соң:

– Сезнең әтиегез Салихҗан Фатыйх мулла улы, шулаймы?! – димәсенме!

Гөлкәйнең өне калмады. Йа Хода, аның мулла нәселеннән икәнлеген белсәләрме?! Иртәгә кире Себергә кайтып китәчәк ич ул! Каян белгән бу укытучы?!

– ...С-с-ез-с пел-л-әсес-с пу-г-гай... – Гөлкәйнең гомердә дә тотлыкканы юк иде, ә хәзер исә бөтенләй тыны катты.

Мансур Ибраһимович кып-кызыл булып басып торган кызның көлдәй агарып китүен күреп, бик нык куркытканын аңлап алды булса кирәк, шунда ук, елмаеп, ягымлы тавыш белән:

– Гөлкәй, зинһар, курыкмагыз, хәзер мулла кызы яисә оныгы булган өчен генә төрмәгә дә утыртмыйлар, уку йортыннан да кумыйлар, – дип тынычландырырга ашыкты. – Минем сезнең якларда булганым бар. Сезнең авылны да, кайбер кешеләрен дә ишетеп-күреп белә идем. Ләкин күптән инде бернинди хәбәрем дә юк. Шуңа гына соравым. Әтиегез Салихҗан исән-саумы?

Гөлкәй, чыннан да, беркадәр тынычланып киткәндәй булды, эчке калтыравы басылды.

– Әти вафат... Ике ел инде.

Мансур Ибраһимович хөрмәт йөзеннән берара тын торды.

– Авыр туфрагы җиңел булсын... Әниегез?

– Әни исән-сау, авылда.

– Димәк, сез ятылаш ятимә... Бу турыда старостага әйтергә онытмагыз, сезгә дәүләт материаль ярдәм күрсәтергә тиеш. Туган якларыгызга бик еш кайтып йөри алмассыз дип уйлыйм. Әтиегезнең абыйсы Гарифҗан исән-саумы?

– Әйе, исән-сау...

– Кайткан очракта миннән сәлам тапшырырсыз. Кемнән дисә, «Ибрай нәби оныгы»ннан диярсез... Аңладыгызмы?! Шулай дисәгез, мине искә төшерер... Онытырсыз, дәфтәрегезгә язып куегыз.

– Онытмам. Ибраһим пәйгамбәр оныгыннан диярмен.

Мансур Ибраһимовичның кара күзләрендә гаҗәпләнү утлары дөрләп кабынды да Гөлкәйнең күңелен өтеп алды. Кыз бер мәлгә горурланып куйды: гел белемсезгә санамасын әле аны укытучы, әбисе юкка гына Гөлкәйгә төннәр буе пәйгамбәрләр тарихын яттан сөйләмәгән...

– Бик яхшы. Ерактан килгәч, Казанда туганнарыгыз бардыр инде.

– Юк, минем монда беркемем дә юк.

Мансур Ибраһимовичның күзләрендә тагын гаҗәпсенү чагылып китте. Ничек инде, унҗиде яшьлек кыз баланың ялгызын Казанга чыгарып җибәрәләрмени... Нәрсә турында уйлаган бу кызның якыннары?!

– Алай икән... Тулай торакка урнаштыгызмы?

– Әйе.

Мансур Ибраһимович, Гөлкәйгә карап, берара сүзсез торды. Кыз бу караштан бөрешеп килде, нишләргә белми, озын толымының очын бөтерә башлады. Мансур Ибраһимович та бу кара чәч көлтәсенә карап, сокланып куйды. Хәзер Казанда мондый чәчләрне сирәк очратасың...

– Ярар алайса. Ә хәзер, Гөлкәй Салихҗановна, шуны әйтәсем килә: куелган таләпләр барлык студентларга да бертигез, шул исәптән сезгә дә. Дәрес калдырмаска тырышыгыз, яхшы укыгыз. Уңышлар сезгә.

– Рәхмәт. Сау булыгыз.

– Хушыгыз, Гөлкәй.

Коридорның икенче башында Гөлкәйне Гөлүсә көтеп тора иде.

– Йә, нигә чакырган сине Мансур Ибраһимович? – Гөлүсәнең кызыксынуы тавышына чыккан, күзләре һәрвакыттагыча түземсезләнеп яна. Гөлкәй ни әйтергә белми аптырап китте.

– Болай гына... Кайдан килүемне сорады. Еpактан булгангадыр инде. Себердән башка беркем дә юк бит.

– Дәрестә әйттең ич инде. Нигә кабат-кабат сорарга?!

– Белмим... Йә «укый алмас» дип уйлыйдыр.

– Ә-ә. – Гөлүсә җаваптан канәгать калды булса кирәк, Гөлкәйне култыклап алды да чыгу ягына таба алып китте. – Бик «каты» укытучыга охшаган шул. Алайса, кызлар «Мансур Ибраһимович, Мансур Ибраһимович» дип авыз суы корыталар. Күрсәтер әле бу Мансур Ибраһимович күрмәгәнне...

Гөлкәй елмаеп куйды. Әле кичә генә Гөлүсә үзе дә нәкъ шулай ук «Мансур Ибраһимович» дип авыз суы корыта иде түгелме соң...

Институт баскычларыннан төшеп җиткәнче үк, Гөлүсәнең бертуктаусыз нәрсәдер такылдавыннан Гөлкәй гарык булды, китапханәдә утырырга кирәклеген сылтау итеп, тизрәк кыздан котылырга ашыкты. Аның үзенең генә каласы, Мансур Ибраһимович әйткән һәр сүзне күңелендә торгызып, яңадан рәхәт мизгелләрне кайтарасы килә иде. Йа Хода, нинди бәхет бирде аңа ул бүген! Кыз укытучы алдында калтырап басып торганын гел онытты. Булсын, Мансур Ибраһимович өйләнгән булсын, балалары да булсын – Гөлкәй бит аның тормышына бәреп керергә җыенмый; бары шундый гүзәл, мөкаддәс Укытучы белән икәүдән-икәү калып, сөйләшү-серләшүен яңадан күңеленнән кичерергә генә тели... Аларның инде нәни генә серләре дә бар – Мансур Ибраһимович аларның авылында булган, бәлки, әти-әнисен дә күреп белгәндер әле... Гөлкәй бу турыда беркемгә дә әйтмәячәк... Кыз, үз уйларының татлы ләззәтенә чумып, әкрен генә шәһәрнең икенче читендә диярлек урнашкан тулай торакка таба җәяү атлады...

...Мансур Ибраһимович, дәрестән чыккач, университетка, үз кафедрасына кайтты. Биредә лекцияләр тәмамланган, укытучылар күптән кайсы-кая таралышканнар. Лаборант кызлар да кайтырга җыенып яталар иде, ләкин эш сәгате бетмәгән булганга, Мансур Ибраһимович алдында ук чыгып китәргә тартындылар. Бераздан арада иң чаясы китәргә рөхсәт алгач, барысы бергә саубуллашып чыгып киттеләр. Кафедра бөтенләй бушап, тынып калды. Өйгә кайтасы килми иде. Тик эшләргә дә мөмкин түгел. Нәрсәдер җитмәгән сыман, нәрсәдер күңелне тыр-

нап тора сыман. Бу тынлык... Мансур Ибраһимович тәрәзә янына килеп басты. Икенче катта гына урнашкан кафедра тәрәзәләре университет китапханәсе ягына карый. Ара-тирә студентлар күренгәләп ала, көзге җил нечкә каен агачының ялангач чыбыкларын туздыра, яшь чыршы ботакларын болгый... Соргылт болытлар караңгылыгында чыршылар, карасу төскә кереп, куркыныч сурәт барлыкка китерәләр, хәтердә күз нуры җитмәс биек наратлар, мәһабәт чыршыларның көзге җил-давылда ыңгырашуы яңара... Мансур Ибраһимович күңелен нәрсә тырнаганын тойды: беренче курс студенткасы белән сөйләшү тынгылык бирми иде аңа. Бу кызны ул беренче көнне үк күреп алды. Мондый озын калын кара толымнар, мондый кыяфәт, зифа буй, мондый йөз алсулыгы Себернең чыршы-нарат урманы һавасын сулап үскән, чәчен кар суы белән юган балада гына була ала. Ялгышмады. Шулай да, кыз үзен Себердән дип таныштыргач, бер мәлгә ышанасы килмәде. Мансур Ибраһимович үзе тумышы белән Себердән, әлеге студентканың авылыннан ерак түгел генә урнашкан Суыксу кантоныннан иде. Фатыйх мулла белән үз бабасы аерылмаслык дуслар булганнар... Кызның әтисенең егет чагын хәтерли, ә Гарифҗан абзасы аның беренче укытучысы булды. Ничә ел инде туган якларына аяк басмаганына... Төшләренә әнисенең кара шәл ябынып керүе, үпкәле караш белән сүзсез генә карап торуы юктан түгелдер... Ата-ана каберенә юлны оныткан кешенең гомере хәерле булмас, дия иде Гарифҗан абзасы. «Юк, кайтам, быел кайтам, – Мансур Ибраһимовичның уйларына үзеннән-үзе коммунист өчен дөрес булмаган ялгау килеп керде. – Алла теләсә... »

* * *

– Математика, математика,  
Геометрия һәм дә алгебра!  
Мин сезне, мин сезне,  
Мин сезне я-ра-там!  
Прыйхади к вараатам! –

дип, бүлмә буенча китабын кочаклап вальста әйләнгән Гөлүсә ахыр чиктә караватка килеп ауды. – Уф! Кызлар, күпме ятларга мөмкин! Әйдәгез кинога! Концертка! Театрга! Кая да булса!

– Иртәгә контроль эш, дустым. – Караватка мендәр куеп, сөялеп утырган Фаягөл китаптан күзләрен алмый гына җавап бирде. – Аннан соң өченчекөн генә концертка бардык лабаса.

– Барсак ни! Тагын барыйк! Без бит Казанда яшибез! Ка-зан-да! Культура үзәгендә!

– Синең белән «стёпка»[1]ны җиткереп бетереп булмас, валлаһи! Көн дә бәйрәм, көн дә туй, имеш! – Фаягөл, тезләрендә яткан китапны япты да күзләрен угалады. – Әйдә, тор, чәй эчик, булмаса.

Гөлүсә килештереп кенә йөзен чыткан булды, караватта чалкан әйләнде дә, кеткелдәп, карчыклар тавышы белән:

– Самавыр куй, кодагый, сәй эсәрбез, – дип кыланып күрсәтте. – Сезнең такта чәйдән[2] минем эчләрем күпте инде. Тоталар да чәй эчәләр, тоталар да чәй эчәләр! Шул «эшләпә» кәнфит белән «сушки»ларыгызны күрәсем дә килми! Шоколад булса иде ичмаса!

– Ә мин үлән чәе эчәр идем. Бездә үлән чәен бик яраталар. – Гөлкәй дә өстәлдән китапларын җыя башлады. – Файдалы да.

– Индийский чәйгә җитми инде барыбер. Их, кызлар... Кайчан без дә шоколадны кетердәтеп тешләп, индийский чәйләр генә эчәрбез икән, ә?! – Гөлүсә хыялланып кулларын түшәмгә сузды, рәхәтләнеп киерелеп алды.

– Ким дигәндә, бер илле елдан – «иң өлкән» бухгалтер булгач. – Фаягөл Гөлүсә янына килде дә, сузылып яткан кызны каравыл кычкыртып, кытыклый башлады. – Әйдә, тор, шоколад белән индийский чәй көтә үзеңне!

Гөлкәй караватта әүмәкләшкән кызларга карап елмайды, өстәл әзерли башлады. Әлбәттә, чәйләре шоколадсыз, ләкин калган барысы да җитешле. Бәрәңгене капчык белән Зөлфиягә алып килделәр, итне, салкыннар башлану белән, Чаллыдан Фаягөлнең әтисе калдырып китте. Суыткычлары юк иде, әлбәттә, шуңа күрә таза гына бозауның шактый зур кисәген, кечкенә капчыкка салып, форточканың тышкы ягына элделәр. Кызларның бәхетенә, быел октябрь уртасында ук кар ятты, борыннарны чеметерлек салкыннар уйный башлады. Суган, кишер, башка вак-төякне Рәмилә белән Гөлүсә бер якшәмбедә авылга кайтып алып килделәр. Гөлкәй үзен кызлар алдында уңайсыз хис итте: ерактан булгач, әлбәттә инде, ул берничек тә бәрәңге дә, ит тә, кишер-суган да алып килә алмады. Казанда сатып алырга акча ягы да сайрак: стипендиядән башка кереме юк... Кыз уйлады-уйлады да көннәрнең берендә эш эзләргә чыгып китте. Студентлар-

[1]«Степка» – стипендия (жаргон).
[2] Такта чәй – прессланган, такта рәвешендәге түбән сортлы чәй.

ның кайберләре эшләп укыганлыкларын ул ишетеп белә иде: егетләр вокзалга вагон бушатырга йөриләр, кайберләре ипи заводында конвейерда ипи салып-майлап тора, кызлар шәфкать туташы булып төнге сменага чыгалар яисә кул эше – чигү, бәйләү алалар... Тик болар Гөлкәйнең вакытын күп алыр сыман тоелды, шуңа күрә акчасы азрак булса да, артык күп вакыт таләп итмәгән эш табарга иде исәбе. Әбисе әйтмешли, фәрештәләрнең «амин!» дигән вакытына туры килгәндер инде: эш сорап кергән беренче китапханәдә үк идән юучы кирәклеге ачыкланды. Көнгә ике тапкыр: иртән һәм төштән соң идәннәрне юарга да, гөлләргә су сибеп, тузан сөртергә. Китапханә зур түгел, балалар китапханәсе генә. Иртән сәгать биштә торып эшләп кайта да, өстен-башын алыштырып, кызлар белән укуга бара. Төштән соң дәресләр беткәч, китапханәнең ялы вакытында тагы бер тапкыр идән юып, тузан сөртә, шуның белән икенче көнгә кадәр – вәссәлам! Айлык эш хакы стипендиядән дә күбрәк – кырык сигез сум илле тиен! Гөлкәй мондый эш турында хыяллана гына ала иде, шуңа үзен кулына бәхет кошы тоткан кебек хис итте. Җитмәсә, беренче көнне үк аванс бирделәр. Гөлкәй сумка тутырып тәм-том, җиләк-җимеш алып кайтты. Кызларның күзе шар булганын күреп, үз-үзе белән горурланып та куйды: юк, югалмаячак ул!.. Башкалар кебек үк өс-башын да карар, кино-театрга да йөрер. Ятимә диеп, дәүләттән теләнмәячәк ул, эшләп ашаячак!..

– Кызлар, мин чәй куям да юл уңаенда Рәмилә белән Зөлфияне алып менәрмен. – Гөлкәй, тарткалашудан башыкүзе тузган, йөзләре кызарып чыккан, үзләре бертуктаусыз кеткелдәгән кызларга кул селтәп, кухняга чыкты, чәйнеккә су агызып, пычранудан төсе беленмәгән гомуми плитәгә утыртты да беренче катта урнашкан уку залына төшеп китте. Тулай торакта уку залы булу зур бәхет иде: теләсәң, кирәкле китапны таба аласың, тыныч, сиңа беркем комачауламый, рәхәтләнеп укы да укы... Шулай да кызларның сирәге монда уку өчен төшә. Күбесе чәчләренә матур прическалар ясап, матур күлмәкләр киеп, үзләре белән кимендә биш-алты калын-калын китапны култык астына кыстырып, йә булмаса кочаклап, арткы рәтләргә елышкан егетләр яныннан биек үкчәле туфлиләрдә тек-тек кенә басып, бик һавалы кыяфәттә тәмле исләр аңкытып үтеп китәләр. Юк, опера театрында да болай ук купшыланмый кызлар. Егетләр исә... К.Марксның калын «Капитал»ын йә Ф.Энгельсның кешенең маймылдан хезмәт нәтиҗәсендә яралганын укып утырган егетләр исә мондый кызларның маймылдан яралганлык-

ларына шикләнә башлыйлар... Ә В.И.Ленин «бер адым алга, ике адым артка» дию белән һич хаклы түгел... Мондый кызлар янында артка атлау һич ярамый... Алга, бары алга гына – залның түрендә урнашкан кечкенә китапханәнең китап бирүчесе янына барып, тагы берничә саллырак том сорарга кирәк... Курсеннәр – егетләр дә төшеп калганнардан түгел. Иң әһәмиятлесе – кире үз урыныңа кайтканда кызга мәхәббәтле караш ташларга йә булмаса күз кысарга гына кыюлык җитсен. Тезләре ялтырап чыккан трико ыштан, иңнәре асылынган футболка матур түгел түгелен дә, тик чалбар белән күлмәк бары институтка кияргә генә шул. Монда да кия башласаң, кайбер урыннары ялтырап тишелеп чыкканын көт тә тор. Ярар, акыллы башлар таркау булалар инде алар – егетләргә «пойдет»... Өй халатыннан, бүлмә башмакларыннан утырган кызлар исә «конкурент» якка дәһшәтле күз утлары җибәрәләр – янәсе, укырга түгел, танцыга барырга кирәк мондый кыяфәттә. Гөлкәй залга кергәч тә, нәкъ менә өй халатыннан калын китапларга күмелеп утырган ике кызга таба юл алды. «Кызлар, әйдәгез, чәй эчәбез, – диде ул, пышылдап кына. – Арыгансыздыр инде». Рәмилә, август аенда иртәләрен җиргә иңә торган томан халәтенә кергән күзләрен китаптан аерып, Гөлкәйгә текәлде, баштарак кызның нәрсә әйткәнен аңламаган кыяфәттәрәк сүзсез торды да «Ә-ә!» дип куйды. Зөлфия исә шунда ук китапларын җыя башлады.

– Кызлар, чәй эчәргә безне дә чакырыгыз әле, ә?! – Кызлардан артта гына утырган ике егет боларның сөйләшүен ишеткән, ахры, күзлеклесе Гөлкәйгә текәлгән, икенчесе яртылаш партага ятып, Зөлфиягә эндәшә. – Без дә бик арыдык!

– Укыгыз, укы! – Зөлфия, тавышын да төшерми, егетләрне кырт кисте. – Чәй эчүгә караганда уку файдалырак! Бигрәк тә сезгә!

– Ә бездә Пушкинның басылмаган шигырьләре бар! Чәй эчерсәгез, укырга биреп торабыз!

Рәмиләнең колагы торды, шунда ук егетләргә борылып, сынап карады:

– Шыттырасыздыр әле! Пушкинның басылмаган нинди шигырьләре булсын! – диде.

– Һи, Артур, шуны да белмиләр икән болар. – Җирән чәчле егет күзлеклегә борылды. – Әллә лекция укып чыгасыңмы үзләренә?!

– Мәхәббәт турында алар. – Күзлекле егет бу юлы Рәмиләгә текәлгән иде. – Басарга ярамый, шуңа күрә басылмаганнар.

Кинәт янәшәдәге берничә партадан берьюлы кисәтүле тавыш яңгырады:

– Шаулашмагыз! Сез үзегез генә түгел монда!

– Кызлар, киттек. – Гөлкәй, Рәмиләнең тузылып яткан берничә китабын кулына алып, уку залыннан чыкты. Кызлар аңа иярделәр. Коридорга чыккач, Зөлфия киң итеп сулыш алды да, тынын җыеп:

– Уф! Бүгенгә җитәр! Башка төшмим, – дип, башын як-якка бора-бора, юл уңаенда гимнастика ясый башлады. Чаттан борылганнар гына иде, арттан теге егетләр куып җитте.

– Ну, кызлар, ничек? Чәй эчәбезме?! – Җирән чәчлесе бик чаяга охшаган, өзми дә куймый. – Шигырьләр укыр идегез.

– Кәнфитегез бармы соң? – Рәмилә, күрәсең, Пушкинның үзенә таныш булмаган шигырьләрен уку өчен бер стакан чәйне кызганмаска карар кылды. – Кәнфитегез булса, пожалысты.

Зөлфия дустына бераз гаҗәпләнеп караса да, дәшмәде, киң итеп елмайды, атлаган уңайга, егетләргә борылып:

– Белмим шул, таныш түгел егетләр белән чәй эчү килешер микән? Кызлар, нишлик икән? – дип чытлыкланды.

Егетләр, нәкъ менә шушы чытлыклану тонын гына көткәндәй, җанланып киттеләр, җирән чәчлесе, кызларның алдына ук чыгып, кулын күкрәк турысына китерде дә, артистларча баш иеп:

– Танышырга әзербез. Мин – Ринат, ә бу галиҗәнап Артур була, – диде. – Ә сезне кемнәр дип белик?

– Белми торыгыз әле. Кәнфит белән шигырьләр алып керсәгез, бәлки, белерсез дә.

Гөлкәй Рәмиләгә, беренче күргәндәй, гаҗәпләнеп карады. Кара син аны, китап корты булып күренсә дә, егетләр белән ничек шәп сөйләшә белә икән бит бу кыз! Ә Гөлкәй менә тартына, сүз табалмый... Кызара. Бу оялчанлыгы аркасында көлкегә калмаса ярый инде...

Егетләр керә дигәч, Фаягөл белән Гөлүсә мизгел эчендә урын-җирләрне җыештырып, өс-башларын рәтләделәр, Зөлфия белән Рәмилә юынып кергәләгәнче, Гөлкәй белән бергәләп табынны хәстәрләп тә куйдылар. Егетләр бүлмә ишеген шакыганда, кызлар инде өстәл янына тезелешеп утырганнар иде.

– Керергә мөмкинме, кызлар? Исәнмесез! Чакырылган кунакларны кабул итәрсезме икән?!

– Килешкән шартлар үтәлгәндә, без кунакларга һәрчак шат! – Рәмилә егетләрнең кулларына күз салды. Сүздә

торганнар, ахры, җирән чәчлесе матур бизәкле тартма, икенчесе бераз таушалган сары тышлы дәфтәр тоткан. Рәмиләнең йөзе яктырып китте. – Узыгыз!

Бүлмәдә урындыклар бишәү генә иде, шуңа өстәл артына утырышканчы, дәррәү торып, өстәлне караватка иңе белән борып куярга туры килде. Кысылып-кысанкырап булса да, ниһаять, утырыштылар. Җирән чәчле егет тартмасын өстәлгә куйды, кызларга карап, беркадәр гаепле елмаю белән:

– Кызлар, үпкәләмәгез, зинһар! Кәнфитебез юк чакка туры килде, шуңа күрә азга гына канәгать булырсыз инде... – диде.

Тартманы ачкач, кәнфит урынына матур итеп тезеп куелган шикәр шакмакларын күреп, кызлар башта сүзсез калдылар, бер-берсенә карашып алгач, Гөлүсә һәрвакыттагыча кеткелдәп көлде:

– Ну молодцы, егетләр! Оста алдагансыз без җүләрләрне...

– Валлаһи дип әйтәбез, Казанны бетереп эзләсәк эзләрбез, әмма киләсе керүгә бер тартма кәнфитне генә табарбыз!

– Алырга акчагыз җитәрме соң?

– Күрерсез менә!

Рәмилә егетләргә чын-чынлап үпкәләде булса кирәк, гомуми көлешкә кушылмыйча, күзлекләре өстеннән генә карап, кырыс тавыш белән:

– Нәрсә, Пушкинның шигырьләре дә кәнфитләрегез кебек үк баллымыни?! – дип, күзлекле егеткә текәлде.

– Юк, шигырьләр, чыннан да, Пушкинныкы, чыннан да, алып кердек. – Күзлекле егет сары тышлы дәфтәргә ымлады, тик үзе шунда ук аны куенына салып куйды. – Чыкканда калдырырбыз.

– Ә нигә хәзер түгел?!

Егетләр, бер-берсенә карап, мут елмаештылар.

– Хәзер үк укырга ярамый аларны. Йоклар алдыннан гына укырга кирәк.

– Димәк, алары да ялган. – Рәмилә ачулы кыяфәт белән урыныннан торды, кызларга карап: – Кызлар, безнең чәй бетеп киткән икән. Кибеткә чыгарга онытканбыз лабаса, – диде.

Җирән чәчле егет шунда ук эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алды, күзлекленең куеныннан дәфтәрне алып Рәмиләгә тоттырды:

– Ярар, ярар, менә берничә куплетын укып карагыз соң. Ошаса, кич белән дәвам итәрсез. Тик ошамаса, без гаепле түгел. Ә хәзер әйдәгез танышыйк. – Егет, Рәмилә-

нең сүзләренә һич кенә дә хәтере калмаганын күрсәтеп, киң итеп елмайды, берәм-берәм кызларга кул суза башлады. – Мин – Ринат.

Артур да нәкъ шулай кызларга кул биреп танышып чыкты, дәфтәргә текәлеп утырган Рәмиләгә дә кулын сузды. Рәмилә кисәк кенә кып-кызыл чөгендер төсенә кергән йөзен күтәрде, чиксез аптыраулы карашын Артурга текәде, тиз генә егетнең кулын кысып:

– Боларны Пушкин язуы мөмкин түгел! – дип пышылдады.

Егет шулай буласын белгән кыяфәттә җилкәсен җыерды:

– Белмим тагы... Мин әйтмим, халык шулай ди...

Кызлар шунда ук, кызыксынып, Рәмиләгә борылдылар, Фаягөл дәфтәргә үк сузылды.

– Юк! Хәзер түгел. Соңрак укырбыз. – Рәмилә дәфтәрне үзе утырган түшәк астына ук тыгып куйды.

Күңелле генә чәй эчтеләр. Егетләр өченче курста укыйлар икән, шуңа да, ахры, сүзгә җор, кыю иделәр, төрле көлкеләр сөйләп, кызларны көлдереп бетерделәр. Шактый вакыт үткәч кенә, кызларның иртәгә буласы контроль эшләре искә төште, егетләрне тиз-тиз бүлмәдән озата башладылар. Алар чыгып ярты сәгать вакыт үтте микән, бүлмә ишеген кабат шакыдылар.

– Керегез, бикле түгел!

Бүлмәгә ниндидер кәгазь тоткан озын буйлы егет килеп керде. Кызларны сөзеп карап чыкканнан соң, ручкасы белән кулындагы кәгазьгә төртеп:

– Тә-әк... Рәмилә, Гөлкәй! Биредә яшиләрме?! – дип сузды.

Кызлар яңа гына өстәлне җыеп, яңадан укырга утырырга әзерләнәләр иде, аптырап, бер-берсенә караштылар. Рәмилә шикле тавыш белән җавап кайтарды:

– Биредә булса, ни булган?!

– Сезне ашыгыч рәвештә комендант чакыра. Рәмилә – китапханәгә, Гөлкәй комендант бүлмәсенә керегез.

Кызлар аптырап калдылар.

– Ә нәрсәгә комендант безне бу вакытта чакыра?! Нигә алай аерым-аерым?! – Рәмиләнең шикләнүе артты гына.

– Китапханәче китапларыгызны вакытында тапшырмаган өчен комендантка зарланган, шуңа сез башта китапханәгә кереп, барысын да үзегез ачыклагыз. Ә Гөлкәйнең документларын тәртипкә китерәсе бар, диделәр.

Рәмиләнең йөзенә канәгатьсезлек чыкты.

– Минем тапшырмыйча калдырган китапларым юк, булуы да мөмкин түгел.

– Мин – түбән курслар буенча тулай торак кураторы. Комендант әйткән сүзләрне генә җиткерәм. Калганын үзегез ачыкларсыз. Барыгыз, бар.

– Әйдәгез, мин дә сезнең белән. – Фаягөл яткан җиреннән сикереп торды.

Егет Фаягөлгә карап алды да яңадан кәгазенә текәлде.

– Тәк... Бер генә минут. Сезнең исемегезне ничек дип белик?! Исемлектә күзгә чагылдыгыз бугай... Хәзер карыйбыз. Ә сез барыгыз, көттермәгез комендантны.

Рәмилә белән Гөлкәй бүлмәдән чыгып киттеләр, Фаягөл егет белән сөйләшә калды.

– Гаҗәп, комендант фамилияләп түгел, ә исем белән чакыра безне, – диде Рәмилә, баскыч буйлап беренче катка төшкәндә. – Бер үк комендантка барабыз, сиңа – бер якка, миңа – икенче якка.

– Сиңа башта китапханәгә кереп ачыкларга кушты ич. Шуңадыр. – Гөлкәй бу сүзләрне Рәмиләне тынычландыру өчен генә әйтте, чынлыкта исә үзе дә аптырашка калган иде. Нинди документлар турында сүз барырга мөмкин?! Тулай торакка урнашканда барысы да тәртиптә иде ич. Әллә мулла кызы булуын белеп алдылар микән?! Мансур Ибраһимович җиткерде микәнни?! Булуы мөмкин түгел...

Комендант бүлмәсе урнашкан коридор ягында утлар сүндерелгән, кеше йөргәнен күрсәтүче бер дәлил дә күренми иде. Гөлкәй, тимер рәшәткә белән бүлеп алынган якка чыгып, тимер йозакны тартып карады. Бикле. Аптырап, кире борылган гына иде, якындагы ишек уемыннан кеше шәүләсе калкуын күреп куркып китте, артка чигенде, салкын рәшәткәгә аркасы белән килеп терәлде.

– Гөлкәй... Курыкмагыз, бу мин, Ринат.

Шунда гына кыз ерактан саркыган сүрән ут яктысында җирән чәчләрне абайлап алды, таныш кешене күреп, җиңел сулап куйды.

– Ә, Ринат... Мине монда комендант чакыра диделәр, үзенең бүлмәсе бикле. Әллә ялгыш аңлаганмын инде.

Җирән чәчләр якын ук килделәр, караңгы коридорда егетнең күзләре ялтырап китте.

– Гөлкәй, ачуланмагыз, зинһар. Комендант түгел, мин чакырдым монда сезне.

Гөлкәй аңламаган кыяфәт белән басып тора бирде. Ринат, бөтенләй үк якын килеп, кызның уң кулын учларына алды, бераз салкынча бармакларны кайнар учында әвәләде.

– Гөлкәй... Сезне иртәгә киного чакырырга мөмкинме?! Мин сезнең белән дус булырга телим.

Кинога?! Нинди кинога?! Нигә?! Гөлкәйнең беркайчан, беркайчан да егетләр белән кинога барганы юк. Гомумән, ниндидер егет белән дус булып йөргәне, бу турыда хыялланганы да юк иде. Авылда чакта классташ егетләр йә булмаса күрше егет-җилән белән кич капка төбендә утырырга чыга, бергәләп утын, печән әзерлиләр, мәктәп кушуы буенча колхоз эшләренә йөриләр, тик беркемнең дә аңа болай якын килеп, «әйдә, дус булыйк» дигәне булмады. Гөлкәй ничектер моны теләмәде дә булса кирәк. Шуңа хәзер бөтенләй аптырап калды, нәрсә әйтергә белми, Ринатка туп-туры карап, беркадәр вакыт дәшми басып торды. Дус булырга?! Егет белән кыз булып йөрергәме?! Бу егет аңарда бернинди хис уятмый... Әнә кулын әвәләве дә ничектер сыерның яңа туган бозавын ялаганы кебек кенә... Ә егеттән аңкыган каты тәмәке исе бөтенләй күңел кайтаргыч... Егет исә, кызның дәшми торуын күреп, үзенчә юрады булса кирәк, кыюланып китте. Кулын ычкындырып, рәшәткәгә сөялгән Гөлкәйне кысып кочаклап алды, колагына иелеп, кайнар пышылдады, кызның иреннәренә үрелде:

– Гөлкәй... Сез миңа бик ошыйсыз... Бик... А-аһ! Ы-ы-ы...

Җан җиренә күсәк белән китереп суктылармыни, егет авыртудан бөгелеп килде. Гөлкәйне моңа әнисе өйрәткән иде.

– Гафу итегез, сез миңа ошамыйсыз.

Гөлкәй юлында бөгәрләнеп торган егетне кырыйга этеп җибәрде дә коридор буенча үз бүлмәсенә таба йөгерде. Эчендә әлеге җирән егеткә нәфрәт уты дөрләде. Кара син аны, ничек тота үзен... Гөлкәйне мәлҗерәп төшәр дип уйлагандыр инде. Мәлҗерәми торсын әле менә. Шул кирәк кабахәткә. Биш катның баскычын өч сикерүдә менеп, ишекне бәреп керде дә эчтән бикләп үк куйды. Кызлар аптырап аңа текәлделәр. Гөлкәйнең сулуы капкан иде.

– Рәмилә кайда?!

– Нәрсә булды?! Гөлкәй, нәрсә булды?! Әллә Ринат рәнҗеттеме?!

Рәмилә инде бүлмәдә икән. Димәк, аны да Артур чакырган. Кыяфәтенә караганда, Рәмилә алай исе киткәнгә охшамаган. Гөлкәй, бераз тынын җыеп, Рәмиләгә эндәште:

– Артурны күрдеңме?!

– Күрдем. Нигә?!

– Кинога чакырдымы сине дә? Нәрсә дидең?!

Рәмилә, көлеп, Гөлкәйне караватына утыртты, чәйнектән су салып бирде.

– Карарбыз, дидем. Иртәгә кадәр әллә хан үлә, әллә ишәк үлә, нәрсәгә алдан юрарга. Ә син, ахры, кире каккансың.

Гөлкәй бераз тынычланды, стакандагы суны эчеп бетереп, кызларга борылды. Гөлүсә, Зөлфия, Фаягөл, сәерсенеп, хәтта беркадәр кызыгып, боларга карап торалар иде. Уңайсыз булып китте.

– Менә кемнәрнедер кинога да чакыра башладылар. Ә безгә кем карар икән?!

Фаягөл алдындагы китабын шапылдатып япты да Гөлкәй янына килде.

– Йә, нигә ошамады инде сиңа Ринат? Прыйнц түгел, әлбәттә, әмма сөйкемле бытбылдык. Мин булсам, ризалашкан булыр идем.

Гөлкәй, читенсенеп, сөлгесен алды, юынырга чыгарга әзерләнгән булды.

– Менә шуңа... Бытбылдык булганга.

– Кызлар, оныттыгызмыни, Гөлкәй бит безнең билгесез шаһзадәгә гашыйк! Нинди Ринат турында сөйлисез! – Гөлүсә Гөлкәйгә якын ук килеп кочып алды, кызның озын толымнарын үзенең аркасына ыргытты. – Минем шундый толымнарым булса, мин мең егетне әсир итәр идем!

– Әйе, егетләр озын чәчле кызларны яраталар шул. – Зөлфия дә Гөлкәйнең толымнарына кызыгып карады. – Мин дә шундый чәчләрем булуын бик теләр идем.

– Юк, дөрес түгел. – Фаягөл исе китмәгәндәй шкафка эленгән көзгегә каранды, кыска киселгән чәчләрен төзәткәләде. – Егетләр кыска чәчле кызларны яраталар, әмма озын толымлыга өйләнәләр, чөнки озын толымлылар беркатлы булалар. Алар белән яшәү уңайлырак, теләсәң ничек алдап була.

– Фаягөл! – Рәмилә усал гына кычкырып алды. – Нәрсә сөйләгәнеңне чамалап сөйлә, яме?!

– Ә нәрсә?! Ничек бар, шуны гына әйтәм ич. Менә Гөлкәй Ринатны кире каккан, ә син Артурны җайлапмайлап озаткансың, шулаймы?! Чөнки Артурның алга таба кирәге чыгуы мөмкин. Ә Гөлкәй Ринатка башка мөрәҗәгать итә алмый инде. Минемчә, бу – беркатлылык.

– Ринат миңа ошамый, аңлашылдымы?! – Гөлкәйнең дә ачуы кабарды. – Әгәр кирәк булса, үзең аны киногә чакыр, Фаягөл. Ул бик теләп ризалашачак.

– Ә нигә, чакырырмын да. – Фаягөлнең исе китмәде. – Мин андый сайланчык түгел.

– Фаягөл! – Рәмилә чын-чынлап тузына калды, Гөлкәй исә, сөлгеләрен алып, юынырга чыгып китте. Беркатлы... Беркатлыдыр инде, егетләр белән аралашканы булмагач.

Үз насыйбы табылыр әле, Алла теләсә. Әбисе әйтмешли, бәхете җилдән сипләнгән түгелдер...

Бу кечтә кызлар беренче мәртәбә көлешмичә, тын гына йокларга яттылар. Рәмилә хәтта Пушкин шигырьләрен укырга онытты. Фаягөлнең үзенә егетләр карамаганына ачуы чыккан иде, шуңа Гөлкәйгә төртмәләнеп, ачуын алды. Нәрсә тапканнардыр шул Себердән килгән беркатлы курчак белән күзлекле акыллы башта... Ни ите, ни сөяге дигәндәй... Иң элек аңа игътибар итәргә тиеш иделәр... Арада кем иң затлы киенә? Ул. Кемнең әти-әнисе югары урында эшли? Аның. Кемнең гаиләсендә соңгы модель машина бар?! Аның инде, аныкында. Төс-кыяфәткә дә төшеп калганнардан түгел. Шулай булгач, бүлмәдә егетләр күзе төшәрлек беренче кандидат – Фаягөл. Ә алар, имеш, толымнарга гашыйк булганнар... Карарбыз әле, кем иң беренче булып егетләр белән йөри башлар икән... Иртәгә үк хәл итәргә кирәк. Болай китап корты булып ятса, егетсез калачак. Ә ул яшьлеген китап тузаны иснәп үткәрергә җыенмый. Меңнәр арасыннан сайлаячак әле ул үз тиңен. Бераздан Фаягөл катгый карарга килде, тынычланып, йоклап киткәнен сизмәде дә...

Гөлкәйнең исә күзләренә йокы тиз генә эленмәде. Бүгенге вакыйгалар аңа һич кенә дә кирәкми иде... Фаягөл белән дә аралары суынган кебек булды. Ләкин Ринатның аны чакырганына Гөлкәй гаепле түгел ләбаса... Ул, гомумән, бу турыда уйлап та карамады, комендант янына дип төште... Ә Ринат аңа бөтенләй ошамый, күңелендә бернинди хис уятмый. Ничек инде яратмаган кеше белән йөреп китәргә кирәк?! Гөлкәй Ринатның үзен кочаклаганын күз алдына китереп бөрешеп куйды, борынына сасы тәмәке исе кергәндәй булды. Юк, беркайчан да. Әгәр менә Ринат урынында Мансур Ибраһимович булса иде... Гөлкәй күзләрен йомды, Ринатны Мансур Ибраһимовичның аксыл костюмына киендереп, җирән чәчләрне кара дулкынга алыштырды. Караңгы коридорда кара күзләр кара упкын булып кызны үзенә суыра башладылар... Менә көчле куллар Гөлкәйне сак кына кочып алдылар, тулы иреннәр, кызның колагына якын ук килеп, йомшак бәрхет тавыш белән кайнар пышылдады:

– Гөлкәй... Сез миңа бик ошыйсыз... Мин сезнең белән дус булырга телим...

Гөлкәй астан, бавырдан, күкрәк читлегеннән ургылып менгән татлы, ләззәтле хис дулкынында бата, иреннәре, кайнарланып, үзләре үк Мансур Ибраһимовичның иреннәрен эзли башлыйлар... Галәм карасында кинәт ярылган йолдыз нуры кебек ап-ак яктылык Гөлкәйнең зиһе-

нен чолгап ала, кыз талгын рәхәтлектә Мансур Ибраһимович кочагында кар бөртеге булып эри, җиргә сеңгән яңгыр тамчысы кебек саркып юкка чыга... озаграк, бу мизгел озаграк дәвам итсен иде...

– Гөлкәй... Гөлкәй!

Кыз күрше караваттан үзенә пышылдаган тавышка айнып китте. Урыныннан чак күтәрелеп, Рәмилә эндәшә иде:

– Гөлкәй... Ыңгырашасың – саташасың, ахры... Уң ягыңа борылып ят... сул якка – йөрәк ягыңа ятма...

Гөлкәй, ниһаять, реаль дөньяга кайтты, Рәмилә әйткәнчә борылып ятты. Йа Хода, менә шундый мәхәббәт бирсәң иде аңа! Мансур Ибраһимовичны оныттырып, үзенең тиңенә шулай гашыйк булса иде! Йа Рабби, Ходаем! Амин!

* * *

...Мансур Ибраһимович онытылырга уйламады да. Һәр атнаның дүшәмбесендә фәлсәфә фәне буенча лекцияләр укыды, һәр атнаның чәршәмбесендә семинар дәресләр алып барды. Гөлкәй укуга бик җаваплы карый иде, математиканы ул, гомумән, ярата, ә гуманитар фәннәр белән кызыксына. Бу кызыксынуы Мансур Ибраһимович исәбенә икеләтә артты. Дәресләрдә беренче көндәге кебек каушамый, калтырамый, сорауларга бик уйлап җавап бирергә тырыша, мөстәкыйль эшләрне дә уңышлы башкара. Мансур Ибраһимович мактауга саран, бик саран иде, шулай да Рәмиләгә һәм Гөлкәйгә кайчакта «Бик яхшы! Молодец!» дип куйгалады. Мондый көннәрне Гөлкәйнең үз-үзе белән горурланудан күңеле тула, иңнәренә канатлар үскәндәй була. Шулай итеп, Гөлкәй уку алдынгысы булып китте. Семестр азагы якынлашканда, укытучылар аңа берничә зачетны «автомат»[1] куярга вәгъдә иттеләр. Мондый дәрәҗәгә Гөлкәй, Рәмилә һәм төркемнән тагы берничә кеше генә лаек булды. Рәмилә белән Гөлкәй һәркайда бергә булдылар. Рәмилә теге вакытта Артурны үзенә якынайтмады да, бик кире дә какмады, егет шулай билгесез хәлдә ике-өч атна тинтерәп йөргәч, үзеннән-үзе юкка чыкты. Акыллы, бик акыллы иде Рәмилә. Гөлкәй шундый дус табуына чын күңеленнән куанды. Пушкин шигырьләрен ярсып, ятар алдыннан кызарына-бүртенә

---

[1]«Автомат» – яхшы укыган өчен узган материалны сорап тормый гына куелган зачет.

укып чыккач, кызлар башка мондый кулъязма эротиканы укымаска сөйләштеләр. Ринат исә икенче көнне үк бер тартма конфет алып керде, Гөлкәйдән гафу үтенде. Шул вакыйгадан соң янынnan үтеп киткән егетләр Гөлкәйгә ничектер башкачарак карый башладылар сыман тоелды, кыз таныш түгел егетләрнең «Исәнмесез!» дип исәнләшүләрен, баш иеп китүләрен хөрмәт билгесе дип кабул итте. Һәрхәлдә, шулай тоелды. Гөлкәйгә башка килеп бәйләнүче булмады. Фаягөл дә теләгенә иреште: ике-өч атна Ринат белән дус булып йөргәннән соң, тагы кимендә ике егетне алыштырды, укуда да сәбәпсез берничә дәрес калдырды. Соңгы атнада Мансур Ибраһимович янына барып, өстәмә дәресләр аласы иде. Башка укытучылар дәрес калдырганга билгеләрне түбәнәйтсәләр дә, алай өстәмә дәресләр билгеләмәделәр. Шулай итеп, 1982 елның декабре җитте. Коточкыч тизлектә Яңа ел, Яңа ел белән бергә зачетлар, аннан соң имтиханнар якынлаша иде. Хәер, моңа кадәр кызларны гына түгел, бөтен илне, хәтта бөтен дөньяны тетрәткән вакыйга булды: унынчы ноябрьдә Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының Генераль секретаре Леонид Ильич Брежнев дөньядан китте. Бу шулкадәр тетрәндергеч вакыйга иде ки, унбишенче ноябрь көнне бөек юлбашчыны күмгәндә завод-фабрикаларның, юлда туктаган машиналарның озын гудогына кушылып, бөтен халык – карты-яше, бала-чагасы – барысы да бик кайгырыштылар. Институтта да дәресләр тоташ сыктауга әйләнде. Күзләре кызарып беткән курсташларына карап, Гөлкәй үзен беркадәр гаепле сизде. Әлбәттә, ул да елады, тик Брежнев үлгәнгә түгел бугай... Әтисе аңа якынрак иде. Зөлфиянең битләре буйлап агып төшкән күз яшьләрен, Рәмиләнең өзгәләнүен күреп, алар өчен үкседе... Дәрес вакытында кайгы сүзләре әйткәндә, Мансур Ибраһимовичның тавышы карлыгып, калтыранып чыкты, Гөлкәйнең Укытучы өчен бигрәк тә үзәге өзгәләнде, аның кайгысын тулысынча үзенә алырдай булды. Тик – ни гаҗәп! – күзләре очрашкач, Гөлкәй кара тирәнлектә кайгы күрмәде. Ниндидер чаткы чагылып китте Укытучының күзләрендә... Өмет чаткысы идеме?! Гөлкәй аңламады, шулай да иркен сулап куйды: Мансур Ибраһимович кайгырырга тиеш түгел... Вакыт үтте, ноябрьне декабрь алмаштырды, илгә дә яңа башлык килде. Барысы да үз урынына төшеп утырды. Мансур Ибраһимович узган атнада сәбәпсез калдырылган дәресләр өчен өстәмә сәгатьләрен тапшырмаган студентлар исемлеген укыды. Исемлек кыска иде: Антонова Людмила, Гаязетдинов Марс һәм Шәрипова Фаягөл. Марс – аңлашыла

инде: егетнең, гомумән, укуга сәләте юк икәнлеге ачыкланды. Людмила кияүгә чыгып йөри, туйлары узгач, үзе килеп аңлатыр. Ә менә Фаягөл... Кызлар бүлмәдә Фаягөл белән сөйләшеп тә карадылар, әмма Фаягөл көлде генә: янәсе, сез бернәрсә аңламыйсыз. Мансур Ибраһимович аның барлык дәрес калдыруларын кичерәчәк. Гомумән, ул икенче семестрда Мансур Ибраһимовичның дәресләренә йөрмичә генә дә имтихан билгесе алачак. Менә күрерсез. Рәмилә бу сүзләргә мөнәсәбәтен чигәләренә бармагын төртеп боргалап күрсәтте: янәсе, Фаягөл ычкынган. Һәрхәлдә, иртән бүлмәдән институтка чыгып киткәндә, Фаягөлнең кәефе күтәренке иде. Бүген ул Мансур Ибраһимович янына өстәмә дәресләр алырга бара. Кыска кара итәкләрен киде, салкын кыш булуга карамастан, өсте шактый ачык кофтасын сайлады. Фаягөл уенча, мондый кыяфәттә аңа бүген теләсә кем (әлбәттә, ир-ат укытучылардан) зачет куя алачак иде. Дәресләр күз ачып йомганчы уздылар. Студентлар дәресләр тәмамлану белән кайсы кая таралышты: кемдер уку залына кереп китте, кемдер тулай торак бүлмәләренә юл алды. Әле Мансур Ибраһимович килергә шактый вакыт бар. Фаягөл ашханәгә кереп тамак ялгап чыгарга булды. Студентларга ашау өчен бирелә торган түләүсез берничә талоны калган иде, шуларга яшелчә салаты, каймак белән ипи сатып алып, иркенләп кенә ашарга утырды, алдына фәлсәфә буенча дәреслекне җәеп салды...

– О-О! Кемне күрәм! Фаечка! Ничек хәлләр?!

Поднос тотып, янәшәсенә килеп утырган Ринатка Фаягөл теләмичә генә җавап бирде:

– Ярыйсы. Үзең нишләп йөрисең?

– Ашханәгә прогулкага килдем. Нәрсә, зачетлар башланды да мәллә?

Фаягөл «интектермә әле» дигәндәй кул селкеде:

– Отработка. Фәлсәфәдән.

– Мансур Ибраһимовичмы?

Фаягөл баш какты, салатны ашап бетереп, каймакны эчеп җибәрде.

– Да-а. Каты чикләвек, сак бул. Күпләргә «койрык»[1] ясый ул «препод»[2].

– Подумаешь, «универ»[3]дан булгач та, кылана инде. Ничего, без дә төшеп калганнардан түгел.

---

[1] «Койрык» – тапшырылмаган зачет яисә имтихан.

[2] «Препод» – преподаватель – вуз укытучысы.

[3] «Универ» – университет.

Ринат шаркылдап көлеп җибәрде, подностан ризыкларын ала-ала, күңелле генә әйтеп куйды:

– Декольтеңның тирәнлегенә караганда, төшеп калган димәссең. Кайсы бәхетлесе юана инде бу матурлыкка карап? Миннән соң, әлбәттә.

– Да... пошел ты!

Фаягөл китабын шапылдатып япты да, җыенып, ашханәдән чыгып ук китте. Мансур Ибраһимович киләсе аудитория буш иде әле. Фаягөл укытучы өстәле каршысына искерүдән таркалырга торган бердәнбер урындыкны китереп куйды, күрше аудиториядән укытучыга яхшырак урындык алып чыгып, матур итеп тигезләп утыртты. Үзе каршы урындыкка барып утырды. Озакламый ишектә Мансур Ибраһимовичның мәһабәт гәүдәсе күренде. Укытучы килешле кара күн пальтодан, партком секретарьлары гына кия торган каракүл бүректән иде. Салкыннан кергәнлеге кызарып киткән бит урталарыннан, кара пальтосында эрегән кар бөртекләреннән күренеп тора. «Киенә белә дә инде, – дип уйлап куйды Фаягөл. – Мондый ир-ат белән урамнан үтүе генә дә ни тора!»

– Исәнмесез, Шәрипова. Нишләп берүзегез? Кайда Антонова, Гаязетдинов? Килмәделәрмени?

– Исәнмесез, Мансур Ибраһимович! Сезгә шундый килешә пальтогыз! Башкалар килмәде шул. Белмим, нишләп килмәгәннәрдер. Югыйсә, мин аларга отр... э-э... Өстәмә дәрескә киләселәрен исләренә төшергән идем.

Фаягөл сабакташларының дәрескә килмәүләрен үзенең уңышы дип кабул итте. Соңыннан кем бу турыда сорап торачак! Мансур Ибраһимович арткы парталарга үтте, өсбашын салып, чәчләрен тарады, өстәл янына килеп утырды. Кара күн портфеленнән журналын алып өстәлгә салды, Фаягөлгә борылды.

– Тә-әк. Шәрипова Фаягөл. Сез сәбәпсез биш дәрес калдыргансыз. Моны ничек аңлатырсыз?!

Фаягөл бу сорау булачагын алдан чамалаган иде, дөресрәге, бу сорауны көткән иде, шуңа бик аптырамый, йөзенә беркадәр серлелек чыгарырга тырышып, ашыкмый гына җавап бирде:

– Мансур Ибраһимович... Дәрес калдырган өчен гафу үтенәм. Шулай килеп чыкты инде. Ләкин мин сезнең дәресләргә шундый яратып йөрдем! Сезнең кебек тәҗрибәле укытучы безнең институтта башка юк. Сез шундый кызыксындырып сөйли беләсез! Сезне тыңлавы шундый рәхәт!

Мансур Ибраһимович урындыгында кыбырсып куйгандай булды, кызыксынып, Фаягөлгә текәлде:

– Шулай булгач нишләп сәбәпсез дәрес калдырдыгыз соң?

Фаягөл үзенең сүзләрен укытучыга ошады дип кабул итте, шуңа күрә, кыюланып китеп, тырнаклары кып-кызылга буялган озынча бармаклары белән өстәлне сыйпаштырып, назланып әйтә куйды:

– Мансур Ибраһимович... Беләсезме... Ничек итеп аңлатыйм икән...

Фаягөл керфекләрен түбән төшергән булды, йөзенә ясалма оялу кыяфәтен чыгарды, бераз дәшми торгач, яңадан мутланып, Мансур Ибраһимовичның күзләренә күтәрелеп карады.

– Беләсезме... – Кызның бармаклары өстәл буенча шуыштылар, үрелеп, укытучының ручка тоткан кулын каплап алдылар. – Биредә, бу шыксыз аудиториядә (кыз күзләрен акшарлары купкан стеналардан, ялангач тәрәзәләрдән йөгертеп алды), миңа аңлатырга, сөйләргә кыен... Бәлки, безгә башка урында иркенрәк сөйләшергә кирәктер?!

Мансур Ибраһимович барысын да аңлады. Әй-йе... Ел саен ук булмаса да, ике-өч елга бер булып тора мондый «сюрприз»лар... Үзе белән генә түгел, башкалардан да ишеткәне бар аның. Гадәттә, тәҗрибәсез ир-ат укытучы зачет яисә имтихан вакытында аудиториягә төркемнән иң соңгы булып кергән мондый декольтелы бәйләнчекләрдән куркып кала, кызкайлар нәрсә генә теләсә дә – зачетмы, экзаменмы – бернинди сораусыз шунда ук куя да чыгара. Янәсе, барыгыз, кадалыгыз, тик миңа гына кагылмагыз... Иң зур ялгышлары да шунда ул ир-ат укытучыларның. Ә кыз җиңүче Наполеон кыяфәтендә чыгып китә, кайткач, якын дус кызларына ничек итеп укытучының башын әйләндерүе, бер кочаклап үбүдән яхшы билге алып чыгуы турындагы уйдырманы кич буе рәхәтләнеп сөйли... Нәтиҗәдә әлеге ир-ат укытучы турында бик үк яхшы булмаган «миф» туа. Мансур Ибраһимович шактый тәҗрибәле шул инде, мондый тозакка гына кабарлык түгел. Ашыкмый гына кулын Фаягөлнең нечкә бармакларыннан азат итте дә, кызның күзләренә туры карап:

– Ә минемчә, зачет тапшырыр өчен укырга дип салынган дәүләт йортыннан да яхшырак урын юк, – диде. – Ягез, җитди сәбәп булса, әйтегез, булмаса, сорауларга күчәбез. Конспектларыгызны күрсәтегез.

Фаягөл һаман да өметен югалтмады, укытучыга башка яктан килеп карарга булды.

– Мансур Ибраһимович... Сәбәбе бар инде аның...

– Сәбәбе булгач, справка яисә башка дәлилли торган кәгазь алып киләләр.

– Минем әнием бик каты авырый шул, Мансур Ибраһимович. Яман чир аңарда, терелергә һич өмете юк... Шуңа күрә аның янына кайтып йөрергә туры килә.

Мансур Ибраһимович журналына күз салды.

– Сез Чаллыдан килгәнсез. Димәк, Чаллыга еш кайтып йөрисез дигән сүзегезме?!

– Авыру әни янына кайтмыйча булмый, үзегез аңлыйсыз...

Мансур Ибраһимовичның бу юлы чын-чынлап ачуы чыкты.

– Фаягөл Низамовна! Укытучыны беркатлы җүләргә санавыгыз белән бик каты ялгышасыз! Төркем журналы буенча, дүрт тапкыр сез бары минем дәрестән генә киткәнсез, бишенчесендә исә, гомумән, бер дәрескә дә килмәгәнсез! Сәгать ярым эчендә Чаллыга очып барып кайттыгызмы?! Алдашмагыз! Укымагансыз икән, икенче юлы килгәндә, бераз акыллырак булырсыз, әзерләнеп килерсез!

Мансур Ибраһимовичның ачулы тавышы, буш аудиториянең стеналарыннан яңгырап, тышка чыкты, күрәсең, – коридорда буталган студентлардан кемдер ишекне ачып, башын тыгып карады. Студентка укытучының бу кадәр тавышын күтәргәнен ишеткәне юк иде Фаягөлнең дә. Кинәт кенә кызу булып китте, бит урталары кызарып чыкты, куллары калтырый башлады.

– Бүген мин калдырган дәресегезнең берсен дә кабул итмим. Өч көннән яңадан килерсез. Әгәр укымыйча киләсез икән, тагы шушы юлны таптарга туры килер. Зачет сессиясе алтынчы гыйнварга кадәр, шуңа тикле «койрык»ларыгызны тапшырып бетермәсәгез, имтиханнарга кертелмәячәксез. Тәртибегезне тикшерүне комсомол җыелышына куярга мөмкин. Аңладыгызмы?!

Бу юлы Фаягөлнең күзләреннән яшьләр коелды. Үкенүдән түгел, гарьләнүдән иде бу яшьләр. Моны Мансур Ибраһимович та яхшы аңлады.

– Әйе, әйтергә онытып торам икән. Икенче юлы үзегез генә түгел, староста яисә төркемнең комсомол секретаре белән килерсез. Алар алдында үзегезне итагатьлерәк тотарсыз дип уйлыйм. Сау булыгыз.

Укытучы чыгып киткәч, Фаягөл, күз яшьләрен сөртәсөртә, ачуыннан алдында яткан ручкасын сындырды. Гөлүсәсен әйтер идем... Күрәсең, калдырган бөтен дәресләрне билгеләп барган. Дус булып кылана, җитмәсә... Ярый әле башка укытучылар Мансур Ибраһимович ке-

бек өстәмә дәрескә китереп йөртмиләр. Ким дигәндә, икеөч атна гына «отработка»га йөрергә туры килер иде Фаягөлгә... Староста, комсорг белән килергә, ди.. Гарьлеген кая куярсың...

Фаягөл, бөтен дөньяга ачуы килеп, тулай торакка кайтып егылды. Беркем белән сөйләшмәде, ашамады, эчмәде. Башыннан ук бөркәнде дә күз яшьләренә чумды... Ә бит ул Мансур Ибраһимовичка чын күңеленнән гашыйк иде. Матур булганы өчен, бөтен кызлар гашыйк булганы өчен, доцент булганы өчен... Дәрес калдыруының сәбәбе дә аның белән якыннан сөйләшергә теләгәннән генә иде. Йөр инде менә хәзер «койрык»лы булып. Йә, бер үпсә шунда, нәрсә була инде, ашаламы әллә?.. Ух, бу ир-атларны! Беркайчан хатын-кызның нәрсә теләгәнен аңламаслар...

* * *

...Яңа ел килеп җитте. Кызлар күптән инде зачетларын тапшырып бетереп, Яңа елны өйдә каршыларга дип кайтып киттеләр. Хәтта Фаягөл дә, көн укып, төн укып, Мансур Ибраһимович янына өч тапкыр барганнан соң, зачет алып, Чаллыга кайтып китте. Гөлкәй өйгә кайту турында хыяллана да алмады. Кайтырга гына өч көн вакыт кирәк, килергә шуның кадәр үк... Ә алтынчы гыйнварда беренче имтиханнары. Юк, мөмкин түгел. Кыз, сыкрап-сыкрап, Яңа елны тулай торакта каршыларга мәҗбүр булды. Шулай да бүлмәдә берүзе бикләнеп утырмас бит инде. Рәмилә үзе белән Әлмәткә чакырган иде дә, Гөлкәй яхшысынмады. Дусты туганнарына очына-очына Казан, институт турында, укуы турында сөйләгәндә, кирәкмәгән күзле бүкән булып утырмас бит инде. Нишләргә дә белгән юк... Шул күршеләргә керсә генә инде.

...Шактый вакытын китапханәдә имтиханнарга әзерләнеп үткәргәннән соң, моңсуланып кайтырга чыккан гына иде, арттан кемнеңдер дәшүен ишетеп борылса, Мансур Ибраһимовичны күреп читенсенеп китте. Энәдәнҗептән киенгән укытучы янында үзен бигрәк мескен сизде. Туны коточкыч иске инде... Мәктәптә үк киеп йөргән тун, җиңнәре кыскарып, кырылып беткән. Яңасына акча җыя гына әле... Итекләренең дә башлары кыршылган, җитмәсә, Себер салкыннарына түзәрлек итеп, эт йоныннан тегелгәнгә, алама Акбайны хәтерләтәләр... Мансур Ибраһимович аңардан Яңа елны кайда каршылаячагы турында сорады. Мондый сорауны көтмәгән Гөлкәй

аптырап китте, җавап сүзләре эзләп торганда, Мансур Ибраһимович, кызның гаҗәпсенүле карашын күреп, аңлатуны кирәк санады:

– Гөлкәй, аптырамагыз, зинһар. Гадәттә беренче курс студентлары Яңа елны тулай торакта каршыламыйлар, өйләренә таралышалар. Берүзегез калгансыздыр дип уйлыйм. Якташым буларак, сезне үзебезгә чакырасым килә. Гаиләм белән танышырсыз.

Мансур Ибраһимович уңайсызланып тамак кырып алды, кулындагы портфелен әйләндерде. Бу сүзләрне ул да үз-үзеннән көтмәгән иде бугай. Кара инде син аны, якташым дип, беренче курс студенткасын өеңә чакырып утыр инде! Дөрес, Казанда аның якташлары күп түгел, һәрхәлдә, ул белгәннәре бармак белән санарлык. Булганнары Мансур Ибраһимович өчен, чыннан да, бик кадерле. Икенчедән, ул күргәннән бирле бу кызның язмышы белән кызыксынасы итте – укуын тикшерде, хәтта бүлмәсендә кемнәр белән торганын ачыклады. Моны үзенең беренче укытучысы Гарифҗан хәлфә өчен эшлим дип уйлады. Әгәр инде үзләренең яртылаш ятимә унҗиде яшьлек кыз туганнарын Казанга тикле ялгызын чыгарып җибәргәннәр икән, димәк, алар ниндидер могҗизага йә булмаса Гөлкәйнең үз-үзен яклый алырына ышанганнар. Ә үз-үзеңне яклавы, яшь кызга түгел, типсә тимер өзәрдәй ир-атка да кыен. Мансур Ибраһимович, үзенең башыннан кичкәнгә күрә, моны бик яхшы белә... Шуңа күрә менә, хатыны белән киңәшләшмәгән дә килеш, яшь кызны өенә Яңа ел каршыларга чакырып утыра...

Гөлкәй дә каушады. Мансур Ибраһимович өенә барыргамы?! Хатыны белән танышыргамы?! Аларның бәхетенә карап елмаерга-шатланыргамы?! Йа Ходаем, моннан да зур газап булуы мөмкинме соң?! Юк, беркайчан да... Аннан соң, Укытучыны кыен хәлгә куя ич ул. Мансур Ибраһимович үзенең хатынына ничек дип аңлатыр?! «Кадерлем, мин Яңа елга беренче курс студенткасын чакырам, син аны яхшы кабул ит инде, яме?!» – Шулай дисенме?! Юк, юк...

– Рәхмәт, Мансур Ибраһимович. Мин Яңа елны ялгызым гына каршыламыйм. Күрше бүлмәдә яшәүче икенче курс кызлары өйләренә кайтмыйлар, мин шулар янына керәм.

Мансур Ибраһимович җиңел сулап куйгандай тоелды Гөлкәйгә. Әлбәттә, этисе яисә туган абыйсы хөрмәтеннән чакыра инде аны Мансур Ибраһимович. Җүләргә дә аңлашыла...

– Ярар алайса. Тәртипле генә уткәрегез бәйрәмне. Яңа ел яңа уңышлар алып килсен үзеңә... Сау бул.

Күрше бүлмә кызлары белән дисә дә, чынлыкта Гөлкәй нишләргә дә белми иде. Беркем белән дә килешмәгән әле. Утызынчы декабрь көнне иртән эштән кайтканда коридорда күрше кызлар күренмәде. Димәк, кайтып киткәннәр. Гомумән, алар этажында беренче курс кызлары яши, югары курслар түбәнрәк бүлмәләрдә торалар иде. Кем уйлап тапкандыр кызларны бүлмәгә курслап урнаштырырга... Ичмаса, өлкәнрәкләр белән яшәсә, ялгызы гына калмас иде.

– Исәнмесез! – Гөлкәй кулындагы чәйнегенә су тутырып, плитәгә утыртып маташа иде, үзенә төбәп әйтелгән сүзләрне берара ишетми торды. Бары янындагы кызның сораулы карашын тоеп кына борылды.

– Исәнмесез!

Кыз елмайды.

– Гафу итегез, сез беренче курс студенткасы, шулай бит?

– Әйе, шулай.

– Сезне бүлмәдә ялгызыгыз калган диделәр.

Гөлкәй кызга бераз шикләнеп карады.

– Кем әйтте?

– Э-э... Ринат әйтте. Ул безнең бүлмәгә кереп йөри.

Гөлкәйнең күңелендә ниндидер ятсыну хисе барлыкка килде.

– Ә сез нигә сорыйсыз?!

Кыз да, бераз читенсенеп, Гөлкәйгә үтенечле карашын төбәде:

– Сез дә берүзегез... Мин дә берүзем. Дөресрәге, мин югары курслар белән торам, ләкин Яңа елны алар белән каршылыйсым килми. Әгәр сез каршы булмасагыз, сезнең бүлмәдә икәү бергә каршылар идек.

Кем икән соң бу кыз?! Нигә үзенең бүлмәдәшләре белән каршыламый?! Риза булганчы сорашырга кирәк. Гөлкәй, куелган сорауга җавап бирми генә, кызга эндәште:

– Әйдәгез, бүлмәгә керик. Озакламый чәй кайный, чәй янында сөйләшербез.

Кыз, Гөлкәйгә ияреп, бүлмәгә керде, як-ягына каранды.

– О-о! Сездә шундый матур, чиста!

– Рәхмәт. Сездә дә шулайдыр – кызлар яшәгән җирдә чиста була инде.

Кыз, көрсенеп, башын чайкады:

– Бездә икенче төрлерәк шул. Шуңа күрә сезнең янга кердем дә инде.

Гөлкәй өстәл әзерләгән арада кыз белән танышты, кайдан икәнен сорашты. Исеме – Чулпан, үзе Әстерханнан икән. Ерактан булгач, ул да өйләренә кайта алмаган.

Бераздан чәй кайнап чыкты, Гөлкәй Чулпанга да, үзенә дә җимешләр салып чәй ясады.

– Беләсеңме, ни өчен Яңа елны үзебезнекеләр белән каршылыйсым килми? – Чулпанның йөзенә, шакшы нәрсә күргән кебек, җирәнү төсе чыкты. – Безнең бүлмә кызлары тарталар, сыра эчәләр, җитмәсә, берсе бүлмәдә егете белән куна. Ирле-хатынлы булып яшиләр. Күз алдыңа китерәсеңме?! Мин шулар белән торырга тиеш!

Бу юлы Гөлкәй аптырады.

– Ничек инде «егете белән куна»?! Сезнең алдамы?!

– Минем үземнең дә күзләр маңгайга менде. Миннән көләләр генә, «артта калган», «авыл ябагасы» дип үртиләр... Коточкыч инде.

– Ә нигә комендантка әйтмисең?!

– Әйтмәгән кая! Әллә ничә тапкыр зарландым. Файдасы гына юк. Комендант чакырган саен, үзләре миннән зарланалар, янәсе, мин кеше белән яши алмыйм, кыргый, мин фәлән, мин төгән... Комендант бернәрсә эшли алмый. Хәзер яный ук башладылар. Бигрәк тә икесе узына – Рая белән Лена исемлесе. Катя, Гуля алай ук түгел, ләкин алар дәшмәгәч, берүзем бернишли алмыйм. Алар белән җүнле кеше тора алмый икән. Шуңа ел саен бүлмәгә яңа студентка кертәләр.

– Ничәнче курста укыйлар соң?!

– Рая белән Катя – дүртенчедә, Лена, Гуля – өчтә. Гаҗәп, шулаймы?! Үзләре тарталар, эчәләр, егетләр белән аралашалар – үзләре рәхәтләнеп укыйлар! Гуля гел бишлегә генә, Рая да шулай диярлек, берничә дүртлесе генә бар, Лена белән Катя да бөтенләй ук төшеп калганнардан түгел.

– Алай була алмый, алдыйлардыр.

– Мин дә шулай дип уйлаган идем. Юк! Үзләре юкта зачеткаларын алып карадым. Беләсеңме, иң гаҗәбе дә шунда: алар чынлап та акыллы, сөйләшүләрен тыңлавы кызык. Мин ишетмәгән әллә нәрсәләр турында беләләр, бәхәсләшәләр. Аларга егетләр дә тартыла. Тик тәмәке тартулары белән эчүләрен һич кабул итә алмыйм инде!

– Синең алда, бүлмәдә тарталармыни?

– Мин югында бүлмәдә дә тарткалыйлар. Кайчакта коридорга чыгалар да, ишек төбенә чүгәләп, тартып утыралар. Бәдрәф янына барып тарталар. Барыбер тәмәке төтене исе киемнәренә сеңә, бүлмәгә керә, мин дә шул ук һаваны сулыйм лабаса! Миңа да сеңә ич ул ис!

– Әйе, яхшы түгел инде. Нишләп сине беренче курслар белән урнаштырмадылар икән соң?

– Соңлабрак килдем шул мин. Мин урнашып йөргәндә, сез барыгыз да яши идегез инде.

Гөлкәй сүзсез калды. Менә шулай да була икән... Югарырак курслар белән яшәве дә җиңел түгел икән... Әгәр Чулпан урынына ул эләккән булса?! Яши алыр иде микән? Яшәмичә кая китәсең инде. Аның үзенең дә коридорда чүгәләп яисә бәдрәфтә тәмәке тартып торган кызларны күргәне бар. Ә Чулпан молодец... Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, диләр бит. Каршы торырлык көче бар икән бу кызның...

– Чулпан, алайса, иртәгә Яңа елны бергә каршылыйбыз. Безнең бераз тарттырган ит бар, ике кешелек кенә пилмән әвәләрбез, салат ясарбыз.

– Ә миңа Яңа ел күчтәнәче итеп дустым шампан шәрабы биреп җибәргән. Кичә генә иптәше кертеп чыккан иде.

Гөлкәй көлеп куйды.

– Дөресен генә әйткәндә, гомердә дә шампан шәрабы эчкәнем юк. Мин аны ничек ачарга икәнен дә белмим.

– Әй, җаен табарбыз әле! Көндез паркта йөреп керсәк тә була.

– Алай булгач, әйдә, безгә йокларга мен! Барыбер кызлар кайтып киттеләр, берүзем кунарга читен. Иртәгә эшкә чыгасым да юк.

– Син эшлисеңмени?!

– Эшләмичә, стипендиягә генә яшәве кыен бит. Ә син ничек җиткерәсең?

– Миңа ай саен әниләр җибәреп тора. Күп булмаса да, җитә шунда.

Гөлкәй көрсенеп куйды. Аның әнисе дә ике тапкыр утыз сум акча җибәрде инде, ләкин Гөлкәйнең ул акчаларны тотарга кулы бармый. Кайтканда берәр зуррак бүләк алып кайтыр әле энисенә...

Гөлкәй кызның чәй эчеп бетергәнен көтте дә савыт-сабаларны җыя башлады, үзе Чулпаннан сорап куйды:

– Син хәзер нишлисең?!

Чулпан җилкәләрен җыерды:

– Әллә тагын... Зачетлар тапшырылган, имтиханнарга иртәрәк әле. Нишләргә дә белгән юк.

– Мин хәзер кер юам, бүлмәне җыештырам. Аннан имтиханнарга әзерләнергә утырырмын дип торам. Төштән соң сәгать өчләрдә, бәлки, урамнан әйләнеп керербез?!

Чулпан ризалашып баш какты. Кухняга чыгып, Гөлкәйгә чынаякларны юарга булышканнан соң, үзләренә төшеп китте. «Болай сөйкемле күренә, – дип уйлады Гөлкәй. – Хәер, кешене бер күрүдән генә белеп бетереп бул-

мый инде. Әнә Фаягөл дә башта нинди сөйкемле иде, ә хәзер...» Нишләптер Фаягөл белән дуслашып китә алмадылар алар. Кызның төртмәләнүенә Гөлкәйнең баштарак ачуы кабарса да, соңрак (Рәмилә киңәше белән!) игътибар итми башлады, «эт күңеле – бер сөяк» дигәндәй, дәшми кала иде. Нәрсә дисәң дә, комендант әйтмешли, биш ел бергә яшисе бар ич әле аларның...

...Яңа ел киче туды. Гөлкәй белән Чулпан көндез паркка бардылар, кайтканда базарга кереп, ике әфлисун, бер лимон сатып алдылар. Шәһәр халкының лимон белән әфлисунны күргәннәре дә юк иде, ә быел Яңа ел алдыннан ниндидер могҗиза булып алды. Базар сатучыларына оҗмах җимешләрен сатарга рөхсәт иттеләр. Гөлкәй үзе генә булса, беркайчан да мондый җимешләрне алырга кыюлыгы җитмәс иде. Чулпан көлде генә. Көньякта үскәнгәдер инде, сату-алу хәйләсен яхшы белә иде кыз. Рәт-рәт матур итеп тезеп куелган сары кояшларны күреп, Гөлкәйнең исе китте. Лимонны күргәне дә, ашаганы да бар иде, әлбәттә, ләкин әфлисун... чыннан да җәннәт җимеше булып тоелды. Әлеге рәтләрнең арткы ягында торган кап-кара мыеклы җимеш сатучы көньяк егете кызларны тәмле теле белән әсир итәргә теләп чакыра башлады, нинди матур кызлар икәнен сөйләп күрсәтте. Гөлкәй оялуыннан Чулпанның җиңеннән тартып, китәргә чамалый башлаган иде дә, кыз чәтердәп чыкты.

– Абый, сез үзегез дә шундый матур егет! Иң тәмле, иң матур әфлисуннар сездә, ахры. Тагы әнә тегендә бер абыйда бар.

– Юк, юк, минекеләр иң баллысы! Менә карагыз әле, сап-сары, теләсәгез, кызгылт-сарысы бар!

– Ә ничә сумга сатасыз?

– Бушлай диярлек, матурым! Ике сум!

– Ә-ә, сезнеке кыйбатрак икән шул. Теге абый бер сум илле тиен диде...

– Кем? Теге кара чутырмы?! Аның җимешләре дә шуның кебек кенә бит!

– Ю-ук, аның да җимешләре шундый матур, түмтүгәрәк! Әйдә, Гөлкәй, аңардан гына алырбыз инде, монда кыйбатрак икән...

– Туктагыз, тукта! Ярар, әйдә, бер сум илле тиен булсын. Алыгыз, матурым.

– Абый, безгә ике әфлисун кирәк шул. Күпләп алабыз без.

– Күпләп?! Ай-яй, матурым, ике әфлисун – күпләп аласызмы?!

– Безнең өчен күпләп инде. Без студентлар бит, авылдан килдек, беркайчан да әфлисун ашаганыбыз юк.

– Кит аннан! Әфлисун ашаганыгыз юкмы? Ай-яй-яй! – Сатучы, ышанган кыяфәт чыгарып, тел шартлаткан булды, көлемсерәде. – Мәгез алайса, молодец кызлар булганга күрә, сезгә генә ике әфлисун – ике сум!

– Ай, абый, рәхмәт! Җимешләрне гел сездән генә алырбыз, Алла теләсә!

– Тагын килегез, матурларым! – Сатучы, көньяк кояшы кебек елмаеп, кызларга ике әфлисун сузды.

Чулпан тиз генә ике сум акчаны бирде дә әфлисуннарны сумкага салып куйды. Сатучы кире уйлаганчы дип, кызлар тизрәк китеп бару ягын карадылар. Икенче урында Чулпан, лимон сатучы белән сатулашып, азрак бәягә лимон алды.

– Әйбер алырга гел синең белән чыгасы икән, – диде Гөлкәй, көлеп. Ул Чулпанның мондый сәләтенә шакката иде. Үзеннән бу якка ни он суы, ни тоз суы юк...

– Ә нәрсә, без бит кибеттән алмыйбыз, базардан алабыз. – Чулпан әфлисуннарны, яңадан сумкадан чыгарып, көн яктысында әйләндерә башлады. – Базар сатулашыр өчен инде ул. Менә бер дә алдатмаган әле абзыкай – әфлисунның берсен кайтышракны биргән.

– Бер сумга яртыны бирсә дә, бер сүз дә әйтмәссең.

Кызлар тагы бер кат базарны әйләнделәр дә кайтыр якка борылдылар.

– Беләсеңме, Казан матур шәһәр, ләкин безнең Әстерханга җитми инде, – диде Чулпан, шак-шок килгән трамвайда кайтканда. – Бездә мондый салкыннар юк. Бу вакытта җиңелчә курткадан йә калын свитердан йөрергә була. Ә монда... туңып бетәсең. О-ох, аякларым ничек өшеде!

– Ә миңа, киресенчә. Бездәге салкыннар янында мондый салкыннар бөтенләй пүчтәк!

– Гаҗәп бит, ә? Икебез дөньяның ике читеннән, ә Казанда очраштык! Ә син нигә укырга Казанга килергә булдың? Үзегезнең тирәдә дә уку йортлары булгандыр инде.

Гөлкәй берара уйланып торды. Үзе турында кешегә сөйләргә бик яратмый иде ул. Шуңа хәзер дә дөресен әйтергә теләмәде.

– Үзем дә белмим... Казанда татарлар яши, шуңадыр. Мин үзем татар булгангадыр.

– Кара, мин дә нәкъ шуның өчен ләбаса! Әти белән әни колак итемне ашап бетерделәр – Казан, Казан, янәсе! Монда урамда хөрмәләр үсмәгәнен беләләрмени алар!

– Кайдагы урамда үсә икән соң ул?

– Нишләп үсмәсен? Бездә үсә. Хөрмә дә, груша да, әстерхан чикләвеге дә. Алма да, чия дә, тагы әллә нәрсәләр үсә бездә.

– Урамда үсәме?!

– Әлбәттә, урамда! Капка төбендә.

– Ә аны кешеләрдән ничек саклыйсыз?!

Чулпан Гөлкәйгә гаҗәпсенеп карады.

– Ә нигә аны кешеләрдән сакларга?! Һәркемнең капка төбендә үскәч, кем тисен?! Шул килгән-киткән килмешәкләр генә кайчакта ботакларын сындырып китәләр! Ә бездәге балык! Уылдык! Руслар әйтмешли, «ешь – не хочу» бездә!

– Бездә дә балык тоталар.

– Сездә икенче төрле ул, мин беләм. Сездә – кызыл уылдык, ә бездә карасы да бар.

Әйе, Гөлкәй бик яхшы хәтерли: уылдык тозлаган, балык киптергән җилсез көннәрдә ихата өстенә коточкыч әшәке ис эленә. Борыныңны кысып, тайгага чыгып качасылар килә... Балыкны агач кайрылары, әллә нинди үләннәр белән төтәтсәң дә, тиз генә бетми бу ис... Әтиседннән дә шундый ис килә иде мондый көннәрдә, ләкин әнисе балык тотып кайткан әтисен сагынып, елмаеп кочып алыр иде... Гөлкәй, трамвайның бозланып каткан тәрәзәсенә карап, шуларны уйланып кайтты. Чыннан да, нәрсә калган аңа монда, бу шау-гөр килеп торган Казанда?! Гаскәриләр кебек төз, таза нарат, чыршы, кедр агачларын калдырып, нишләп йөри ул бу тынчу урамнарда?! Әти-әнисе, бабасына колач җитмәслек Себер ят булган кебек, Гөлкәйгә дә Казан шулай мәңге ят булырмы икән?! Себердә туган, чыршы урманнарының саф һавасын сулап үскән җан беркайчан да бу туфракка ияләшә алмаса нишләр?! Үләр алдыннан балаларына «Себергә, туган туфрагыгызга кайтыгыз» дип әманәт әйтерме?! Ах, язмыш, язмыш, нишләп шаярасың син болай кеше гомере белән?! Мансур Ибраһимович... Ул да сагына микән туган якларын?.. Мөгаен, сагынадыр. Сагынмаса, беренче курс студенткасы белән якташлыгына басым ясап тормас иде. Әйе, Мансур Ибраһимович Казанда булганда, ул ялгыз түгел. Тик ул гына янәшәдә булсын...

...Кичке якта салатларны әзерләп кенә бетергәннәр иде, кинәт кухняда су бетте. Краннан җеп калынлыгында гына ага иде су, анысы да, тып-тып тамып, бераздан юкка чыкты. Савыт-саба юылмыйча калу, димәк, чиста савыт-сабасыз калу куркынычы туды. Ярый әле Чулпан югалып калмады, бүлмәгә кереп, тиз генә кер кайната торган чиләк белән идән чиләген тотты да чыгып барган-

да ук «Гөлкәй, әйдә беренче этажга, сушилкага!» дип кычкырды, үзе, чаптырып, баскычтан төшеп тә китте. «Сушилка» дигәннәре кер юу һәм киптерү өчен махсус җайланган аерым бүлмә иде. Гөлкәй ачкычларын шалтыратып төшеп җиткәндә, чәнти бармак калынлыгында аккан суга, унлап кран булуга карамастан, чират җыелган. Чулпан өченче булып баскан. Гөлкәй кызның җитезлегенә хәйран калды.

– Без бер бүлмәгә түгел, аерым бүлмәләргә, – дип кычкырды Чулпан, Гөлкәйнең керүен күреп шаулаша башлаган чиратка. – Мин өченче этажда яшим, ул – бишенчедә.

Чират бераз чәпчеде дә тынды. Ул арада кызлар чиләкләрен тутырып менеп тә киттеләр.

– Берәр чиләк кенә бирәләр, су бөтенләй бетәргә чамалый икән. Әйтерсең бүлмәдә бишәр чиләк бар! Күп дигәндә ике чиләк инде, аны да кызганалар. Болай буласын белсәмме?..

Чулпан нәрсә эшлисен әйтеп өлгермәде, кинәт баскычка абынып, исеректәй чайкалып торганнан соң, кулыннан сулы чиләген селтәп төшереп җибәрде. Чиләк, арттан менгән Гөлкәйне баштанаяк суга коендырып, шалтыр-шолтыр баскыч буенча аска тәгәрде.

– О-ох, Гөлкәй, гафу ит, зинһар?! – Чулпан, Гөлкәйгә караган да эчтән ургылып менгән көлүен чак тыеп тора. – Гафу ит...

Гөлкәй түзмәде, лычма булган күлмәген сыпыра-сыпыра, үзе беренче булып көлеп җибәрде. Чулпанга шул гына кирәк иде, иелә-бөгелә:

– Яңа елда су коену бәхеткә ул, дустым... Һи-һи-һи... теләк телә, тизрәк... Һи-һи-һи... – дип кеткелди башлады, үзе шунда ук чиләк артыннан аска омтылды. – Мин хәзер менеп җитәм, бер дә аптырама!

Чулпан, чыннан да, чиләген яңадан тутырып, тиз менде. Гөлкәй өс-башын алыштырган гына иде.

– Йә, теләк теләдеңме?!

Гөлкәй елмаеп кулын селтәде:

– Теләдем – киләсе Яңа елда башка су коендырмасыннар, дидем.

– Юкка көләсең. Безнең якта шундый гадәт бар – Яңа ел кичендә якын кешеләреңә су сибәсең, алар эчтән генә теләк телиләр. Теләкләре кабул була.

– Әйдә, алайса, мин дә сине коендырам, тизрәк теләк телә! – Гөлкәй, шаяртып, тулы чиләкне кулына алды, кизәнгәндәй итте.

– Ай-яй-яй! – Чулпан, пырхылдап, шул минутта ук бүлмәдән чыгып качты.

Күңелле иде Чулпан белән. Ничектер җиңел, бернинди борчу-кайгы күңелгә кереп тә карамый. Була бит шундый шат холыклы кешеләр. Рәмилә белән дә күңелле, тик Рәмилә һәр эшне, һәр адымын уйлап эшли... Аңарда Чулпанга хас ваемсызлык юк. Аның каравы Рәмилә ышанычлы, нык, Рәмилә янында үзеңне җитди, аек акыллы шәхестәй хис итәсең. Гөлүсә кайсы ягы беләндер Чулпанга охшаган, тик ул... башка төрлерәк. Эчкерлерәк микән?!

...Кичке алтыда кызыл почмакка телевизор карарга төштеләр. Монда да халык шактый җыелган иде инде, күбесе – егетләр, яңа кызларны кызыксынып күздән кичерделәр. Гөлкәй бу карашлар астында бөрешеп килде, Чулпан исә кайберләре белән күңелле генә күрешеп чыкты,ерактарак утырганнарына кул селтәде.

– Безнең бүлмәгә кереп йөриләр алар, – диде ул аптырап караган Гөлкәйгә. – Күрәсеңме, чыршы төбендә үк утырган кара свитер кигәнен? Ул – безнең тулай торакның студентлар советы председателе. Исеме – Василий. Васька. Аның уң ягында утырганы – беренче курсларның кураторы. Исеме – Сергей. Сережа.

Бусын Гөлкәй дә таныды. Теге вакытта алар бүлмәсенә кергән озын буйлы егет иде бу. Димәк, куратор булуы чын икән. Гөлкәй ансын да ялган дип уйлаган иде. Чулпан тагы әллә кемнәрне атады – Гөлкәй барысын да исендә калдыра алмады. Телевизор экранына текәлгәннәр генә иде, кызыл почмакка Ринат белән Артур килеп керделәр. Чулпан аларга да кул селтәде. Василий белән нәрсәдер пышылдашканнан соң, Ринат кызлар янына килде.

– Сәгать уникедән соң уку залында дискотека була, – диде ул, яртылаш иелеп. – Төшәрсезме?!

– Төшәбез, әлбәттә! – Чулпан икесе өчен дә җавап бирде. – Яңа ел төнендә бүлмәдә бикләнеп яту планда каралмаган.

– Молодцы! – Ринат яңадан үз эшләре белән чыгып китте. Артур әле Васька белән, әле Сережа янына барып нәрсә турындадыр кызып-кызып бәхәсләшә иде. Бераздан егетләр өчесе дә кызыл почмактан чыктылар.

Телевизордан «Җиңел пар белән!», «Шурикның Яңа ел маҗаралары» картиналарын караганнан соң, кызлар күтәренке күңел белән бүлмәләренә менеп киттеләр. Пилмән пешереп, өстәлне матурлап бизәп куйгалаганчы, сәгать унбер тулды. Иске елның соңгы сәгате туды. Фаягөлнең әниләре калдырган кечкенә генә искерәк магнитоласы бар иде, аны радиодулкынга көйләп куйгач, бүлмә җанланып китте.

– Әйдә, шампанны ача торабыз, – диде Чулпан. – Без ачканчы, кимендә ярты сәгать үтәчәк.

Алай ук озак вакыт кирәк булмады. Чулпан үзенең бүлмәдәшләреннән шешәне ничек ачарга кирәклеген сорашып менгән иде, шуңа аларның инструкциясе нигезендә, көлешә-көлешә, башта ялтыравыклы кәгазьне сүттеләр, аннан тимерчыбыкны борырга керештеләр. Гөлкәй шешәне егылмасын дип тотып тора, ә Чулпан бик тырышып чыбыкны бора. Бер-ике минуттан соң шешә чайкалып китте, кызларның котын алып, мылтыктан аткан тавыш, Чулпанның «ай!» дип кычкырганы ишетелде, шул ук мизгелдә бүлмә караңгылыкка чумды. Гөлкәй нәрсә булганын аңларга да өлгермәде. Каяндыр өстән, тып-тып итеп, яңгыр тама башлады.

– Чулпан?! – Гөлкәй тизрәк ишекне барып ачты. Коридордан кергән яктылыкта Чулпанның чиксез аптырап түшәмгә карап торуы күзгә чалынды.

– Болай ук шартларга тиеш түгел иде ул. – Чулпан яктырак урынга чыкты. Кызның күзләрендә беркадәр шүрләү чагыла иде. – Синең шампан шешәсен ачканнарын күргәнең бармы?!

– Бар. Телевизорда.

– Минем дә телевизорда күргәнем бар. Болай ук шартламый. Әллә ачыган микән?! Юлда килә-килә, бәлки, ачыгандыр.

– Шәраб ачый дип уйлыйсыңмы?!

– Кем белә. Безнең якта йөзем шәрабы ясыйлар да, ачыса, капкачын ыргыта, әлбәттә, ләкин болай шартламый бит.

– Алайса, аны эчәргә ярамый инде. – Гөлкәй шәраб түгелгән кулларын сөлгегә сөртте. – Җитмәсә, лампочкасыз да калдык бугай. Син әллә шешәне лампочкага төзәгән идеңме?!

– Син нәрсә инде. Мин гомумән беркая да төзәмәдем, шешәне син тотып тордың ич. Кызлар «бөкесе шуышып чыга» диделәр. Ул башта шуышты да аннан шартлады.

– Утсыз нишлибез инде?!

– Тукта, бездә шәм бар бугай. Хәзер алып менәм.

Чулпан йөгереп кенә үзләренә төшеп китте, Гөлкәй, өстәлгә якынрак килеп, шампан шешәсен кулына алды. Шәраб шешәнең төбендә генә калган иде. Калганы – өстәлдә, түшәмнән тып-тып тамып утыра... Әй-йе, менә сиңа Яңа ел диген...

Бераздан Чулпан үзе белән лампочка тоткан ниндидер егетне ияртеп менде.

– Йә, нәрсә булды монда?! – Егет, көр тавыш белән

эндәшеп, бүлмәне күздән кичерде, тып-тып шампан шәрабы тамып утырган түшәмне күргәч, шаркылдап көлеп җибәрде. – Ну, кызлар, молодцы! Шәп каршылыйсыз Яңа елны!

– Дамир, ә ул бик нык шартлады. Ачыган булганга шулаймы?!

Дамир тагы да ныграк көләргә тотынды, урындык куеп, лампочканы алыштыра башлады.

– Ачыган булса да, ачымаса да, шешә төбендә сезгә авыз итәрлек кенә калгандыр әле. Менә лампочкагызның шартламавы бәхет инде, юкса пыяла кисәкләре бөтен бүлмәгезне тутырган булыр иде.

Егет кулындагы үзе белән алып менгән лампочканы борып куйгач, бүлмәдә гөлт итеп ут кабынды. Өстәл турында гына булган икән шул лампочкалары. Җитмәсә, түшәмдә зур гына юеш түгәрәк урыннан һаман да шампан саркый...

– Ну, булды. – Егет Гөлкәйгә төбәлеп әйтеп куйды. – Яңа лампочкага алыштырырга онытмагыз. Бусын коридордан гына борып алып кердем. Бүгенгә бара, ләкин озакка чыдамас, иске.

– Ә бу шәрабны эчәргә ярый алайса?! – Чулпан шешәне чайкап күрсәтте.

– Әлбәттә, ярый! Электрикка салып бирсәгез дә зыян итмәс иде, ләкин, күрәм, үзегезгә дә әз калган. Икенче юлы егетләрдән ачтырырсыз шампанны!

– Ә нәрсә, без үзебез дә начар ачмадык. – Чулпан инде көлүен чак тыеп тора иде. – Рәхмәт, Дамир. Яңа ел белән сине.

– Сезне дә шулай ук. Дискотекага төшәсездер бит? Ярар, әлегә пока!

Дамир чыгып киткәч, кызлар бер-берсенә карап тордылар да, шаркылдашып, көлеп җибәрделәр. Күзләреннән яшьләр атылып чыкканчы көлештеләр. Бераздан Гөлкәй, исенә килеп:

– Чулпан, Яңа ел җитә ләбаса, соңга калабыз! – дип, өстәлгә түгелгән шампанны сөртә башлады. Ниһаять, тәлинкәләргә кайнар пилмәнне бүлеп, өстәл артына утырышканда, сәгать унике тула язган иде инде. Калган шампанны чәй чынаякларына бүлгәч (бокаллары, кызганычка каршы, юк иде), икесенә дә яртышар чынаяк шампан шәрабы туры килде. Радиодан КПСС Генераль секретареның чыгышын тапшыра башладылар.

– Йә, Гөлкәй, күзеңне йом да иң-иң зур теләгеңне телә! – Чулпан үзе дә нәкъ шулай итәргә җыена иде. – Әйдә, бер, ике, өч!

Кремль курантлары төнге уникене сукты. «Йа Ходаем, – күзләрен йомган килеш Гөлкәй теләк теләде. – Минем синнән беркайчан да бернәрсә дә сораганым юк. Шушы бердәнбер теләгемне кабул итсәнә! Йа Рабби, Раббым!»

Соңгы курантлар тынды, Советлар Союзы Гимны яңгырый башлады. Гөлкәй белән Чулпан баскан килеш чынаякларын чәкештерделәр. Гөлкәйнең үз гомерендә беренче мәртәбә Яңа елны каршылавы иде.

– Яңа ел белән, Гөлкәй! – Чулпанның күзләре җемелдәп яна, йөзе бәхеттән балкый. – Яңа уңышлар, яңа бәхетләр алып килсен Яңа ел!

– Яңа ел белән, Чулпан. – Гөлкәйнең дә дулкынлануы тавышына чыкты. – Сиңа да бары яхшылык кына китерсен Яңа ел! Исәнлек-саулык, уңышлар насыйп булсын!

Бераз әчкелтем, әмма тәмле икән шампан шәрабы. Гөлкәй авыз итте дә чынаягын өстәлгә куйды. Ул арада коридорда шаулашкан, кычкырган тавышлар ишетелә башлады. Гөлкәй белән Чулпан ни булды икән дип йөгерешеп чыксалар, озын коридорның теге башыннан ук җепкә тагылгандай кулга-кул тотынышкан, «Яңа ел белән! Яңа ел белән!» дип кычкырып килгән студентлар төркеме күренде. Болар өлкәнрәк курслар иде булса кирәк. Атлаган уңайга тавышка йөгереп чыккан студентларны үзләре белән ияртәләр.

– Гөлкәй, бикләә ишекне, киттек әйлән-бәйләнгә!

Гөлкәй тизрәк ишекне бикләп чыкканда, әлеге әйләнбәйлән алар янына килеп җиткән генә иде. Кызларны да үзләре белән ияртеп, кулга-кул тотынышкан төркем коридорның бу як читенә килеп җитте дә кире борылды, баскычтан дүртенче катка юнәлде. Анда да шулай ук коридор буенча барып, студентларны, паровозга таккан шикелле, үзләре белән ияртеп, йөгереп диярлек өченче катка төшеп киттеләр. Монда инде кычкырудан туктап, җырлый башладылар: «В лесу родилась елочка, В лесу она росла...». Ниһаять, бөтен коридорларны да уратып чыгып, әйләнбәйләннең башы музыка уйнаган уку залына кереп барганда, койрыгы әле икенче катка гына якынлашып килә иде. Чулпан белән Гөлкәйнең көлә-көлә, җырлый-җырлый хәлләре бетте, йөгерә-йөгерә тыннары калмады.

– Вәт менә кайда ул күңеллелек! – Зал уртасына куелган чыршы тирәсендә берничә катлы әйлән-бәйләндә бөтерелгән Чулпаннан да бәхетлерәк кеше юк кебек иде. – Ә без «өйгә кайта алмыйбыз» дип кайгырабыз!

Гөлкәй дә үзен (мөгаен, үз гомерендә беренче тапкырдыр) чын студент итеп сизде. Дәресләр, семинарлар, за-

чет-имтиханнар – берсе дә студент тормышын тулысынча күрсәтә алмый икән. Студент тормышы менә шулай юктан бар ясаудан башлана икән... Юк ризыктан туй ясау. Юк шатлыктан бәйрәм ясау. Юк дуслардан компания булдыру! Гөлкәй чын күңелдән үзенең Казанга килүенә, студент булуына шатланды, куана-куана, көлә-көлә, түгәрәктә бөтерелде. Бераздан дәртле музыка куйдылар. Әле генә кулга-кул тотынышып, балалар бакчасындагы кебек әйлән-бәйлән ясаган студентлар басып калган урыннарында заманча бию көйләренә тирбәлә, сикерә башладылар. Гөлкәй мондый көйгә бии белми иде. Тик бу әһәмиятлемени! Беркем дә аның оялчан хәрәкәтләренә игътибар итми, беркем дә урынсыз авыз ермый. Бераз бер урында таптангач, Гөлкәй якын-тирәдәге шактый остарган биючеләрнең хәрәкәтләрен кабатлый башлады. Алай кыен түгел икән ләбаса! Гөлкәйнең көйне, ритмны сиземләве бик әйбәт, шуңа туры китереп, аяк-кулларны селкетүе дә ярыйсы гына килеп чыга башлады. Бераздан ул инде, гомерендә беренче мәртәбә дәртле бию биегәнен дә онытып, үзе кебек үк студентлар диңгезендә чайкала иде...

...Икенче көнне төш җиткәндә генә уяндылар. Уяндылар да, урыннан торырга теләмичә, шактый вакыт тәрәзәдән кергән кышкы кояш нурларында иркәләнеп яттылар.

– Беләсеңме, Гөлкәй? – Чулпан йөзтүбән яткан килеш куллары белән иягенә таянган да хәйләкәр генә елмая. – Бу – минем үз гомеремдә беренче мәртәбә каршы алган Яңа елым.

– Минем дә. Өйдә чакта без беркайчан да алай Яңа ел дип төнне йокысыз үткәрми идек.

– Студент тормышы кызык инде, әйеме?! Ничә тапкыр вальс биедек! Син әйт әле, бии белмәгән килеш, диген!

– Өйрәндек бит инде. Хәзер бездән дә оста биюче юктыр, мөгаен!

Кызлар бер-берсенә карап көлештеләр. Чулпан, тагы да хәйләкәрләнеп, Гөлкәйгә күз кысты:

– Ә сиңа кайсы егет белән биюең ошады?!

Гөлкәй дә бер дә аптырамады, сорауга сорау белән җавап кайтарды:

– Ә сиңа?!

– Ә миңа матрос киемендәгесе белән. Исеме генә ямьсез – Вил. – Чулпан яңгыратып көлеп алды. – Башта колагыма «фил» булып ишетелде. Әллә ничек әйтергә – Вильме, әллә Вилмы?!

– Ә-ә, безнең төркемнән ул. Әйбәт егеткә охшаган. Исеме белән бик горурлана: Вил – димәк, Владимир Ильич Ленин. Дөресен генә әйткәндә, кыскарткач, ямьсез инде ямьсезен дә, аның каравы фамилиясе матур – Абдуллин.

– Абдуллин Вил. Ярыйсы. Чыннан да әйбәт егетме?!

Гөлкәй көлеп куйды:

– Кем белгән аларны. Төркемдә әйбәт инде – кычкырмый, тавышланмый, һаваланмый, тик үзен бик җитди тота. Бездән зуррак ич ул – флотта хезмәт итеп кайткан. Диңгезче.

– Үлеп яратам диңгезчеләрне. Ә сиңа кем ошады?!

Гөлкәй кичә үзе белән вальс биегән егетләрне хәтереннән үткәрде. Их, шулар арасында берәү булса иде... Юк шул.

– Берсе дә ошамады. Барысы да сагыз кебек бәйләнергә генә торалар.

– Матур шул син, Гөлкәй. Күз явын алырлык. Синең белән урамнан үткәндә, егетләр муеннарын сындырырлык итеп борылып калалар. Мин дә шулай матур булсам иде!

Гөлкәй, уңайсызланып, караваттан торып утырды, төнлә тузып таралган толымын баш тирәли урап куйды.

– Әй, арттырма инде, Чулпан. Синең сөйкемлелегең, синең зәңгәр күзләрең миндә булсын иде әле!

– Матурлык белән дә түгел, бәхете булсын хатын-кызның. Әни гел шулай ди.

Кызлар җыенып, юынып, кичә ашалмый калган, тәрәзә төбендә төн үткәргән Яңа ел пилмәнен җылытып ашаганнан соң, урамда йөрергә чыгып киттеләр. Кич белән исә аларны дәртле дискотека тагы үзенә чакырды...

* * *

...Вакыт ничек үтәме?! Бармак араларыннан шуышкан ком шикелле. Иләккә агызган су кебек. Искән җил кебек, чылтырап аккан чишмә кебек... Вакыт, артына борылып карамый йөгергән шук малай кебек, алга чаба. Бары алга гына. Тик кеше хәйләкәр шул. Алга чапкан вакытны туктата алмавын аңлагач, кеше аны үз хәтерендә туктарга мәҗбүр итә, уйларын артка чигерә-чигерә, вакыт әфәндегә үткәннәрне яңадан күз алдында торгызырга куша. Таләп итә...

Студентларның көтелгән кышкы каникуллары килеп җитте. Гөлкәй – ни гаҗәп! – тагы ялгызы. Барлык имтиханнар бишкә бирелгән, куркулар, куанычлар, күз яшьләре, имтихан алдыннан йокысыз төннәр – барысы да артта калган. Тик Гөлкәй тагы ялгызы... Бу юлы

әнисен, туган ягын сагынуы шулкадәр көчле иде ки – Гөлкәй ике көнгә генә булса да кайтып килергә карар бирде. Булсын, каникулы юлда – поездда үтсен. Эшеннән дә китсен – башка эш табар. Ике көн, бары ике көн... Шундый уйлар белән хыялланып йөргәндә, Гөлкәйгә Төмәннән телеграмма килеп төште. Бертуган абыйсы каникул вакытында кунакка килергә җыена икән. Гөлкәй янына кунакка. Мөмкинме бу?! Абыйсы армиядән соң Төмәнгә барып эшкә урнашкан, шунда ук гаилә корып, үз тормышы белән яшәп ята иде. Гөлкәйнең түбәсе күккә тиде. Берүзе генә килә микән абыйсы, әллә хатынын да алып килә микән?! Җиңгәсе белән әле яхшылап дуслашырга да өлгермәделәр ич. Абыйсы былтыр өйләнде, быел җәй көне алар кунакка кайтканда, Гөлкәй Казанга китеп барды... Икесе бергә килсәләр, ничек әйбәт булыр иде... Казанны күрсәтер, кино-театрларга йөрерләр иде. Әйе, Гөлкәй әлегә ялгыз, ләкин Гөлкәй моңсу түгел!

– Якупова, сезне вахтага чакыралар.

Ишекне кемдер шакып тормый гына ачып, шул сүзләрне кычкырды да юкка чыкты. Гөлкәйнең күңелен шунда ук дулкынлану биләп алды, өстәл артыннан сикереп торганда, урындыгы артка авып китте. Гөлкәй моны сизмәде. Тиз генә бүлмәсен бикләп алды да, биш катның баскычларын өч сикерүдә очып, аска – вахтага төште. Чит-ят кешеләрне тулай торакка кертмәс өчен куелган әйләнмәнең теге ягында мәһабәт гәүдәле ир-егет басып тора иде.

– Абый! – Гөлкәйнең тавышы буш коридор буенча яңгырады, кайтаваз булып, салкын тәрәзәләргә килеп бәрелде. – Аб-бый!

Ир-егет муенына килеп сарылган кызны кечкенә баладай күтәреп алды, колач җитмәс кочагына кысып, зыр-зыр әйләндерде.

– Сеңлем! Гөлкәй!

Ниһаять, хисләренең ташкынына түзә алмый, сулкылдап елаган Гөлкәй йөзен абыйсына күтәрде.

– Абый... Шундый сагындым! Үлеп!

Абыйсының үзенең дә күзләре дымланып киткән иде, сеңлесен яңадан кочагына кысты.

– Без дә сагындык, Гөлкәй. Әни сиңа күп сәламнәр әйтеп калды. Йә, ничек яшисең?! Әллә ябыгып киткәнсең инде?

– Барысы да әйбәт, абый. Сагындыра гына. Җиңгәй килмәдеме?

– Юк, эшеннән китә алмады. Әйдә алайса, бүлмәңә

чакырасыңмы соң?! Мине синең янга кертергә ашыкмыйлар әле. Бик каты икән кагыйдәләрегез.

Ир-ат якында гына бу ике туганның очрашуын каш астыннан карап торган вахтер хатынга ымлады. Гөлкәй, күз яшьләрен сөртә-сөртә, вахтерга атлады.

– Тётя Поля, бу минем бертуган абыем. Себердән үк килгән. Зинһар өчен, кертегез инде.

Вахтер хатын усал, бик усал иде, ләкин бу юлы нишләптер, гадәттәгечә чәпчемәде.

– Ярар, паспортын калдырсын да, керер. Тик сәгать кичке сигезгә кадәр генә. Әгәр монда төн кунасы килә икән, комендантка гариза языгыз.

– Язабыз, тётя Поля, язабыз!

Абыйсының зур-зур сумкаларын күтәрмәкче булып тотынган иде дә, кая ул! Таш тутырганмыни, шулкадәр авыр иде алар.

– Әллә алтын тутырып килгәнсең инде, – диде Гөлкәй, көлеп.

– Әни тутырып җибәрде ул алтынны. Менә күрерсең әле.

Бүлмәгә кереп, сумкаларны куюга ук, Гөлкәй тизрәк комендант янына ашыкты.

– Һәрвакыт туры китереп булмый аны, – диде ул абыйсына. – Урынында булса, гаризага кул куйдыртып калырга кирәк. Югыйсә кайда кунарсың?!

– Кайгырма, Казанда кунакханә бетмәгәндер. – Абыйсының әллә ни исе китмәде. – Шулай да синең янда торсам, әйбәтрәк инде. Бар алайса, бар.

Бераздан Гөлкәйнең кәефе кырылып менде. Комендант гаризага кул куймаган иде. Янәсе, ир-ат кеше кызлар бүлмәсендә тора алмый. Гөлкәйнең исә күргән-белгән таныш егетләре барысы да каникулга кайтып киттеләр. Шулай булгач, абыйсына кунакханәдә кунарга кала.

– Кем соң сезнең комендант – ирме, хатын-кызмы?!

– Хатын-кыз. Алай ук усал түгел иде ул, нишләп киреләнәдер.

– Һм-м. Хатын-кыз булгач, сөйләшүе кыенрак инде. Әйдә, бергә төшеп карыйк әле.

Комендант бүлмәсенә кергәч, абыйсы елмаеп кына исәнләште, исемен-фамилиясен атады, Себердән килүен аңлатты. Куен кесәсеннән Әфган сугышында катнашканлыгын дәлилләүче кенәгәсен, алып, комендантка күрсәтте. Зинһарлап, үтенеп, сеңлесе янында калырга сорады. Тәртипсезләнмәскә, тавышланмаска сүз бирде. Аракыны бөтенләй эчмәвен әйтте.

– Сез барыгыз да шулай сайрыйсыз, – диде комендант төксе чырай белән. – Тавыш куптаргач соң була. Сезнең вәгъдәгез миңа нигә кирәк!

Шулай да комендант абыйсына кире какмады, гаризага кул куйды. «Егетләр янына дип язам, кайда кунасын үзегез карарсыз», – диде. Димәк, Гөлкәй Илһам абыйсы белән тагы биш көн буе күрешә-сөйләшә ала! Кызның шатлыгы эченә сыймады.

– ...Йә, Гөлкәй, ничек яшисең?! – Гөлкәй чәй әзерләгән арада, абыйсы тулай торакның коридорларыннан уратып, юынып керергә өлгергән иде. – Йортыгыз болай ярыйсы күренә, чиста. Студентлар каникулдадыр инде, очрамадылар.

– Каникулда. Әйбәт яшим, абый, Аллага шөкер. – Гөлкәй әбисенең сүзләрен искә төшереп, елмаеп куйды. – Торырга урын-җир бар, стипендия бирәләр, ашау әйбәт – студентка тагы нәрсә кирәк инде?

– Ул пенсия дигәнегез күпме соң?!

– Стипендия, абый, стипендия. Кырык сум. Җитеп тора. Иш янына куш булыр дип, мин эшлим дә бит әле.

– Ничек инде – эшлисең?! – Илһам, ялгыш ишеттемме әллә дигәндәй кашларын җыерып, Гөлкәйгә текәлде. – Ә укуың нишли?!

– Җиңел эш ул, абый, көнгә ике тапкыр идән юам. Укудан соң. Әнигә әйтмә тик, яме?

– Юк, тукта әле, эшләп укып булмый ул, Гөлкәй. Әгәр укуыңа зыян китерә икән, эшең турында онытырга туры килер. Нәрсә, акча җитмиме?

Гөлкәй, ник әйткәненә үкенеп, аңлатырга тотынды:

– Әйтәм ич инде, абый, укуга кадәр, укудан соң бер сәгать идән юып кайтам. Башка кызлар бу вакытта бүлмәгә кайтып йоклыйлар. Йоклап ятканчы, әзрәк үзеңә булыша алсаң, бер дә начар түгел, шулай бит? Әйдә, булганы белән капкалап, чәй эч әле, суынмасын.

Илһамның карашында шик куерды гына.

– Алайса, дөрес әйтәләр – сезнең ул стипендиягә генә яшәп булмый инде. Мин юлда килгәндә сорашкаладым – студентлар иkенче, өченче курстан коела башлыйлар, диләр. Кем эшләп укый алсын?!

– Абый! – Гөлкәй чын-чынлап пошына калды. – Абый. Мин бөтенләй чит-ят шәһәрдә, аңлыйсыңмы?! Монда безнең бернинди туганнарыбыз юк! Әгәр бер-бер хәл килеп чыкса – әйтик, итегемне генә урласалар да – мин гел ялангач калам дигән сүз. Шуңа күрә акчаны бераз саклап, кысыбрак тотарга, эшләргә туры килә, ләкин әлегә эш минем укуыма бернинди дә зыян китерми. Әгәр ко-

мачаулый башласа, мин эшне ташлаячакмын. Укуның никадәр кадерле икәнен мин аңлыйм.

Илһам шап итеп маңгаена сукты.

– Гөлкәй! Мин монда сүз куертып утырам, күчтәнәчләр турында гел онытканмын лабаса. Яле, биеп күрсәтә беләсеңме икән?!

Илһам, ишек төбендә калган зур сумкаларын ачып, берәм-берәм күчтәнәчләрен чыгара башлады.

– Менә сиңа кайнатмалар, тутырмалар, каклар, казылыклар, – тагы нәрсәләр бардыр, белмим, боларын әни тутырды. Менә болары күрше Әминәттәй күчтәнәчләре. Болары – Тәлгать белән Гайшә җиңгәйнекеләр. Болары...

Сумкаларны бушата торгач, бүлмә идәненең яртысы банкалар, төргәкләр, пакетлар белән тулды. Гөлкәй хәйран калды. Нишләтергә инде боларны?! Суыткычлары гына да юк бит ичмаса. Тәрәзә төбендә бозылырлар инде.

– Абый! – Гөлкәй, кулына нәрсә алырга белмәгәндәй, учларын җәеп, аптырап калды. – Абый! Боларны ничек күтәреп килдең? Поездда ук бозылгандыр инде болар?!

Илһам сумкадан башын күтәрми генә әйтә куйды:

– Болар кичә тутырган, барысы да. Мин самолетта очтым дип әйтмәдеммени?!

Гөлкәй шаккатты. Самолетка билет бәяләре күз алдына китермәслек кыйбат булып тоелган иде аңа. Илһам соңгы сумкасын бушатырга тотынды.

– Ә менә хәзер иң әһәмиятлесе – сиңа миннән һәм Энисә җиңгәңнән бүләк. Мәле, киеп карале!

Илһам сумкадан яхшылап ак бүз чүпрәккә төрелгән зур гына төргәк тартып чыгарды. Төргәк эченнән каеп теккән тун килеп чыкты.

– Абый! Бу миңамы?! – Гөлкәй, үз күзләренә ышанмыйча, тунны кулына алды, уң ягына әйләндерде. Якасы, җиңнәре, итәге, изүе ак төлке мехыннан каелган кара тун затлы, бик затлы иде. – Аһ! Абый!

– Киеп кара әле, өстеңә таман микән?! Энисә җиңгәң кодачаларыннан тектерде, үзеңне күрмәгәч, әллә таман, әллә юк?!

Гөлкәй яңа тире исе килеп торган җиңел тунны өстенә киде, икегә үргән озын толымнарын тун өстенә чыгарып, агачтан ясалган изү сәдәфләрен каптырды. Зифа тун кызның зифа буй-сынын кочып алгандай иркәләнеп кенә өстенә ятты. Озынлыгы да нәкъ Гөлкәй теләгәнчә – тезләренә кадәр иде.

– Абый! Чынлап та миңамы бу?! – Көзге алдында бөтерелгән Гөлкәйнең күзләренә яшь эленде. – Мең-мең рәхмәт, абый... Әминә апайга да мең рәхмәт...

– Сиңа булмый, монда кадәр күтәреп килгәч, кемгә булсын инде. Яле, бу якка борыл әле. – Илһам сеңлесен күздән кичерде. – Болай таман күренә.

– Таман булмыймы соң, абый! Минем мондый тунны төшемдә дә күргәнем юк! – Гөлкәй тунны, өстеннән салып, көн яктысына күтәреп карады. – Ай-яй! Коточкыч кыйбаттыр инде бу!

– Тукта, тукта, салмый тор. Тагы бер бүләк бар әле сиңа. – Илһам сумкасыннан кечерәк төргәк тартып чыгарды. – Монысы энидән. Туныңа пар итеп тектерде. Бияләйләрен үзе бәйләде.

Төргәктән шулай ук ак төлке тиресеннән тегелгән очлы түбәле, колакчынлы кызлар бүреге белән ак куян йоныннан бәйләнгән бияләйләр килеп чыкты. Озын колакчыннарга ак мехлы кечкенә шарлар тагылган иде.

– Әйе, минем сеңлемне матур диләр иде, дөрес икән. Кар кызы булдың, валлаһи. – Илһам алдында басып торган ак бүрекле, каю тунлы кызга сокланып карады. – Тфү-тфү, күз тимәсен үзеңә тагы! Җылы өстеңдә туздырырга язсын, Гөлкәй! Котлы булсын киемең!

– Рәхмәт, абый, зур рәхмәт сиңа, энигә, җиңгәйгә! Сез булмасагыз, нишләр идем!

– Ну, бүләкләрне өләшеп бетердем бугай. Әйдә, чәй эчик, булмаса.

Гөлкәй тунны кадерләп кенә караватына җәеп куйгач, табынга бер-ике кайнатманы ачты. Чәенә киптергән җимешләр салды. Аһ бу җиләк исе, туган як исе...

– Әнинең хәле ничек, абый?! Бик юксынамы мине?!

– Юксынса да, безгә сиздерми инде. Берүзе калды шул бигрәк. Үзебезгә чакырабыз да, йортны ташлап китәсем килми, хәлем җиткәнче йөрим әле, ди.

Гөлкәйнең йөрәге кысылып куйды. Картлык көнендә ялгыз калуы, ай-һай, читендер лә... Нигә, нигә Казанга озаттылар инде аны?! Энисе янында гына да яши ала иде бит ул. Авылда эше дә табылган булыр иде әле...

Илһам сеңлесенең моңсулануын сизеп алды.

– Син борчылма, Гөлкәй, без эни янына еш кайтып йөрибез хәзер. Атна саен ук булмаса да, айга бер кайтабыз. Мин хәзер башка эштә – «КРАЗ» машинасы йөртәм. Ерактагы буровойларга йөрибез, дөресрәге, вертолетта очабыз. Сменалы эштә мин. Акчасы да бик яхшы. Җиңгәң канәгать. Үзең ничек, сагынасыңмы?!

– Сагынмаган кая ул, абый! Үлеп сагынам.

– Түзәргә кирәк, Гөлкәй. Укуыңны ташларга ярамый. Әй! Биш ел ул беләсеңме ничек тиз үтеп китә? Сизми дә каласың! Казанга да ияләшерсең. Кияүгә чыгып, балалар

үстерерсең, Алла теләсә. Ничек соң, егетләр бик интектермиләрме үзеңне?!

Гөлкәйнең бит очларына алсулык йөгерде.

– Егетләр кайгысы юк әле, абый. Укулар ничек дип сора.

– Укулар ничек, алайса?

– Бишле! Барлык имтиханнардан да!

Илһам, елмаеп, көрәк кадәр учын Гөлкәйгә сузды:

– Ай, молодец! Котлыйм – бир бишне! Әйтәм бит, минем сеңлем маһы бирмәячәк дип! Ай, молодец! Укуы бик авыр түгелме соң?

– Кайсылары авыр инде, кайсылары – җиңел. Күбрәк математика укыйбыз әле. Аннан... фәлсәфә.

– Фәлсәфә? Әти, мәрхүм, ярата иде фәлсәфәне. Хәтерлисеңме, без фәлсәфә китабы битләреннән көймә ясап агызгач, ничек ачуланган иде?! – Илһам моңсу гына елмайды. – «Тарихны суга салып агыздыгыз сез» дигән иде. Һич онытмыйм шуны!

Әйе, әтисе ярата иде фәлсәфәне. Гөлкәй дә ярата... Фәлсәфәнеме, әллә...? Кызның күз алдында Мансур Ибраһимович гәүдәләнде. Гөлкәйнең яңа киемнәрен күрсә, гаҗәпләнер иде микән?! Әллә игътибар да итмәс идеме?! Их, күрсен иде...

– Ярар, сеңлем, тамак туйды, әйдә, күрсәт инде миңа шәһәрегезне. Аэропорттан килгәндә әллә ни күреп булмады. Нинди дә булса кызыклы урыннар бардыр бит Казанда?!

– Әлбәттә, абый! Мин сиңа лекция сөйли алам хәтта! Хәзер, табынны җыештырам да, шәһәргә чыгарбыз!..

Бүген Гөлкәйнең иң бәхетле көне булды. Яңа тунын киеп, абыйсы белән шәһәргә чыктылар, Кремль янында, Болак буйларында, Бауман урамында йөрделәр. Абыйсы Гөлкәйгә яңа итекләр, яңа күлмәк, кофта, туфлиләр сатып алды. Әйтерсең бөтен акчасын Гөлкәйгә генә тотарга дип сөйләшеп килгән иде. Гөлкәй кире кага башлагач, көлде генә.

– Бердәнбер студентка сеңеленә дә булыша алмагач, нинди абый булам инде мин, – диде. – Җитмәсә, Себердән килгән абый!

Кич белән театрга «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакленә бардылар. Күңелле үтте аларның көннәре. Алда әле шундый тагы дүрт көн көтә Гөлкәйне. Абыйсы яту белән ирләргә хас булганча җиңелчә генә гырлап йокыга китте. Гөлкәй исә, бу көннең бәхетле минутларын дәвам итәргә теләгәндәй, йокыга тиз генә бирешмәде. Ул бәхетле, бик бәхетле иде. Абыйсына рәхмәт хисе күңеленнән

ургылып, күз яшьләре булып, мендәренә коелдылар. Башыннан ук юрган белән капланып, тын гына үкседе кыз. Кайгы гына түгел, колач җитмәс шатлык та елата икән кешене. Абыйсы бернинди бүләксез, буш кул белән генә килсә дә, Гөлкәй барыбер шулай ук шатланыр иде. Казанда бернинди туганы, бернинди кайгыртучысы булмау шулкадәр авыр... Аңа бит әле унсигез дә тулмаган, күңеле белән бала гына бит әле ул... Аның әле әнисе кочагында назланасы, сөеләсе килә...

...Икенче көнне Илһам прокат бүлегеннән кечкенә генә суыткыч алып кайтты. Бәясен бер елга алдан үзе түләп куйды. Бүлмәдә урнаштырырга урын булмаганлыктан, суыткычны шактый киң тәрәзә төбенә куярга булды. Моның өчен тулай торакның агач остасы янына барып, «дуслашып», кирәкле инструментлар, такта кисәкләре алып килде, тәрәзә төбен суыткыч сыярлык итеп киңәйтеп, яхшылап беркетеп куйды. Кояш нурларыннан саклау өчен суыткычның тәрәзә ягын фанера кисәге белән капладылар. Әлбәттә, суыткыч кечкенә иде, шулай да шыплап тутыргач, абыйсының алып килгән күчтәнәчләре сыеп бетте. Тәрәзәнең тышкы ягында форточкадан асылынып торган әйберләрне куяр өчен такта беркетте. Аннан соң абыйсы ялангач чыбыкта эленеп торган электр лампочкасы урынына якындагы кибеттән гади генә, әмма килешле абажурлы лампа белән өстәл лампасы алып кайтты, аларны урнаштырды. Розеткалары селкенеп, ватылып беткән иде, Илһам аларны да рәтләде. Савыт-саба шкафының каерылып төшкән ишекләрен борып, ныгытып куйды. Кызларның китап киштәләре дә юк, китапларын караватастында чемоданда саклап интегәләр иде. Гөлкәй әле Яңа елга кадәр үк сигез сумга тимердән эшләнгән китап киштәсе сатып алган иде, ләкин бетон стенага кадак кагып булмаганга күрә, анысы да, тузанланып, карават астында ята. Абыйсы стенаны шул ук агач остасыннан алган дрель белән бораулап, киштәне яхшылап кагып бирде.

...Икенче көнне алар Үзәк ял паркына йөрергә чыктылар. Әкрен генә йомшак кар явып тора, көннең салкынлыгы да таман гына. Гөлкәй абыйсына имтиханнарны ничек бирүе, нинди сораулар туры килүен көлә-көлә сөйли, абыйсы исә, күп нәрсәне аңламаса да, аңлаган хәтлесенә сораулар биреп, әңгәмә кора. Ерактан караганда күбрәк абый белән сеңелне түгел, ә ике гашыйкны хәтерләтә иде бу пар. Атракционнар арасында Илһамның күңеленә иң ошаганы биеклектән карау өчен ясалган «күзәтү тәгәрмәче» булды. Гөлкәй Илһамга үзе белгән

кадәр Казан тарихын сөйләде, тәгәрмәчнең иң биек урыныннан шәһәр районнарын күрсәтте.

– Әнә теге якта Казансу Иделгә тоташа, – диде ул, көнбатышка күрсәтеп. – Әнә...

Гөлкәй кулын сузган килеш тотлыгып калды. Ул күрсәткән якта, аларның каршында тирбәлүче арбада, нәкъ Гөлкәй кебек кулларын сузып, Мансур Ибраһимович янәшәдә утырган хатын-кыз белән ике балага нәрсәдер аңлата иде. Ул, әлбәттә, Гөлкәйне күрми. Илһам, сеңлесенең тынып калуын күреп, каршыдагы арбага борылды.

– Танышыңмы әллә? – диде ул, Гөлкәйнең бөтенләй телсез калуына гаҗәпләнеп.

– Укытучым. Мансур Ибраһимович.

Илһам каршы арбага гипнозга тартылган кебек текәлгән сеңлесен тагы бер кат күздән кичерде. Гөлкәй, ниһаять, исенә килеп елмайды.

– Фәлсәфә фәнен укыта ул. Үзе тумышы белән Себердән икән, хәтта безнең авылны, Гарифҗан абыйны яхшы белә. Мәчет турында да сорады.

– Алай бик бәйләнмәдеме соң?

– Юк... Сорады гына.

Ул арада җиргә төшеп җиттеләр. Гөлкәй артына борыла-борыла атлады.

– Себердән дисең алайса... Мансур Ибраһимович диденме?! – Илһам җитдиләнеп китте, нәрсәдер оныткан кешедәй, урынында туктап калды. – Әйдә, таныштыр әле безне.

Гөлкәй сискәнеп куйды. Мансур Ибраһимович гаиләсе белән йөрергә чыккан, Гөлкәй аның янына бара алмый. Җитмәсә, хатыны шактый көяз икән...

– Юк, абый! Нәрсәгә сезгә танышырга?! Ул әле безне тагы да укытачак. Юк, юк, абый, уйлама да.

– Алайса, мин хәзер үзем барып танышам.

Абыйсы «күзәтү тәгәрмәче»ннән яңа гына төшеп җиткән Мансур Ибраһимович ягына таба атлады.

– Абый! Миңа бик читен булачак! Абый, зинһар өчен, җүләрләнмә инде!

Гөлкәй, елардай булып, Илһам артыннан ияpде. Никләр әйтте икән... Нәрсә турында сөйләшергә мөмкин Мансур Ибраһимович белән?! Җитмәсә, хатыны янында...

Ул арада Мансур Ибраһимович гаиләсе икенче якка борылып китеп баралар иде инде. Алты-җиде яшьләр тирәсендәге кечкенә улы нәрсәдәндер зарлана, ахры, кулларын күрсәтә-күрсәтә, әтисеннән нидер таләп итә. Менә Мансур Ибраһимович, туктап, улы янына чүгәләде, күн перчаткаларын салып, малайның бияләйле кулларын уды,

тунын каккалады. Ахырдан кечкенә малайны күтәреп алды да күккә чөйде. Яңа гына яшь аралаш ыңгырашкан малай, тирә-якны яңгыратып, шырык-шырык көлә башлады. Шунда ук икенче улы әтисенә килеп сарылды: «Әти, әти, мине дә күтәр, мине дә!»

– Исәнмесез! Гафу итегез, бер минутка гына сезнең игътибарны җәлеп итәргә мөмкинме?!

Мансур Ибраһимович янына килеп баскан бу парга гаҗәпләнеп карады. Әлбәттә, абыйсының артына ук елышкан Гөлкәйгә игътибар итмәде, үзенә эндәшкән Илһамга текәлде. Ярый әле абыйсы кеше белән итагатьле сөйләшә белә...

– Мансур Ибраһимович, мин сез укыткан бер студентканың абыйсы, Якупов Илһам. Себердән Казанга кунакка килдем. Бүген паркка йөрергә чыккан идек, сезне очраттык.

Мансур Ибраһимович Илһам артына елышкан кызга үрелеп карады. Гөлкәй, соң дәрәҗәдә уңайсызланып, абыйсы артыннан чыкты.

– Исәнмесез, Мансур Ибраһимович...

Укытучының кара күзләре зураеп ачылдылар. Үз алдында басып торган кара толымлы кар кызында элеккеге кыскарып, искереп беткән тунлы Гөлкәйне тануы авыр иде.

– Гөлкәй, сезме соң бу, ялгышмыйммы?! – Мансур Ибраһимович, берара сүзсез басып торгач, исенә килеп, хатынына борылды. – Розалия, хәтерлисеңме, мин сиңа безнең яктан бер кыз укырга килгән дип сөйләгән идем?! Менә ул кыз шушы була инде. Танышыгыз: Розалия Әминовна, минем тормыш иптәшем. Гөлкәй, минем якташым. Ә сез, димәк, Гөлкәйнең абыйсы – э-э... Илһам Салихҗанович. Бик шатбыз!

Мансур Ибраһимович Илһамның кулын кысты. Розалия дә, абый белән сеңелне күздән кичергәч, күңелле генә «Исәнмесез!» дип куйды. Күз карашы күбрәк абыйсында тукталды бугай... Әллә Гөлкәйгә генә шулай тоелдымы?!

Мансур Ибраһимовичны балалары һаман итәгеннән тарткалыйлар иде.

– Әти, әти, әйдә көзгеле бүлмәгә, әйдә!

Әтиләре урынына Розалия җавап бирде.

– Әйдәгез, минем белән, әтиегезнең сөйләшәсе бар. Мансур без «көлке бүлмәсе»нә керә торабыз.

– Ярый, мин сезне куып җитәрмен, Розалия.

Хатынын, балаларын күз карашы белән озатып калганнан соң, Мансур Ибраһимович Илһамга борылды.

– Йә, ничек, Казан ошадымы соң? Элек бирегә булганыгыз бар идеме?

– Беренче тапкыр килүем. Гөлкәй миңа барысын да күрсәтте инде. Матур, борынгы шәһәр икәне сизелеп тора.

– Әйе, Казан бик борынгы, күпне күргән шәһәр. Уку йортлары да күп. Сеңлегез монда килеп бер дә ялгышмаган.

Мансур Ибраһимович, елмаеп, Гөлкәйгә текәлде. Бик ягымлы, бик җылы иде аның карашы. Гөлкәй укытучыны бары кырыс кыяфәттә генә күрергә өйрәнгәнлектән, бу җылы карашка тиз генә ияләнеп җитә алмады. Шул ук кара күзләр, тик бу юлы алар сине упкынга суырмый, ә каядыр очарга чакыра бугай... Иңнәрдә канатлар үскәндәй була, йөрәгең әллә кая җилкенә...

– Гөлкәй, безгә туңдырма алып кил әле, зинһар. Әнә теге почмакта сатып торалар, күрәсеңме?!

Абыйсы, Гөлкәйне читкә җибәреп, Мансур Ибраһимович белән үзе генә сөйләшергә тели инде. Нәрсәгә кирәк бу кадәр кылану?! Гөлкәй чын-чынлап абыйсына үпкәли башлады, эчендә кирелек кабарды. «Күрмим» диясе килде. Кыш көне кем туңдырма сатып торсын инде?! Шулай да аякларын көчкә кыймылдатып, абыйсы күрсәткән якка таба атлады.

– Мансур Ибраһимович, сезнең белән болай урам өстендә сөйләшкәнем өчен гафу итегез, зинһар. «Ятып калганчы атып кал» рәвешендә килеп чыга инде.

Мансур Ибраһимович Илһамга кызыксынып карады.

– Нинди дә булса үтенечегез бармы әллә?

– Үтенеч кенә түгел, гозер дисәгез дә була. Беләсезме, Казанга Гөлкәйнең берүзен җибәрергә туры килде бит. Туганнарыбыз да юк бу шәһәрдә. Бәлки, бардыр инде алар, тик аралар өзелгән. Ә кыз баланың берьялгызын зур шәһәргә чыгарып җибәрү, үзегез аңлыйсыз, бик куркыныч. Бигрәк тә авылдан килгән кыз баланы. Тәвәккәлләргә туры килде, Гөлкәйнең үзенә ышандык.

«Ярый инде, аңлаганнар, – дип уйлады Мансур Ибраһимович. – Исләренә кереп чыкмаса да, бернәрсә эшли алмыйсың».

– Гөлкәй бик җаваплы, җитди кызга охшаган. Югалмас дип уйлыйм.

– Анысы шулай, тик барыбер дә күңел тыныч түгел. Гозерем шул, Мансур Ибраһимович: әгәр Гөлкәй тормышта бик авыр хәлгә калса, сезгә килеп ярдәм сорый аламы?!

Укытучы, Илһамга текәлеп, шулай ук җитди җавап бирде:

– Ярдәм сораган кешене мин беркайчан да кире борып чыгармаячакмын. Тик шунысы бар: Гөлкәй миннән ул ярдәмне сорармы?! Ярдәм тәкъдим иткән очракта да, кабул итәрме аны?! Сеңлегез бик горур, җитди, мөстәкыйль шәхескә охшаган. Ә мин аның һәр адымын контрольдә тота алмаячакмын, бу, нигездә, мөмкин эш түгел.

Илһам авыр сулап куйды.

– Әти шундый иде безнең. Коеп куйган әти сыйфатлары аңарда. Шулай да күз-колак булыгыз инде, Мансур Ибраһимович. Беренче елны гына булса да.

– Әлбәттә, мин аның укуын, тәртибен күзәткәләп торырмын, ләкин сезнең гаиләнең бала алдындагы бурычын мин үз өстемә ала алмыйм. Монда сезнең күзәтүегез, сезнең ярдәмегез кирәк. Мине дөрес аңлагыз, зинһар.

– Мансур Ибраһимович, мин һич тә үз өстемнән бурычны төшерергә җыенмыйм. Әлбәттә, сеңлем өчен, аның язмышы өчен иң беренче чиратта мин җаваплы. Мин моны аңлыйм. Шулай да, якташ буларак, сезгә мөрәҗәгать итсә, каршы килмәссезме?!

Мансур Ибраһимович елмаеп куйды.

– Ә сез сеңлегез кебек үк бик кире. – Укытучы, көлемсерәп, бер мизгел уйланып торды. – Юк, кире түгел, максатчан диимме?! Өзми дә куймый, миннән уңай җавап ишеткәнче сөйләшәчәксез. Кайчакта бик кирәк сыйфат. Ярый, мөмкин кадәр, кулдан килгәнчә күзәтермен, тик кабатлап әйтәм: мин Гөлкәйнең язмышы өчен җаваплы түгел. Сеңлегезне сез үзегез сакларга, якларга тиешсез.

– Әлбәттә, Мансур Ибраһимович! Бик зур рәхмәт сезгә! Безнең якларда булсагыз, зинһар, кунакка керми китмәгез!

Укытучы моңсуланып китте, карашын җиргә төшерде.

– Бәлки, керермен дә, – диде ул. – Күптән инде туган якларда булган юк. Бәлки, быел ук кайтырга туры килер.

– Алдан хәбәр итсәгез, сезне каршы алып, кулда гына йөртәчәкбез, Мансур Ибраһимович! Үзем шәхсән кайтачакмын!

– Ну, алай ук кулда йөртергә кирәкмәс, бала түгел. Шулай да сезнең якларга да килеп чыгарга исәп бар. Гарифҗан абзыйны да күреп сөйләшәсем килә. – Мансур Ибраһимович көлке бүлмәсеннән чыгып килүче гаиләсен күреп алды. – Ярар алайса, килештек. Хәерле юллар сезгә!

– Рәхмәт, сау булыгыз, Мансур Ибраһимович!

...Укытучының китеп барганын күрсә дә, Гөлкәй читтәрәк бер урында басып тора бирде. Үзе килсен әле

абыйсы... Нишләп әле сеңлесен алай юктан кимсетә... Гөлкәй үзенең хаклы түгеллеген акылы белән аңлый, шулай да күңеленнән абыйсына бик нык хәтере калган иде.

– Туңдырма алмадыңмыни?! – Абыйсы берни булмагандай елмая. Ә Гөлкәйнең карашы усал, бик усал...

– Абый, мин җүләр түгел инде. Кыланмасаң да була.

– Ярар, ярар, үпкәләмә. Мин Мансур Ибраһимовичтан синең укуың, тәртибең турында гына сораштым. Синең алда дөресен әйтә алмаган булыр иде.

Гөлкәй абыйсына күтәрелеп карады.

– Соң, нәрсә диде инде Мансур Ибраһимович? Бик зарландымы?

– Әйтергә кирәк, алай зарлану сүзләрен ишетмәдем. Әйбәт укый, актив, тәртипсезләнми, диде. Молодец! Безнең нәсел сынатмый ул!

– Тагын нәрсәләр сөйләштегез инде?!

– Кунакка чакырдым үзен. Бәлки, килеп чыгармын, диде.

– Абый, ә син минем сүзләргә генә ышанмыйсыңмыни?! Нигә инде аны укытучыдан кат-кат сорашырга?!

Илһам сеңлесенең иңнәреннән кочып алды.

– Ышанам, Гөлкәй. Шулай да мин әти урынына калган кеше. Синең турында мин кайгыртмасам, кем кайгыртыр?!

– Мин кечкенә түгел инде, үзем турында үзем дә кайгырта алам...

– Йә, ярар, әйдә, онытыйк бу сөйләшүне. Нәрсә, гомергә бер кунакка килгән абыеңа үпкәләп торырга җыенасыңмы әллә?!

Гөлкәй дә сүрелде. Чыннан да, үзенә шултикле яхшылыклар эшләгән абыйсына ничек каты бәрелә... Ярамый болай, ярамый...

– Гафу ит, абый. Укытучы алдында уңайсыз булды, мин шуңа гына...

Мансур Ибраһимович урынында башка укытучы булса, Гөлкәй үпкәләү турында уйлап та карамас иде. Тик Мансур Ибраһимовичның хатыны, балалары... Нигә, нигә күрде инде ул аларны?! Алар Гөлкәйнең тормышында юк һәм була да алмыйлар. Бары Укытучы гына. Бары Ул гына...

...Биш көн күз ачып йомганчы узган икән. Соңгы тапкыр абыйсы белән кибетләргә чыктылар, соңгы тапкыр концертка бардылар. Гөлкәй, энисенә һәм җиңгәсенә бүләккә дип, татар телендә берничә әдәби китап сатып алды – Себердә татарча китап табуы җиңел түгел иде.

Әнисенә бүләккә күптәннән алып куелган шәльяулыгын да, төреп, абыйсының сумкасына салды. Килгәндәге зур-зур сумкаларның бушап калуына Илһам шатланды гына. Дөрес, бушап калды дисәң дә, җыена торгач, сумка тулып, көчкә яптылар. Илһам кайтыр якка билетны тагы самолетка алган иде, сеңлесе «аэропортка кадәр озата барам» дисә дә, ризалашмады. «Саубуллашырга яратмыйм» диде. Гөлкәй үзе дә артык киреләнмәде, шулай да абыйсын тукталыштан автобуска утырып киткәнче озатып калды...

Әкрен генә атлап, тулай торакка кайтты, вахта артында утырган тётя Поляга көчәнеп кенә елмайды. «Озаттыңмы абыеңны?» «Озаттым». Бигрәк биектә яши икән Гөлкәй. Баскычларның исәбе юк сыман. Кайда куйды соң инде ачкычын... Ишекне ачар да, аннан абыйсы «Кайттыңмы, Гөлкәй?» дип дәшәр кебек... Илһам хәтта Гөлкәй идән юган китапханәгә дә барган иде. Янәсе, нинди эш, авыр түгелме... Гөлкәй ямансу гына буш бүлмәне күздән кичерде дә, өс-башын салганнан соң, урын җәйми генә караватына барып ятты, күзләрен йомып, уйга чумды... Абыйсының килүе аның өчен бәйрәм булды. Дөресен генә әйткәндә, Гөлкәй абыйсы үзе янына килер дип һич уйламаган иде. Армиядән кайтканнан бирле аларга яхшылап аралашырга да мөмкинлек булмады, шулай да бергә уйнап үскән күңелле балачак елларын онытмаган, күрәсең. Кич буе, төн буе шул балачак еллары, әнисе, әтисе турында сөйләштеләр, Гөлкәй беркемгә сөйли алмаган күңел серләрен, курку-пошынулары турында сөйләде, абыйсыннан киңәш алды. Ә күпме акча калдырды ул аңа! Хәзер инде эшләмәсә дә була, шулай да эшен ташламаячак әле Гөлкәй. Киткәндә дә абыйсы: «Гөлкәй, берүзең каласың. Төрле хәл булуы мөмкин. Әгәр авырлык килеп чыга икән, һич курыкмый Мансур Ибраһимович янына бар. Себер татарлары якташлыкның кадерен беләләр, ул сиңа ярдәм итми калмас», – диде. Мансур Ибраһимович... Гөлкәйнең күз алдына парктагы очрашу күренеше килеп басты. Ике мәһабәт гәүдәле ир-ат тыныч кына сөйләшәләр... Дөньяда Гөлкәй өчен иң кадерле булган ике ир-ат. Хәтта йөз-кыяфәтләре белән дә бер-берсенә охшаган ич алар! Гөлкәйнең бу турыда беркайчан да уйлаганы юк иде. Чыннан да, күзләрнең, кашларның каралыгындамы, йөз алсулыгындамы, әллә атлап йөрүдәме – нindидер якынлык бар ич. Менә нигә кадерле икән Мансур Ибраһимович...

...Гөлкәй төш күрде. Имеш, кая йөгергәнен дә белмичә, йөгерә дә йөгерә... Болыннар, далалар, таулар аша

һаман каядыр йөгерә... Менә инде хәле дә бетте. Туктыйм гына дигән иде – караса, алдында упкын... Артка чигеним дисә, артта да упкын... Кинәт каяндыр Мансур Ибраһимович килеп чыкты. «Курыкма, Гөлкәй, бу упкын чын түгел. Әйдә, бергә атлыйбыз» дип, аягын упкынга суза... Гөлкәй курка, атларга курка. «Әйдә, Гөлкәй, курыкма». Мансур Ибраһимович беренче булып упкынга атлый һәм... һавадан йөзеп китә. Гөлкәй дә аның артыннан ташлана, тик... оча, упкынга оча...

Гөлкәй шыбыр суга манчылып уянып китте. Төшендә йөрәген биләп алган курку хисе өнендә дә дәвам итте. «Ля хәүлә вә ля куәтән... Бисмиллаһ-ир-рахман ир-рахим...» Кыз белгән догаларын укыштыра башлады. «Хатын-кызга көндезен өйдә ялгыз йокларга ярамый, бастырыла» дип күпме әйткәне булды әбисенең. Йокыга киткәнен сизми калган ич. Төш түгел инде бу, ниндидер бастырылу. Уф-ф... Кызлар да тагы ике көннән соң гына киләләр бит әле, ничек ялгызы түзәсе булыр. Гөлкәй торды, башын-күзен юып кергәч, тәрәзә янына килеп утырды. Ап-ак бәскә төренгән агачлар янында мәһабәт яшел чыршы моңаеп утыра... Ботак-канатларына ак юрган бөркәнгән... Гөлкәй әлеге чыршыны рәсемгә төшерәсе килүен аңлады, тиз генә кәгазь белән акварель буяуларын алды да яңадан күңеле белән тыштагы моңсулыкка чумды...

* * *

– Димәк, өйләнгән дисең инде. – Гөлүсә кулындагы тунны, әйләндерә-әйләндерә карап, Гөлкәйгә сузды, йөзенә мут елмаю чыкты. – Бик кызганыч. Абыең киләсен белгән булсам, каникулга да кайтмаган булыр идем.

– Белеп кайтып киттең, Гөлүсә. – Рәмилә дә Гөлкәйнең башлыгын, салып, кызга бирде. – Барысы да искиткеч матур, үзеңә бик килешә, Гөлкәй. Котлы булсын, җылы өстеңдә тузсын!

– Әйе, арзан әйберләр түгел болар. Абыең сиңа тун алыр өчен шактый билен бөккән, күрәсең. Рәхмәт әйттеңме соң? – Фаягөл, күрәсең, көнләшә, шуңа тагы төртмәләнә. Югыйсә үзенең өстендәге киемнәре бер дә арзанлы түгел...

– Ой! Оныткаммын! Рәхмәт әйтергә оныткаммын! Әле дә ярый искә төшердең, Фаягөл. – Гөлкәй, бер дә күңеле кырылмый, караватында тузылып яткан яңа киемнәрен җыештыра башлады. Кызлар һәр яңа киемне тотып кына түгел, киеп карап чыкканнар иде. – Хатка язармын инде.

– Кызлар, калганын белмим, вәт минә суыткыч шәп булган. – Зөлфия сумкасындагы кучтәнәчләрен суыткыч янына өеп маташа иде. – Гөлкәйнең ризыкларын тиз генә ашап бетерәбез дә минекеләргә тотынабыз.

– Әһә, ә безнекеләр нишли, бозыламы?! – Рәмилә дә үзенең таш тутыргандай авыр сумкасын ишек яныннан өстерәп килде. – Уф, кызлар, безнең дәүләттә гиперинфляция башланды. Товар күп, яңа суыткыч алырга акча юк!

– Куяр өчен урын да юк – торак кризисы! – Гөлүсә шунда ук Рәмиләнең шаяруына кушылып көлә башлады. – Әллә берәр капкорсакны вакытлыча квартирант итеп кертәбезме?!

– Квартирантлар хәзер кереп җитәр алар. – Фаягөл инде сумкасын бушатып бетергән иде. – Аларга сызгыр гына.

– Кемне күз алдында тотасыз, иптәш Шәрипова?!

– Кем булсын инде – шуларны.

– Әһә. Аңлашылды. – Гөлүсә тиз генә коридор ишеген ачып кычкырды. – Шулар, сез кайда?! Шәрипова янына кирәгез!

Кызлар көлештеләр. Соңгы вакытларда бүлмәләренә чәй эчәргә йә Чулпан, йә күрше кызлары, бер дә юкта таныш-белеш егетләр кереп йөри башлаганнар иде. Күрәсең, Фаягөл шуларны күз алдында тота. Аңа мондый компанияләр ошамый, бигрәк тә Чулпанга каныга иде. Чулпанның бер дә исе китми, Фаягөлнең төртмәле сүзләренә дә җиңелчә көлеп кенә җавап кайтара. Ул да каникулдан килеп җиткәндер инде.

– Йә, кемдә нинди яңалыклар бар?! Кемнең хәләл җефете үзе югында өйләнеп куйган?!

Гөлүсәнең шушы сүзләрне генә әйтүе булды, Зөлфия кулындагы банкасын идәнгә төшереп җибәрде, үзе, агарынып, Гөлүсәгә текәлде.

– Сиңа кем әйтте?! – Кызның тавышы калтыранып чыкты, зур ачылган күзләрендә рәнҗү чагылды.

Кызлар аптырашып тынып калдылар.

– Нәрсәне?! – Гөлүсә дә һичнәрсә аңламый Зөлфиягә текәлгән иде. – Шаярып кына әйтәм ич, кемнең егете өйләнеп куйган, дим. Әллә?!

Зөлфиянең күзләренә яшь тыгылды, кулын селтәп, бүлмәдән йөгереп чыгып китте. Аның артыннан ук Рәмилә чыгып йөгерде. Бүлмәдә киеренке тынлык урнашты.

– Кызлар, валлаһи, бернинди начар уйсыз әйттем ич. Шаярып кына. – Гөлүсә, үзе дә аптырап, кулларын җәйде. – Күрәсең, чыннан да бер-бер хәл булган инде...

Кызлар да аптырашып калганнар иде. Гөлкәй банка ватыкларын җыя башлады, аңа Гөлүсә дә кушылды. Бераздан Зөлфия белән Рәмилә кире бүлмәгә кайттылар. Зөлфия моңсу гына караватына барып утырды.

– Зөлфия, дустым, гафу ит, зинһар. – Гөлүсә, Зөлфия янына килеп, кызның кулларын кысып алды. – Белеп әйткәнем түгел иде. Урынсыз шаяру килеп чыкты, зинһар, гафу ит, Зөлфия! Белмәдем бит!..

– Әйдә ярар, үтте инде. – Зөлфия көчәнеп елмайды. – Һаман искә төшә дә авыр булып китә.

– Нәрсә булды соң, кычкырышкан идегезме?! – Фаягөл Рәмиләнең усал каравын күреп тукталып калды. – Юк, сөйлисең килмәсә, сөйләмә, болай гына соравым.

– Барыбер кайчан да булса ишетелер иде. Монда бездән студентлар күп укый. Вәт... Мәктәптә чакта ук дус булып йөргән егетем мин кайтканчы өйләнгән дә куйган... «Миңа укыган хатын кирәк түгел» дип әйтә, ди... Үзе тракторист, янәсе... Беркем бернәрсә сизми дә калган. Ичмасам, кычкырышмаган да идек.

Зөлфиянең яңадан күз карашы томанланды.

– Беләсеңме, нәрсә әйтәм мин сиңа? – Рәмилә кызны иңнәреннән кочып алды. – Җүләр ул синең егетең. Ә өйләнүе бик әйбәт. Барыбер сиңа гомер буе тынгылык бирмәс иде, «син укыган, син фәлән» дип интектерер иде. Шулай булгач бер дә кайгырма, башыңны югары күтәреп йөр. – Рәмилә Зөлфиянең бите буйлап аккан күз яшьләрен сөртте. – Менә күрерсең, синең кебек кызга шундый егет табылыр әле – авылга кара «Волга» машинасында гына кайтып төшәрсез, кара костюмлы, галстуклы, ак күлмәкле ирең белән култыклашып кына урамнан үтеп китәрсез – менә шунда күрер ул хыянәтче кемнең кем икәнен!

– Әярату?! Ә мәхәббәт нишләр?!

– Дустым, әгәр сиңа көн саен «син укыган, син чукынган» дип такылдый башласалар, мәхәббәтнең исе дә калмый! Ышан сүзләремә!

– Әй кызлар, бу егет халкы коточкыч инде. Нәрсә турында гына уйлыйлардыр! Бүген сиңа бер төрле сөйли, иртәгә икенче кызга барып шул ук сүзләрне кабатлый! Имансызлар, валлаһи!

– Барысы да түгел инде. – Гөлкәй Зөлфияне юатырга теләсә дә, юатырдай сүзләр таба алмады. Ай-һай, авырдыр сөйгәнең ташласа... Ташласа гына түгел, башкага өйләнсә! – Араларында яхшылары да булырга тиеш...

– Вот именно. Алайса, без кемгә кияүгә чыгарбыз?! – Гөлүсә урыныннан сикереп торды. – Кызлар, әйдәгез, чәй

эчәбез, ә?! Мин гаепле, димәк, өстәлне үзем хәзерлим, үзем җыям!..

...Тагы дәресләр башланды. Математика, математика... Математика ярый, кирәкле фән, тик минә фәлсәфә мәңгелек булсын иде... Нишләп инде шундый меңәр еллык тарихы булган зур фәнне студентлар бары бер ел дәвамында үзләштерергә тиеш?! Бу дөрес түгел! Ә укытучы?! Ничек итеп ул мең еллык тарихны ниндидер тугыз айга сыйдырып бетерергә тиеш?! Юк, Гөлкәй моның белән килешми... Гөлкәй үзенең Мансур Ибраһимовичтан аерылуын күз алдына китерә алмый иде. Мәңге шулай булыр кебек: Мансур Ибраһимович аларга ел саен фәлсәфә серләрен өйрәтер, ә ул дәрес саен Укытучының кара давыл күзләренә кереп батар... Мәңге шулай булсын иде!

*Икенче бүлек*

## Мансур Ибраһимович

Яз, яз... Яз. Әле генә кышкы салкыннан колаклар чыңлый иде, ә хәзер минә итекләр, басар урын тапмый, су ера. Быел яз иртә килә, ахры, – егерме сигезенче февральдә күк күкрәп, яшенле яңгыр яуды. Гаҗәпме?! Гаҗәп. Кемнәр корылыкка юраса, кемнәр «фаҗига булачак» диде. Мансур Ибраһимовичның да көннәре тынгысыз – быел университетка зур тикшерү килә, шунлыктан һәр укытучының шәхси йөкләмәләре, лекция-дәресләре, планнары өр-яңадан каралып, кафедра утырышында тикшерелде, кемнәрдер шелтә алды, кемнәргәдер кисәтү ясалды. Мансур Ибраһимовичның һәр папкасы, һәр кәгазе үз урынында, тәртиптә, шуңа артык борчыласы да юк кебек иде. Ләкин борчылмаса, Мансур Ибраһимович булмый шул инде ул. Язның ягымлы көннәре дә, җылы кояш нурлары да, хәтта гаилә мәшәкатьләре дә беразга онытылып торды. Тик язның килүенә студентлардан да артыграк шатланган кешеләр, мөгаен, юктыр. Әле күңелне куркытып торган җәйге сессия еракта, офык читендә күренгән җилкән сыман гына – әле дулкын, әле болыт каплап китә. Кыш көне чирканчык алган беренче курс студентларының йөрәге инде билгесезлек алдында курkынып типми, зачет-имтиханнарның нәрсә икәненә төшенгәннәр, шуңа күрә яз аларның күңелләренә яшәү яме, яшьлек хисе булып ургылып килеп керде. Институт коридоры кызлар көлешүеннән яңгырап торды,

егетләр гадәттәгедән кычкырыбрак сөйләшә башладылар, әле анда, әле монда һавага «Красная Москва», «Душистый табак» одеколоны исе эленеп калды. Яз хәтта укуга да үзгәрешләр салды – дәрес калдырулар, дәрестә йокымсырап утырулар ешайды. Укытучылар боларның барысына да беркадәр елмаеп, яшьлек белән көрәшеп булмый инде дигәндәй, мәсьәләгә аксакалларча фәлсәфи якын килделәр. Тик Мансур Ибраһимович кына түгел. Аның лекцияләрендә, математика дәресләрендәге кебек, арткы парталардан ара-тирә гырлау тавышын ишетү гадәттән тыш хәл иде. Әйтерсең Мансур Ибраһимович беркайчан гашыйк булмаган да беркайчан язгы салкынча кичләрне шәһәрнең бер башыннан икенче башына кадәр трамвай юлы буйлап сөйгәне белән кулга-кул тотынышып йөрмәгән... Шундый студент дәрестә йокламый кайчан йокласын?! Мансур Ибраһимович Гегель турында сөйләгәндә аның уенда бары Гөлинә йә булмаса Гөлсинә генә инде... Их, яшьлек!..

Гөлкәй дә әледән-әле үзендә ниндидер көтелмәгән күңел күтәренкелеге йә, киресенчә, үзәк өзгеч моңсулык сизде. Кичләрен кызларның кинога йөрүләре ешайды, һәр көн диярлек аларны егетләр озата кайтты. Озакламый бүлмәдәшләре барысы да үзләренә дус егетләр табып куйдылар. Хәтта Рәмилә булып Рәмилә дә үзе кебек үк зур күзлекле, чандыр озын буйлы егетне күңеленә якын итте. Дөрес, аларның мөнәсәбәтләре башкалардан шактый аерыла иде: кичләрен Рәмиләне урамда йөреп керергә чакырырга килгәч үк, кыз белән егет арасында кызу бәхәс башлана, кайтып кергәндә дә шул ук хәл – дөньяны онытып, ике гашыйк дөнья турында бәхәсләшәләр иде. Бәхәсләшәләр, әмма бер-берсенә үпкәләүнең әсәре дә юк! Менә шундый мөнәсәбәтләр дә була икән бу дөньяда... Зөлфиянең дә күңел яралары бераз тартылды, элеккеге кебек авылга кайтырга бик ашкынмады. Бераздан күрше бүлмәдә генә торучы зур уйчан күзле егетне якын күрә башлады... Гөлүсә исә яз көннәре килүгә ничектер тынып калгандай булды. Һәрвакыт шат күңелле, йөзеннән елмаюы китмәгән, коридорның әле теге, әле бу башында кыңгырау чыңыдай кычкырып көлүе ишетелеп калган кызның болай моңаюына бүлмәдәшләре тиз генә ияләшә алмадылар, Гөлүсәне «ни булды да, ни булды» дип аптыратып бетерделәр. Янәсе, әгәр дус кызларын берәрсе рәнҗетсә, бүлмәләре белән тотып кыйнаячаклар! Тик кызлар юкка борчылганнар: Гөлүсәгә берни дә булмаган, гашыйк икән ләбаса ул! Кемгә диегез – авызыннан ике кәлимә сүзне һич тартып алып булмаган Дамирга! Дами-

ры да коридорда Гөлүсәне очраткан саен ике күзен мөлдерәтеп кызның артыннан карап кала, тик эндәшми генә... Ә Гөлүсә аптырамады, бер-ике атна җавапсыз гыйшык утларында янып йөргәч, үзе Дамирны киногa чакырды. Шунда кызлар беренче тапкыр егетнең шатлыктан комач кебек балкыган йөзен күрделәр, аннан да бигрәк, матур йомшак баритонына исләре китте... Фаягөл исә барысын да уздырды: райкомда яхшы гына урында эшләгән бер абзыйның сөяркәсенә әйләнеп куйды. Гөлкәй генә... ялгыз иде. Беркемне күңеленә якын итә алмады. Кинодан озата кайткан егетләргә «дустым бар» дип котылды. Кызларга исә «ошамыйлар алар миңа» диде. Әлбәттә, кайдадыр күңел түрендә ул беркайчан да Мансур Ибраһимович белән бергә булмаячагын аңлый иде. Димәк, аңа үз тормышын җайга салырга кирәк, үз тиңен табарга кирәк... Тик берничек тә күңелгә кереп утырган Мансур Ибраһимович сурәтеннән котылу юк. Бигрәк тә һәр атнаны икешәр тапкыр аның дәресендә утыргач... Акылы кайчак бу хиснең артык икәнен, кирәк түгел икәнлеген тәкрарлый, ә күңеле исә моның белән килешми. Укытучының кара күзләрендә дөнья үзе чагыладыр төсле, шулай булгач, бу дөньяда гыйшык та, мәхәббәт тә, ярату да бар. Мансур Ибраһимовичның күңелендә дә гыйшык, мәхәббәт, ярату бар, тик ул бу турыда үзе дә белми әле... Ул – Гөлкәйнең Alласы. Кайчак Гөлкәй үзенең мондый уйларыннан куркып китә, хисләренең артык тышка чыгуыннан куркып, күзләрен яшерә, әнисе турында уйлый башлый. Ләкин кызның борчылуы юкка – кара күзләр аның бу халәтен сизми. Әллә укытучы фәлсәфәдән башка, гомумән, бернәрсә белән дә кызыксынмый микән?! Әйтерсең тормышта Сократ, Демосфен, Диоген һәм тагы шундый «ген»нар гына бар... Тигез, җайлы, уңайлы тормыш, шундый ук тыныч караш. Мәңгелек тынычлык символы диярсең... Тик көннәрнең берендә Гөлкәй аудиториягә кергән укытучының карашын күреп имәнеп китте. Бер караганда, барысы да элеккечә иде кебек: Мансур Ибраһимович, тиз-тиз атлап, аудиториягә керде, кулындагы портфеленнән кәгазьләрен алып өстәлгә куйды. Менә ул хәзер тәрәзә янына барып басар, тыштагы күренешкә сокланып карап алгач, аудиториягә борылыр. Гөлкәй дә, башкалар да бу хәрәкәтләрнең барысын да яттан беләләр. Тик алар көткәнчә булмады. Кәгазьләрне куйгач, укытучы, аска карап, ниндидер тонык, сүрән тавыш белән: «Исәнмесез...», – диде. Бу исәнләшү аның иреннәреннән газаплы ыңгырашу булып ишетелде. Алай гына да түгел, бераз вакыт аска карап, тын гына басып

торганнан соң, укытучы студентларга күтәрелеп карады. Гөлкәйнең өне калмады. Һичшиксез, Мансур Ибраһимовичка нәрсәдер булган иде. Күз төпләренә кара капчыклар эленгән, йөзе саргайган, карашы тонык, томанлы. Аудиториягә үтәли карап, беркемне күрми. Әкрен генә дәреснең темасын әйтте дә сөйләп китте. Бик авырдан кубып сөйләде, нәрсә сөйләгәнен үзе ишетмәгәндәй, сүзләр агышында буталып бетте, ялгышты. Ахырдан кәгазьләренә текәлеп, шуннан гына укый башлады, кайбер озын-озын фразаларны диктант яздыргандай, әйтеп яздырды. Аның лекцияләрендә мондый хәлнең булганы юк иде әле. Гөлкәйнең йөрәген шом басты, бәгыре өзгәләнде. Булган, нәрсәдер булган укытучыга! Йа Хода, авырып китте микән әллә?! Әллә берәр авыр сүз әйттеләр микән?! Әллә эш урынында күңелсезлекләр килеп чыкканмы?! Гөлкәйнең миендә мең төрле сорау бөтерелде, тик берсенә дә җавап табалмады. Мансур Ибраһимович дәрес бетәргә ун минут кала студентлар белән саубуллашты да аудиториядән җәһәт кенә чыгып китте. Гөлкәйнең әле тагы ике пар дәресе бар иде. Тик нәрсә ул дәресләр! Әгәр Мансур Ибраһимовичка аз гына булса да ярдәм итә ала икән, бернигә карамый аның артыннан җир читенә йөгерәчәк. Һәм йөгерде дә. Рәмиләгә берни аңлатмый-нитми, пальтосын ничек кирәк алай иңнәренә элде, төймәли-төймәли, институтның ишегалды баскычына чыгып, Мансур Ибраһимовичны көтә башлады. Озакламый, киенеп, Мансур Ибраһимович та чыкты, беркадәр бөкрәеп, картларча әкрен адым белән урамга юнәлде, уңга борылды да тротуар буйлап атлап китте. Бераз калышып, Гөлкәй аның артыннан иярде. Озак, бик озак атлады Мансур Ибраһимович. Юл уңаенда очраган телефон будкасына кереп, каядыр шалтыратып чыкты. Укытучының кызылы янып торган светофорга юл аркылы чыгуын күреп, Гөлкәйнең хәле китте, ярый әле юлда машиналар юк иде. Адымнары Мансур Ибраһимовичны Үзәк паркка алып килделәр. Парк уртасыннан күпер аша санаторий ягына чыкты да, кеше-кара күренмәгән Революция аллеясындагы әле кардан арчылып та бетмәгән утыргычлар янына килеп, кулындагы портфелен куйды, юеш эскәмиягә утырды, кулы белән йөзен яшереп, тезләренә капланды. Укытучының иңнәре дерелди иде. Агачлар артына посып күзәткән Гөлкәйнең, моны күреп, ихтыярсыз, күзләреннән яшьләр коела башлады, сулкылдап йөрәге типте, тыны капланды. Гөлкәй укытучыдан да бигрәк өзгәләнде. Хәзер үк йөгереп барып, Мансур Ибраһимовичны иңнәреннән кочып юатасы, кара чәчләреннән иркәләп, барлык кайгы-

сагышларын оныттырасы килде. Аның бу теләге шулкадәр көчле иде ки, Гөлкәй, чыннан да, шул якка таба бер-ике адым ясады да туктап калды. Ярый әле акылы җиңде. Үзенең мондый адымы белән укытучы күңеленә өстәмә җәрәхәт кенә ясаячагын аңлый иде Гөлкәй. Нәрсә, нәрсә булды икән аның Укытучысына?! Кем шушы хәлгә төшергән аны?! Нигә елый ул?!

...Бүлмәсенә кайткач, Гөлкәй иң әүвәл, суыткычтан аю мае алып, аякларын уды. Өч сәгатькә якын кар өстендә басып торганда сизмәгән, тик кайтканда аякларының түзеп булмаслык чемердәвеннән бик каты өшеткәнен аңлап алды. Аю мае бутап, сөт җылытып эчте, мәтрүшкәле-җиләкле чәй ясады, аю тамырын – женьшеньне – төнәтергә куйды. Хәзер инде авырып ятмас. Мансур Ибраһимович турында кем кайгыртыр икән?! Ул да бит, юеш тактада шулхәтле вакыт утырып, салкын тидерәчәк инде. Нәрсәләр генә булды икән Укытучыга?! Парктан аякларын көч-хәл белән кыймылдатып чыгып барган Мансур Ибраһимович күз алдына килде. Юк, нәрсәдер эшләргә кирәк. Мансур Ибраһимовичка дарулар, үләннәр кайнатырга кирәк. Терелтергә кирәк аны, терелтергә!.. Шундый уйлар белән Гөлкәй утырган җиреннән сикереп торды, суыткычны ачып, берәм-берәм кайнатмаларны, карават астындагы сумкасыннан киптергән үләннәрне барлый башлады. Ул арада Рәмилә кайтып керде.

– Уф, Гөлкәй, син кая китеп югалдың?! – Рәмиләнең тавышы кырыс, әмма борчылганы йөзенә чыккан. – Кызлар инглиз теле түгәрәгенә калдылар, ә мин, синең өчен борчылып, өйгә кайтып киттем. Нәрсә булды?!

– Рәмилә! – Гөлкәй бу юлы дустыннан яшерүне кирәк тапмады. – Миңа бернәрсә дә булмады. Ә менә Мансур Ибраһимович авырый!

Рәмилә Гөлкәйгә сынап, туп-туры итеп күзләренә карады.

– Әйе шул, бүген кыяфәте юк иде. Ә син каян беләсең авырганын?!

– Беләм. Өенә барырга кирәк аның, үләннәр илтергә. Ничек табыйк икән адресын?!

Рәмилә уйлана калды. Укытучы өенә барыргамы? Килешеп бетәр микән соң?!

– Аһ, Гөлкәй, әллә ни сөйлисең син. Кеше авырмый тормый инде. Мансур Ибраһимович та тимердән түгел, авырыр да терелер.

– Юк, юк, андый тиз генә үтә торганга охшамаган аның авыруы. Бер уңайдан сорашып та чыгарбыз, бәлки, безнең ярдәм кирәктер?!

Рәмиләнең карашы беркадәр йомшарган кебек тоелды.

– Деканатта адресын беләләрдер дә инде, безгә бирмәсләр. Гөлкәй, туктале, хатыныннан яхшы түгел бит, нәрсә диярбез?!

– Нигә, мәктәптә укыганда авырган укытучы янына бара идек бит әле, монда нишләп ярамасын? Без бит дарулар гына илтәбез.

– Ай, Гөлкәй, Гөлкәй... – Рәмилә, уфылдап, баш чайкады. – Хатыны карар иде әле...

– Һаман хатыны да хатыны! Хатынында аю мае бар дисеңме?! Женьшень тамыры бардыр дисеңме?! Алайса, сөекле хатынына гына бирербез дә ишек төбеннән борылырбыз!

– Нигә кызасың әле?! Мин болай гына әйтәм ич. Аннан соң, нишләп әле син Мансур Ибраһимович турында алай кайгыртасың?

Гөлкәй мизгел эчендә кызарып чыкты. Саклык турында бөтенләй онытты лабаса! Рәмилә – ышанычлы дусты, әмма аңа да серен ача алмый ул...

– Рәмилә... Беләсеңме... – Гөлкәй күзләрен читкә алды. – Мансур Ибраһимович минем якташым ул. Э-э... Туганым кебек. Күрше авылда гына яшәгән. Минем әтине белә икән. Абый килгәч, алар очрашканнар иде. Тик беркемгә дә бу турыда әйтмә, зинһар, яме?! Мин сиңа ышанам, шуңа гына әйтүем...

– Алай икән.

Рәмилә һаман өстен салмаган иде әле, шул көе караватына барып утырды. Бераздан шап итеп маңгаена сугып куйды.

– Миндә бит аның өй телефоны бар!

Гөлкәй, гаҗәпсенеп, Рәмиләгә борылды.

– Исеңдәме, беренче дәрестә старостага – Гөлүсәгә – «кирәк була калса» дип, әйтеп яздырган иде? Шунда мин дә дәфтәргә теркәп куйдым. На всякий случай.

Рәмилә сумкасыннан дәфтәрен тартып чыгарды.

– Менә. Эш телефоны да, өй телефоны да бар.

Гөлкәй шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Шунда ук телефон номерларын Рәмиләнең дәфтәреннән үзенең блокнотына күчереп куйды.

– Вахтада бик ялынып сорасаң, шалтыратырга рөхсәт итәрләр, бәлки. Әйдә, төшеп карыйбыз.

...Трубканы, шактый озак торып, Мансур Ибраһимович үзе алды. Тавышының карлыгуы бетмәгән иде.

– Гөлкәй?! – Мансур Ибраһимович, күрәсең, гаҗәпләнеп, бераз дәшми торды. – Әйе, тыңлыйм.

Хәзер инде Гөлкәй аптырап калды. Нәрсәдән башларга?!

– Мансур Ибраһимович... Миңа сезне күрергә кирәк иде. Бик кирәк.

Күңеле белән сиземләп, «хәл белергә киләм» дисә, укытучы рөхсәт бирмәячәген аңлады кыз.

– Э-э... Хәзер үкме? Берәр хәл булмагандыр бит?!

– Юк. Сезнең белән сөйләшергә кирәк иде, Мансур Ибраһимович. Бик кирәк.

Гөлкәй, җүләр кешедәй, һаман бер үк сүзләрне кабатлады. Укытучы да аптырады булса кирәк, бераз тын торды. Аннары тынын җыеп, бераз көрсенеп әйтә куйды:

– Мин бүген эшкә баралмыйм инде, Гөлкәй. Әгәр бик ашыгыч булса, өйгә килә аласың.

– Каршы килмәсәгез, мин Рәмилә белән килер идем...

Адрес буенча Мансур Ибраһимович яшәгән йортны тиз эзләп таптылар. Ишек кыңгыравы да бик нәзакәтле, матур тавышлы икән. Йомшак йоннан бәйләнгән аксыл свитер кигән, өй чалбарыннан ишек ачарга чыккан Мансур Ибраһимовичның элеккечә төсе юк, күз төпләре шешенгән иде.

– Исәнмесез, кызлар! Узыгыз, рәхим итегез.

Кызлар кыенсынып кына эчкә уздылар, ерак китәргә базмыйча, ишек төбендә таптандылар. Мансур Ибраһимович кызларның читенсенүен күреп елмайган булды.

– Монда кадәр үк килгәч, керми китмәссез бит инде. Әйдәгез, барыбер өйдә миннән башка кеше юк, кыенсынмагыз.

Ниһаять, өс киемнәрен, итекләрен салып, кызлар иркен генә кунак бүлмәсенә – зал ягына уздылар. Китаплар, китаплар... Стена буенда бөтен яктан да китап киштәләре сузылган. Пианино. Уртада түгәрәк өстәл, челтәрле өстәл лампасы. Бите ачылган китап, янында бөгәрләнгән кәгазь. Мансур Ибраһимович аны тизрәк кулына алып йомарлады, борылып, комод тартмасына салып куйды. Кызларга йомшак кәнәфигә ишарә итте.

– Утырыгыз.

Кызлар, утыргач та сүзне нәрсәдән башларга белми, бераз дәшми тордылар. Рәмилә Гөлкәйнең сүз башлавын көтә, ә тегесе кып-кызыл булып кызарып тик утыра. Мансур Ибраһимович инициативаны үз кулына алды.

– Ягез, институтта нинди яңалыклар, нинди моң-зарлар бар? – диде ул, беркадәр авырдан кубып.

Мансур Ибраһимович алар килгәнче ятып торган, ахры, битләренә сырлар чыккан. Бу сырлар аны үз яшеннән бераз олыгайтып җибәрәләр шикелле. Гомумән, укытучы соңгы көндә ничектер картаеп киткән кебек.

Ниһаять, Рәмилә төртеп алганнан соң, Гөлкәй исенә килгән кебек булды.

– Мансур Ибраһимович, зинһар, ачуланмагыз инде. Бернинди ашыгыч эш юк безнең. Сезнең авырып киткәнегезне белдек, шуңа күрә сезгә дәваланырга үләннәр, майлар алып килдек. Себер үләннәре, әнкәй җибәргән.

Гөлкәй, ашыга-ашыга, сумкасыннан төргәк-төргәк үләннәр, каклар, кечкенә банкадагы кайнатмалар, киптергән җиләкләр, майлар чыгара башлады. Үзе һәрберсенең исемен атап, ничек кулланырга кирәклеген әйтә торды. Бераздан өстәл өсте банкалар, төргәкләр белән тулды. Мансур Ибраһимович дәшмәде, кинәт кенә авыр уйга чумды. Йөзенә караганда, укытучының күңеленнән әллә нинди давыллар кичте. Әрнү дә, сагыш та, ачу да, рәхмәт хисе дә, үпкә-рәнҗү дә бар иде шикелле. Тик кемгә?!

– Рәхмәт, – диде ул, бераз утыргач. Тавышы өзелеп, калтыранып чыкты. Нәрсә турында уйлый икән соң ул?! – Рәхмәт, Гөлкәй. Рәхмәт, Рәмилә.

Рәмилә тагы Гөлкәйгә төртеп алды, күзләрен уйнатып, ишеккә ишарәләде. Киттек, янәсе. Юк, Гөлкәй болай гына китә алмый. Ул үзе бу үләннәрдән төнәтмә ясап эчермәсә, укытучыны башка кеше дәваламаячак.

– Мансур Ибраһимович, сез авырыйсыз, сезгә ятып торырга кирәк. Әгәр аш бүлмәсендә хәстәрләргә рөхсәт итсәгез, без хәзер, чәй кайнатып, төнәтмәләр ясар идек.

Рәмилә Гөлкәйнең кыюлыгына шаккатты. Укытучы да, күндәм песи баласы кебек, йомшак кына әйтә куйды:

– Әйе шул, тагы температурам күтәрелә бугай. Хәлем юк. Йөткерәм дә. Ятып тору зыян итмәс иде.

Кызлар, өстәл өстендәге төргәкләрне кочаклап, аш бүлмәсенә чыктылар. Кечкенә генә бүлмә, җыйнак кына шкафлар, савыт-сабалар. Рәмилә чәйнеккә су тутырып плитәгә утыртты.

– Хатыны кимендә ике-өч көн өйдә булмаган, – диде ул, Гөлкәйнең колагына пышылдап. – Савыт-саба юылмаган, аш пешерелмәгән.

Гөлкәй үзе дә күрә иде. Димәк, хатыны кунакта вакытта ниндидер күңелсезлек килеп чыккан. Әйтәм бит, нәрсәдер булган укытучыга...

Төнәтмәләрне ясап куйгач, Гөлкәй кайчан, ничек, күпме эчәргә кирәклеген кәгазьгә язып, һәрберсенең капкачына кыстырды. Өч чынаякка өч төнәтмәне тигез итеп бүлде дә подноска тезде, җиләкләрне, какны, кайнар суда изеп, аерым савытка салды, суыткычтан аю маен алып, аны да төнәтмәләр янына подноска куйды. Хәзер Мансур Ибраһимович янына керәсе иде.

– Әйдә, – диде Рәмиләгә.

Тик Рәмилә башын гына чайкады.

– Минем алда аңа уңайсыз булачак. – Рәмилә Гөлкәйгә бераз сынап карады шикелле. – Син үзең генә кер, якташыннан читенсенмәс.

Гөлкәй килеште. Чыннан да, укытучы кешегә, бигрәк тә ир-атка кызлар алдында авыруын күрсәтү яхшы түгелдер... Рәмилә дөрес әйтә. Әгәр хатыны өйдә булса, Гөлкәй үзе дә укытучы янына кермәс иде. Тик хәзер башка хәл.

Әкрен генә ишек шакып, Гөлкәй бүлмәгә узды. Караңгылатып куелган тәрәзә пәрдәләре көн яктысын яшерәләр. Мансур Ибраһимович свитерын салган, майкадан гына, күкрәктән юрганга төренгән. Гөлкәй кергәч, яткан урыныннан бераз күтәрелде, читенсенеп елмайган булды.

– Калтырата башлады әле. Ныклап авырып киттем, күрәсең.

– Хәзер, Мансур Ибраһимович. Туган як үләннәре бик тиз аякка бастырыр үзегезне.

Гөлкәй подносын якында торган тумбочка өстенә куйды, беренче чынаякны, алып, укытучыга сузды.

– Башта менә монысын эчәргә кирәк. Аннары менә бу измәне кабыгыз.

Мансур Ибраһимович төнәтмәне соңгы тамчысына кадәр эчеп куйды, ачысыннан йөзен чытты. Тәмлерәктер дип, измәне капкан гына иде, анысы тагы да ачырак булып чыкты.

– Ай-яй, – диде ул, күзләрен йомып, – бигрәк ачы даруларың. Күңелне болгата.

– Дару ачысы файдага гына. Әби шулай ди торган иде.

Чыннан да, ун-унбиш минуттан Мансур Ибраһимовичның маңгаенда тамчы бөртекләре күренде. Укытучы тәмам изрәде. Рәмилә янына чыгып, савыт-саба юарга булышып кергәч, Гөлкәй тагы аңа дәште, икенче чынаяктагы төнәтмәне эчерде. Укытучының калтыранып, көчхәл белән күтәрелгәнен күреп, күңеленә шом йөгерде. Яхшыга түгел иде бу.

– Мансур Ибраһимович, күкрәгегезне, аркагызны менә бу май белән сыларга кирәк. Үзегез сылый аласызмы?

Тик укытучы җавап кайтармады, тагы изрәп йокыга китеп бара иде. Гөлкәй Рәмилә янына чыкты.

– Хәлләр начар, – диде ул, Рәмиләгә туры карап. – Бүген Мансур Ибраһимович тора алмаячак.

Рәмилә чын-чынлап борчыла калды.

– Бәлки, «скорый» чакырырга кирәктер?! Ай Аллам, хатыны кая китте икән соң?!

Ул арада эчке яктан ыңгырашкан тавыш ишетелде. Кызлар, йөгереп, бүлмәгә керделәр. Мансур Ибраһимович берни белештерми, караватта бәргәләнеп ята иде.

– Гөлкәй, син дөрес эчердеңме үләннәреңне?! Белеп эшлисеңме?!

Гөлкәй үзе дә агарып киткән, тик ул Рәмиләгә ныклы тавыш белән җавап бирде.

– Белеп эчердем, Рәмилә. Хәзер әле соңгысын эчерергә кирәк.

Мансур Ибраһимович ыңгырашудан бераз туктаган арада, көч-хәл белән авызына ике-өч кашык төнәтмә коя алдылар. Авыру берничә тапкыр йотып куйды.

– Хәзер бераз тынычланырга тиеш, – диде Гөлкәй, пышылдап. – Мәк суы бу, йоклата торган.

Чыннан да, бераздан Мансур Ибраһимович ыңгырашудан туктады, тигез сулыш ала башлады. Кызлар бүлмәдән чыктылар.

– Рәмилә, Мансур Ибраһимовичны бу хәлендә ташлап китәргә ярамый. Мин бүген монда калам. Сиңа тулай торакка кайтырга кирәк.

Рәмилә үзе дә аңлый иде, шулай да аптырап әйтеп куйды:

– Бәлки, миңа да синең белән калыргадыр?!

– Тулай торакта безне югалтырлар, эзли башларлар. Син кайтып берәр нәрсә уйлап чыгар инде, зинһар, тик монда калуым турында гына әйтмә. Туганнарында кунарга калды, диген.

– Синең Казанда туганнарың юклыгын һәркем белә.

– Алайса, нәрсә әйтергә дә белмим. Үзең уйла инде.

– Ярар, башка институттагы дус кызлары кунарга ала килделәр, диярмен. Тик...

Рәмилә, ничек әйтергә белмәгәндәй, тынып торды.

– Нәрсә?!

– Соң... Хатыны кайтып керсә, ни диярсең?!

Гөлкәй аптырап калды.

– Ә нәрсә диярга тиеш мин?! Ничек бар, шулай әйтермен.

Рәмилә килештерми башын чайкады.

– Ярар, үзеңә карыйсың... Бәлки, миңа да кабат килергәдер?!

– Хәзер кич булды, син кайтып җиткәнче караңгы төшә. Төнлә йөрмәссең инде, Рәмилә.

Рәмилә китте. Гөлкәй Мансур Ибраһимович янына керде, кулын укытучының ут кебек маңгаена куйды. Бәлки, Рәмилә хаклыдыр – «ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәктер? Шулай да Гөлкәй күңеле белән үзенең үләннәре-

нең көченә ышана – абыйсын «себер үләте»ннән саклап калган үләннәр гади салкын тиюне генә җиңә алалар бит инде. Салкын тию генә булса... Мансур Ибраһимович йоклый, тик Гөлкәй көткәнчә тыныч йокламый. Кайчакта башын уңга-сулга бәргәләп ала, кайчак, кашларын җыерып, ыңгырашып куя. Бу хәлдә аю мае да әллә ни ярдәм итә алмас. Барыбер аз булса да сыларга кирәк. Гөлкәй җылыда сыекланган майны уч төбенә салды, Мансур Ибраһимовичның юрганын күкрәк турыннан ачып, майны тәненә ышкыды. Укытучыга кагылу белән, кыз әллә нишләп китте – күңелен ачыттырып, чиксез ярату, сөю тойгысы баш калкытты, сөйгән кешесенең шулкадәр якынлыгын тою рәхәт бер хис дулкынын барлыкка китерде. Шул минутта ук үзенең бу хисеннән үзе оялды. Кара инде син аны, Укытучы авырып ята, ә аның башында нинди уйлар бөтерелә. Оятсыз! Тик кулын Мансур Ибраһимовичның тәненнән аерырга ихтыяр көче җитмәде... Сөеп-яратып, бертуктаусыз ир-атның таза кулбашларыннан, беләкләреннән сыйпады, бит алмаларын иркәләде, маңгаен, кара чәчләрен сыпырды. «Син терелергә тиеш» дип пышылдады. Эченнән Ходай Тәгаләгә «Йа Ходаем, Укытучымның хәлен җиңеләйтсәнә, юлларында торган авырлыкларны алсана, бәхетле гомер, саулык-сәламәтлек бирсәнә!» дип ялварды. Төн уртасы узгач, Мансур Ибраһимовичның хәле тагы начарланды, кемнедер исеме белән атап чакыра башлады, саташты. Гөлкәй суыткычтан тапкан кирәкле даруларны, изеп, төнәтмәләренә кушты, булдыра алган кадәр Мансур Ибраһимовичка йоттырды, бераздан тагы мәк суы эчерде. Ниһаять, таң беленер вакытта гына Мансур Ибраһимович, изрәп, тыныч йокыга талды. Гөлкәй урындыгын укытучының баш очына ук китереп куйды да, башын Мансур Ибраһимовичның башына терәп, аның сулышын тойган хәлдә, күзләрен йомды...

...Мансур Ибраһимович гаҗәеп бер хис белән уянып китте. Тәне бераз авырта, әмма кичәге кебек кыйнап ташлагандай түгел инде. Кул-аяклары да үзенә буйсыналар. Үзе янында кемдер утыруын шәйләп, башын шул якка борды. Борынына татлы хуш ис килеп бәрелде. Янәшәдә генә мендәргә таралган кара чәчләрдән аңкый иде бу ис. Мансур Ибраһимович, кулын күтәреп, әлеге кара чәчләрне сыйпады. Шул ук мизгелдә мендәрдән Гөлкәйнең бераз агарынган йөзе күтәрелде.

– Мансур Ибраһимович! Уяндыгызмы?! Аллага шөкер! Үзегезне ничек хис итәсез?!

Кызның иреннәрендә, күзләрендә тыенкы оялчан ел-

маю балкый. Мансур Ибраһимович кичә булган хәлләрне исенә төшерергә тырышты. Әйе, Гөлкәй аңа шалтыраткан, дус кызы белән өенә килгән иде шул. Үләннәр алып килгән иде. Мансур Ибраһимович, көчкә басып торуына карамастан, аларны көтеп алды, чөнки Гөлкәйгә бирәр хәл булгандыр дип уйлады. Юк, кыз аның өчен борчылып килгән икән...

– Гөлкәй... Сез әллә монда утырдыгызмы?! Төн буенамы?!

Гөлкәй елмайды, чәчләрен төзәткәләде.

– Хәзер барысы да әйбәт, Мансур Ибраһимович. Кичә сезнең температурагыз бик югары иде. Саташтыгыз. Шуңа сезне калдырып китә алмадым.

Алай икән... Мансур Ибраһимович көрсенеп куйды, башын чайкады.

– Гафу итегез, Гөлкәй. Сезгә уңайсызлык тудырганмын.

– Юк, юк! Бернинди дә уңайсызлык булмады. Киресенчә...

Гөлкәй тотлыгып калды, кызарып чыкты. Мансур Ибраһимович аның менә шулай самими кызаруын бик ошата иде. Дәрес вакытында да кызара ул, кайчак бер сәбәпсезгә дә кызарып утыра...

– Мин-иртән иртүк-үлән чәйләре ясадым, хәзер алып керәм.

Кыз тиз генә бүлмәдән чыгып китте. Мансур Ибраһимович караватыннан күтәрелә башлаган гына иде, башы әйләнүгә түзә алмыйча, чак егылып төшмәде. Хәле юк икән. Күрәсең, кичә хәлләре мөшкел булган... Әгәр бу кыз булмаса, нишләгән булыр иде икән ул?! Розалия... Үз хатыны исән-сау була торып, ятлар кулына кал инде... Мансур Ибраһимович, бу турыда уйларга теләмәгәндәй, күзләрен йомды. Ә уйлар, күч аерган бал кортларыдай, шунда ук башын сырып алдылар...

...Бәла көттереп килми, диләр иде, Мансур Ибраһимович моңа шушы көннәрдә генә ышанды. Аның тыныч, расписаниегә салынган тормышы берничә сәгать эчендә умарта күчедәй тузгыды. Көннәрнең берендә эштән кайтуга аны өстәлдә язу көтә булып чыкты. Розалия язган. Мансур Ибраһимович кәгазьне укып чыкты да берни аңламады. Әллә ышанмадымы?! Ничек булса да, кабат-кабат укыды. Аңлаганчыга кадәр, һәрбер сүз баш миенә кереп, үз урынын тапканчыга кадәр.

*«Мансур! Сиңа шушы хатны калдыруыма гаҗәпләнмә. Үзеңә, күзләреңә карап кирәкле сүзләрне әйтә алмас идем. Мин синнән китәм. Башка кайтмаска китәм.*

*Без Хәйдәр белән бергә яшәргә килештек. Син аны беләсең. Без күптән дуслар, моңарчы сиңа әйтә алмый йөрдем. Балалар әлегә әниләрдә яшәп торырлар. Мине эзләмә. Хуш!*

*P.S. Булдыра алсаң, кичер. Син әле үз бәхетеңне табарсың».*

Хатның эчтәлеге аңына барып җитү белән, Мансур Ибраһимович нишләргә белми миңгерәеп калды. Ничек инде «китәм»?! Ни сәбәпле?! Ун ел гомер иттеләр алар, юньләп кычкырышканнары да булмады лабаса. Балалар үстерделәр. Ничек инде китәргә мөмкин?! Дөрес, алай мөкиббән китеп бер-берсен яратмадылар, әмма тыныч яшәделәр бит! Розалиянең эти-әниләре ризалыгы белән өйләнештеләр, Розалия үзе дә каршы түгел иде кебек. Мансур беркайчан Розалиягә хыянәт итмәде. Нәрсә җитмәде икән бу хатын-кызга?! Нишләп балалары турында уйламаган ул?! Үз этиләре барында үги эти белән үстерергә ничек йөрәге җитә аның?! Хәйдәр... Ух, оятсыз. Дус булып, гаиләгә керде, Мансурның ипи-тозын ашады. Һәм... хатынын да алып киткән. Әлеге мизгелдә Мансур Ибраһимовичка Хәйдәр очраса, өзгәләп атар иде. Кайдан эзләргә инде бу хаиннарны?!

...Юк, өзгәли алмады аларны Мансур Ибраһимович. Хатынын эзләп тапты, әлбәттә, тик күзләрендә моңарчы чалынмаган, эзе дә булмаган нindidер очкын күрде. Йөрешендә җиңеллек, керфек очларында сөю күрде. Бәхетле иде хатыны, аңардан китүе белән бәхетле иде... Мансур Ибраһимович Розалиягә бары бер генә сорау бирде: «Балаларны нишләтәбез?!» Розалия җавапсыз баш чайкады. Белми ул, белми... уйламаган. Килешенмәгән. Ә балалар бит кечкенә түгел, барысын да аңларлык яшьтә.

...Ул көнне Мансур Ибраһимович озак итеп шәһәр урамнары буенча йөрде. Бернәрсәгә исе китми, аяклары тыңлаган якка барды да барды. Караңгы төшкәнчегә кадәр шулай иләсләнеп йөрде. Апрельнең салкын җиле үзәгенә үтте, юка пальтосын өзгәләрдәй булып тырмады. Дөньяның барлык давыллары килеп тырмаса да, Мансур Ибраһимовичның исе китмәс иде. Күңел давыллары күпкә гайрәтлерәк. Менә уты яндырылмаган салкын квартирасына кайтты, өстен дә алыштырмыйча, залга үтте, стенкадагы бардан каты коньяк чыгарды. Мансур Ибраһимовичның аракы белән дуслыгы юк иде. Ә бүген аңа бары аракы гына ярдәм итә алырдай тоелды. Икенче көнне иртән төбенә кадәр бушаган шешәне күреп имәнеп китте. Ярый әле иртәнге сәгатьтә үк дәресләре юк. Төшкә кадәр йоклап, бераз айныгач, эшенә юнәлде. Кичен тагы

шул ук хәл кабатланды. Шул ук шәһәр буйлап кросс, аннан ялгыз мәҗлес... Юк, ялгыз түгел икән, күңел давыллары иптәшкә өермәләрне алып килде. Юк, үлгәндә дә балаларны бирмәячәк ул Хәйдәргә! Аның балалары ул, аныкы! Халык судында гына түгел, дөнья судына куйсалар да, балаларын бирмәячәк! Ничек аңламый Розалия шуны! Берьюлы ике куян атып булмый. Имеш, балалар да, яңа ир дә – барысы да аныкы гына икән. Ә Мансур Ибраһимовичка нәрсә кала?! Ялгыз иргә нәрсә кала?! Үскәч, балалары: «Әти, нигә безне үги әтигә бирдең?» – дип килеп сорасалар, нәрсә әйтер ул аларга?! Юк, үлгәндә дә балаларын ятка бирмәячәк!

...Өченче көнне дә шул давыллы-өермәле аракы галәмәтенә кереп баткач, Мансур Ибраһимович тозакка эләккәнен чамалады. Тик карышырлык ихтыяры калмаган иде. Юк, балаларын беркайчан да аңа бирмәячәкләр... Судьялар белән киңәште ул. Өмет аз, диделәр, бары Розалия үзе риза булса гына. Суд һәрвакыт балаларны әниләре белән калдыра. Бу – язылмаган закон. Әти кеше балаларны начар карый дип кем әйткән?! Кем?! Җавап бары шешә төбендә генә табылыр сыман тоелды...

...Гөлкәй шалтыратканда да, чираттагы шешәне ачарга тора иде ул. Кыз киләсен белгәч, кулы бармады. Болай да көне буе урамда йөреп талчыккан, бөтен гәүдәсе, тәне, сөякләре сызлый, башы гөжләп авырта. Бүген дәресен дә җүнләп укыта алмады, университетка шалтыратып, авырып китүен әйтте.囗штә ни булганын инде беләләр иде – Хәйдәр белән бер кафедрада эшли ләбаса. Ялгызы гына үлеп китсә дә, берни булмас кебек иде...

...Гөлкәй тагы Укытучының йөзендә кара күләгәләр йөгерешүен күрде. Әгәр Мансур Ибраһимович үзе терелергә теләмәсә, Гөлкәй дә, аның үләннәре дә авыру алдында көчсез. Барысы да аның үзеннән генә тора.

– Мансур Ибраһимович, менә шушы дару үләне суын эчеп җибәрегез, зинһар.

– Гөлкәй, сез бит дәрестә булырга тиешле! Минем аркада дәресләрегезне калдырдыгызмы?!

Гөлкәй, җитдиләнеп, Мансур Ибраһимовичка күтәрелеп карады. Нәрсә дисен инде? Калдырды һәм калдырачак. Тик моңа укытучы беркайчан да риза булмас, хәзер үк өеннән куып чыгармаса ярый инде.

– Мин бит бары бер-ике көн генә, Мансур Ибраһимович. Сез терелгәнче генә. Хатыныгыз кайткач, мин китәрмен. Бәлки, аңа сезнең авыруыгыз турында хәбәр итәргә кирәктер?!

Мансур Ибраһимовичка тагы кыен булып китте. Күңе-

лендәге авыр хисне кем беләндер бүлешәсе килә иде. Тик Гөлкәй белән генә түгел...

– Әйе, әлбәттә... Мин шалтыратырмын. Тик әле ул тиз генә кайтмас, аннары юк белән борчыйсым да килми. ...Кунакта, еракта ул. Ә менә сезнең дәрес калдыруыгыз әйбәт булмаган.

– Бүген дәресләр бетте инде, мин иртәгә барырмын.

Гөлкәй кулындагы чынаякны Мансур Ибраһимовичка сузды. Ачы дару, бигрәк ачы... Тормыш ачысы диярсең. Тик дару ачысы – дәвалый, ә тормыш ачысы яралый гына.

– Мансур Ибраһимович, сезнең ашыйсыгыз да килә торгандыр. Әгәр теләсәгез, мин чәй эчәргә тиз генә коймак-фәлән әвәләп алам?! Аннан аш куярмын.

Мансур Ибраһимович башын чайкады.

– Юк, Гөлкәй, рәхмәт. Бер валчык та кабасым килми. Менә чәй эчсәм була.

Гөлкәй урыныннан ук сикереп торды.

– Ай, онытып торам лабаса! Кайнагандыр, чәй куйган идем инде. Хәзер чәй ясап кертәм.

Гөлкәй кабаланып чыгып китте. Ул арада Мансур Ибраһимович тагы торырга теләп урыныннан күтәрелде, тагы башы әйләнде. Бу юлы алай зыянлы түгел бугай. Гомумән, авырып урын өстендә ята торган кеше түгел ләбаса ул, бүген әллә нишләгән... Гөлкәй алдында ялангач ятуы да уңайсыз, шуңа урындык артына эленгән юкарак футболкасын, өй чалбарын алып киде, аякларын салындырып, караватка утырды. Юк, басып ук булмас, ахры. Йә егылып китәр. Аннары ничектер үзең турында кайгыртучы барын тою рәхәт иде, гел шулай җылылыкны тоеп, сизеп ятасы гына килә иде. Әллә ничек яшәделәр алар Розалия белән: һәркайсысы үзенчә, үзе теләгәнчә, бер-берсенең эшләренә катышмадылар, хәтта бер-берсе турында кайгыртмаганнар да икән... Мансур Ибраһимович хәзер генә үзенең гаебен аңлый башлады. Яраттымы соң ул Розалияне?! Әллә эти-әнисе профессор булган өчен, кеше арасына чыгу өчен генә өйләндеме икән?! Яратты кебек... Һәрхәлдә, өйләнеп бераз вакыт узгач, «хатыннан уңдым» дип шатланды. Розалия өс киемнәре тегү салонында дизайнер-модельер булып эшли, зәвыклы, матур киенә, төсе-гәүдәсе дә бик килешле, күркәм иде. Хәтта балалар тапкач та, яшь кызлардай, матурлыгын саклап калды. Әйе шул, ир-ат күзе төшәрлек. Нишләп бу турыда элегрәк уйланылмаган да нишләп көнчелек хисе күңелгә кереп тә карамаган?! Күрәсең, хатын-кызны әзрәк көнләп алу да кирәк булгандыр, үзенең

яратуын, мәхәббәтен дә күрсәтергә кирәк булгандыр. Алай дисәң, бәйрәм саен чәчәк бүләк итә торган иде инде, кинотеатрларга да, ресторmanagers да баргалаштырдылар. Тик профессор гаиләсендә үскән кызга нәрсә ул чәчәк... Мансур Ибраһимович үзе дә имтихан саен җыеп кайта ул чәчәкне. Әйе, мондый гаиләдә чәчәкнең кадере юк. Барган спектакльләре, кинолары, опера-балетлары кечкенәдән үк каралып, ятланып беткән. Алайса, нәрсә эшләргә кирәк иде икән?! Мансур Ибраһимович хатын-кызга матур сүзләр сөйли белми, мондый сүзләрне ялагайлану дип кабул итә. Коры шул син, иптәш доцент... Агач тел. Бүрәнә тел. Соң инде, соң...

...Подностагы чынаякларын шалтыратып, май кояшыдай елмайган Гөлкәй килеп керде. Чәчләрен баш тирәли урап куйган. Йөзе бераз агарган, элеккеге кебек алсуланып тормый. Йокламагангадыр инде. Кайсы ягы беләндер әнисенә охшаган шикелле. Әгәр барысы да яхшы тәмамланса, быел Мансур Ибраһимович эти-әнисенең каберенә кайтып киләчәк. Ул нәзер әйтте. Гөлкәй подносын тумбочкага куйды, куе итеп ясалган чәйне Укытучыга табарак шудырды.

– Торуыгыз бик әйбәт булган, Мансур Ибраһимович. Әби әйтә иде, яткан сырхау гел ята ул, торганы бәрәкәтле, ди иде. Тик өзлегергә генә ярамый сезгә. Менә каен җиләге кайнатмасы белән эчегез әле чәегезне.

Мансур Ибраһимович ел буе чәйсез торган кешедәй, рәттән өч чынаяк чәй эчте, тирләде-пеште. Йөзләре алсуланып китте, тазара баруы күз алдында иде. Гөлкәйнең шатлыгының чиге булмады. Шулай да күңелендә кире хис тә кымырҗып куйды. Мансур Ибраһимович терелсә, ул кире тулай торакка кайтып китәчәк...

Ниһаять, Мансур Ибраһимович яңадан юрганына төренеп ятты. Гөлкәй аның баш очындагы мендәрне күтәртебрәк, рәтләп куйды. Укытучы күптән тел очында торган соравын бирде:

– Гөлкәй, ә сез минем авырганны каян белдегез?!

Гөлкәй бер мизгелгә аптырап китте, бит урталары тагы алланып чыкты. Паркта күрде микән әллә?! Алай булырга тиеш түгел иде кебек...

– Сезнең дәресне тыңлаганда авырганыгызны чамаладым. Дәрестә сез элекке кебек сөйләмәдегез.

Әйе шул, Мансур Ибраһимович моны үзе дә белде. Буталып бетте ул, җөмләләрен дә рәтсез-чиратсыз төзеде. Аракы чоңгылына кереп баткан иде... Студентлар сизмәгән булса ярый инде. Оятын кая куярсың... Ә чоңгылдан тартып алучы шушы кыз бит. Шушы кыз аны

тормышы турында уйланырга, ялгышларын күрергә ярдәм итә. Абыйсына ул кызга күз-колак булырга вәгъдә биргән иде. Чынлыкта исә киресенчә килеп чыкты.

Мансур Ибраһимович, үрелеп, Гөлкәйнең кулларын үзенең учына алды.

– Гөлкәй! Мин сезгә бик рәхмәтле. Сез мине... зур ялгыштан коткарасыз.

Укытучы йомшак кулларны бер-бер артлы иреннәренә китерде, ихлас күңелдән үпте. Җылы, назлы куллар. Хатын-кыз куллары. Кара, шулай кулны кулга алудан да ниндидер татлы хис туар икән! Мансур Ибраһимович тәне буйлап кайнар дулкын таралганын сизде, күңел түрендә нәрсәдер кымырҗып куйды. Розалиянең куллары мондый түгел иде шикелле. Юк, алар һәрвакыт салкын иде. Һәм бернинди хис уятмыйлар иде кебек. Ләкин Мансур Ибраһимович һәрвакыт Розалияне тели иде, аны көтеп ала иде... Мансур Ибраһимовичның тормышында бер генә хатын-кыз булды – Розалия генә. Әллә мәхәббәтнең нәрсә икәнен белмәде микән ул?!

Гөлкәй исә кулларын тартып алмады. Аның китаплардан укыганы бар – мондый очракта кызлар кулларын, һичшиксез, тартып алырга, үзләре йөгереп чыгып китәргә тиешләр. Ә аның алай итәсе килми. Киресенчә, ул бу халәтнең дәвамын көтә. Дәвамы булырга тиеш бу назның, булырга тиеш! Күңел сорый, көтә, таләп итә!..

Мансур Ибраһимович та үзенең арттырып җибәргәнен аңлап алды. Гөлкәйнең әллә ни уйлавы бар... Ул бит бары рәхмәт йөзеннән генә кызның кулын үпте. Бары рәхмәт йөзеннән генә.

– Рәхмәт, Гөлкәй! Чын күңелдән рәхмәт сезгә.

Гөлкәй чыннан да кыенсынып куйды. Мансур Ибраһимович аңа балага карагандай карый иде. Мансур Ибраһимович аңарда хатын-кызны күрми. Бу – коточкыч...

Бераздан Гөлкәй суыткычтан тавык ите табып, аш куйды, үзе дә чәй ясап эчте. Эшенә барырга кирәк. Тик Мансур Ибраһимовичның берьялгызын калдырып китәргә курка. Аш бүлмәсендә чүп чиләге артына тезеп куелган бушаган шешәләрне күреп, Гөлкәй шаккатты... Кичә күрмәгән иде. Мансур Ибраһимовичмы?! Шул хәлгә төшкәнме?! Гөлкәй белә: ир-ат шешәгә болай кинәт бары чарасызлыктан, тормышка, үз-үзенә ышанычын югалтканда гына баш ия. Абыйсы белән дә шундый хәл булып алды. Әфган сугышыннан соң тыныч тормышта үз-үзен таба алмый интекте. Абыйсын упкыннан этисенең үлеме, энисенең ялгызлыгы тартып алды. Ә Мансур Ибраһимовичка нәрсә булган?! Кайда аның хатыны, балалары?!

Мондый авыр хәлдә алар Мансур Ибраһимович янында булырга тиеш бит...

...Ярый әле китап бирүче Рәйхана апа киң күңелле, эчкерсез кеше. Мансур Ибраһимовичтан рөхсәт алып, Гөлкәй эшенә шалтыратты, зинһарлап сорады, «авырыйм, бүген тагы килә алмыйм, иртәгә киләм» диде. Рәйхана апа идәннәрне үзе юып кайтырга булды. Ниһаять, кызның күңеле тынычланып калды, аш бүлмәсендә авыз эченнән генә көйли-көйли, тавык шулпасына токмач басарга кереште...

Мансур Ибраһимович һаман да үз тормышы, соңгы вакыйгалар хакында уйланып ята иде. Кайчан гына әле ул Казанга килде, университетның тарих факультетына укырга керде, аны кызыл дипломга тәмамлаганнан соң, фәлсәфә кафедрасына аспирантурага чакырдылар... Шуннан соңгы тормышы бары бер омтылышка – зур кеше булу, профессор булуга гына корылган икән. Хәтта Розалиягә өйләнү дә нигездә шуның өчен булган, хәзер Мансур Ибраһимович моны таный... Янәсе, профессор кызы – этисе киявен юкка чыгармас, үстерер... Үзенең тормышын гына түгел, Розалиянекен дә җимергән, ничек шуны аңламаган ул! Ә Розалия нишләп аңа кияүгә чыкты икән? Нишләп аның шушындый эчке ямьсезлеген күрә алмаган? Хәер, Мансур Ибраһимович кебек икейөзлеләр күп булмагандыр, югыйсә үз тиңен сайлап алыр иде. Ә ул үзе көчсез, характерсыз, җегәрсез икән... Аракыга ябышуын кара инде син аның. Дөрес, беренче көнне аракы чыннан да күңеленә җиңеллек бирде, кайгы бераз таралып киткәндәй булды. Розалиягә ачуы басыла төште, үзен дә алай битәрләүдән туктады. Тик икенче көнне бу халәтне, бу җиңеллекне күпме генә кайтарырга теләсә дә, булмады. Яңадан Розалиягә, Хәйдәргә, тормышка ачуы кабарды, үзен алардан өстен куйды. Егылганчы эчкән аракы барыбер күңел давылларын басмады. Өченче көнне исә алдагы шешәне бушаткач, үзен бик кызганды, өстәлгә башын куеп, сулыгып-сулыгып елады, үз тормышы, үз язмышы дөньяда иң кызганыч булып күренде. Аннан да бәхетсезрәк кеше юк иде. Калган көннәрдә әлеге хисләр бер кич дәвамында ук кабатлана башлады. Менә ул җиңеллек эзли, юк, таба алмый; тагы эчә, ачуы кабара, кемнедер тукмап атасы килә; бераздан бу халәт тә үтә, үзгәрә, тагы аракы дозасы кирәк була, аннан үз-үзен кызгана башлый, күзләреннән яшьләр коела, сулкылдый... Һәм өстәлгә башын салган килеш йоклап китә. Иртән эшкә барасы булса, бераз салмый чыгып китү мөмкин түгел – баш әйләнә, бу кирәкмәгән башны кисеп атасылары килә,

күңеле болгана. Тирә-як томанга күмелә. Эшенә ничек барыр, коллегалары алдында ничек күзләрен күтәреп карар... Ничек укытыр ул! Тик салып куйган «йөз грамм» гына хәлне яхшыртып җибәрә...

Мансур Ибраһимович авыр сулап куйды. Нишләп эшендә аңа беркем бер сүз әйтмәде, нишләп «Мансур, тукта, тыел!» дип киңәш бирмәде?! Барысы да ят кешеләр шул. Кешенең кешедә эше юк. Бәлки, кемдер шатлангандыр да әле. Галим кешеләр арасында көнләшү, хөсетлек кара елан булып ята. Хәер, алай дисәң, бу көннәрдә ул кафедрада бик күренмәскә тырышты. Студентлар гына сизеп алганнардыр инде. Әнә Гөлкәй дә «авырганыгызны сиздем» диде. Бу дөньяда аның турында кайгыртучы бердәнбер кеше ул. Әгәр ул булмаса, кичләрен ялгызы күбенгәнче эчә торган «тыныч алкоголик»ка әйләнгән булыр иде...

Үзе турында уйлаганны сизгәндәй, бүлмә ишеген шакып, Гөлкәй килеп керде.

– Мансур Ибраһимович, сезгә кайнар шулпа ашарга кирәк. – Кызның үзеннән үк тәмле аш исе аңкый. – Мин монда алып кермәдем, әгәр мөмкин булса, торып карагыз әле.

Үзе Укытучыга урыныннан күтәрелергә ярдәм итте, бу юлы ир-ат, чыннан да, үзендә беркадәр көч сизде. Һәрхәлдә, кичәге кебек түгел инде. Әкрен генә кымшанып, аякларына торып басты, бер яктан Гөлкәйнең ярдәме белән, икенче яктан стеналарга тотына-тотына, аш бүлмәсенә чыкты, киң артлы утыргычка утырды. Үзенең шушындый мескен халәтен аңлап, ачы итеп, ирония белән елмайды.

– Агуланганмын, ахры, мин, Гөлкәй, – дип куйды. – Син аңлагансыңдыр инде.

Гөлкәй, ниһаять, күптән көткән «син»не ишетте. Якын кешегә генә өлкәннәр шулай дәшәләр. Якын кешегә генә, бик сирәк очракта гына шулай әйтәсе килмәгән серне әйтеп була. Димәк, Мансур Ибраһимович аны якын күрә. Нинди бәхет!

– Борчылмагыз, Мансур Ибраһимович. Сез көчле кеше, бу авыруны гына җиңә аласыз. Мин сезгә ышанам.

Менә шулай гади генә әйтте. «Мин ышанам» диде. Ләкин артка чигенмәслек итеп, каршы килмәслек итеп әйтте...

...Аштан соң Мансур Ибраһимовичның тагы хәле киткән кебек булса да, ятасы килмәде, зал ягына чыгып, кәнәфигә утырды, кулына гәзит алды, озын аяклы лампаны кабызды. Студент кына булуга карамастан, Гөлкәй

алдында аңа читен, хәтта читен генә дә түгел, ә куркыныч иде. Күңеленең кайсыдыр өлеше кызның тизрәк чыгып киткәнен көтә, ә икенче ягы исә, кыз кайтып китсә, тагы чоңгылга батуыннан курка... Әгәр бу студентка аның өстеннән әләкләп йөрсә, әгәр «алкаш» дигән исемен таратса?! Әгәр кыз икейөзле булып чыкса?! Юк, ул моңа ышана алмый. Бу зур кара күзләрдә ниндидер җылылык, якынлык бар кебек. Әгәр Гөлкәйгә дә ышанмаса, бу тормышта кемгә генә ышана ала соң ул?! Сөекле хатыны якын дусты белән хыянәт иткән бер вакытта аңа кешеләргә ышанычны саклап калу бик кирәк... Шуңа күрә китәргәме, китмәскәме икәнен сайлауны Мансур Ибраһимович Гөлкәйнең үз иркенә куйды.

...Савыт-сабаларны юып кергәч, Гөлкәй залда утырган Мансур Ибраһимовичны күреп шатланып китте. Димәк, укытучының хәле күзгә күренеп яхшыра. Ә аңа тулай торакка кайтып китәргә вакыт җитә... Ә китәсе килми. Эгоист ул Гөлкәй. Үзе турында гына уйлый.

Мансур Ибраһимович аңа каршыдагы кәнәфидән урын күрсәтте.

– Гөлкәй, күптән сорыйсым килә иде: сез болай саф татарча итеп сөйләшергә кемнән өйрәндегез? Хәтта Себер ягыннан икәнегезне чамалап та булмый.

Гөлкәй кыенсынып кына укытучы каршына барып утырды, сөйләве авыр истәлекләрне кузгаткандай, беркадәр моңсу итеп елмайды.

– Әти өйрәтте. Әби дә. Барысы да инде. Безнең гаиләдә бары саф татарча гына сөйләшкәннәр, элек-электән үк. Бу – бозарга ярамаган кагыйдә.

– Ә авыл кешеләре белән ничек аралаша идегез?!

– Авылда авылча. – Гөлкәй көлемсерәп куйды. – «Мин әйтәйен, песнеңке Себер татарларыныңкы тел шондай куй, пестә «чык» теймиләр, пестә «цык» тейләр куй. Нейцек тейсәләр тә, пес пелмәс элек нәчек полганын»[1].

Мансур Ибраһимович та көлемсерәде. Аның күңелгә ятышлы әлеге «цыкылдау»ны ишетмәгәненә күпме вакыт үткән инде... Күпме вакыт. Хәтта ул үзе Гөлкәй кебек алай җиңел сөйләшә алмый. Розалиянең дә, үзенең дә татарчасы кайчак бозылып китә, оялырлык дәрәҗәдә бозыла...

– Әйе... Ә мин сезнең әтиегезнең егет чагын хәтерлим. Безнең авылга алар концерт куярга килгәлиләр иде. Әти-

[1] «Мин әйтәм, безнең Себер татарларының теле шундый ки, бездә «чык» димиләр, бездә «цык» диләр ки. Ничек итеп әйтсәләр дә, без элек ничек булганын белмибез» (Себер татарлары сөйләшеннән).

егез гармунчы булып истә калган. Бик оста уйный иде, безнең авылның бөтен кызлары гашыйк иде үзенә.

– Әни – җырчы. Абый да баянда уйный.

– Алайса, сездә дә бу талант бардыр дип уйлыйм?!

Гөлкәй бераз кыенсынып баш какты.

– Әйе инде... Мин дә бераз җырлыйм.

Мансур Ибраһимовичның күзләре очкынланып китте, тураебрак утырды.

– Гөлкәй, мөмкин булса, җырлагыз әле, ә?! Үзебезчә итеп?

Гөлкәй артык ялындырмады, кулында кәнәфи өстенә япкан җәймәнең бер читен әвәли-әвәли, башын бераз югарырак күтәреп, күкрәктән чыккан матур тавыш белән җыр сузды. Бик моңлы итеп, сузып, үзләренең авылларында яратып җырлана торган «Утырдым көймәнең түренә» көен җырлады.

Утырдым көймәнең түренә,
Карап иштем сыуның төбенә.
Сыу төпкәйләрендә ич кара йук,
Аллам язган эшкә цара йук.
Сайрама ла гәккүк ай гаршымта,
Сайра сана агац пашында.
Син сайрасаң да ла мин моңланам,
Төрле гайгы-хәсрәт башымта.
Ай цылтыр ла цылтыр ней цылтыртай,
Тургавайлар[1] төшкән өй мәллә.
Кулларында гуцлы[2] ай пирцәткә,
Бик партавай йөргән ир мәллә...
Туп-туп гына паскан туратымның
Тубыгынта яшел туты бар.
Төшмәсең лә күзең матур ярга,
Гомереңтә сүнмәс уты бар...

...Моң. Үзәк өзгеч моң. Моңнан туган ялгызлык. Ләкин бу хис йөрәкне авырттырмый, мондый хистән йөрәк башкачарак сулкылдый, башкачарак әрни, ниндидер йомшак элпәгә, өрфиягә төренгәндәй, әрнешүе йолдызлар җемелдәве кебек, талгын һәм тыныч... Бу хистән, качып, урамга чыгып йөгерәсе килми, бу хис ярсытмый, дулатмый, бәгырьне таламый. Моңнан туган ялгызлык хисе тамырлар буенча әкрен генә канга тарала, җелеккә үтеп керә, аңга тоташа. Менә шунда гына әлеге ялгызлыкның Ходай тарафыннан бирелгәнлеге, үзгәртеп булмаслыгы, кире кайтмаслыгы ачыклана. Шунда гына акыл Алла әмеренә тулысынча буйсына...

---

[1] Тургавайлар – сәүдәгәрләр.
[2] Гуцлы – куначлы.

...Гөлкәй җырлап бетергәннән соң да, Мансур Ибраһимович, каядыр тәрәзәгә текәлгән килеш, шактый вакыт дәшмичә утырды. Ниләр кичкәндер Укытучы күңеленнән – Гөлкәй аңламады. Хәер, теләмәде дә. Йомшак кәнәфигә чумган килеш, үзе дә хыялында туган якларына кайтып килде, әнисен, әтисен искә алды. Әтисе, мәрхүм, җырга-уенга бик оста, ә әнисе бик матур җырласа да, сәхнәгә үк менәргә ояла, тарткалаша иде. Әтисе барыбер аны сәхнәдә җырларга күндерә алмады. Урыны оҗмахта булсын...

– Рәхмәт, Гөлкәй.

Мансур Ибраһимович авыр сулап куйды, ләкин карашы яктыра, күз төбендәге җыерчыклар тарала төшкәндәй тоелды Гөлкәйгә. Әгәр Гөлкәйнең җырлавы Укытучыга ярдәм итсә, ул көне буе, төне буе җырлап утырырга әзер...

– Гөлкәй, сезнең бабагызга без «мулла бабай» дип дәшә идек. Ул чыннан да указлы мулла булганмы?

Гөлкәй сискәнеп китте. Гомумән, мулла турында, мәчет турында сүз чыкса, аңа каяндыр куркыныч яныйдыр төсле, бик ерактан, сабый чактан әнисенең яшьләнеп беткән күзләре, әбисенең куркынган йөзе килеп баса, үзен, якыннарын яклау, саклау хисе өскә бәреп чыга. Шуңа күрә хәзер дә Мансур Ибраһимовичка бик теләми генә, көрсенеп җавап бирде.

– Бик озак тарих инде ул, Мансур Ибраһимович. Әгәр теләсәгез, мин сөйләрмен, тик... кешегә белдерерсез дип куркам.

Мансур Ибраһимович, бераз үпкәләгән кыяфәт белән:

– Син нәрсә инде, Гөлкәй, – дип куйды. – Алай сөйләргә куркыныч булса, сөйләмә. Болай гына соравым.

Кыз тагы көрсенеп алды.

– Юк, куркыныч түгел. Тик безнең гаиләгә насыйп булган авырлыклар нәкъ менә шулай сөйләнеп йөрүләрдән башланган диләр. Мин сезгә ышанам.

Гөлкәй бу кичне инде икенче тапкыр «мин сезгә ышанам» диде. Чыннан да, башка якташларына караганда, Мансур Ибраһимовичка бу кыз белән сөйләшүе җиңелрәк икән. Юк, ышанычлырак бугай...

– Минем бабайның этиләре Казан арты авылларының берсендә яхшы хәлле крестьян булганнар. Үзләренең, артык зур булмаса да, җир биләмәсе, каралты-кура, хайван-терлекләре булган. Бабайның ике абыйсы исә указлы мулла, ә аларның бабалары хәтта ишан дәрәҗәсендәге кеше булган дип сөйлиләр иде. Аларын мин бик яхшы белмим. Һәрхәлдә, нәселебез дини булгандыр инде, чөнки

безнең бабай этине дә намаз укырга өйрәткән, киленне дә бик сайлап, намаз укый белә торганны гына яучылаганнар. Утызынчы елларда бабайны туган җирләреннән Себергә сөргәннәр. Әти әле сабый бала гына булган. Шуннан Себергә, кечкенәрәк бер авылга килеп төпләнгәннәр. Үзегез беләсез, безнең авыл юл өстеннән бераз читтәрәк, аулактарак бит, күрәсең, алай артык килеп борчучы да булмагандыр инде. Сугыштан исән-сау кайтып, бераз яшәгәннән соң, бабай урман эченәрәк, бераз качырып, мәчет салган, үзе үк мулла вазифасын да башкара торган булган. Аннан этине дә шул һөнәргә өйрәткән. Авыл халкы мәчеткә йөргән, гореф-гадәтне саклаган. Безнең авылда элек авыл советы булмаган, чөнки авыл бик кечкенә. Миңа сигез-тугыз яшьләр булгандыр, бездә дә авыл советы оешты.Ерактан килгән ниндидер элеккеге бер түрәне авыл советы секретаре итеп билгеләп куйдылар. Менә шуңа мәчет турында кемдер әйткән, янәсе, үз кеше итеп, якын күреп әйткәннәрдер инде. Икенче көнне үк килеп бабайны, этине һәм тагы берничә картны кулга алдылар, «коммунист була торып, халыкка агу тараткашнар» диделәр. Мәчетне халык күз алдында җимерделәр. Бабай төрмәдә үлеп китте, этине ике ел утырганнан соң гына чыгардылар...

– Ә бабаң да, этиең дә ничек коммунист булдылар икән соң?

– Бабайны сугышта коммунист итеп язганнар, ә эти комсомолдан соң үзе теләп коммунистлыкка алынгандыр. Мәчеткә йөрүләре күңел өчен булгандыр инде. Берсе икенчесенә комачауламый иде ич. Эти, мәсәлән, сәхнәдә уйный, җырлый, бии иде, шул ук вакытта мәчеткә барып җомга намазы да укый иде. Бабайга бу җырбию бик ошамаса да, алай кычкырышканнарын хәтерләмим.

Мансур Ибраһимович Гөлкәйнең самимилегенә шаккатты. Яшь әле, аңламый... Бу авылдагы мәчет турында ул вакытта бөтен тирә-як шаулады. Әлбәттә, үзәккә җиткерергә бик теләмәсәләр дә, урындагы обком секретарена шактый эләккән дип сөйләделәр. Коммунизм гөрләп торган җитмешенче еллар башында, имеш, кайсыдыр бер авылда шулай ук гөрләп мәчет эшләп ятсын әле... Мөмкинме бу!

– Әйе... Хәзер аңлашыла.

Гөлкәй, бер сөйли башлагач, туктый алмагандай дәвам итте:

– Шул вакыйгадан соң эти ничектер бик биреште, сәламәтлеге дә начарланды. Төрмәдән чыгып, биш-алты ел

гомер иткәннән соң дөнья куйды. Үләр алдыннан мине үзенә чакырып алды да: «Кызым, үз өстемдәге әманәтне сиңа калдырам. Бабаң «монда безнең нәселгә инде кадер-хөрмәт булмас, үз туган якларыбызга кайтып төпләнегез» дип, миңа әманәт әйткән иде, булдыра алмадым. Зинһар, син булса да үтә шул бурычны, нәселебездә тап булып калмасын», – дип әйтте. Менә... мин шуңа Казанда.

Гөлкәй, ниһаять, күңелендәгесен әйтеп бетерде бугай, киң сулыш алып тынып калды...

Мансур Ибраһимович хөрмәт йөзеннән бераз вакыт дәшми утырды. Аның да күңелендә әле моңарчы беркемгә дә сөйләмәгән әллә никадәр серләре, мөлдерәмә тулы ярларыннан ташырга торгандай, дөньяга чыгарга чиратка тезелгән иде. Тик Мансур Ибраһимович үзен тыйды...

– Әйдә, Гөлкәй, хәзер инде мин уйныйм, син тагы берәр җыр җырла, яме?!

Укытучы, авырсыныбрак булса да урыныннан кузгалып, стена буендагы пианино янына килеп утырды, капкачын ачып, инструмент телләре буенча бармакларын йөгертте. Бүлмә бер мәлгә Сәйдәшев моңнары белән тулды. Гөлкәй шаккатты. Әлбәттә, ул пианиноны күргән, ләкин Мансур Ибраһимович уйный белә дигән уй һич кенә дә аның башына килмәде – йә хатыны уйный, йә балаларын уйнарга өйрәтәләр дип уйлаган иде. Ялгышкан икән ләбаса...

Гөлкәйнең гаҗәпләнүе кыяфәтенә үк чыккан, күрәсең, шуңа күрә уйнаган хәлдә артына борылып караган Мансур Ибраһимовичның йөзенә елмаю кунды.

– Мин дә бераз музыкага гашыйк кеше ич, Гөлкәй. Юкка гына Төмәндә музыкаль мәктәптә укымадым... Менә бу яңа җырны беләсеңме икән?!

Мансур Ибраһимович салмак кына «Мәтрүшкәләр»не уйный башлады, берничә аккордтан соң ук аңа пианино янына килеп баскан Гөлкәй кушылды. Консерватория залларында да тавыш белән тонның бу кадәр туры килүе сирәк буладыр, валлаһи... Ә моңнар берсе артыннан берсе агылып кына торды. Аклы-каралы пианино телләреннән туган сихри авазлар йөрәккә кереп урнашкан кайгы-хәсрәт, сагыш-моңны бер җепкә тезделәр дә, киек казлар шикелле бер-берсенә тагылып, ачык калган тәрәзәдән очып чыгып киттеләр... Ике йөрәк тә сулыгып елап туйган сабыйдай бушанып, тынычланып китте, ике йөрәк тә дөньяга таң вакытында ачылган, битен чык суы белән юган чәчәк бөреседәй хушланып, сафланып калды. Әйтерсең бу йөрәкләр мәңге бергә тибәсе иде...

* * *

...Мансур Ибраһимович Гөлкәйнең зачеткасына «бик яхшы» билгесен зур итеп, күренеп торырлык итеп сырлап, матурлап куйды. Юк, аңа һич кенә дә Гөлкәй өчен кызарырга туры килмәде: кыз имтиханга бик җентекле әзерләнгән иде. Җитмәсә, дүрт бишледән соң бишенчесен куюы укытучы өчен һич кенә дә авыр түгел.

– Котлыйм сезне, Гөлкәй Салихҗановна, – диде ул, Гөлкәйнең кызаруын күрмәмешкә салынып. – Үзегезне хәзер икенче курс студенткасы итеп санасагыз да була! Уңышлар сезгә!

– Рәхмәт...

Әйе, бүген кызлар соңгы имтиханнарын тапшыралар. Иртәгә инде аларның һәркайсысын йә тузанлы автобус, йә бөркү электричка, йә булмаса чакрымнарга сузылган поезд юллары көтә... Иртәгә аларны туганнары, дуслары, эти-әниләре көтә! Гөлкәйнең дә күңеле өзелеп-өзелеп туган якларына ашкына, хәтта атна буе поезд тынчулыгына да түзәргә әзер ул! Тик тизрәк өйгә генә кайтасы иде, әнисенең йомшак куенына сарылып, өзелеп-өзелеп елыйсы иде... Гаҗәп икән бу хисләр дулкыны. Бер яктан, өзелеп авылына кайтасы килә, икенче яктан, Мансур Ибраһимовичның кара күзләреннән башка аңа авыл ник кирәк... Тик инде кайтырга дип билет алынган, сумкалар тутырылган. Шулай булгач, телиме-теләмиме, тәгәрмәчләр җырын тыңлыйсы гына кала...

– Гөлкәй, ашыкмасагыз, имтихан беткәнче калыгыз әле, зинһар. Сезгә берничә соравым бар иде.

Гөлкәй имтихан ахырын көч-хәл белән көтеп җиткерде. Мансур Ибраһимович ведомостьны, тутырып, деканатка тапшырганнан соң, коридорда басып торган Гөлкәй янына килде.

– Әйдәгез, Гөлкәй, юл уңаенда сөйләшербез.

Урамда җәй шау-шуы иде. Агачларның яшел яфракларына тузан сарылган, кояш нурлары да май аендагы кебек күзне чагылдырмый, ә нәкъ баш түбәсеннән сибелә; сусызлыктан суырылып кипкән иске асфальт тоз чыгарылган карьер кебек агарып калган. Урамда әлсерәгән автобуслар, күләгә эзләп чапкан троллейбуслар, мәрткә киткәндәй салмак трамвайлар кайнар һава дулкыннарында чайкалалар. Урамда җәй шаулый... Гөлкәй, Укытучы белән янәшә атлаудан бәхет табып, боларның берсенә дә игътибар итми.

– Гөлкәй, быел үземнең туган якларга кайтып килергә исәп тотам бит әле. Туганнарым булмаса да, эткәм-әнкәмнең кабере анда. Гарифҗан абзыйны да күрәсе килә иде. Шуңа күрә сезгә тукталырмын дип уйлыйм. Мөмкин булырмы икән?!

Гөлкәйнең куанычыннан тыны кысылды. Мансур Ибраһимович... Гөлкәй янына кунакка килә! Гөлкәй янына!!!

– Әлбәттә, Мансур Ибраһимович.

Гөлкәй шатлыгын Укытучыдан яшерергә тырышса да, бу хисләр ташкыны кызның йөзенә бәреп чыкты, күзләреннән нур булып агылды. Мансур Ибраһимович та сизде, әлбәттә. Сизде һәм күңеле булды. Кара, якташ якташ шул инде, туган булмаса да, үзеңнеке...

– Алайса, мин сезнең авылга гына кайтырмын инде башта. Үзебездә бер туганым да калмады шул...

– Әгәр алдан хәбәр итсәгез, каршы алачакбыз, Мансур Ибраһимович. Безнең авылга кадәр бары атта гына барып җитеп була, транспорт бик йөрми.

– Алайса, мин сезнең адресыгызны язып алыйм әле.

Мансур Ибраһимович куен кесәсеннән блокнот алып, Гөлкәйнең, аның абыйсының адресын язып куйды. Кем белә бит, юл газабы – гүр газабы, дигәннәр борынгылар, кирәк булуы бар. Әлегә кайчан һәм ничек юлга чыгасын күз алдына китермәсә дә, Мансур Ибраһимович быел әти-әнисенең кабере янына барасын төгәл белә иде. Розалия белән балалары кире кайтканнан соң, аның бу теләге куерды гына...

– Син үзең кайчан кайтып китәсең, иртәгәме?

– Әйе, иртәгә үк.

– Әйберләреңне, китапларыңны калдырырга урын бармы соң?

– Тулай торакта саклау камералары эшли, кичә үк шунда төшереп куйдык.

– Билетны да алгансыңдыр инде. Поездгамы, әллә самолеткамы?

– Поездга алдым.

Менә әйтер сүзләре дә әйтелеп бетте кебек. Гөлкәйгә чаттан уңга борыласы, ә Мансур Ибраһимовичка – сулга. Сүзсез генә урам чатына килеп җиттеләр, җәяүлеләр сукмагында туктап калдылар. Мансур Ибраһимович, нәрсәдер әйтергә теләп тә әйтә алмаган кешедәй, Гөлкәйгә текәлде. Гөлкәй исә бу караш астында каушады, битләре ут

булып янып чыкты, күзләре белән искергән асфальт ташын бораулый башлады.

– Ярар, Гөлкәй, хушлашыйк алайса. Исән-сау кайтып җит, әниеңә, абыеңа, Гарифҗан абзыйга миннән сәлам әйтә тор. Хәерле юллар сиңа!

– Рәхмәт, Мансур Ибраһимович. Без сезне көтеп калабыз!

Гөлкәй борылып ике-өч адым атларга да өлгермәде, артыннан яңадан бәрхет тавыш яңгырады:

– Гөлкәй!

Мансур Ибраһимович шул ук урынында басып тора иде. Гөлкәйгә таба омтылып куйды.

– Гөлкәй...

Сораулы карашка тиз генә җавап таба алмады Укытучы. Әллә инде үзе үк кызардымы?!

– Гөлкәй. Теге вакытта... мин авырып киткәч... Сез миңа бик ярдәм иттегез. Мин бу турыда беркайчан да онытмамын. Рәхмәт сезгә!

Ә Гөлкәй әле бая гына Укытучы авызыннан яңгыраган «син»не көткән иде. Юк, рәхмәт тә, башкасы да кирәкми аңа, бары әнә шул җанга якын «син» ешрак яңгырасын иде... Тик, күрәсең, Укытучының «син»гә күчеп араны якынайтасы килми... Әллә авыру вакытын искә алу гына кыенмы икән?!

– Мансур Ибраһимович! Мин ул турыда оныттым да инде. Шулай да ... рәхмәтегезгә рәхмәт!

– Сау булыгыз, Гөлкәй.

– Сау булыгыз, Мансур Ибраһимович.

Агач ботагыннан җил белән өзелеп төшкән яфраклар сыман, икесе ике якка атладылар. Икесе ике якка: Гөлкәй – уңга, Мансур Ибраһимович – сулга...

* * *

...Күңелеңдә җыелган бөтен кайгы-хәсрәтне кемгәдер бушатасың килә, ләкин ышанычлы кеше тапмыйсыңмы?! Дөнья әхлагыннан гыйбрәт алып, «миннән дә бәхетсезрәкләр бар икән әле» дип, җаныңа юаныч табарга телисең, ләкин сиңа күңел коесын бушатырга теләүчеләр табылмыймы?! Күз яшьләреңнән оялмыйча юату сүзләре ишетәсең киләме?! Ә бәлки, кемнәндер үзеңне үтә тәҗрибәлерәк санап, дөнья бизмәнен күбрәк тартканыңны күрсәтеп, бераз масаеп аласың киләдер?! Ә син юлга чык.

Бер эшең булмаса да, дөньяның иң эшлеклесе кыяфәтенә кереп, ике-өч көнлек юлга чык. Юлчылар чишелмәслек мәсьәләләреңне бары синең каланчадан гына торып хәл итәрләр, юатырлар, ышандырырлар, көйләрләр, җайларлар... Һәм әле яңа гына Каф тавыдай күренгән проблема кырмыска өемедәй кечерәеп калыр... Бер уңайдан үзең дә кемнеңдер Каф тавы кадәр проблемасын хәл итәрсең, юатырсың, ышандырырсың, көйләрсең, җайларсың. Күңел дигән галәмең бушап, тынычланып калгач, эшне озакка сузмый, кире өеңә юл тот. Яңадан уйлан, эзлән, тап, югалт, кычкырыш, килешү төзе – ягъни яңадан яши башла...

Мансур Ибраһимович әлеге схеманың беренче этабында иде. Менә икенче тәүлек инде колаклар борынгы Греция ишкәкчеләренеке кебек үк бер ритмга тимер рельсларга бәрелгән көпчәкләр тавышына күнегеп киләләр, поезд пошкыруына да сискәнмиләр, станцияләрдәге су тутыручыларның сүгенү тавышларын кырыйдан гына үткәреп җибәрәләр. Ә юл ерак. Әле мәшһүр Урал тауларын уза гына башладылар, алда күз күреме җитмәслек тигезлекләр, сазлыклар, урманнар. Алда – күңелләрдә билгесезлек дәрьясы булып гәүдәләнгән данлы Себер. Мансур Ибраһимовичның мондый ерак юлга поездда чыгуының үзенә генә билгеле сәбәбе дә бар иде. Югыйсә Розалия һәм дуслары самолетка билет алырга күпме үгетләделәр. Юк, самолеттан караганда Урал тавының ак томаннары да, Себер сазлыклары да күңелдә биеклектән куркудан башка хис калдырмыйлар. Ә аның курку тулы күңел белән туган җир туфрагына аяк басасы килми. Аның юл өстендә Урал тауларына кадәр артыннан кул селтәп калган каен кызларына елмаясы, үзен каршылап кул сузган чыршы егетләренә баш иясе килә, аның калын купе тәрәзәләре аша да үтеп кергән туган як җиленә сәламләү сүзләре пышылдыйсы килә. Бу – аның туган туфрагы, туган җире... Әлеге «туганлык»ның чикләре кайда башланып кайда беткәнен Мансур Ибраһимович үзе дә белми. Мөгаен, көнбатышка таба соңгы кедр агачы үскән урындадыр. Тик менә поезддан төшеп, сабый чакта яшел чирәмдә тәгәрәп үскән авылына кермичә, кырыеннан узып киткәндә генә күңеле ничек түзәр... Моны Мансур Ибраһимович күз алдына китерә алмый иде.

...Поезд йөрешен әкренәйтте; күрәсең, борылмага яисә туннельгә керәләр инде. Мансур Ибраһимович уйланып яткан урыныннан торды, коридорга чыкты. Әле бик иртә,

төн белән таң тоташкан вакыт кына, шуңа вагонда йөрүчеләр күренми.Ерактагы урман башлары алсу нурга буялган. Озакламый кояш үзе дә күренер, үлән өсләренә төшкән ак болыттай чык бөртекләрен үз янына чакырып алыр... Мансур Ибраһимович поездның икелатәтелгән тәрәзә пыяласында үз шәүләсен, дөресрәге, үзенә төбәлгән үз күз карашын күреп бер мәлгә сискәнеп китте. Кара син аны, элегрәк игътибар итмәгән икән... Һәр көн иртән үзен көзге каршында күрергә өйрәнсә дә, бу юлы үз карашында ниндидер ят чалымнар шәйләде Укытучы. Нәрсәдер югалган, нәрсәдер өстәлгән кебек иде. Күңелендә дә шулай: югалтты ул, һичшиксез, нәрсәнедер югалтты... Элеккегечә тыныч, ваемсыз, үз кыйбласы, үз ышанычы, идеаллары булган тормышын югалтты сыман. Нәрсә өстәлде?! Ачу. Тупаслык. Ышанмау. Көрәш. Әйе, ул үзенең көрәшергә сәләтле икәнен аңлады: балалары өчен көрәште, хатынын ят ир кулыннан тартып алды. Хатыны кире кайтты кайтуын, тик элеккеге Мансур белән Розалияне генә кайтарып булмады. Барысы да кире кайтты: кичен бергәләп чәй эчүләр, эш турында, мәдәни тормыш турында сөйләшүләр, ял көне гаилә белән паркка чыгулар – барысы да кире кайтты... Мансур белән Розалияне кире кайтарып булмады. Күрәсең, кайтарып алырлык мәхәббәтләре булмагандыр инде... Хатынының гаепле күзләрен күрү авыр иде. Үзенең күзләре дә шундый ук гаепле иде... Кирәк идеме бу көрәш?! Мансур ышана: кирәк иде, һичшиксез кирәк иде. Беренче вакытта Розалияне иреннәреннән үбәргә тайчынса да, төннәрен күбрәк мәкалә язып үткәрсә дә, Мансур ышана: балалары мәхәббәте аның өчен иң кадерле, иң изге хис. Ата булып, гаиләле булып, балаларның мәхәббәтен тоеп яшәү, алар турында кайгыртта алу – бу кагылырга, таркатырга ярамаган, буыннан буынга тапшырыла килгән, бик сирәк ир-атта гына була ала торган изге сәләт. Мансур Ибраһимович моның өчен көрәшергә дә әзер.

– Нәрсә, йоклап булмыймы әллә? – Йөгерә-атлый узып барган вагон хуҗабикәсе, мут елмаеп, Мансур Ибраһимовичка дәште. Бу озын буйлы чибәр ир-атны хатын беренче көнне үк игътибарга алган иде. – Чәй эчәсегез килсә, минем купега керегез. Кайнар чәй белән сыйлармын үзегезне.

– Рәхмәт.

Мансур Ибраһимович, кая җитүләрен сорарга теләсә

дә, өлгермәде: җитез хатынның яшел киеме инде тамбурда чагылып калды. Ниндидер станциягә туктадылар, ахры, тышта утлары сүнеп килгән тонык лампочкалы баганалар, ике-өч катлы таш йортлар күренде, зур-зур сумкалы агай-түтиләр вагонга керә башладылар. Мансур Ибраһимович, боларның ыгы-зыгысында катнашырга теләмичә, яңадан купесына кереп ятты...

* * *

Әкрен генә искән талгын җилдә ара-тирә агач яфраклары селкенеп куя. Тирә-якта ниндидер илаһи моң, илаһи тынлык. Мансур Ибраһимовичның утыра-утыра тез башлары оеп бетте, арка умырткасы чеметкәли башлады. Тик күңелендәге әрнү хисе басылмаган иде әле. Ниһаять, ул әнисе, әтисе янында зиратта. Ике янәшә кабер буяулы тимер рәшәткәле, эскәмияле, башка каберләр янында караучысы бар икәне күренеп тора. Рәхмәтулла абзый карыйдыр инде. Бүген иртә белән зиратка килгәндә үк Мансур Ибраһимовичның күңеле тыныч түгел иде: әтиәнисенең каберен таба алмый интегеп йөрүдән, күмелгән урыннарын югалтудан бик курыкты. Ярый әле зират каравылчысы Рәхмәтулла абзый барысын да аңлады. Ерак юлдан кайтканын белгәч, «әй, мосафир икәнсең, улым» дип, шунда ук зират капкасы ачкычларын шалтыратты, ә Ибраһим улы икәнен белгәч, бөтенләй күзләре яшьләнде. «Атаң-анаң бик хөрмәтле кешеләр иде, балам, – диде ул, алдан сукмак буйлап барганда, – сине дә бер кайтырсың дип көткән идек. Апаңның вафат булуын ишеттек. Оҗмахта булсын урыннары. Менә шушында ята Ибраһим мөгаллим белән Хәлимә остазбикә...» Мансур Ибраһимович, тез буыннары калтыравын җиңеп, Рәхмәтулла карт артыннан уңга таба атлады. Карт тимер рәшәткәне ачты, Мансур Ибраһимовичка юл бирде. Әтисенең кабер ташы яңартылып, гарәп язулары өстәлгән иде. Хәер, Мансур Ибраһимович беренче мизгелдә моны күрә алмады – кисәк кенә күз аллары караңгыланып китте, йөрәге дөп-дөп бәргән хәлдә, кабер янына килеп тезләнде. «Әти!.. Әни!..» Бәгырьдән чыккан пышылдау, үзенә кайтаваз булып, колагында кат-кат яңгырады. «Киткәндә безгә дә сугылырга онытма, олан». Рәхмәтулла абзый, Мансур Ибраһимовичның үзен-үзе белештерми баш кагуын күреп, тизрәк китәргә ашыкты.

Гөлкәй тын гына зират капкасы төбендә басып тора иде. «Әйдә, кызым, атыңны тугарыйк та, бездә чәйли торырсың. – Рәхмәтулла карт пошкырынып торган ат янына килде. – Укытучың әрвахлар белән сөйләшә, китик, рәнҗемәсеннәр».

...Әй, вакыт, никләр болай тиз үтәсең дә никләр без яраткан кешеләрне үз куеныңа яшерәсең икән? Әле бит кайчан гына нәни Мансур әнисенең калын беләкләрендә иркәләнергә, этисенең әрекмән яфрагыдай каты колакларыннан тарткаларга ярата иде. Хәтта мәктәп укучысы булгач та, бик рәхәтләнеп, әнисенең куенында изрәп йокыга китә торган иде... Сигезенче класстан соң Төмәнгә укырга киткәндә исә иң газаплысы анасыннан аерылу булды. Беренче айларда әнисенең ягымлы йөзе һәр көн төшләренә кереп интектерде, төннәрен яшь малай, ана назына сусап, мендәргә яшьләрен койды. Эти-әнисенә бик тансык, олы яшьтә генә көтеп алынган, апасыннан күпкә яшь Мансур иркә, бик иркә иде. Бераздан эти-әнисез интернатта яшәү үзенекен итте, күрәсең, иркә гөлҗимешнең энәләре тырпайды. Авылын, яшьтәшләрен дә ул кадәр юксынмый башлады, унынчы класстан соң этисе Казан турында башлап авыз ачкач, берсүзсез риза булды. Этисенең яратып әйтә торган сүзе бар иде. «Ипинең валчыгын да әрәм итмәскә тырыш, улым. Белемнең бөртеген дә югалтма». Өстәмә аңлатма таләп итми торган бу сүзләр Мансур Ибраһимовичка тормыш девизы булды. Казанда тырышып укыды, ләкин читтән килгәнгә, бу мәгърур борынгы шәһәрдә туганнары да булмаганга, әлбәттә, Мансурга кыен булды. Кайчакта әнисенең ике хатына бер хат язарга да вакыт таба алмый иде. Күңеле белән иң якын кешеләренә өч сүз җиткәнен дә тоя, тик менә өч сүзне язу өчен Мансурга өч сәгать утырырга кирәк. Ничек аңламаган ул?! Кайтарып булмый торган ялгыш ясавын ничек аңламаган?! Дүртенче курста укыганда, бербер артлы эти-әнисе дөнья куйдылар. Егет этисен соңгы юлга озатса да, әнисен күмәргә кайтып җитә алмады – өч сәгатькә соңга калды. Яңа сибелгән кабер туфрагына ятып үксеп-үксеп елады, дөнья җимерелгән кебек тоелды. Этисенең үлемен авыр кичергән Мансурга әнисе дә үзен болай тиз ялгыз калдырып китәр дигән уй башына да кереп карамаган иде. Әйталмый калган, язылмый калган сүзләре – җылы сүзләре – кабер туфрагына бәрелде. Мансур үзен кире Казанга китәргә мәҗбүр итә алмый газап-

ланды. Ләкин вакытны кайтарып алып булмый, ялгышларны төзәтергә соң иде. Ике атна буе иртәдән кичкә кадәр көзге салкын тайга эчендә каңгырап йөргәч, ниһаять, егетнең күңел әрнүләре басыла төшкәндәй булды, Казанга билет алды. Үз кануннарына корылган тормыш әкрен генә үз агымы, Мансур көйләп куйган җае буенча акты да акты. Өйләнеп җибәрде, берәм-берәм балалары туды. Аспирантура бетерде, галимлек юлында үз сукмагын тапты. Дөнья көйле генә, ипле генә бара иде...

...Әй, вакыт! Син һәрвакыт ашыгасың, әйтерсең без мәхлукларның газапларын күрмисең дә. Күрсәң, ялгышларыбызны төзәтергә кушар идең. Кайтарып булмый торган ялгышлар була, дияр идең. Төзәтеп булмый торган ялгышлар була, дияр идең. Якын кешеләр янда булганда, аларның кадерен белегез, дияр идең. Әй, вакыт! Син үзең бер дә ялгышмыйсың микәнни соң?! Синең һәр мизгелең үз урынында микәнни соң?! Нигә безне шулай бер дә ялгышмыйча яшәргә өйрәтмисең син?! Әллә безгә ялгышларның ачысын татып, күңелебезнең керләрен әнә шул ялгыш ачысы белән кырып-кырып юу кадерле микән?! Әллә кешегә шунысы да кирәк микән?!

...Кичке салкынча җил каяндыр сазлык исе китерде. Мансур Ибраһимович соңгы тапкыр авыр сулап куйды, урыныннан күтәрелеп, кабер рәшәткәсен япты. Бите күз яшьләре тозыннан юл-юл булып агарган, катып киткән иде. Ә менә күңеле йомшады, үзен Каф тавыдай басып торган авыр таш мунчаладай телгәләнде, юкарды. Мансур Ибраһимович, зират капкасын чыккач кына, үзен көтеп торучы барлыгын искә төшерде. Ерак түгел генә, тезләрен кочаклап, чирәмдә Гөлкәй утырып тора иде.

– Гөлкәй, син әллә көне буе мине шушында көттеңме?!

Гөлкәй, борылып, урыныннан торды, елмаеп:

– Юк, Мансур Ибраһимович. Мин Рәхмәтулла бабайларда идем, – дип җавап бирде. – Әйдәгез, ул сезне чәйгә чакырды.

Картның өе авылның иң кырыенда булып, ялгыз карт яшәгән өй таләпләренең барысына да җавап бирә. Тышкы кыяфәте үк моңлы, күп еллар кичергән, хуҗасы белән бергә картайган икәне сүзсез дә аңлашыла. Рәхмәтулла карт кунакларны болдырга чыгып каршылады.

– Әйдәгез, оланнар. – Картның тавышы да үзе кебек тыныч, басынкы. Мансур Ибраһимович Себер татарлары

телен онытмавына сөенеп куйды. – Чәйләп алырбыз, Гөлкәй кызым аш та пешерде, әйдәгез.

Чыннан да, Мансур Ибраһимович зиратта вакытта, Гөлкәй бабайның идәннәрен юды, аш бүлмәсе тәртибен бозмый гына табак-савытларын рәткә китерде. Картның газ плитәсе дә, суыткычы да юк иде, шуңа күрә ашны каклаган иттән учак өстендәге кечкенәрәк казанда пешерергә туры килде. Учак күмерен күп ялкыннар күргән самавырга салып, чәй кайнатты. Тулай торактагы газлы-плитәле тормыштан соң мондый беренчел тормыш белән очрашу кызык та, тансык та иде...

Ир-атлар ашны мактый-мактый ашаган арада, Гөлкәй самавырны яңартырга куйды.

– Картайды алаша. – Рәхмәтулла карт тешсез авызы белән моңсу гына көлемсерәде. – Карчык дөнья куйганнан бирле, мин үзем ашарга пешерә алмыйм шул. Күршеләрем онытмыйлар тагы, йә аш кертәләр, йә кереп пешереп бирәләр. Син, олан, озаккамы соң?..

– Юк, Рәхмәтулла абзый. Тамырлар Казанда инде минем.

Рәхмәтулла карт шулай инде дигәндәй баш какты.

– Әйе... Тузганак та шулай: очып китә дә башка урынга барып тамыр җәя. Әйе... Башка урынга.

Мансур Ибраһимович аңламады: гаепләве идеме бу картның, әллә хуплавымы?!

– Атаң кабере янына кайтуың бик әйбәт анысы. Апаң еш кайта иде.

Гөлсем апасы, мәрхүмкәй, Төмәндә генә тора иде шул. Аны күмәргә дә кайта алмады. Әллә апасы белән аралары бик якын булмады микән? Меңәр чакрымны бер көндә узу мөмкин түгеллеген картка ничек аңлатасың? Гөлкәй дә үзен уңайсыз сизде. Хәзер Рәхмәтулла бабай Укытучысын гаепли башласа, аңа бик читен булачак. Шуңа сүзне икенчегә борырга теләп:

– Безнең яклар бер дә үзгәрмәгән, бабай, – дип куйды.

– Табигатьне үзгәртү мөмкин түгел, оланнар. Үзе теләсә генә үзгәрә ул.

Картның, күрәсең, үзе яшәгән яклардан читкә чыкканы юк... Көнбатышка табарак сәяхәт итсә, бер дә болай димәс иде... Тик олы яшьтәге кеше белән сүз көрәштерергә Мансур Ибраһимович җүләр түгел.

– Кайтмадым дип, үзеңне бер дә гаепләмә, олан. Әнә табигатькә кара: бер генә җәнлек-җанвар баласы да карт

ата-анасын кайгыртып яшәми. Аю баласы, аягына басып беренче аугa чыкканнан соң, анасын ташлый.

Карт әйтәсе җөмләсен әйтә дә мәгънәсенә төшенергә вакыт биргән кебек тынып тора. Тагы коточкыч фикерләрен әйтә... Мансур Ибраһимовичның «мин аю баласы түгел» дип кычкырасы килә...

– Без табигатьтән өстен түгелбез. Атаң-анаң сине бер дә гаепләмәделәр.

Юк, сүксен иде бу карт. «Нигә ата-анаң янына кайтмадың, нигә хат кына булса да язмадың» дип сүксен иде. Мансур Ибраһимовичка җиңелрәк булыр иде.

– Анаң һәрвакыт синең белән горурланыр иде. «Минем оланым Казанда укый» дип әйтер иде.

Нигә, нигә бу карт аның күңел яраларында актарына?! Кем аңа рөхсәт биргән?! Мансур Ибраһимовичның өзгәләнүе әз булды мәллә?! Нишли бу карт, нишли?! Карт, әвеш-түеш китереп чәйнәгән ипиен йотып җибәргәннән соң, Гөлкәйгә төбәлеп сорап куйды:

– Синең анаң, олан, әлегә исән-сау бит?

Гөлкәйнең «әлегә» сүзеннән аркалары чымырдап китте. Көч-хәл белән авызын әйләндереп:

– Исән-сау... Аллага шөкер, – дип әйтә алды.

Шунда гына Мансур Ибраһимович барысын да аңлап алды. Юк, карт һич кенә дә аның күңел яраларында казынырга җыенмый иде. Рәхмәтулла картның барлык әйткән сүзе Гөлкәйгә төбәлгән икән. Мансур Ибраһимовичның хәле картка бик аңлашыла, күрәсең. Тик аның ялгышларын язмыш башка кабатламасын. Гөлкәй кабатламасын.

Бераз тын гына утырганнан соң, Мансур Ибраһимович үзе сүз башлады:

– Әткәй-әнкәйне онытмаган өчен рәхмәт яусын, Рәхмәтулла абзый. Каберләрен гел карап торгансыз.

Карт, укытучы сүзен ишетмәгәндәй, эчкән чәенә өрә-өрә, шакмаклы шикәрне чәенә манчып, авызында җебетте.

– Һич яратмыйм «писок» дигән шикәрне. Тәме юк. Шакмаклы шикәр табуы кыен. Кибеткә кайтармыйлар. – Бераз тын торгач әйтә куйды: – Ибраһим минем яшьти иде, мәрхүм. Каберен мәктәп укучылары карый, агач рәшәткәне дә, эскәмияне дә алар ясады. Тимер рәшәткәне апаң куйдырды. – Тагы бераз торгач, өстәп куйды: – Коръән сүрәсен Абдул тимерчедән яздырдым. Киреләнсә дә, кулы ята аның. Атаң васыяте.

Карт, әлбәттә, хәйләле иде. Ибраһим вафатыннан соң

авылында сердәше калмады. Күңеле тулган чакта Рәхмәтулла карт зиратка бармый, кая барсын? Гомер иткән карчыгы белән, Ибраһим яшьтие белән серләшми, кем белән серләшсен? Аларның каберен карамый, кемнекен карасын? Мансур Ибраһимович та моны аңлады, әлбәттә. Инде кич булып килә, кайтасы юллары да бар.

– Ярар, Рәхмәтулла абзый. Мин әле тагы килермен, тик бүген кайтасы бар, хуҗалардан яхшы түгел.

– Кунып калыгыз дияр идем дә, кыз оланга яхшы булмас.

Рәхмәтулла карт кунакларны озата чыкты. Гөлкәй ерак түгел генә утлап йөргән атны алып килде, тиз арада Мансур Ибраһимович белән арбага җиктеләр. Укытучы инде бу дилбегә-бауларны оныткандыр дисә дә, яшьтән канга сеңгән һөнәр тиз генә онытылмаган икән. Карт белән саубуллашып, атны баеп килгән кояш артыннан юырттылар. Һәркем үз уена чумган иде. Тәгәрмәчләр сыкрануын дәшми генә тыңлап баргач, Гөлкәй кечке тын һавада җыр сузды:

Кайтырмын дип, хатлар язуыма
Көннәр түгел, айлар үттеләр;
Тик юлларым, сиңа илтмәенчә,
Еракларга алып киттеләр.

Бер кайтмасам, әнкәй, бер кайтырмын,
Утыңны сүндерми, мине көт;
Сине көттереп тә кайталмасам,
Кичер мине, әнкәй, гафу ит...

«Кичер мине, әнкәй, гафу ит...» Мансур Ибраһимович авыз эченнән генә шушы сүзләрне кабатлады. Күңел күз яшьләрен көндез үк сыгып бетергән иде инде, шуңа бу ташны йотуы күпкә авыррак булды. Юк, ул әле Себер киченең зәңгәр тынлыгында яңгыраган бу җырның үз тормышында нинди әһәмиятле буласын да, күңелендә шушы җыр яңгырый башлау белән бернинди аралар ераклыгына, эш тыгызлыгына карамый, кышын да, җәен дә әнкәсенең каберенә очып кайтуын, аяклары йөри алганчы үзенең Мәккәсе әлеге зират булачагын белми иде...

...Калган көннәрне Мансур Ибраһимович туган авылына үзе генә чыгып китте. Ат җигеп йөри белә, шуңа Гөлкәйне дә борчыйсы килмәде. Тәгәрәп үскән балачак болыннарында йөрде, күлдә су коенды, балык каптырды.. Якташлары, күптәнге сыйныфташлары белән очрашты,

авылда үзен онытмаганнарын белеп шаккатты. Туган туфрактан аерылып киткәч, дөнья кешеләре дә аның үзе яшәгән урында гына барлыгын таныйлардыр сыман иде. Баксаң, алай түгел икән. Күпме хатирәләр, күпме дуслар туган якларында калган икән! Мансур Ибраһимовичның, ниһаять, күңеле үз урынына утырды, тынычланды. Шул тынычлану белән бергә икенче хис баш калкыта башлады: Казанның кысан квартирасы, шунда калган ике юеш борын тансыкланды... Менә аңла инде син кеше күңелен.

Мансур Ибраһимовичны Төмән вокзалында каршы алучы да, үзләренең авылларына алып кайтучы да Гөлкәй иде. Абыйсының, кызганычка каршы, экспедиция белән тайгага чыгып киткән чагы туры килде. Гөлкәй коеп куйган әнисе икән: шундый ук озын кара толымнар, кара күзләр. Шундый ук ягымлылык, җылылык, пөхтәлек. Тик Сәрви апайның (Гөлкәй әнисенең тулы исеме Сәрвәриҗиһан иде) кайчандыр кара толымнары, юкарып, көмешләнгән дә күз карашында беркайчан да югалмый торган сагыш теркәлеп калган. Мансур Ибраһимовичны бик җылы кабул итте. Хәер, бөтен авыллары белән җылы кабул иттеләр: Мансур Ибраһимовичны кунакка алырга дип чират билгеләнгән иде инде. Калган көннәрне Гөлкәйнең әтисе, әбисе зиратына бардылар, ана белән кыз кул күтәреп дога укыганда, Мансур Ибраһимович беркадәр уңайсызланып калды. Үзенең андый һөнәре юк иде. Әнә алар, ичмаса, күңелдәге авырлыкны дога белән җиңеләйтәләр... Гарифҗан хәлфәне дә исән килеш күрә алмады: беренче укытучысы бер ай элек кенә дөнья куйган икән. Дөньяның асыл затлары китә торалар. Юк, болай әйтәсе килми: дөньяның асыл затлары юлларын мәңгелектә дәвам итәләр. Көннәрнең берендә ул үзе дә шунда юл тотар. Кайчак Мансур Ибраһимович үзе яшәгән дөньяның фанилыгын, үзе яшәячәк икенче дөнья барлыгын бөтен күңеле белән кабул иткәндәй тоела. Бу тормышта әле ул үзен тапмады, әле ул бу тормыш кануннары белән килешеп бетә алмады, аның күңеле бу дөнья таләпләреннән риза түгел, кайдадыр аны икенче дөнья, икенче яшәеш көтә сыман... Ахирәт дөнья дигәннәре әллә шул микән?!

...Ниһаять, Мансур Ибраһимович китәсе көн килеп җитте. Станция авылдан егерме биш чакрым ераклыкта иде, шуңа Гөлкәй Укытучыны ат белән үзе илтә барырга булды. Иртән Сәрви апа Мансур Ибраһимовичка сумка

тутырып күчтәнәч төяде. Укытучы алмаска теләп рәхмәт яудыра башлаган гына иде, Гөлкәйнең көлемсерәп баш чайкавын, «үпкәләячәк» дип пышылдавын сизеп алды. Нишлисең, йоласы шундый инде бу якларда. Зур чемодан янына тагы шундый ук зурлыктагы сумка өстәлде. Ул да булмады, берәм-берәм кергән күрше хатыннары кулында тагы төргәкләр күренде. Нәтиҗәдә Мансур Ибраһимовичка тагы бер сумка юлдаш булды.

– Кайтсагыз, керми китмәгез. – Сәрви апаның күзләре яшьләнде. – Ишекләребез һәрвакыт ачык булыр. Алланың рәхмәте белән, исән-сау йөрергә язсын. Җәмәгатегез, балаларыгыз исән-сау булсыннар, кайгы күрми яшәгез, амин!

Капка төбенә җыелган авыл халкы кайсы утырып, кайсы чүгәләп дога кылдылар. Барысы белән күрешеп чыкканнан соң, Мансур Ибраһимович арбага утырды, кузгалдылар. Ир-атларның каты итеп кул кысуларын, үз итеп арка кагуларын, хатын-кызларның «исән-сау йөрергә язсын, олан» дип пышылдауларын, кулъяулык белән күзләрен сөрткәләүләрен күреп, укытучының бер мәлгә йөрәге сыкрап алды: шәһәр җирендә мондый туганлык юк һәм булмаячак! Шәһәр кешеләре бер-берсенә урман ерткычлары кебек: көчсезләрне бәреп кенә торалар. Цивилизация дип аталган шәһәр чынлыкта ерткычлар яшәгән урманнан да хәтәррәк икән ләбаса...

* * *

...Ат, салмак кына атлап, биек чыршылар арасыннан салынган юл буйлап бара. Ара-тирә чыршылар арасында нечкә, зәгыйфь каен кәүсәләре күренеп кала, чикләвек куаклары күзгә чалына. Һәрнәрсәдә табигать биргән күркәмлек, һәрнәрсәдә хозурлык. Үзеннән-үзе Тукайның сүзләре искә төшә: «Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат...» Бераздан юл чыршылар гаскәрен үтеп, шактый тапталган такыр юлга килеп чыкты, юлның бер ягыннан, һич көтелмәгәндә, кап-кара болытлар белән капланган офык ачылды. Авыр кара болытлар офыкны гына түгел, күкнең шактый өлешен биләп алганнар иде.

– Яңгыр яварга җыена, – Мансур Ибраһимович атның дилбегәләрен киереп тартты, кызулатырга теләп, «Һо-у, малкай!» дип кычкырып алды. – Ашыкмасак, яңгыр ас-

тында калуыбыз бар. Ә мондагы яңгырларда, үзең беләсең, өйдә утыруы яхшырак.

Гөлкәй елмаеп кына куйды. Яңгыр түгел, кар-боз яуса да, туфан кузгалса да, Мансур Ибраһимович янәшәдә булганда, аңа бернәрсә куркыныч түгел. Кулыннан килсә, ул гомере буена менә шулай, Мансур Ибраһимович янәшәсенә утырып, әкрен генә ат арбасында юыртыр иде...

Бераздан, чыннан да, яңгыр аларны куып җитте. Иң элек яңа гына домна миче кебек кыздырган кояш күлгә чумгандай юкка чыкты, дөнья мизгел эчендә караңгыланып китте. Шул ук минутта агач башларына көчле җил китереп бәрде. Тирә-як йөзьяшәр чыршы-наратларның ыңгырашуы белән тулды, җиргә корыган ботаклар сынып төште. Һавада җил белән күтәрелгән үлән сабаклары, сынган кечкенәрәк ботаклар, коры-сары бөтерелде. Аннан берән-сәрән эре тамчылар тама башлады, агач башларын туздырып йөргән җил җиргә ятты. Акбүз бия дә, тиздән яңгыр коеп түгәсен сизгән кебек, адымнарын кызулатып, юыртуга күчте, тәгәрмәч күчәрләре, менә таралам, менә таралам дигәндәй, бертуктаусыз ыңгыраша башладылар. Мансур Ибраһимович чын-чынлап борчыла калды. Инде урманны да чыктылар, барып җитәргә дә ерак калмады кебек, тик барыбер өлгерә алмаслар, ахры.

– Урманда гына каласы иде безгә, – Мансур Ибраһимович, Гөлкәйгә борылып эндәшсә дә, күбрәк үз-үзенә әйтә бугай. – Анда, ичмасам, ышыкланырга агачлар бар иде. Ачыклыкта чыланырбыз бит. Арбада җәймәише әйбер юк микән?!

Мансур Ибраһимович бер кулы белән дилбегә тоткан хәлдә арбадагы печәнне кармалаштырды. Юк, җәймәгә охшаган нәрсә сизелмәде.

– Сезнең өстегездә дә юка. – Укытучының борчылуы артканнан-арта иде. – Әллә кире борылыйкмы?!

– Мансур Ибраһимович, моннан ерак түгел күл бар. Аның янында, ялгышмасам, аучылар өе булырга тиеш. Шунда ышыкланырга була.

Мансур Ибраһимович акбүз биягә дилбегә очы белән җиңелчә генә селтәнде:

– Һо-у, Кашка! Чап әйдә, чап, малкай!

Ул арада яңгыр тамчылары ешлады, күк йөзен яшен кисеп алды, тирә-якны яңгыратып гөрселдәде. Алда ялтырап күл күренде, тик аның янында каралты-корылма

чалынмады. Бераздан каралган черек бүрәнәләр өстенә яшел үлән үскән өем янына барып җиттеләр. Янгыннан калган аучылар өенең хәрабәләре иде бу. Күлнең икенче ягыннан күкне җир белән тоташтырган ак стена күренде.

– Боз белән ява! Гөлкәй, төш әйдә, атны тугарабыз!

Мансур Ибраһимович күз ачып йомганчы Кашканың камыт бауларын чишеп, атны тәртә арасыннан чыгарды, Гөлкәйгә, ерак китмәсен өчен, Кашканы хәрабәләр янында үсеп утырган яшь каенның ботагына бәйләп куярга кушты. Үзе көч-хәл белән арбаны юлдан читкәрәк, үләнлерәк тигез урынга тартып чыгарды да утырырга йомшак булсын өчен салынган яшел печәннең бер өлешен арба астына ыргыта башлады. Печән астыннан арбаның иң төбенә җәелгән, бер ягыннан теткәләнеп беткән иске брезент җәймә килеп чыкты. Җәймә ике кешегә бөркәнеп утырырга кечкенә, җитмәсә, ертык иде. Гөлкәй белән икәү, яңгыр бәреп явасы яктан салындырып, җәймәне арбага беркеттеләр. Кечкенә куыш сыман урын барлыкка килде.

– Гөлкәй, арба астына кер, тиз!

Кыз караңгы куыш эченә чумды, ул арада брезентка, тып-тып итеп, бертуктаусыз яңгыр тамчылары бәрелә башлады. Гөлкәй, кырын яткан килеш, бер урынга өелгән печәнне ятарга җайлы итеп таратты. Арбаның брезенты салынып төшкән ягыннан Мансур Ибраһимовичның ботинкалары күренә. Нигә керми инде... Чылана бит. Брезентка бәрелгән тавыш көчәйде, «тып-тып» килүдән «шакы-шокы» иткән тавышка күчте. Боз ява... Ниһаять, арба астына, шуышып, Мансур Ибраһимович керде.

– Ай-яй эре боз ява. – Укытучының тавышында эчкерсез борчылу ишетелде. – Зур зыян салмаса ярар инде. Гөлкәй, сезгә салкын түгелме?

Гөлкәй чыннан да калтыранып куйды. Юк, салкыннан түгел. Арба астында, әлбәттә, утырырлык урын юк иде, болай да терсәккә таянып, яны белән ятып тора. Мансур Ибраһимович та шул хәлдә диярлек үрмәләп керде. Менә кулына тоткан костюмын Гөлкәйнең өстенә яба. Мондый кайгыртудан кыз бөрешеп килде, үзе дә аңламастан, Мансур Ибраһимовичка таба шуышты, борынына яңгырга чыланган ак күлмәктән аңкыган затлы одеколон катыш ир-ат тәне исе килеп керде. Мансур Ибраһимович исе... Кыз кинәт кенә күңелендә, язгы ташкын булып, сөеләсе, яратыласы килү хисе ургылганын тойды,

шул хисне тыя алмый, ташкынга буйсынып, бөтен гәүдәсе белән калтырый башлады. Мансур Ибраһимович читкә борылган хәлдә арбаның тышкы ягында коеп түккән яңгырны күзәтә иде. Ниһаять, Гөлкәйгә таба әйләнде, башын чайкап:

– Ну ява, – дип куйды. – Мондый яңгыр астында калсаң, бер ай урыннан тора алмый ятуың бар... Гөлкәй, сезгә ни булды?! Салкынмы?!

Арбаның тышкы ягыннан төшкән сүрән яктылык Гөлкәйнең күзләрендә чагылды. Бер мәлгә Мансур Ибраһимович сүзсез катып калды. Мондый карашны аның беркайчан да беркемнән дә күргәне, тойганы юк иде. Үзенә төбәлгән зур кара күзләрдә өзелеп ярату, тугрылык, буйсыну, курку, нәрсәдер көтү, таләп итү, тагы ир-атны үзенә тарта торган әллә нинди хисләр ярылып ята иде. Йа Хода, бу хатын-кыз аны өзелеп ярата лабаса! Бу хатын-кыз аның артыннан җир читенә барырга, утка ташланырга, суга батарга әзер икән бит! Бу хатын-кыз гомере буе аныкы, бары аныкы гына булырга әзер икән бит! Мансур Ибраһимович бу турыда белми идемени?.. Белә иде, һичшиксез, белә иде... Һәр дәрес саен, һәр көн саен кызның күзләрендә чагыла, керфекләреннән саркый иде бу мәхәббәт. Мансур Ибраһимович моны күрергә генә теләмәде... Юк, хәзер дә теләми. Кирәкми аңа бу хис. Аның гаиләсе, балалары бар. Аның Гөлкәй тормышын җимерергә хакы юк. Кирәкми...

Мансур Ибраһимович нишләргә белми сүзсез калды. Нәрсә дә булса әйтсә, Гөлкәйне рәнҗетер сыман тоелды. Аптырап, кызның костюмын рәтләде, кечкенә кызчыкны юаткандай, маңгаена тузгып төшкән чәчләрен артка сыпырды. Тик кулы кызның битенә кагылуы булды, әйтерсең бөтен тәнен электр тогы кисеп үтте, баш миен яшен уты телде. Икесенең арасында ниндидер күзгә күренмәс энергиядән күпер барлыкка килде, Гөлкәйнең эчке калтыравы аңа күчте. Әйтергә теләгән юату сүзләре мизгел эчендә җилгә очтылар. Нәрсә эшләгәнен аңламастан, бер кулы белән кызның болай да тузгып таралырга торган толымын сүтә башлады. Иреннәре бертуктаусыз «Гөлкәй, Гөлкәй...» дип кабатладылар. Гөлкәй... Кызның өстеннән костюмы шуып төште, үзе Мансур Ибраһимовичның кайнар кочагына килеп керде. Ир-ат кызның татлы ис килгән озын чәчләрендә буталды, кулы зифа гәүдә буйлап йөгерде, Гөлкәйнең ут кебек кайнар

күкрәкләренә кагылып алды... Иреннәре кызның дерелдәгән иреннәрен эзләп тапты; шашынып, гомердә хатын-кыз күрмәгән яшь-җилкенчәктәй, Мансур Ибраһимович сөю ләззәтенә бирелде. Дөнья гаме онытылды. Икесе өчен дә мизгел туктап калды, тышта котырынган яңгыр да, бертуктаусыз ялтыраган яшен камчысы да, күкнең гөрселдәве дә – берсе дә күренмәде дә, ишетелмәде дә. Юка кофтаның сәдәфләре, җил белән ачылган өрфия капкалар сыман, үзләреннән-үзләре ычкынып киттеләр, кайнар иреннәр кызның аккош муенын иркәләде, назга сусаган күкрәкләрен суырып үптеләр. Дөнья тоташ ак нур халәтенә керде. Шул нур эчендә бер күзәнәк кенә зәгыйфь тавыш белән Мансур Ибраһимовичка «Нишлисең...» дип эндәште. Ак нур дулкынланып китте, бер читендә сорау билгесе барлыкка килгәндәй булды. «Нишлисең?!» Бу юлы күзәнәкнең тавышы көчлерәк яңгырады. «Нишлисең?! Нишлисең?!» Бу күзәнәк тынгысыз, начар күзәнәк, Мансур Ибраһимовичның аны ишетәсе килми... Әмма ак нур таркала, тарала башлады, күз алдына Гөлкәйнең керфекләре йомылган, татлы ләззәткә чумган йөзе уелды. «Н-и-ш-л-и-с-е-ң?!» Күзәнәк бертуктаусыз пульс белән Мансур Ибраһимовичның аңына бәрә иде. Йа Ходаем, нишли ул... Туктарга кирәк, бу исерүдән туктарга кирәк! Әле соң түгел! Исенә килеп, кинәт кенә кызны кочагыннан читкә этәрде, тыны, сулуы кабып, «Гөлкәй! Гафу ит...» дип пышылдады да арба астыннан коеп яуган яңгырга тәгәрәп чыкты. Читтәрәк яңгырда әлсерәп торган Кашканың бауларын ычкындырып, әһ дигәнче ат өстенә сикереп менде, бар куәтенә куалап, болын буенча чаптырып китте. Эчке ярсуы басылганчы, аңы, уйлары үз урынына утырганчы ат өстендә чапты, кыргый бабасы шикелле, коеп яуган яңгырга карамый, тезләре, үкчәләре белән атның кабыргаларына төртә-төртә чапты да чапты... Вакытны кире кайтарып булса иде икән! Егерме биш яшен кире кайтарып булса иде икән! Өйләнмәгән яшь егет чагын кайтарса икән! Йа Ходай, әгәр син булсаң, әгәр синең кодрәтең шундый киң булса, кайтар минем яшьлегемне! Минем өзелеп яраткан хатын-кыз белән бәхетле буласым килә! Күкне урталай кисеп, коточкыч калын япьле яшен ялтырады, шул ук мизгелдә, Мансур Ибраһимовичның баш өстендә диярлек чытырдатып күк ярсуы ташыды. Ат чабып барган җиреннән кисәк өркеп китте, сыртын сикертеп, өстендәге җайдагын атып бәрде.

Мансур Ибраһимович чирәм буйлап тәгәрәде. Ярый әле чирәм куе, яшел, йомшак иде, ир бернинди авырту сизмәде. Әллә ул гомумән нәрсә дә булса сизәмләү сәләтен югалттымы?! Җирдә чалкан яткан килеш битенә боз катыш яңгыр тамчылары бәрүен дә, күкне бизәп, әледән-әле яшен камчылары уйнавын да, кайдадыр еракта Кашка кешнәвен дә – бернәрсәне дә ишетмәде, күрмәде. Яңгыр басылганчы, тышкы дөньяны сиземләү сәләте үз халәтенә кайтканчы шулай ятты. Ниһаять, соргылт күк йөзеннән болыт ертыклары берән-сәрән соңгы тамчыларын ыргытып киттеләр, тирә-якны нурга күмеп, зәңгәр киңлек ачылды, дөнья кошлар тавышы, бөҗәкләр безелдәве белән тулды. Мансур Ибраһимович, тәненең һәр күзәнәге сыкравын сизгән хәлдә, әкрен генә торып утырды, тирә-якка каранды. Кашка күренми иде. Өсте-башы лычма су, апак күлмәге юылмаслык булып яшел үлән тапларына буялган, аксыл чалбар балакларының эчке ягы ат тиреннән кап-кара булганнар... Ярый әле арбада калган чемоданында алмаштырырга өс киеме бар. Көч-хәл белән атны эзләп табып, арба янына әйләнеп кайтканда, кояш бернәрсә булмагандай яңадан җир йөзен домна мичедәй кыздыра, тереклек ияләре чистарып калган табигатькә рәхмәтле төстә һәркайсы үз эше белән шөгыльләнә башлаган иде инде. Саннан чыгып арыган Кашканы Мансур Ибраһимович үз иркенә җибәрде. Гөлкәй брезент җәймәне арбаның арткы ягына җыеп салган, уртага элекке кебек коры печән тутырган. Үзе бер якка аякларын салындырып утырып тора. Мансур Ибраһимовичны күрүгә, арбадан сикереп төште, бераз уңайсызланган кыяфәт белән янына килде.

– Гөлкәй... Гафу ит мине, зинһар... Мин үземне кулда тотарга тиеш идем.

Гөлкәй зур күзләрен укытучыга төбәде. Юк, үпкәләүнең тамчысы да юк иде бу күзләрдә. Киресенчә, ниндидер җитдилек, әһәмиятле сүз әйтергә теләгән кешенеке кебек, кыюлык чагыла иде.

– Мансур Ибраһимович! – Кыз, башын артка ташлап, укытучының күзләренә текәлде. – Сезгә гафу үтенергә кирәкми. Мин моны үзем теләдем, чөнки мин сезне яратам. Өзелеп. Сезне беренче күргән мизгелдән алып мин сезне өзелеп яратам.

Нишләргә соң, ничекләр итеп бу кызга үзенең хисләрен рәнҗетмичә генә әйтеп бирергә?! Йа Ходай, ярдәм ит аңа, ярдәм ит...

– Гөлкәй... – Мансур Ибраһимович ныклык өчен кызның кулларын учына алырга теләсә дә, кагылырга курыкты. Аңа бу кызга кагылу, гомумән, куркыныч... – Без беркайчан да бергә була алмаячакбыз. Син дә моны беләсең. Мин синең тормышыңны җимерергә теләмим.

– Нигә, нигә бергә була алмыйбыз?! Сез өйләнгән булгангамы?!

Мансур Ибраһимович авыр сулап куйды, башын чайкады.

– Сезнең миңа өйләнүегез кирәкми. Бергә булсак, сез мине яратсагыз, шул җитә.

– Гөлкәй, ни сөйлисең син?! Мин беркайчан да сине сөяркә итеп тотмаячакмын, аңла!!!

– Алайса өйләнегез миңа! Сез дә бит мине яратасыз, мин беләм! Мин моны күрдем! Тойдым!

– Гөлкәй, авыр сүзләремне гафу ит. Әтиең үлгәч, сиңа бик авыр булды, шулай бит?! Сиңа дөнья җимерелгәндәй тоелды, шулаймы?!

Нишләп әле ул әтисе турында сөйли?! Сүз аларның хисләре турында бара, нишләп әтисен искә ала ул?!

– Әгәр мин хатынымнан аерылсам, балаларым әтиләрен югалткан кебек ятим калырлар иде. Мин моңа беркайчан да бармаячакмын. Син дә мине аңларсың дип уйлыйм, Гөлкәй.

Менә нәрсәдә икән эш... Гөлкәй һәрвакыт Мансур Ибраһимович белән үзе арасында аның хатыны тора дип уйлады. Юк икән... Эш катлаулырак икән. Кинәт дөнья ак һәм кара төсләргә чумды. Барысы да бик гади икән бит – дөньяда бары тик ак һәм кара төсләр генә яши икән. Кызыл, сары, зәңгәр – болар барысы да уйдырма. Иллюзия. Кешеләргә яшәү кызыклырак булсын өчен уйлап табылган хыял дөньясы. Ә чынлыкта – ак һәм кара. Башка төснең булуы мөмкин түгел.

– Димәк, безнең арада сезнең балаларыгыз тора. – Гөлкәй, тавышы калтыравын басарга теләп, бераз тынып торды. – Алайса, мин алар үскәнче көтәргә әзер. Биш ел, ун ел, егерме ел! Бары тик мине яратыгыз гына! Мин гомер буе көтәргә әзер! Мин сезне бик яратам!

Гөлкәй яңадан Мансур Ибраһимовичка килеп сарылды, горурлыгын, оялуын аяк астына салып, укытучының иреннәренә үрелде. Кем белә, бәлки ул соңгы кабат үбәдер аны... Ир-атның кызны этеп җибәрергә көче җитмәде, тик барыбер йөзен Гөлкәйнең кара чәчләренә яшерергә

өлгерде... Әлегә ул ургылып килгән бу хистән аптырап калган, нишләргә дә белми, гаҗиз иде. Аның сөясе, сөеләсе килә, бик килә! Тик аның сөю-сәгадәте яшьлектә булырга тиеш иде. Аның тормыш расписаниесендә балаларга, хатынына карата гынаярату хисе бар! Ә мондый мәхәббәттән ул курка...

– Гөлкәй, мин поездга соңга калам. Әйдә, җыеныйк.

...Поезд, әлбәттә, Мансур Ибраһимовичны көтеп тормаган, китеп барган. Димәк, Төмәнгә кадәр икенче поездның килгәнен берәр сәгатьләп көтәсе бар. Аннан самолетта очасы.

– Гөлкәй, син кайт инде, кичкә калырсың.

Станция читендә очлары корыган ялгыз каен агачына сөялеп торган Гөлкәй баш чайкады. Юк, аның Мансур Ибраһимович янында үткәргән һәр секунды гомер бәясенә тора. Ниндидер күңел сиземләве белән кыз Мансур Ибраһимовичның үзеннән ераклашуын сизә кебек. Ә аның сөйгәнен җибәрәсе килми. Аһ, юкка ул үзенең хисләрен укытучыга ачып салды. Юкка... Нишләргә соң, нишләргә?!

– Мансур Ибраһимович... Мин...

Мансур Ибраһимович та үзен аңламады. Әллә нишләде ул. Станциягә кадәр калган юлны янында утырып килгән Гөлкәй турында уйланып барды. Бу кыз аңа якын, бик якын иде. Чынлыкта алар арасындагы бу якынлык күптәннән – кызны беренче күргән мизгелдән үк башланды бит. Беренче дәрестә үк Мансур Ибраһимович Гөлкәйне үз янына чакырып алмадымыни?! Яңа елны үз өендә каршыларга ул дәшмәдемени?! Авырып ятканда аның янына Гөлкәй йөгереп килмәдемени?! Ә монда – туган якларына – Гөлкәй тартып китермәде микән аны?! Сызылып аткан таң кебек, бу сөю аның тормышында сиздерми генә тамыр җәйгән ләбаса... Мансур Ибраһимович авыр сулап куйды. Әйтерсең бүгенге коеп яуган яңгыр астында аңа мәхәббәтнең, өзелеп сөюнең нәрсә икәнен аңлатып бирделәр. Әйтерсең ул бу кызны гомере буе сөйгән, гомере буе нәкъ менә аны гына көткән. Бу толымнар, бу керфекләр, бу сусыл иреннәр бары аныкы гына булырга дип яратылганнар. Ул шундый якын, шундый якын... Бер сәгатькә генә, бер мизгелгә генә булса да, ул аны ярата ала, аны иркәли ала...

– Гөлкәй!

Йөрәк акылны җиңде. Акыл тартышты, тартышты да,

җегәре бетеп, уйлау сәләтеннән баш тартты. Гөлкәйгә текәлгән караштa акылның эзе дә юк иде. Моны Гөлкәй дә күрде.

–Мансур Ибраһимович...

Кызның күзеннән яшьләр коелды. Мансур Ибраһимович шуны гына көткәндәй, кызны кысып кочаклады, үз теләге белән, аек аңында килеш иреннәреннән суырып үпте. Күзләрен үпте, керфекләренең һәр бөртеген үпте. «Минем бәхетле буласым килә... Минем мәхәббәтнең нәрсә икәнен татып карыйсым килә...» Иреннәрендә тоз тәмен сизде.

– Елама, Гөлкәй. Сөю күз яшьләреннән торырга тиеш түгел.

– Мансур... абый...

Юк, ул аңа әле «Мансур» дип дәшә алмый. Шулай да «Мансур абый» «Мансур Ибраһимович»тан якынрак сыман...

– Мансур абый... Ә сез мине яратасызмы соң?! Әз генә булса да?!

– Яратам, бик яратам!.. Мең тапкыр, миллион тапкыр яратам, Гөлкәй! Ничек яратуымны син белмисең, Гөлкәй! Соңга калган мәхәббәтем, гөлем-гөлкәем минем! Үлеп, өзелеп яратам!

...Каен яфраклары пышылдыймы моны?! Әллә җил шулай шаяртамы?! Юк, бу таныш бәрхет тавыш, мондый тавышны дөньяда башка һичкем кабатлый алмый. Бу бәрхет тавыш аны яратам, ди. Мансур Ибраһимович Гөлкәйне яратам, ди! Күктән яуган ләйсән яңгыр булып, Гөлкәйнең күңеленә бәхет иңде. Язгы ташкын булып, ургылып, шатлык килеп керде. Гөлкәй әллә көлде, әллә елады – үзе дә аңламады. Бертуктаусыз кара дулкын чәчләрне сыйпады, әле битләрен укытучының битенә куйды, әле аның калын иреннәрен үпте. Сөюдән тилергән кешеләр була, диләр, булсалар, алар Гөлкәй кебек булалардыр. Кайгыга күңел чыдый, ә менә бәхеткә – юк, чыдый алмый... Тилерә.

...Самолетка кереп утыргач та, Мансур Ибраһимович тиз генә айный алмады. Күз алдында һаман поезд станциясеннән озатып калган Гөлкәй иде. Гөлкәй, Гөлкәй... Каян гына барлыкка килдең син? Нишләргә инде хәзер? Йөрәге тулы сөю. Татлы, ләззәтле хис. Яшь кызга гыйшык тотуы үзе оят. Яшь аралары күпме соң... Мансур Ибраһимович әле бу турыда уйламаган иде. Йа

Хода... Булсын. Аның мәхәббәт хисен, сөю хисен татып карыйсы килә. Шагыйрь әйтмешли, «нинди татлы, нинди ләззәтле син, яшерен сөю, яшерен мәхәббәт...» Мансур Ибраһимович үзалдына елмаеп куйды, күзләрен йомды. Көндезге вакыйгаларны берәм-берәм яңадан хәтерендә торгызды. Ул әле бәхетле иде. Газабы соңыннан булыр...

* * *

– Кызым, кайда иләсләнеп йөрдең тагы?!

Әнисе Гөлкәйнең соңгы арада өйдән озакка чыгып югалуын өнәми. Тайга тайга инде ул, һәр почмагы куркыныч белән тулы. Гөлкәй исә атка атлана да чыгып китә, атка атлана да чыгып китә. Бу юлы да кыз арыган кыяфәт белән елмайды, тик алдагы көннәрдәге кебек үзенең бүлмәсенә кереп бикләнмәде.

– Кара әле, әни. Сиңа ошыймы?

Кулындагы төргәген сүтеп, әнисенә сузды. Менә нигә һәр көн югалган икән бу бала. Тагы сурәт төшерә башлаган. Ана кызы кулындагы киндергә сокланып карады.

– Ай, матур ясагансың, кызым. Туктале, бу соң Камышлы күл түгелме?!

Гөлкәй тагы елмайды. Әлбәттә, Камышлы күл. Бары аларның Камышлы күле генә үзе шундый сихри, үзе ярсу. Бары Камышлы күлнең генә бер ягыннан кояш балкый, ә икенче ягыннан тоташ стена булып яңгыр явып килә, яшен ялтырый. Ә менә күл буенда ярсу җилгә ботакларын туздырган каен Камышлы күл каены түгел. Ул тимер юл станциясе читендә үскән каен, кәүсәсендә күп гашыйкларның вәгъдәләрен сырлаган, күп яңгырлар, җилдавыллар, күп мәхәббәтләр күргән каен. Гөлкәй белән Мансур мәхәббәте турында ишеткән каен...

– Алайса, сиңа ошый инде, әни?!

– Ошавын ошый да, кызым, болай югалып йөрүең ошамый. Иртәгә китәсең бит инде, әйберләреңне җыярга вакыт.

– Әй, җыябыз ла аны, әни! Җыелган инде алар минем!

Чыннан да, Гөлкәйнең үзе белән алып китәрдәй әйберсе күп түгел иде. Аның нәрсәсен җыясың инде.

– Мунча ягылган, кызым. Үзем генә кермәдем, сине көттем.

– Алайса, әйдә, әни, киттек. Мине ныклап каен себеркесе белән чабарсың!

Кызу мунчада чабынып, юынып туйганнан соң, ана белән кыз мунча алдына чыгып утырдылар. Әнисе җимешле үлән чәе ясап алып килгән иде, рәхәтләнеп эчтеләр. Икесенең дә күңелләре булды. Тик әнисе киенергә өлгергән кызын туктатты.

– Гөлкәй, кызым, сиңа сүзем бар иде.

Әнисе беркайчан да болай рәсми сөйләшми. Гөлкәй, аптырап, башына ураган сөлгесен сүтеп, озын чәчләрен киптерер өчен аркасына таратып салды.

– Тыңлыйм, әни. Юлда сак булырмын, чит кешеләр белән сөйләшмәм, әйберләрне нык саклармын. Казанда яхшы укырмын. Хат язармын. Тантаналы вәгъдә бирәм!

Әнисе кызына кушылып елмаймады. Гомумән, әнисе беркадәр моңсуланып, сагышланып киткән.

– Балам, син дә үсеп җиттең инде. Озакламый кияүгә сорап егетләр килә башлар. Алдыңны-артыңны карап йөрсәң иде, кызым.

Гөлкәй оялчан елмайды.

– Борчылма, әни. Миндә әле егетләр кайгысы түгел. Укырга кирәк, егетләр качмас.

Сәрви апа авыр сулап куйды.

– Шуннан куркам да инде, кызым. Егетләр кайгысы булырга тиеш синдә.

Гөлкәй аңламады. Ничек инде, кызын укырга дип җибәрә ич әнисе, нинди егетләр кайгысы теләп торырга мөмкин?!

– Әллә нәрсә сөйлисең, әни. Аңламыйм.

Сәрви апа тагы авыр сулады, ләкин ана күңелендәгесен әйтергә тиеш иде. Ялгышмый микән ул?

– Кызым, син үз тиңеңне табарга тиеш.

– Әни, әллә мине кияүгә озатырга чамалыйсың инде?!

Гөлкәй кычкырып көлеп җибәрде. Барыбер көлүендә шом чагылып калды. Әнисе нәрсәдер әйтергә тели, әйтә алмый. Нәрсә?!

– Әни, зинһар, әйт инде, интектермә. Әллә берәр кияү таптыңмы?!

– Мин тапмадым, кызым. Синең ялгышуыңнан куркам.

Ниһаять, Сәрви апа тәвәккәлләде. Кызының күзләренә туп-туры карады да, тынын җыеп:

– Кызым, бу Мансур Ибраһимович сиңа кем ул?! – диде.

Гөлкәй эченнән аһ итте. Куркуы күзләрендә чагылды, күрәсең, әнисенең күзләрендә шундый ук курку барлыкка килде. Кинәт мунча домна миче кызуыннан да эссерәк булып китте, һава җитми башлады.

– Соң... Укытучым... Ни инде... Фәлсәфә фәнен укыта. Син беләсең ич, әни.

Ана ялгышмаган икән. Мансур Ибраһимович монда чакта кызының күзләрендә балкыган хисне «укытучысына хөрмәтедер» дип юраган ана ир-ат киткәннән соң ачыктан-ачык сөю хисе икәнен күрде. Кызына әйтергә курыкты. Күңеленнән үзе дә ышанмады хәтта.

– Ай, балам, өйләнгән, ике баласы барлыгын аңлыйсыңмы соң син?!

Әнисе телдән әйтмәсә дә, барысын да аңлаганын белдерде. Ана күзеннән бернәрсәне дә яшереп булмый шул. Гөлкәйгә ялганлап торуның кирәге юк иде.

– Әни, мин аны өзелеп яратам бит.

– Ярамый, кызым, болай яратырга ярамый! Мондый мәхәббәт гөнаһ ул, зур гөнаһ, балам! Калдыр син бу уйларыңны!

– Әни, ә син әтине яраттыңмы?!

Сәрви апа тынып калды. Алар ярәшеп өйләнештеләр. Сәрви Салихҗанны күреп белсә дә, элек аралашканнары юк иде. Яраткандыр инде, ничә ел гомер иттеләр бит. Кычкырышмадылар, ятларга карамадылар...

– Яратмыйча, кызым. Ирең булган кешене яратырга Алла куша.

– Ә син аны онытып, башка кешегә кияүгә чыга алыр идеңме?!

– Көфер сүз сөйлисең, Гөлкәй! Укытучың сиңа тиң түгел, балам! Араларына кермә, балаларын аталарыннан мәхрүм итмә! Хатынының күз яшьләрен җыйма, Гөлкәй! Болар сиңа бәхет китермәс! Ходай каргышыннан саклан!

– Әй әни, нишлим соң! Әгәр Ходай Тәгалә безне шулай яраткан икән, нишлим соң?! Минем күңелгә бу гыйшыкны Ходай Тәгалә салмаганмыни?! Син бит әйтә идең, дөньядагы бер эш тә Ходайның кодрәтеннән башка эшләнми, агачтан яфрак та төшми дип әйтә идең! Шулай булгач, безне ул очраштырмаганмыни?!

– Әстәгъфирулла, кызым, ни сөйлисең син! Сезгә җибәрелгән сынау ул, кызым, яхшы аңла!

Гөлкәй дәшмәде. Сынаумы, түгелме – анысын киләчәк күрсәтер. Әлегә ул ярата, аны сөяләр – моннан да зуррак бәхет булуы мөмкинме соң?! Сәрви апа да үзен бераз тыйды. Юк, болай Гөлкәй берни аңламас. Тынычлап әйтергә кирәк. Күңеленә шайтан коткысы керсә, тиз генә котылырмын димә.

– Кызым, син бит акыллы, тыңла әле, балам. Уйлап кара бераз. Ул өйләнгән, хатыны, балалары бар. Янында яшь кызлар кайнап тора. Шуларның берсе – син. Аңа синең башны әйләндерү берни дә түгел! «Яратам» дияр, кочаклар, үбәр, үзенә кирәген алыр да ташлап китәр. Кемгә кирәк булырсың син шуннан соң?! Кем кияүгә алыр үзеңне?!

– Ул мине ярата, әни. Миңа аннан башка беркем кирәк түгел. Хәтта мине алдаса да, башка беркемгә дә кияүгә чыкмаячакмын.

Харап булган икән баласы. Соң икән, соң. Гөлкәйнең холкын белә Сәрви – нәкъ әтисе кебек, бер фикер башына кереп утырган икән инде, тиз кенә чыгарырмын димә. Үзе кискән агачка абынып аягын сындырмыйча, барган юлын ташламас... Сәрви авыр сулап куйды. Нишлисең, барысы да Алла кулында.

– Барысы да Алла кулында, кызым. Болай әйткәнне аңламый торган булгач, мин берни эшли алмыйм инде. Ничек ул бәндәнең безгә тукталырга бите җиткәндер.

– Безгә килгәндә ул минем яратуымны белми иде әле, әни. Мин аңа киткәндә әйттем. Яхшы кеше ул, син юкка борчыласың, әни. Ул башта үзе үк мине кире какты. Соңыннан гына «яратам» диде... Ул да мине ярата, әни, тик белдерәсе генә килмәгән!

– Әй, балам, икегезнең берегезгә аек акыллар бирсә иде Ходай! Амин!

...Мансур Ибраһимович һәрвакыт аек акыллы иде. Бу юлы акылы үзенә хыянәт итә башлады. Казан аэропортында самолеттан төшүгә үк каршы алучы кешеләр арасында калын кара толымнарны эзләде. Берничә сәгать эчендә ул әлеге толымнарны, кара күзләрне сагынырга өлгергән иде. Соңыннан үз җүләрлегенә үзе шаккатып, автобуска ялгызы гына атлады. Әле сентябрьгә кадәр айдан артык вакыт бар...

*Өченче бүлек*

## Әлфис

– Әти, ә бу болан баласы янында аның әнисеме, әллә этисеме?!

Мансур Ибраһимович Рөстәмне, җилкәләреннән төшереп, җиргә бастырды да, елмаеп:

– Ә син үзең ничек уйлыйсың? – диде.

Рөстәм, башын уңга борып, җилкәсен сикертте:

– Белмим тагы... Әниседер инде. Алайса, аның этисе кайда?!

Мансур Ибраһимович бер мәлгә аптырап калды. Янында малайның бетмәс-төкәнмәс сорауларына җавап табарга Розалия дә юк. Алар зоопаркка чыгып киткәндә, әниләре эшкә җыенып калды.

– Шуны да белмисең, Рөстәм. – Быел икенче сыйныфны тәмамлаган Руслан эшлекле кыяфәттә этисе өчен җавап бирергә булды. – Аның этисе, ризык алып кайтырга дип, ауга чыгып киткән. Шулай бит, эти?!

Әй бу балалар дөньясы. Әле генә Мансур Ибраһимович хайваннарның кешеләр кебек гаиләле булып яшәмәүләре, зоопаркта бик сирәк бала тудырулары турында аңлатырга тырышып авыз ачкан гына иде, Русланның җавабыннан соң ачылган авыз шап итеп ябылды. Балаларга синең лекция укуың кирәкми шул...

– Әлбәттә, шулай, улым. Әйдәгез, әнә тегендә маймыллар сикерәләр, шулар янына барыйк.

Руслан белән Рөстәм, этиләреннән бер адым да калмый, алга атладылар. Рөстәм кулындагы чыбык белән тирә-яктагы үләннәрне кыя-кыя, сикерә-йөгерә атлый, ә Руслан нәкъ менә этисенең адымнарын кабатларга тырышып, бик җитди кыяфәт белән янәшәдән бара. Гомумән, Руслан өчен этисе – кумир. Кечкенәдән үк Розалия ханым Русланга чуар футболкалар кидерә алмый газапланды. Барлык балалар яратып кигәнне Русланның киясе килмәде. «Миңа этинеке кебек ак күлмәк алыгыз!» дип үкерде. Ак күлмәктән соң галстук белән чалбар таптырды. «Эти кебек булам мин!» диде. Моның үзенең сәбәпләре дә бар иде, әлбәттә. Руслан – беренче бала, аны тапканда әле Розалиянең аналык хисләре уянмаган иде... Бала чүпрәкләрен күргәч, күптән түгел генә институт бетергән кызның коты очты. Юк, бу мәхшәрне

юганда аның тырнаклары сыначак. Гомумән, йокысыз төннән соң ул кеше түгел. Төн Розалиягә йоклар өчен бирелгән. Ә монда ниндидер кечкенә төргәк самолет үкерүеннән дә катырак тавыш белән үкереп ята. Күкрәк сорый. Юк, ул бу газапны күтәрә алмый. Хатынның ун көн дигәндә сөте кипте. Ә Русланда аллергия башлангач, Розалия өчен шунысы ачыкланды: ул бала карар өчен сәләтле түгел. Ул әле «ана» дигән бөек исемне кабул итү дәрәҗәсенәирешмәгән. Таба ала, ләкин бага алмый. Шулай итеп, барлык гаилә мәшәкатьләре Мансур Ибраһимович өстенә ятты. Әйе, аның аспирантура бетерәсе, диссертация яклыйсы бар, ләкин аңа авыр түгел иде. Ул яшь, таза, җегәрле иде. Бу кып-кызыл төргәген дә күр әле син аның: Мансур кулына эләгү белән тынычлана, бишеккә салалармыни?! Бишек дигәннән, Мансур Ибраһимович шәһәр квартирасына хас булмаганча, авыл өендәге кебек итеп, сиртмәле бишеген дә көйләп куйды. Шуңа күрә көндез бала карарга килгән Розалия әнисенең дә эше җайланды: баланы бишеккә сала да, кәнәфигә утырган килеш, аягы белән генә чайкатып утыра, үзе гәзит-журнал укый... Розалия мондый эшләрдән азат иде. Бәлки, шуңадыр, икенчегә балага узганын белгәч, артык истерика куптармады, Мансурга «үзең карарлык булсаң, табам, мин карамыйм» диде. Икенчеләре – Рөстәм – тыныч булды. Күкрәк сөте имгәнгәме, беренче айларда көн-төн йоклаудан башканы белмәде. Бәлки, шуңадыр Розалия дә беркадәр үзгәреп китте, тырнакларын кызганып кына булса да, сирәк кенә икенче баласының чүпрәкләрен юудан да тайчынмады, Русланга да якынайды сыман... Тик барыбер балаларга Мансур якынрак иде. Ярата ул аларны: йоклаганда малайларының колак артына борынын куя да, шушы тәмле истән ләззәтләнеп, гомере буе шушындый кечкенә малайлар үстерергә сәләтле икәнен уйлап ята. Күрәсең, бу сәләт, бу йомшаклык аңа әнисеннән күчкәндер инде.

...Көне буе төрле-төрле кошлар, җәнлекләр карап, йөгереп-куышып, балалар арыдылар, Рөстәм трамвайда кайтканда ук Мансур Ибраһимовичның кулларында йоклап китте. Руслан әтисенең янәшәсендә бик җентекле кыяфәттә тәрәзәгә карап утырган була, тик кайчакта малайның керфекләре кушыла да башы тәрәзә пыяласына бәрелә. Руслан шунда ук күзләрен ача, әтисенә карый. Янәсе, менә нинди зур ул, әтисе кебек трамвайда йокла-

мыйча да кайта ала... Юк, Мансур Ибраһимовичка бу ике нарасыйдан да кадерлерәк кеше юк. Аһ, Гөлкәй... Син икенче дөньяда, син бу сабыйлар янында була алмыйсың. Син – минем хыялым, беркайчан да тормышка ашмаячак татлы, ләззәтле хыялым. Һәм ялгышым. Сиңа, башымны югалтыр дәрәҗәдә кайнарланып, мәхәббәт сүзләре пышылдаганда, мин ялгыштым. Я-л-г-ы-ш-т-ы-м!!! Әлеге сүз инде берничә атна буена Мансур Ибраһимовичның миен бораулый, төннәрен йокларга ирек бирми... Уйламаган ул, сабыйлары хакында уйламаган. Розалияне сабыйлары хакына кире кайтаруы турында уйламаган. Ул сабыйларына хыянәт итә алмый. Ул аларны ташлап, икенче бер хатын-кыз белән яши алмый. Хәтта ул хатын-кыз өзелеп сөйгәне, көтеп алган яры булса да. Хәтта Гөлкәй булса да...

...Гөлкәй дә бу вакытта, тулай торакның тәрәзәсеннән карап, нәкъ Мансур Ибраһимович турында уйланып утыра иде. Нинди бәхетле ул! Иңнәренә канат куйгандай, иптәшләренә караганда бер атна элегрәк Казанга очып килде, китапханәгә барды, китап бирүче Рәйханә апасына үзе урынында эшләп торганы өчен рәхмәт әйтте, Себер күчтәнәчләре тапшырды. Өзелеп сөйгән укытучысын очратмаммы дип, ничә тапкыр университет тирәсен әйләнде... Йөрәге өзелеп очрашуны көтә иде. Институтка барып, расписание алып кайтты. Мансур Ибраһимович быел тагы алар төркемендә укыта икән... Бу юлы логика – мантыйк – фәненнән керә. Нәкъ шулай ук, былтыргыча: лекцияләр дә укый, гамәли дәресләрне дә үзе үк алып бара... Нинди бәхет!

...Беренче булып Гөлүсә килде. Зур сумкаларын идәнгә ыргытты да: «Гөлкәй! Җаным! Үләм икән! Исәнме!» –дип, сөрән салучылар тавышы белән кычкырып, Гөлкәйнең кочагына ташланды. Бер-берсен зыр-зыр әйләндереп туйгач, кызлар караватларга утырдылар, яңадан бер-берсен күздән кичерделәр. Гөлүсә әллә ни үзгәрмәгән, тик кояш ашаудан тәне каралып, сары чәчләре агарып-аксылланып киткән дә борын өстенә мул итеп сипкелләр сибелгән. Гөлкәйгә бик җентекләп карап торганнан соң:

– Гөлкәй җаным! Үзгәргәнсең диимме соң? Әллә тагы да матурлангансың инде? – дип, тагы Гөлкәйнең кочагына ташланды. – Сагындым, ай-яй, үлеп сагындым үзегезне!

Гадәттә үзен тыныч тоткан Гөлкәйнең кыланышларында, чыннан да, ниндидер үзгәреш сизелә иде. Гөлүсәнең

сүзләренә кычкырып көлеп җибәрде, күзләреннән якты нурлар коелды сыман. Тормыштан бик канәгать кешеләр шулай көләләр.

– Үзгәргәнменме?! Картайгансың диясең киләме?! Сездән башка гына унсигезне тутырып килдем ләбаса!

– Кит аннан! Әйе шул, синең туган көнең июльдә ич! Котлыйм, чын күңелдән котлыйм, дустым! Бәхетле бул, сау-сәламәт яшә!

Гөлүсәнең ярты вагон сыярдай сумкасын бушатып, кызлар чәй эчәргә генә утырганнар иде, каты итеп ишек шакыдылар, ул да булмый бүлмәгә, томырылып, Чулпан килеп керде. Әстерхан кызы, кап-кара булып кояшта янган, нәкъ чегән кызы кыяфәтенә кергән, тик зәңгәр күзләре генә бу кыяфәткә туры килмичә, кызның башка кавемнән булуын искәртеп торалар иде.

– Кызлар! Казанга көньяк сәламнәре алып килдем, кабул итәсезме?

Гөлүсәнең гаҗәпләнүдән күзләре түгәрәкләнде.

– Үләм икән! Чулпанмы соң бу?! Әллә чегән кызымы?! О-о!!!

Кызлар тагы, бер-берсенең кочагына атылып, зыр-зыр әйләнделәр, бер-берсен чеметкәләп, көлешеп туйгач, өстәл артына утырдылар.

– Йә, кызлар, җәй көннәре ничек үтте? – Чулпан, ике көн буе чәйсез торган кешедәй, бер йотуда чынаягын бушатты. – Ай-яй эчәсем килгән, тагы берне ясап алыйм әле?

– Рәхим итеп. Җәй көннәре авылда печән чабып, киптереп, алып кайтып һәм өеп үтте. – Гөлүсә әлеге процессның нинди әһәмиятле икәнен күрсәтергә теләгәндәй, куллары белән һәрберсенә ымнар ясап сөйләде. – Тагы суган, чөгендер эшкәртеп, чүп утап, кәтмәнләп һәм башка шундый эшләр эшләп үтте.

Чулпан, гаҗәпләнгәндәй, Гөлүсәгә борылды:

– Нигә, бер дә ял итмәдеңмени?

Гөлүсә көлде генә.

– Әйтәм ич, ял итүем шундый эшләр эшләп үтте. «Авылда ял итү» дигән сүз үз эченә әлеге процессларны ала. Шул авылда ял итү дип атала.

Гөлүсәнең көлүенә кызлар кушылды. Көлеп арыгач, Гөлкәйнең җәй көне нәрсә эшләве белән кызыксындылар. Кызда былтыргы тартынудан җилләр искән иде.

– Бездә әлеге процесслар бераз киметелгән формада

кабатлана, – диде ул, йөзендә елмаю балкытып. – Ягъни җәй көне миңа да чүп утарга һәм печән өстендә аш әзерләп торырга туры килде. Дөрес, бездә печәнне урманда гына калдыралар, өйгә үк алып кайтмыйлар. Сазлыклар күп бездә, шуңа юл туңгач, ягъни кыш көне генә печән-саламны сөйрәтеп алып кайталар. Моннан тыш, Себернең урман-күлләрен үзем белән алып китеп булмады, шуңа Казанга аларның кечкенә копиясен эшләп алып килдем. Таныш булыгыз: минем туган ягымның иң сихри күле – Камышлы күл.

Гөлкәй күрсәткән юнәлештә стенага борылдылар. Кызның караваты янындагы стенага рамкага утыртылган рәсем эленгән иде. Чулпан белән Гөлүсә гаҗәпләнүдән телсез калдылар, шактый озак рәсемгә текәлеп торганнан соң, Чулпан әйтә куйды:

– Туктале, Гөлкәй, син моны үзем ясадым дип әйтергә телисеңме?!

Гөлкәй баш какты.

– Әлбәттә, үзем. Тагы шул сихри күлнең сихерләре ярдәм итте.

Гөлүсә тел шартлатты.

– Ай-яй, дустым... Карале, ә нишләп ул каенның очлары корыган?!

Гөлкәйгә дә беркадәр моңсу булып китте.

– Бездә каен сирәк үсә бит... Үскәне дә мондагы кебек туры, төз түгел, җиргә сыгылып үсә. Ачык җирдә, юл буенда үскәннәренең очлары корый. Поезддан карап барганда бигрәк кызганыч инде үзләре.

Гөлүсә һаман сихерләнеп рәсемгә карап тора иде әле.

– Ай, Гөлкәй. Рәсем ясаганыңны беләидем, ләкин болай итеп... ясыйсыңдыр дип уйламый идем. Нигә син рәссамлыкка укырга кермәдең соң?!

Гөлкәй көлде генә. Әгәр рәссамлыкка укыта торган җирдә Мансур Ибраһимович укытса, әлбәттә, керер иде... Тик аңа бу институтта да яхшы.

– Ә син, Чулпан, кайда булдың? Синнән, шәт, печән җыйдырмаганнардыр? Шәһәр кызы ял итә белә инде ул, әйеме?

Чулпан серле кыяфәттә күзләрен кысты.

– Минем кайда ял иткәнне гомердә дә әйтеп күрсәтә алмыйсыз.

– Йә, ялындырма инде, әйт, кайда ял иттең? Квартирадан да чыкмагансыңдыр әле.

– Шулай ди менә. Хәзер. Апагыз, беләсегез килсә, җәй көне стройотрядта булды. Студентларның төзелеш отрядында.

Гөлкәй белән Гөлүсә аңламадылар. Нәрсәседер таныш иде бу атаманың, кайдадыр ишеткәннәре бар кебек иде... Чулпан, кызларның аңламыйча торуларын күреп, көлеп җибәрде.

– Әһә, белмисезме?! Анда беренче курс студентларын бик алмыйлар шул, шуңа белмисез дә. Стройотряд ул – студентларның җәйге ялларын файдалы үткәрү максатында төзелгән хезмәт отрядлары. Колхоз-совхозларга уңышны җыеп алуда ярдәм итү өчен төзелә. Аңлашыламы? Җәй буе урып-җыюда яки төзелештә эшлисең дә аннан сиңа акча бирәләр.

Чулпан, бераз тынып торганнан соң, дөньяның иң эшлекле кешесе кыяфәтендә дәвам итте:

– Җәй буе помидор белән кавын-карбыз җыеп, дөресрәге, ашап, күзләр орбитадан чыга язды, мин сиңайтим. Башка күрәсем дә килми ул яшелчә-җимешләрне. Ә менә кичке уеннар, кызлар! Гомердә онытасым юк. Ул учак янында гитарага җырлап утырулар дисеңме, ул биюләр, ул сөйләшүләр... шундый романтика анда, кызлар, шундый романтика!!! Бер көтү егетләр!!! Сине сайламыйлар, син сайлыйсың! Барганыма һич үкенмим!

Чулпан шундый ымсындырып сөйли иде, бераздан Гөлүсә үпкәләбрәк әйтеп куйды:

– Шулкадәр әйбәт булгач, нигә безне дәшмәдең соң? Без дә барган булыр идек. Алайса, үзе генә барган да хәзер мактанып утыра.

– Әй, кызлар, мин бит Әстерханга кайткач кына, абый әйтүе буенча аның отрядында гына эшләдем! Үзем генә булсам, әниләр һич җибәрмәс иде! Киләсе елга, Алла теләсә, күз күрер. Беләсезме, мин нинди генә мәзәк ишетмәдем анда! Менә тыңлагыз әле.

Чулпан, күрәсең, артыграк мактанып ташлавын сизде, шуңа сүзне икенчегә борырга теләп, тавышын үзгәртәүзгәртә, мәзәк сөйләргә кереште:

– Ике грузин сөйләшә икән. «Карале, кадерлем, Вован «Волга» сатып алган, ди, ишеттеңме? Һич аңламыйм, нәрсәгәдер аңа ул пароходлар, пристаньнар, көймәләр һәм балыклар...»

Кызларның яңгыравык тавышлары бүлмә эченә генә сыймый, коридорга, ачык тәрәзәдән урамга ташып чык-

ты. Бүлмә үзе дә мондый тансык көлүне сагынган иде, ахры, танылган артистларның стенадагы акшар, буяу купкан урынга ябыштырылган портретлары да кызларга кушылып көлә сыман тоелды...

* * *

...Мансур Ибраһимович бу юлы аудиториягә бераз көттеребрәк килеп керде. Гөлкәйнең дулкынланудан эче кымырҗып алды, яңаклары кызарып чыкты. Күпме көтте ул бу мизгелне, күпме көтте! Менә хәзер аларның күзләре очрашыр... Шунда Мансур Ибраһимович Гөлкәйнең ничек сагынуын күрер, тояр... Менә хәзер... Тик Мансур Ибраһимович йөз студент арасыннан Гөлкәйне эзләп табарга ашыкмады. Хәер, аны эзлисе дә юк – менә ул, иң алгы рәттә Рәмилә янәшәсендә утыра. Нәкъ укытучы каршында. Сөйгәне каршында. Ә сөйгәне аны күрми, күрми, күрми... Әллә ул Гөлкәйне бер дә сагынмаганмы?! Әллә аны күрергә теләмиме?! Мөмкин түгел!.. Гөлкәй иреннәре кипшенүен тойды. Ярга атылган балык кебек, суларга һава җитми башлады. Укытучы аңа үтәли карап, күрмичә, студентларга нәрсәдер сөйли иде. Тавышы колакны иркәли, тик аңга барып җитми... Туктале, болай хискә бирелергә ярамый. Гөлкәй, беренче калтыравын басып, үзен нәрсәдер уйларга мәҗбүр итте. Бераз йөрәге урынына утыргач, үзалдына елмаеп куйды. Вәт җүләр ул!!! Җүләр булмый! Тиле! Мансур Ибраһимович укытучы лабаса, йөзләгән студент алдында Гөлкәйне килеп кочакласынмыни инде! Әлбәттә, ул Гөлкәйне күрмәмешкә салыша! Шулай кирәк. Соңыннан, барысы да соңыннан. Күрешерләр дә, аңлашырлар да. Гөлкәй җиңел сулап куйды, укытучы сүзләре колагына үтеп керә башлады.

– Мантыйк кайчандыр фәлсәфә фәненнән аерылып чыккан. Мин сезгә бу турыда беркадәр сөйләгән идем инде. Барлык фәннәрнең башлангычы ул – фәлсәфә фәне. Искә төшерик: «Бердәм дөнья кеше тарафыннан да, Алла тарафыннан да яратылмаган, ул мәңгелек кабынып һәм сүнеп торган уттан яралган, ул булган, ул бар, һәм ул булачак». Кем сүзләре бу?!

Аудитория дәшмәде. Күрәсең, җәй көннәрендә мәңгелек дөнья турында уйланырга студентларның вакытлары калмаган иде. Мансур Ибраһимович та җавапны озак

көтмәде. Ул да студентларның белемнәре имтихан алдыннан чүпрә кебек күпереп, аннан соң сулганын күптән белә иде булса кирәк.

– Алайса, икенче бер канатлы гыйбарә, шул ук авторныкы. Бәлки, бусы истә калгандыр: «бер үк елгага ике тапкыр кереп булмый». Кем әйткән моны?!

Бусын Гөлкәй дә белә иде, шунда ук кул күтәрде. Мансур Ибраһимович аның кул күтәргәнен күрде, бик яхшы күрде, тик сүз бирергә ашыкмады. Тагы бер тапкыр сорауны кабатлады. Күрәсең, бу юлы тагы берничә кул күтәрелгәндер, Мансур Ибраһимович арттагы рәттә утырган кыздан сорады:

– Юк, Вәлиева, Платон түгел. Фейербах?! Фейербах кайсы гасырда яшәгән соң? Бераз уйлап җавап бирегез. Кем белә тагы?

Гөлкәй кул күтәреп утыруын дәвам итте. Юк, сорамый аннан укытучы, сорамый. Нигә инде? Гөлкәй янында утырган Рәмилә түзмәде, кычкырып әйтә куйды:

– Мансур Ибраһимович, Якупова белә.

Мансур Ибраһимович, яңа гына күргәндәй, Рәмиләгә борылды. Күз карашында салкынлык чагылып китте.

– Сездән сорамадым, Хәсәнова. Аудиториядәге тәртипне бозарга уйласагыз, хәзер үк чыгып китә аласыз.

Рәмилә шунда ук башын аска иде, бераз утыргач, борылып, Гөлкәйгә текәлде. Кызның карашында гаҗәпләнү чагыла иде.

Мансур Ибраһимович шундый ук салкын тавыш белән дәвам итте:

– «Бердәм дөнья кеше тарафыннан да, Алла тарафыннан да яратылмаган, ул мәңгелек кабынып һәм сүнеп торган уттан яралган, ул булган, ул бар, һәм ул булачак» дип, бөек философ Гераклит әйткән. Инде уйлап карагыз: әгәр галим тарафыннан телгә алынган ут кабынып яисә сүнеп тора икән, димәк, аны кемдер яисә нәрсәдер кабыза һәм сүндерә дигән сүз булып чыга. Без фикер йөртү нәтиҗәсендә алдагы гыйбарәнең төгәл булмавын ачыкладык. Бу – мантыйкый алым. Кем яисә нинди законнар дөньяны кабызып-сүндереп, икенче төрле әйткәндә, үзгәртеп тора ала?! Мантыйк фәнендә бу мәсьәләләргә дә тукталырбыз.

Яңадан Мансур Ибраһимовичның тавышы ерагайды, яңадан Гөлкәйнең аңына шик-шөбһә үтеп керде. Нишләп әле укытучы Рәмилә белән шулай дорфа сөйләште?!

Рәмилә бит тәртип бозмады, киресенчә, ул Мансур Ибраһимовичның игътибарын җәлеп итәргә генә теләде.

– Нәрсә булган бу Мансур Ибраһимовичка? Әллә хатыны белән кычкырышкан инде.

Аһ бу Рәмиләне. Мансур Ибраһимович турында сөйләгәндә, хатынын искә алмый калмый. Әллә юри Гөлкәйгә төрттерәме? Гөлкәй дустының соравына җавап итеп җилкәсен генә сикертте. Әле ул үзе дә белми... Менә дәрестән соң янына барыр да барысын да ачыклар.

Тик дәрес бетүгә, Мансур Ибраһимович элекке кебек тоткарланмады, тиз генә кәгазьләрен җыйды да аудиториядән чыкты да китте. Гөлкәй иптәшләрен кузгаткалап коридорга атылып чыкканда, укытучыдан җилләр искән иде инде. Гөлкәй берни аңламады. Көтеп алган уку көне авыр хис белән тәмамланды. Мансур Ибраһимович үткәрәчәк киләсе дәрес әле алдагы атнада гына...

Соңгы көннәрдә тулай торак күзгә күренеп җанланды, киләсе студентлар килеп беткән, бүлмәләренә урнашканнар иде иде. Фаягөл генә күренми. Кызлар бүлмәсендә дә җанлылык, яңа үзгәрешләр барлыкка килде – Зөлфия үзе белән кечкенә генә аквариум алып килгән. Шунда ук су тутырып, чистарырга – тонарга куйдылар. Икенче көнне Чулпан, полиэтилен пакетка салып, каяндыр балыклар алып керде.

– Бүләк иттеләр, – диде ул кызларның соравына. – Гади булсалар да, койрыклары матур үзе тагы. «Гупяшка» дип аталалар.

Өч балык, аллы-гөлле төстәге койрыкларын болгап, үзләренең яңа өйләре белән таныша башладылар. Әле аквариумда суүсемнәр дә, ташлар да юк, гади суда гади балыклар йөзеп йөри... Шулай да кызларга бу өстәмә куаныч булды.

– Ура, хәзер безнең йорт хайваннарыбыз ишәйде. – Гөлүсә һәрвакыттагыча бүлмәне яңгыратып көлде. – Хуҗа абзыйга үзенә генә күңелсез иде, хәзер инде аңа иптәшләр табылды. Туктале, ә нишләп алар өчәү?! Кайсы кыз, кайсы егет?! Нигә парлы түгел?!

Кызлар да сораулы карашларын Чулпанга төбәделәр. Тегесе «әллә тагы» дигәнрәк кыяфәт белән җилкә җыерды.

– Шулай бүләк иттеләр инде. Мин балыклар буенча специалист түгел, биргәнне генә алдым. Алайса, тагы берәрне сорап карармын.

Өч балык. Өчәү. Гөлкәй хәтта авыр сулап куйды. Нишләп шулай килеп чыга соң әле – нишләп бу дөнья парлы түгел?!

Икенче көнне ике пар дәрес кенә булды. Өченчесе башлангач, Гөлкәйне хәсрәткә салган яңалык кереп әйттеләр – алар курсы бәрәңге җыеп алуда ярдәм итү өчен колхозга китә. Ике атнага! Бүген, тиз генә тулай торакка кайтып, эш кием-салымнарын, кирәкле әйберләрне сумкага тутырасы да иртәгә иртә белән институт баскычында җыеласы. Гөлкәй бу турыда бөтенләй уйламаган иде. Бердән, Мансур Ибраһимовичны күреп сөйләшә алмый кала, икенчедән, китапханәдәге эшендә тагы кыенлык килеп чыга. Рәйханә апасы ни әйтер...

– Кызлар, нишлибез инде?! – Зөлфия, еларга җитешеп, өр-яңа курткасын чемоданыннан тартып чыгарды. – Быел гына алдылар әниләр, ничекләр итеп бәрәңге җыярга киеп барырмын инде?! Карарлыгы калмас бит, Ходаем!

– Аптырама, Зөлфия, хәзер җаен карарбыз. – Фаягөл килгәнче кызлар белән яшәп торган Чулпан куртканы кулында әйләндерде. – Әлләй, матур булган. Котлы булсын, өстеңдә тузсын, дустым. Минем үземнең дә бер эш киемем юк, ләкин табабыз аны. Мир төкерсә, күл була. Алдагы елларда барганнарныкы әллә кая китмәгәндер, шул чумаданнарында тузанланып кына ятадыр. Тәк, кемнәрнең нәрсәсе юк?!

Чулпан кемгә нинди кием җитмәгәнен билгеләде дә Гөлүсә белән таныш-белешләреннән кием җыярга чыгып та киттеләр. Фаягөл, күрәсең, колхозга барырга да килеп җитми инде. Нәрсә булды икән?! Менә әкәмәт, бер ел буе бергә торып, өй телефонын да язып алмаганнар. Шалтыратып, хәлен белешерләр иде, ичмаса. Кайчакта битарафлыктан да начар әйбер юктыр сыман...

Озак та үтмәде, бер кочак кием күтәреп, Гөлүсә белән Чулпан бүлмәгә кайттылар.

– Кызлар, һәркайсысының кесәсендә кайсы бүлмәдән алынганлыгы турында язу бар, югалтмагыз. Итекләрнең эченә язылган.

Итекләр барысына да кирәк иде, ярауга-ярамауга карап, һәркем үзенә дигәнен сайлап алды. Бу студент халкы гаҗәп инде. Минут эчендә бүлмәдә киемсезләр калмады. Кызлар, гөр килеп, Чулпанга рәхмәт әйтә башладылар.

– Әй, миңа нәрсә! – Чулпан, исе китмичә, кулын гына селтәде. – Безнең бүлмәгә ярты «общага» җыела, бүлмә һавасын сулыйлар бит әле. Шушындый кыен вакытта да ярдәмнәре тимәгәч, мин ни өчен аларга чәй куеп йөрим соң?!

Икенче көнне студентларны алып китәргә тиешле автобуслар, бик озак көттереп, төш вакытында гына килделәр. Кечкенә генә «пазик»ка утызлап кеше кереп тулуын күреп, автобус йөртүче бераз канәгатьсезлек белдерсә дә, артык чәпчемәде, кушылган тек кушылган дигәндәй, озата баручыны эзләп тапканнан соң, кузгалып та киттеләр. Казанны чыкканчы автобуслар бергә бардылар, аннан төрлесе-төрле колхоз-совхозларга таралыша башладылар. Шактый озак бардылар әле алар. Гөлкәйләр утырган автобус бигрәк күңелле булып чыкты: студентларның, машина тавышын басарга теләп, кычкырып җырлый-җырлый тамаклары карлыкты. Бераздан юл авыл ягына борылды, автобус әле бер якка, әле икенче якка янтая башлады, әледән-әле сикергәләде, моторы пошкырынды, тәгәрмәчләр, баткаклыкка эләгеп, зырылдап әйләнә башладылар. Машина сикергән саен, кызларның әче тавыш белән чинап җибәрүеннән йөртүче бертуктаусыз сүгенде. Ниһаять, зур гына урманны чыккач, авыл үзе дә күренде. Студентлар җиңел сулап куйдылар. Аларны каршы алучы кеше председатель үзе иде.

– Килдегезме, кызлар, егетләр! – Башына козыреклы кепка кигән искиткеч зур мыеклы ир-ат, автобустан төшкән һәрбер студентны кочаклап алырдай булып, күрешеп торды. Үзе араларыннан «старший»ны эзләде. – Кайда соң әле җитәкчегез?

– Монда мин, монда. – Һаман машина йөртүчене көйләп-җөйләп йөргән аспирант егет рәиснең каршысына килеп басты. – Ирек булам мин, ә сез Җәүдәт Мияссәровичмы?!

– Нәкъ үзе. – Рәис канәгать йөзен тутырып елмайды. – Сездән башка эш харап – басу тулы бәрәңге. Бик вакытлы килеп җиттегез. Давай, бүгенгә клубта кунарсыз, аннан өйләргә таратырбыз үзегезне.

Студентлар, дәррәү кубып, рәис артыннан иярделәр. Көн кичкә авышкан, авызларына бер валчык кермәгән студентлар, авыл урамнарыннан барганда, коймадан иелгән алмагач ботакларындагы кып-кызыл алмаларны

эләктерә башладылар. Авыл халкы, әлбәттә, мондый кыланышны өнәмәде, кайбер йортлардан каһәрләү сүзләре ишетелеп калды. Хәер, ашау турында рәис тә кайгырткан икән: юл уңаенда колхоз ашханәсенә кереп, студентларны суынган борчак ашы белән тамак ялгатырга онытмады. Шуңа күрә, авылның икенче ягында биеклектә урнашкан клубка килеп җиткәндә, студентларның күңеле күтәрелгән, кәеф яхшы иде.

– Менә, кызлар, егетләр, бүгенгә урын әллә ни яхшы булмас, кызлар – сәхнәдә, егетләр урындык рәтләре артындагы буш урында ятарлар. Сезне, дөресен генә әйткәндә, болай күп килерсез дип уйламадык. – Рәис, сүзләрен раслагандай, куллары белән һаваны кистереп алды. – Шулай. Ирек, билгеләнгән дүрт әби бар, пажалысты, өч-дүрт кеше итеп таратыгыз балаларны. Калганнарны иртәгә урнаштырабыз.

Председатель киткәннән соң, аспирант Ирек кемнәрнең әбиләр янына китәсен ачыклады. Егетләр, әлбәттә, төнгелеккә биредә калырга булдылар. Һәрнәрсәгә өлгер Чулпан да чәчрәп чыкмакчы булган иде дә, Гөлүсә җиңеннән тотып калды: «Тукта, бүгенгә монда калыйк. Бәлки, иртәгә яхшырак йортлар бирерләр. Әбиләрнең черегән идәннәрен юарга өлгерербез әле». Ул арада шунда буталган авыл малай-шалайлары кызларны әбиләргә озата киттеләр. Калганнар, клуб тирәсенә чыгып, авыл белән таныша башладылар. Авыл шактый зур, ахры. Һәрхәлдә, Гөлкәй күреп өйрәнгән утыз-кырык йорт кына түгел инде биредә. Шулай да йортлары бик иске, начар күренәләр, капка төпләрендә дә күбрәк әби-бабай утыра. Вак-төяк малайлар күп түгел. «Яшьләр шәһәргә китеп беткәннәр, күрәсең», – дип уйлады Гөлкәй. Үз авылларында да шулай – мәктәп бетергән кыз-егетләрнең бик сирәге авылда кала. Күбесе, белем-бәхет эстәп, шәһәргә китеп бара... Ә колхозга булышырга шундый ук егет-кызларны, ләкин чит егет-кызларны шәһәрдән сорап кайтаралар. Гаҗәп инде бу дөнья.

...Төннең шактый салкын булуы ачыкланды. Идәнгә җәяргә матрац-түшәкләр биргәннәр иде, ләкин алары да сан ягыннан җитмәгәнгә, бер түшәккә икешәрләп ятарга туры килде. Өсләренә ябынырга да шулай ук – ике кешегә бер юка одеал... Болай да төн уртасына кадәр сөйләшеп-көлешеп яткан студентлар, бер-ике сәгать борсаланып яткач, торып, җылы киемнәрен киеп яттылар.

Барыбер салкын иде – таң атуга, йөткергән тавышлар ишетелә башлады...

Икенче көнне исә иртән үк яшьләрне агроном үзе килеп уятты. Кичәге колхоз ашханәсендә тамак ялгап алганнан соң, студентларны бәрәңге басуына алып киттеләр. Монда инде гөрләп эш кайный иде. Баксаң, колхозда вак-төяк эштә эшләүче апа-абыйларны да бәрәңге басуына җибәргәннәр икән. Студентларга чиләкләр тараттылар, бәрәңге буразналарын казып барган трактор артыннан кара туфрак өстендә чәчелеп-сибелеп калган бәрәңгеләрне җыярга һәм янәшәдә көтеп торучы биек әрҗәле машиналарга тутырырга куштылар. Бер караганда эш авыр түгел иде. Студентлар, шаян сүзләр әйтешеп, көлешә-көлешә, эш башладылар. Кызлар чиләккә тутыра, егетләр машинага илтә. Староста буларак Гөлүсә, бер урыннан икенче урынга йөреп, эш барышын күзәтә, аспирант җитәкченең һәрбер сүзен үтәргә тырыша, үзе дә эшкә катнаша иде. Икенче урында бәрәңгене капчыкларга тутырттылар. Янәсе, тегеләре – кышкылыкка саклау өчен булса, болары – көзге базарларда шәһәр халкына сату өчен. Чулпан командасы нәкъ менә шушында эләкте. Кыен түгел – кап-кара туфрак өстендә «менә ул мин» дип кинәнеп яткан сары гәүдәле эре бәрәңгене чиләккә саласы да, тулгач, абзыйлар янына барып, капчыкка бушатасы. Абзыйлар капчыкларны машинага төйиләр. Баштарак кызлар бу таныш түгел ир-атлардан тартынсалар да, соңыннан ияләнеп киттеләр тагы, шаярып та алгаладылар, исемнәрен дә белделәр. Әлбәттә, Чулпан-чая тырышты. Абзый дигәннәре утызның өске ягында булып, әле өйләнә алмый йөрүче колхоз егетләре булып чыкты.

– Кызлар, тырнакларыгыз нишләр инде, – диде берсе, уфтанган булып. – Шәһәр кызларының куллары бик назлы, диләр, ап-ак бармакларыгызны пычратырсыз инде.

– Пычратсак, юарга сезгә кушмабыз әле. – Чулпан оялып тормады. – Безнең тырнакларыбыз сынса сынар, ә менә сезнең безне күреп йөрәкләрегез ватылмасын, сакланыгыз!

– Йөрәкләр бетте инде, ватылды. Әллә берәрегез шушы безнең ватылган йөрәкләрне дәваларга янныбызда каласызмы?!

– Өметегезне сузмагыз, безнең йөрәкләр барысы да хуҗалы. Йөрәк дәвалаучыларны үзегезнең авылдан табыгыз!

– Табасы булса, тапкан булыр идек инде. Сезне көтеп яшәдек!

Капчык тоткан озын буйлы сары чәчле егет Гөлкәйнең чиләк белән килүен күрде дә, яртылаш тулы капчыгын күтәреп, каршысына чыкты.

– Миңа сал, чибәркәй. Мәңге бәхетле булырмын.

– Рәхим итеп.

Чиләкне күтәреп салганда, егет, Гөлкәйнең кулын эләктерергә чамалап, капчык авызын ычкындырып җибәрде. Сары бәрәңгеләр шыбырдап җиргә коелдылар.

– Әй, кызлар, – Гөлкәй кычкырып көлде. – Капчык авызы да тота белмәгән егетләр белән сөйләшеп торган булабыз, карагыз әле!

Үзеннән мондый кыюлыкны көтмәгән иде. Егет тә кызарды, сибелгән бәрәңгеләрне капчыкка салгалады да китеп барган Гөлкәй артыннан ташланды.

– Гөлкәй, йөгер, кач!

Чулпан тавышына борылып карася, үзен куа килгән егетне күреп, Гөлкәй дә, көлә-көлә, басу уртасына йөгерде. Ерак китәргә өлгермәде, сары чәчле егет, ике генә атлап, үзен куып та тотты, кулларына күтәреп, зыр-зыр әйләндерде.

– Җибәр, җибәр, дим! Җүләр!

– Минеке буласыңмы соң?! Әйе, дисәң, җибәрәм!

– Кит моннан! Минем егетем бар! Җибәр!

– Булса соң! Егетең еракта бит! Әйт, хатының булам, диген, шуннан соң җибәрәм.

– Җибәрмичә генә кара, хәзер председателегезгә жалу бирәм, – диде Гөлкәй, көлә-көлә.

– Алайса, гел шушылай күтәреп торам.

– Гомер буе күтәреп торырсыңмы?!

– Гомер буе күтәрәм! Әйт, синеке булам, диген!

– Вәт җүләр! Алайса күтәр. Миңа да бик яхшы, бәрәңге чүплисе юк! – Гөлкәй нишләптер яшьлектә була торган мондый уен-көлкегә бик шат иде. Юк, аның йөрәгендә бары бер генә ир-ат, бары берәү генә... Ә мондый уеннар – җүләрлек, тилелек... Яшьлек. Әле ул бит яшьлектә яши!

– Шушылай күтәреп үзебезгә алып кайтам алайса! Киттек!

Егет, Гөлкәйне күтәргән килеш, басу юлына, авылга таба атлады. Гөлкәй дә, уеннан уймак чыкмагае дип, курка калды, бар көченә кызларга кычкырды.

– Кызлар! Чулпан! Коткарыгыз!

Артларыннан, йөгерә-йөгерә, Чулпан белән Гөлүсә килеп җиттеләр. Ул арада аспирант-җитәкче күренде. Егет, чарасыз калып, Гөлкәйне җиргә бастырырга мәҗбүр булды, колагына гына:

– Күз салдым, кызый, үзеңә, онытма, – дип пышылдап калды.

Гөлүсәнең ачуы купкан иде.

– Кызлар, сез монда эшләргә килдегезме, әллә егетләр белән шаярыргамы?! Тизрәк җыеп бетерсәк, тизрәк кайтып китәбез бит! Нишләп председатель алдында безнең авторитетны төшерәсез?!

– Йә, Гөлүсә, кызма, без гаепле түгел, – диде Чулпан. – Егетләр үзләре безгә бәйләнә.

– Бәйләндереп тормаска иде!

– Алайса, безне теге якка күчер! – Гөлкәй, ымлап, бәрәңгене капчыксыз гына машина тутыручылар ягына күрсәтте. – Үзебезнекеләр янында тынычрак булыр!

– Барыгыз, үзегезнең урынга Ольга белән Римманы монда чакырыгыз! Алар сездән тәртиплерәк! Башка болай эш ташласагыз, деканатка билгеле булачак! «Стёпка»дан мәхрүм калуыгыз бар!

Кызлар Гөлүсәнең болай тузынуын җитәкчелек алдында гына икәнен бик яхшы аңлыйлар иде. Аңа да эш күрсәтергә кирәк бит. Әнә аспирант күрмәгән арада күз кыса... Хәйләкәр дә соң инде.

Ул арада төш җитте. Төшке ашны, бидоннарга салып, кырга ук алып килгәннәр иде, авылга кайтып йөрисе булмады. Төштән соң вакыт әкренрәк үткән сыман тоелды. Иртәнге җорлык суынып килә иде. Буыннар да талчыкты, тезләр бөгелми башлады... Арытты. Кичне көчхәл белән көтеп җиткерделәр. Әрҗәле машинага төялеп, яңадан клубка кайтып төшүгә үк, студентларны өйләргә тарата башладылар. Шул ук әрҗәле машина Зөлфия, Гөлкәй, Гөлүсә һәм Чулпанны тыштан таза гына күренгән бер өй янында төшереп калдырды.

– Әйттемме мин сезгә, әбиләрнең черек идәннәрен юып мәшәкатьләнмәячәкбез дип, – Гөлүсә торасы йорттан канәгать иде. – Менә, рәхим итегез. Бухгалтер өе!

Хуҗалар кызларны яхшы гына каршы алдылар. Кичке аш та ашаттылар, чәй эчерделәр. Дөресрәге, әле хуҗа эштән кайтып җитмәгән иде, хуҗабикә – Гайшә апа – кызларга ачык йөз белән торды. Шунда ук кисәтеп куярга да онытмады.

– Кызлар, яныгызга авыл егетләре килеп йөрмәсеннәр, – диде ул, беркадәр җитди итеп. – Минем үсеп килүче кызым бар, тәртипсез булып үсмәсен.

– Юк, юк, апа, – диештеләр кызлар, – без бернинди егетләргә дә карамыйбыз, Алла сакласын! Безнең егетләребез Казанда!

– Сез карамассыз да, сезгә карыйлар шул. Ел саен була андый хәл. Сак булыгыз, кисәтеп әйтәм.

Егетләр, чыннан да, көн саен килделәр. Бераз караңгы төшеп, күз бәйләнүгә, капка төбендә ниндидер хәрәкәт башлана иде. Караңгыда тәмәке утлары җемелдәшә башлый, йөткергән тавышлар ишетелә, йортның бүрәнәләренә кечкенә балчык кисәкләре ява... Гармун сызыла. Янәсе, кызлар, без монда – чыгыгыз. Кызлар да үз сүзләрендә торды – капка төбенә чыгу түгел, әлеге тәмәке утлары җемелдәшә башлау белән йокларга яталар иде. Хуҗа Бәдертдин абзый егетләр белән «разбираться» итәргә капка төбенә чыгып китә. Бераздан егетләрнең гармун тавышлары ерагаеп, дәртле җырлары ишетелеп кала:

Уйна тальян гармуныңны,
Телләре лә батмасын шул,
Уят үзәкләрен өзеп,
Кызлар йоклап ятмасын...

...Көннәр кояшлы торды. Бәрәңгене озакка сузмадылар – бер атна-ун көн дигәндә, утыз студентның, авырып, Казанга кайтып китүчеләрдән калган өлеше колхозның утыз гектарга утыртылган икенче икмәген җыеп та бирде. Тик «Казанга кайтабыз» дип шатланган студентларны бәрәңгедән соң чөгендер басуы көтә булып чыкты. Дөрес, председатель, яңа басуга чыкканчы, аларга әле ял итәргә һәм ...концертка әзерләнергә тагы бер көн вакыт бирде.

Концерт дигәннәрен һаман да шул тиктормас Гөлүсә белән аспирант Ирек уйлап таптылар.

– Безнең авылга килгән студентлар концерт куймыйча китмиләр иде. Без кемнән ким?! Ичмаса, әзрәк акча эшләрбез.

Ирек Гөлүсәнең соңгы сүзләренә акаеп карады. Янәсе, нинди акча турында сүз барырга мөмкин. Алар авыл халкын «культурный яктан агартырга» тиешләр. Бары шул гына. Гөлүсә дә аптырамады.

– Сез авыл халкы дигәч тә, аларны дөм кара наданнар дип уйламагыз инде, – диде ул, сак кына. – Мин бит юл чыгымнарын капларлык акча турында сүз алып барам.

Безне монда алып килгән өчен бензинга түләгәннәрдер бит?! Ә кем түләгән?! Институт. Димәк, безгә бу акчаны кайтарып бирергә кирәк. Сүз шуның турында бара. Сез каршымыни?!

Аспирантның әйтер сүзе табылмады. Шулай итеп, билет бәясен илле тиеннән килештеләр. Кызлар Гөлүсә белән горурланып куйдылар: кем-кем, ә менә Гөлүсә үзенең сүзен үткәрә белә инде...

Концерт программасын да Гөлүсә тиз төзеде.

– Чулпан, син биисең, – диде ул, ике дә уйламый. – Клубта сәхнә киемнәре бар, бу яктан кыенлык юк. Гөлкәй җырлый, Рәмилә шигырь сөйли. Зөлфия, син нәрсә эшлисең?!

– Нигә безнең бүлмә генә?! Нигә башкалар катнашмый?! – Зөлфиянең нәрсә эшлисе уйланылмаган әле. – Мин җырламыйм да, биимим дә, шигырь дә сөйләмим.

– Димәк, билет сатып торасың. Безнең бүлмә активлык күрсәтергә тиеш, чөнки сезгә дә таянмасам, мин кемгә генә таяна алам соң?! Әллә сез мине кыен хәлдә ташларга уйлыйсызмы?

– Ташламыйбыз, Гөлүсә, кайгырма. Башкалар да катнашсын дип әйтәм.

– Әлбәттә, катнаша. Өч номер белән генә концерт куймыйбыз инде, анысы билгеле. Мәсәлән, Михаил гитарада уйнар, Любаны рус биюләрен оештырырга күндерәсе булыр, тагы... Тагы кемнәр бар әле безнең?

– Исемлекне ал да инде, һәркемнең йөкләмәсен язып чык. – Гөлкәй җырларга һич тә каршы түгел иде. – Үзеңне дә кыстырырга онытма.

– Их, Фаягөл булса, ул акробатик күнегүләр ясар иде дә, юк шул...

Кызлар бер мәлгә моңсуланып алдылар. Фаягөлдән һаман хәбәр юк иде. Нинди генә булмасын, бергә яшәгән дус кызларын сагыналар иде алар...

Концерт буласы көнне көне буе яңгыр койды. Чиләкләп-чиләкләп, җирнең үзәгенә үткәреп, тоташ соры яңгыр стенасы көне буе күз алдында торды. Бер яктан бу бик әйбәт иде: басуга чыга алмадылар, көн репетиция ясап үтте. Икенче яктан мондый пычракта машиналар басуга керә алмыйлар, димәк, аларның монда торасы көннәре тагы арта... Гөлкәй болай да билгесез хәлдә өзгәләнә, төннәрен Мансур Ибраһимович, ачулы кыяфәт белән төшләренә кереп, үзәген өзә...

Үзләренең төркемнәрендә баянчы юк иде, авыл баянчысын дәштеләр. Аны күреп, Гөлкәй аһ итте: бу теге беренче көнне басу буйлап куышкан сары чәчле егет – Әлфис иде. Колхозда машина йөртүче булып эшли икән. Кичләрен клубта яшьләрне биетә. Ул да, Гөлкәйнең җырлавын белгәч, «карап карыйк әле» дигән кыяфәт белән баян каешларын җилкәләренә элде, сыздырып уйнап җибәрде.

– Нәрсә җырлыйбыз, чибәркәй?!

Гөлкәй Җәүдәт Фәйзинең Равил Фәйзуллин сүзләренә язган «Сагыш» җырын җырлыйсы иде. Егет көлде генә.

– Син аны миңа көйләп күрсәт, – диде. – Мин председатель Җәүдәт абыйдан кала, сезнең башка Җәүдәтегезне дә, Равилегезне дә белмим. Көе ничек ул җырның?!

...Коеп яуган яңгырга карамастан, клуб халык белән шыгрым тулды. Утырырга урын булмаганнар ян-яктагы буш урыннарга чүмәшкәннәр. Күрәсең, юлсыз-асфальтсыз бу якларны артист халкы бик якын күрми. Концертны Җәүдәт Мияссәрович (авылча – Каз Җәүдәте) башлап җибәрде.

– Хөрмәтле авылдашлар! – Председательнең тавышы шактый калын, көчле икән. – Быел безнең авылга бәрәңге алуда булышырга Казанда укучы студент яшьләр килде. Башка елларда, үзегез беләсез, «Оргсинтез» заводы эшчеләре булыша иде. Яшьләр яшьләр инде, яхшы эшлиләр, яхшы ашыйлар (зал елмаешып алды), зарланмыйлар, кушканны тыңлыйлар. Менә бүген, безнең күңелне күреп, концерт күрсәтергә дә исәплиләр. Бәрәңгене алар көче белән бик тиз, районда беренчеләрдән булып, җыеп алдык. Хәзер чөгендергә тотынырга исәп, Алла теләсә. Мин авыл халкы исеменнән әлеге кызлар һәм егетләргә рәхмәтемне белдерәм! Бик зур рәхмәт, егетләр һәм кызлар!

Зал гөрләтеп кул чапты. Беренче номерны (аны доклад дисәң, дөресрәк булыр) халык кызыксынып көтсә дә, өметләре акланмады: Ирек Бариевич, фәлсәфә кафедрасы аспиранты, яшь укытучы, Коммунистлар Партиясе Президиумының чираттагы утырышы турында чыгыш ясады. Халык бик сүлпән кул чапты. Шундый зур вакыйга белән авыл халкының аз кызыксынуы яшь укытучыны бик гаҗәпләндерде. Гомумән, соңыннан Ирек Бариевич үз-үзенә «бу авылда Президиум дигән сүзне аңлыйлармы икән?» дип сорау бирде...

Икенче булып Чулпан биисе иде. Тын залга авыл халкы бик яратып караган һинд киноларыннан дәртле көй

агылуы булды, халык тагы гөрләтеп кул чабарга тотынды. Ул да булмады, кызыл сариларын җилфердәтеп (каян тапкан диген!), сәхнәгә яланаяклы Чулпан йөгереп-биеп чыкты, матур буй-сынын әйләндереп-тулгандырып, килешле хәрәкәтләр ясый башлады. Халыкның исе китте. Ничек инде шулай, нәкъ менә кинолардагыча мул итеп сөрмә ягылган каш-күзләрне уйнатырга була?! Чулпанны кат-кат чакырдылар. Аннан шундый ук уңыш белән Гөлүсә шаян хикәя сөйләде. Алдагы номер Гөлкәйнеке иде. Шәһәр халкы алдында ничек җырласаң да ярый, ә авыл халкы көйгә-моңга бик сизгер... Тавыштагы ялган ноталарны хәзер тотып ала. Кыз, каушавын басарга тырышып, сәхнәгә чыкты, икенче яктан, баянын уйната-уйната, Әлфис күренде. Гөлүсәнең хикәясеннән соң көлеп туймаган халык, моңсу көйне ишеткәч, бераз тынычланып китте. Гөлкәй, Әлфиснең ым кагуына сизелер-сизелмәс баш селкеп, бер аккордны уздырып җибәрде, тынычланып, үз-үзенә ышанганнан соң гына, җыр башлады:

Мин сиңа йомшак таң җиле
Юллаган идем,
Чәчләреңнән иркәләр дип
Уйлаган идем,
Мин сине сагынып бер җыр
Чыгарган идем,
Җан дуслар яратып аны
Тыңлаган иде.
Җыр сиңа ошар дип йөрдем
Ваемсыз булып,
Ә ул сиңа барып җиткән
Авыр сүз булып...
Инде җилләр дә юлламыйм,
Чыгармыйм җыр да,
Теләсәң, үзең җанымны
Кил дә бер тыңла...

...Җырның көе дә, сүзләре дә бик моңлы. Сәхнә уртасында кызыл милли күлмәктән, чиккән ал алъяпкычтан басып торган, ике яклап үргән калын толымнары тезләренә кадәр төшкән Гөлкәйнең үзеннән дә бик якты бер моң сирпелә сыман. Бу кичне авыл егетләренең һәммәсе Гөлкәйгә гашыйк иде. Сызгыра-сызгыра, аяк тибә-тибә кызны яңадан сәхнәгә чакырдылар. Аңа бу турыда инде Әлфис әйтеп куйган иде.

– Кызый, син бер җыр белән генә котылам димә. Кимендә бер өчне әзерлә, – диде ул көндез, Гөлкәй тавышы-

на баянын тартып. Чыннан да, шулай булды. Икенче җырын җырлап бетерүгә үк, халык тагы давыл куптарды. Гөлкәй күрде: бигрәк тә арттагы рәтләрдә утырган, колхоз кырында сүз кушкан, капка төбенә җыелган буйдак егетләр тырыштылар. Концертны алып баручы Гөлүсә генә халыкны тынычландыра алды.

– Кадерле иптәшләр, безнең әле тагы бик матур җырлаучыларыбыз, бик матур биючеләребез бар. Әллә сез аларны тыңларга, күрергә теләмисезме?! Якупова Гөлкәй сезнең өчен соңрак җырлар. Ә хәзер сәхнәдә Хәсәнова Рәмилә! Каршы алыгыз!

Рәмилә сәхнәгә матур милли күлмәктән, башына ак калфак киеп, күзлеген салып чыкты. «Беркемне дә күрмәсәм, әзрәк каушармын» диде. Аның гомерендә беренче тапкыр сәхнәгә чыгуы иде.

Белмим, әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын,
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...

Такташ Такташ шул инде. Имеш, Такташ та булсын, халыкны да дулкынландырмасын. Рәмиләне дә чын күңелдән көчле алкышларга күмделәр. Аннан рус кызлары милли биюләрен башкардылар, гитарада уйнадылар, тагын татар җырлары, шигырьләре китте... Халык таралышканда, төн уртасы җитә иде инде.

– Уф, кызлар, сез ничек уйлыйсыз, без хәзер чәй эчәргә хаклымы?! – Гөлүсә кулындагы зур кошелёгын чыкылдатып япты. Хәйран гына акча җыелган. – Кайткач, мәйтәм, хуҗалардан чәй сорасак, ачуланмаслар бит?!

– Минемчә, ачуланмаслар. – Әлфис китмәгән икән әле. – Әйдәгез, кызлар, караңгыда таныш түгел егетләрнең үзегезне урлавы бар, машинада гына кайтарып куям. Каршы килмәсәгез.

– Ә ул дөрес әйтә, – Рәмилә, бераз Әлфискә карап торгач, егетнең сүзләрен җөпләп куйды. – Караңгыда пычракка батып ятуыбыз да бар.

Машинада кайту, дөресрәге, машина өстендәге арбада кайту, чыннан да, әйбәт булды: клуб төбендә, кызлар чыкканны саклап, бер көтү егет-җилән басып тора иде. Кайбер кызларны группадаш егетләр озата китте, кайберләре, юл уңаенда төшеп калырга дип, Әлфис арбасына җайлаштылар. Машина капка төбенә кайтып туктагач

та, кызлар кереп ятарга ашыкмады. Зөлфия башын күккә чөйде дә, әкрен генә: «Кызлар, карагыз әле», – диде.

Чыннан да, төннең тынлыгы, сихрилеге искиткеч иде. Әйтерсең көне буе җиһан өстенә яңгыр койдырган болытлар эреп юкка чыкканнар: күк йөзендә томанга өртелгән ярты ай балкый, йолдызлар җемелдәшә. Салкынча тынлык өй каршына утыртылган тирәк агачының һәр ботагына уралган; каршыдагы ялангач юкә дә, җәйге ыгы-зыгыны, хуш исле чәчәкләренә агылган бал кортларын сагынып, моңаеп утыра кебек...

– Әйдәгез, кызлар, хуҗалардан яхшы түгел, – диде Гөлүсә, урам башында аяк тавышлары ишетелү белән. – Керергә кирәк.

– Гөлкәй, син бер генә минутка калып тор әле. – Әлфис бик ялынып әйтте. Нәрсәгә өметләнә инде бу егет?! Гөлкәйнең беркемне якын итмәвен кызлар күптәннән беләләр. Шуңа егет сүзләренә карамый кереп китәргә җыенган кызга Рәмилә йомшак кына пышылдады:

– Син, Гөлкәй, йөрисең килмәсә, кистереп әйт инде бу егеткә. Ымсынып тормасын һаман. Без монда болдыр төбендә генә сине көтеп торырбыз.

Гөлкәй үзе дә моны аңлый иде. Әлфиснең үзенә өздереп каравын, мөмкинлек чыккан саен янында чуалуын, көн саен капка төбенә килүен, башка егетләрне янына да җибәрмәвен күптән сизә иде. ...Һәм егетне бераз кызгана да иде. Әй газаплыдыр ул җавапсыз мәхәббәт...

– Гөлкәй, – егетнең тавышы да калтырап чыкты, җиңелчә калтыранган бармаклары кызның кулларын кысты. – Гөлкәй... Исемеңне әйтсәм дә, әллә нишләп китәм. Каян килеп чыктың син минем юлыма, Гөлкәй?! Беркайчан да бу кадәр утларда янганым юк иде...

– Әлфис, – Гөлкәй бик тыныч иде. – Син үз тиңеңне табарга тырыш инде. Син гармунчы, гармунчыга бөтен кызлар үлеп гашыйк булалар бит. Ә минем бик яраткан кешем бар, мин синең хисләреңә җавап бирә алмыйм, Әлфис.

Егет кайнарланып китте.

– Алдыйсың син, Гөлкәй. Юк синең егетең, юк! Мин бу турыда сораштым инде.

– Мин бит егетем бар, димәдем, яраткан кешем бар, дидем. Мин аны бик яратам, Әлфис, аңлыйсыңмы?!

– Мин шулкадәр кыяфәтсезмени, нигә кире кагасың?! Син җырлыйсың, мин җырлыйм, уйныйм, килешеп яшәр

идек, Гөлкәй. Укып бетергәнеңне көтәрмен, валлаһи дип әйтәм!

– Син мине бөтенләй ишетмисең, Әлфис. Сиңа дөрес әйткәннәр, минем егетем юк, чөнки мин егетләр белән йөри алмыйм! Минем өзелеп яраткан кешем бар, аңлыйсыңмы, юкмы?!

Гөлкәйгә бу сүз боткасы туйдыра башлаган иде. Кара син аны, Гөлкәйнең тормыш юлын сызып та бирә. Имеш, син җырлыйсың, мин җырлыйм...

Әлфис тә кинәт кенә сүрелде.

– Алайса, бернинди өмет юк, дисең?!

– Дус булып калыйк, Әлфис. Башка сүз әйтә алмыйм.

– Ярар, Гөлкәй, – Әлфиснең тавышы тонык иде, – димәк, башка юл юк, дисең. Сау бул!

Егет, йөгереп, машинасына кереп утырды, кабызып, тәгәрмәчләреннән балчык чәчрәтә-чәчрәтә, зур тизлектә китеп барды. Гөлкәй моңсу гына кызлар артыннан болдырга керде. Гаебе юк иде аның, шулай да эчне нәрсәдер тырный...

...Икенче көнне тагы көне буе яңгыр яуды. Студентлар эшкә чыга алмадылар, иртән ашханәгә барып ашап килгәннән соң, идарә каршында җыелып утырганнар иде, агроном үзләрен кире өйләренә кайтарып җибәрде. Имеш-мимешкә караганда, яңгыр туктамый атна буе явасы икән. Шулай булгач, студентларның Казанга кайтып китү ихтималы да юк түгел икән, чөнки бәрәңге уңышы җыеп алынган, ә чөгендер турында колхоз белән килешү төзелмәгән... Гөлүсәнең әлеге имеш-мимешләре Гөлкәйнең күңелен җилкендерде. Казан, Казан... Тизрәк, тизрәк кайтасы иде.

...Кичке якта үзләре торган йорт каршына Әлфиснең машинасы килеп туктады.

– Гөлкәй, Гайшә апа сыерын алып кайта алмый интегә. «Гөлкәй төшсен әле, шул кызны гына тыңлый иде сыерым» ди. Бәдертдин абзыйны да алып төшәргә кушкан.

Чыннан да, хуҗаларның бер азгын сыеры бар иде. Ни гаҗәп, Гайшәападан саудырмыйча, абзар-кураны дулап чапкан шул сыер, Гөлкәй башын йә ияк астын сыйпап, көйләп-җырлап торганда, дөньяның иң күндәм хайванына әйләнә иде. Гайшә апа моны бөтен күршеләренә сөйләп, авыл халкы таң калган иде. Шуңа Гөлкәй һич тә гаҗәпләнмәде, тиз генә итекләрен киеп алды да Әлфискә эндәште:

– Бәдертдин абый әле эштән кайтмаган бит. Үзем генә барырмын.

– Тукта, мин дә синең белән барам.

Рәмилә, тиз генә киенеп, урамга чыкты. Һаман яңгыр коя иде әле. Гөлкәй машинага кереп утырды, янына Рәмилә менде.

– Кайда калган соң ул юньсез сыер?!

– Аргы як болында, ди. Мин күрмәдем, күршегез әйтте.

Машина, яңгырдан соң җыелып калган күлдәвекләрне ера-ера, авыл башына чыкты, бәрәңге җыйган басуны үтеп, урман кырына килеп туктады.

– Килеп җиттек. – Әлфис ничектер бик тынычсызланып әйтте. Ул арада агач арасыннан бер ир-ат чыгып, Рәмилә утырган якның ишеген ачты.

– Шушындамы?! Монда көтү йөрми түгелме соң?

Рәмилә, күзлеген күтәрә-күтәрә, тирә-якны караштырган арада, теге ир-ат эндәште:

– Төшегез, кызлар. Гайшә апагызның сыеры әнә теге басуда качып калган.

Рәмиләнең сикереп төшүе булды, аның артыннан кымшанган Гөлкәйне этә-төртә, кабинага теге ир-егет менеп утырды, машина кузгалып та китте. Гөлкәйнең йөрәгенә курку үрмәләде. Машина көзгесеннән Рәмиләнең, кулларын бутый-бутый, алар артыннан йөгергәне күренеп калды.

– Төшерегез мине! Төшерегез, дим! – Гөлкәй бар көченә янында утырган ир-атны төрткәләде. – Ач ишекне, сикерәм!

– Соң инде, чибәркәй, соң. – Ир-ат, Гөлкәйнең йодрыкларын сизмәгән дә кебек, мыскыллы көлемсерәде. – Хәзер сиңа җиргә сикерергә түгел, булачак хәләл җефетеңнең куенына сикерергә кирәк!

Гөлкәй шунда барысын да аңлап алды. Аңлады да, канатлары җилсез асылынып калган җилкән кебек, чарасыз тынып калды. Менә нәрсәдә икән эш...

– Урладылар сине, чибәркәй, урладылар! – Егет кычкырып көлде. Әйе, Гөлкәйнең бу яклардагы гадәт турында әллә ничә тапкыр ишеткәне бар иде: кызларны туй алдыннан урлап кайталар. Телисеңме, теләмисеңме – гадәте шулай. Күпчелек очракта кыз үзен урлатырга риза булып, бу турыда ата-аналары белеп тора; кайбер очракта кызны чын-чынлап урлыйлар... Мондый кызлар кире кайтмый, урланган йортта килен булып яшәп кала, чөнки

урланып кире кайткан кызны кем кияүгә алсын... Гөлкәй бу сүзләрнең барысын да колак яныннан үткәреп җибәргән, чынга алмаган, дөресрәге, үзенә кагылмый торган бер йола дип караган иде...

– Әлфис, нигә дәшмисең?! Кичә бит мин сиңа барысын да әйттем инде, Әлфис!

Әлфис, ап-ак булып рульгә ябышкан, әйтерсең җир күчәрен әйләндерә.

– Башка юл юк, диде, Гөлкәй. Бары шулай гына син минеке булырсың.

– Мин беркайчан да синеке булмаячакмын, беркайчан да!

Янындагы егет тагы ихахайлап көлде.

– Булырсың, матурым. Безнең егетләр сине моннан түгел, Казаннан да урлап кайтачаклар! Хәзер синең язмышың шушы Әлфис инде, тик кенә кайт!

– Әлфис, мин барыбер кире кайтачакмын, аңла, зинһар, төшереп калдыр мине!

– Юк, Гөлкәй.

– Мин синең белән тормаячакмын, барыбер кире кайтачакмын, кире кайтачакмын!

Гөлкәйнең күзләренә яшь тыгылды, тавышы калтырады. Күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, бар көче белән янындагы егеткә ябырылды, ярсуланып, йодрыкларын төйнәп, әзмәверне тукмады.

– Ух, кара син моны! Кызый, хәзер үк тынмасаң, бәйләп салабыз!

Гөлкәй туктарга уйламады да. Тырыша торгач, үрелеп, машинаның ишеген ача торган тотканы борып өлгерде, ир-атны төртеп төшерә язды. Әлфис шунда ук бер кулы белән Гөлкәйгә ябышты.

– Рәфис, яп ишекне!

Рәфис көч-хәл белән әрле-бирле уйнаган ишекне тотып япты, әшәке сүзләр әйтеп сүгенде. Каяндыр аяк астыннан бау алып, кызның кулларын алга каерып бәйләде.

– Менә шулай, матурым. Сине түгел, борыныннан ут чыгарган үгезләрне дә җигәбез без, качмый тор!

Гөлкәй сулык-сулык килде.

– Мин барыбер синеке булмыйм, барыбер качам, барыбер синең белән тормыйм...

Әлфис сүзләрен теш арасыннан изеп чыгарды.

– Барыбер, бер кичкә, бер төнгә булса да, минеке булырсың, Гөлкәй.

Караңгы төште, әле һаман баралар да баралар. Урман юлы сикәлтәле, ике көн яуган яңгырдан соң тәмам изрәгән, кайбер урыннарда тәгәрмәчләр бушка әйләнеп тора. Гөлкәй, моны аңлап, шунда ук Ходайга ялвара башлады: «Йа Ходам, коткар мине, коткар, машиналары батып калса иде, чыгалмыйча ятса иде, йа Ходам, әлхәмдүлиллаһ!» Шушы ялваруны ишеткәндәй, машина, моторын үкертә-үкертә, бер урында тәгәрмәчләрен әйләндерә башлады. Әлфис артка чикте – тәгәрмәчләр артка да шулай ук әйләнделәр. Алга газ бирде – шул ук хәл. Рәфис тагы әшәке сүгенде.

– Сүгенмә, абый. Лутчы, чыгып, тәгәрмәч астына берәр нәрсә ташла.

– Кызны карап тор.

Машина юлны бик нык изгән иде, Рәфиснең якында аунап яткан чыбык-чабыкны сазлыкка ташлавы бушка булды. Машина бер урында үкереп утыруын дәвам итте.

– Бар инде, берәр юкарак агач ише нәрсә алып кил, – дип кычкырды Әлфис. – Болай файда юк!

Рәфис урманга кереп китте. Әлфис машинаны, әле алга, әле артка чигендереп, сазлык җирдән чыкмакчы була, тик бушка. Ул арада черек агач кәүсәләре тотып, Рәфис килеп чыкты, тәгәрмәчләр астына салып, арткы яктан машинаны этәргә әзерләнде. Әлфис тә, үзе утырган якның ишеген ачып, арткы тәгәрмәчләргә текәлде, газга басып, машинаны үкертте. Гөлкәй көткән мизгел иде бу... Шуышып кына, кулы белән ишек токасын борды, шуышып кына машинадан төште дә урман куелыгына кереп йөгерде. Бар көченә йөгерде, агач ботакларына бәрелә-бәрелә, кайсы якка чапканын абайламый, кош булып очты. Әйтерсең аның язмышы менә шушы йөгерү тизлегеннән тора иде. Артта кычкырынган, сүгенгән тавышлар ишетелде, машина үкерүеннән туктады. Тын урманда лап-лоп килгән итек тавышлары яңгырады. Гөлкәй белә: йөгергән, качкан киекне иртәме-соңмы – барыбер куып тоталар. Шуңа күрә яшеренергә кирәк. Ләкин монда кая яшеренәсең – бар булганы яфракларын койган имән дә каен! Җитмәсә, каерып бәйләнгән кул йөгерергә комачаулый. Хәле китә башлаган Гөлкәй, бер мизгелгә туктап, як-якка каранды. Әнә сул якта урман карасурак кебек. Шунда йөгерергә кирәк. Ул арада артыннан кычкырган тавышлар якынайган кебек булды. Хәзер, хәзер... Бераздан Гөлкәй чыршылык арасына килеп керде. Монда инде

теләгәнеңчә йөгереп булмый иде – рәт-рәт тезелгән чыршылар үзләренең араларыннан җил дә үтмәслек итеп басканнар. Бер-ике рәтне ничек кирәк алай әйләнеп, сикереп, тырнашып узгач, Гөлкәй мәһәббәт чыршы төбенә килеп егылды. Кадерлем, яшер мине, яшер... Канат-ботакларыңны күтәр дә кире төшер... Чыршы ботаклары аста киң, куе иде, төбенә үтеп кермәслек чытырман иде. Гөлкәй җиргә сеңеп бетеп диярлек, иң аскы ботаклар астыннан чыршы кәүсәсенә таба шуышты-тырнашты. Хәзер аның соңгы, хәлиткеч көрәше. Әгәр шушы тырпаешкан чыршы энәләрен, чыршы ботакларын ерып, эчкәрәк үтеп керсә, аны күрмәячәкләр. Әгәр юк икән – хуш, бәхил бул, Мансур Ибраһимович... Укытучының исеме аңында чагылып китү Гөлкәйгә өстәмә көч бирде, битен сыдырган ботакларны сизмичә, һаман кәүсә төбенә, эчкәрәк ыргылды. Туктарга кирәк иде, хәзер куып килүчеләр якын булырга тиеш. Тавыш-тынны чыгарасы түгел...

– Син теге якны кара! Шушында керде ул, әллә ни ерак китә алмас. Рәте белән барыйк, аңладыңмы?

Моны Рәфис кычкыра. Әлфиснең тавышы ишетелми, итек тавышлары бер ерагайган, бер якынайган кебек. Гөлкәй дөрес яшеренде, ир-атлар аны эчкәрәк кергән дип уйларга тиешләр. Бу чыршы посадкасы башында озак юанмаслар. Тын гына ятарга кирәк, тын гына... Гөлкәйнең сулуы капкан иде, көч-хәл белән киң итеп тын алудан үзен тыеп тора алды. Бите буйлап ниндидер җылылык ага. Иреннәренә кадәр агып төшкәч, Гөлкәй кан тәмен сизде. Ерттырган инде, битен ерттырган. Куллары да әрнешә. Җитмәсә, чыршы энәләреннән тып-тып яңгыр тама. Көзге, салкын яңгыр. Түзәргә кирәк. Менә тагы тавышлар ишетелә. Бу юлы кайдадыр ерактарак. Ир-атлар чыршы рәтләрен актаралар. Йа Ходаем, сакла мине.. Әнием, кадерле әнием... Әтием, рухыңа дога кылам: коткар балаңны бу явызлардан... Шау-шу тагы якынлашты.

– Без монда чакта кире имәнлеккә чыгып йөгермәгәндер бит инде.

Әлфиснең тавышы монысы. Нигәдер Гөлкәй аны дошман күрми. Мәхәббәт егетнең аңын томалаган. Бары шул гына. Гөлкәй үзе дә шундый түгел идеме соң?!

– Урман аркылы авылга кайта белми. Ызначит, килгән юлга чыгып йөгерсә генә.

– Анда без бар дип уйлый бит ул. Анда чыкмаячак. –

Әлфис, тел шартлатып, үкенеп куйды. – Караңгыда таба алмаячакбыз. Нигә синең сүзне тыңладым мин дурак?!

– Яхшы карарга иде, чыгып качмаган булыр иде. Үзең мәми авыз.

– Барыбер тормаячак иде ул кыз. Күзләрен кара син аның, янып торалар. Андыйлар, иярләмәгән кыргый тай кебек, кулга ияләшми.

– Ярар, төн буена урманда йөрештереп торырбыз. Иптәш кызы авылны күтәргәндер инде. Бәладән баш-аяк. Бу якта бүре-фәлән дә күп бит әле ул.

Гөлкәй бу турыда уйламаган иде... Аркалары чымырдап китте. Төне буе монда ятасы булса, ничек түзәр? Шуны гына көткәндәй, аркасына суык үтеп керде, лычма су булган киемнәре кызны шундый ук юеш җиргә сылап куйгандай булды. Калтыратты. Кыз шактый озак кымшанмыйча ятты. Түзәргә кирәк. Бу явызларның кулына барып кергәнче, үлүең артыграк... Кызык, әгәр ул шушында үлеп китсә, Мансур Ибраһимович сөйгәне белән күрешә-сөйләшә алмаганына үкенер идеме икән? Бәлки, үкенүдән елар да иде әле... Гөлкәй, үз-үзенә ачуы килеп, кулларын бәйләгән бауны чәйни, як-якка тарткалый башлады. Сөйгән кешеңнең кайгысын күрү турында хыялланып ята бит, юньсез! Мансур Ибраһимович үлеп китсә, сиңа ничек булыр иде соң, җүләр?! Кыз ачуы белән бауның яртысын диярлек чәйнәп өзде. Калган яртысын шулай ук җепселләргә аерып, өзгәләп бетерде. Аяк тавышлары ишетелми кебек. Шулай да сак булырга кирәк. Гөлкәй, кулларын баудан тәмам ычкындырып, беләзек турысын уды, бармакларына кан йөгергәнен тойды. Җылынырга кирәк, җылынырга. Бите һаман әрнешә, иске ылыслар, пәрәвезләр, тагы әллә нәрсәләр ябышып катты. Әз генә уңайлы итеп ятса иде... Бераз селкенүгә, якында гына Рәфис тавышы ишетелде:

– Ишеттеңме?! Нәрсәдер кыштырдаган сыман.

Әлфис тә, бераз вакыт дәшмичә, тыңлап торды булса кирәк.

– Юк, берәр тычкан-фәләндер.

Гөлкәй тын алырга да куркып ятты, башына кан йөгерде. Ничек сизмәгән ул... Күрәсең, болар төнгелеккә кайтырга уйламыйлар да. Гел шушында торырлар микәнни соң?

– Бүре-фәләнгә юлыкмаса ярар иде. Исән-сау гына булсын иде. Иртәгә ничек җавап биреп бетерербез диген?!

Аңламый Гөлкәй: Әлфис аның турында күбрәк кайгыртамы, әллә үзе турындамы?

– Юлыкса, кычкырырга тиеш. Урманда ишетелә ул, кайгырма.

– Әйдә, теге яктан әйләнеп килик әле. Мужыт, берәр җирдә качып кына торадыр.

Тагы аяк тавышлары ерагайды. Гөлкәй үзе булдыра алганча уңайлы итеп ятты, тезләре белән чыршы кәүсәсен әйләндереп алды. Ян-ягына яткан сабый бала кебек иде ятуы. Болай кыен түгел кебек...

Шактый вакыт үтте. Гөлкәйнең тәне оеды, бик оеды, кызның түзәр хәле калмагач, сугышта разведчик булган бабасын искә төште. Ул да шушы халәткә охшаган хәлләр сөйли иде. Шулай булгач, кымшанмыйча түзеп яту ул – бабаңнан килгән зур сәләтең инде синең. Димәк, тын гына ятасың. Сәгать алтыларда яктырырга тиеш. Хәзер сәгать ничә икән?! Күп дигәндә, тугыз-уннар тирәседер. Күзгә төртсәң күренми. Җитмәсә, салкын үзәккә үтә. Себердә мондый салкын юк. Анда коры салкын. Ул болай үзәккә үтми. Анда чыршылар да икенче төрле, бу кадәр тырнамыйлар... Кинәт алдында гына нәрсәдер кыштырдады. Нәрсәдер тавышсыз гына чыршы тирәли йөгереп үтте. Тагы алдына килеп, чыршы ботакларын кымшатты, араларыннан шома гына шуышып, нәрсәдер Гөлкәйнең йөзе алдында ук диярлек пәйда булды. Бу нәрсәдер дигәне ике янып торган яшькелт ут иде. Бу ике яшькелт ут бүре күзләре иде. Гөлкәйнең тыны катты. Күзләрен бүре күзләреннән алмый, кымшанмыйча ята бирде. Менә ул соңгы минутлар... Әгәр кычкырса, йөгереп чыкса?! Әлфис аны ишетәчәк бит, коткарачак... Гөлкәй бераз вакыт үзе дә бүрегә генә каршы тора алыр... Бабасы өйрәткәнчә, иң беренче бүренең аскы ияген эләктереп, кысып тотарга кирәк... Һәм җибәрмәскә. Телен эләктерә алсаң, бигрәк тә әйбәт. Шуннан бүре аны бугазлый алмаячак. Кулын чәйнәп бетерер, әлбәттә, тик үзенең исән калу мөмкинлеге бар. Ул арада ярдәмгә Әлфис белән Рәмис тә килерләр. ...Ике яшел ут бернинди хис белдерми, светофор уты кебек янып тора иде. Салкын, уйсыз-исәпсез утлар. Юк, бүре кышка каршы ялгыз йөрми инде. Якында гына иптәшләре бардыр. Алай дисәң, әле бит көз айлары керде генә. Салкын утлар кымшанып куйдылар, Гөлкәй бүренең һаваны иснәгәнен абайлап алды. Әлбәттә, кан исен сизеп килгән инде бу. Яшькелт утлар яңадан Гөлкәйнең

күзләренә текәлделәр. Гөлкәй дә кымшанмады. Ярар, Ходай бүредән чәйнәлеп үләргә насыйп иткән икән, карышып торуның файдасы юк. Үләргә тек үләргә. Син үзең бая гына бүре авызында үлү яхшырак дип әйтмәдеңмени?! Менә ул мөмкинлек туды да. Тик бүре, шактый вакыт күзгә-күз карап торганнан соң, борынын чыршы ботаклары арасыннан алды, тын гына шуышып, караңгыда юк булды. Гөлкәй, үз күзләренә үзе ышанмыйча, әле аннан соң да шактый вакыт тыңлап ятты. Урманда әллә нәрсәләр кыштырдый, ботаклар сынып төшә, әллә нинди тавышлар ишетелә иде. Куркыныч, бик куркыныч булып китте. Чыгып йөгерәсе килде. Тик кая йөгерер?! Юлны белми, хәтта авылның кайсы якта икәнен дә белми... Ул арада күзләрен йокы баса башлады. Салкын алай калтыратмый кебек, киресенчә, мунча ләүкәсендә утыргандай, эсселәнде. Бер кат халат өстеннән киелгән лычма су курткасы да юка инде югыйсә, бу кадәр кыздырырга тиеш түгел. Ул бит «тиз кайтам» дип чыгып китте, киенеп тә тормады. Ә йокы килә... Әзрәк йоклап аласы иде... Хәзер бүре килмәс инде, китте бит ул. Әз генә йоклап алыр да, торып, берәр якка атлар...

...Гөлкәй ир-ат тавышларына уянып китте.

– Булмый болай. Күптән авылда җиденче төшләрен күреп ятадыр. Ә без синең белән төне буе урман каравыллап чыктык. Әйдә, кайтабыз.

– Барыбер кайтырга кирәк инде. Кайтмаган булса, кешеләрне җыеп, эзли чыгасы булыр. Ничек җавап биреп бетерергә... Исән-сау гына булса ярар иде диген син!

Әлфис һаман бер үк сүзләрне кабатлый иде. Имеш, ничек җавап бирәсе... Баштарак нишләп бу турыда уйламагандыр! Тавышлар ерагайды, димәк, киттеләр булса кирәк. Гөлкәй кымшанасы итте, тик гәүдәсе карыша иде. Нишләгән әле ул?! Бөтен тәне дер-дер килеп калтырый. Аяк-куллары үзенә буйсынмый кебек. Оегандыр, күрәсең. Кыз, көч-хәл белән кыймылдап, чыршы төбеннән чыкты. Урман эче бераз яктырган сыман. Ерактарак машина кабызган тавыш ишетелде. Бераз үкереп утыргач, машина, күрәсең, баткаклыктан чыкты, моторның тигез тавышы иртәнге тынлыкта яңгырап алгач, ераклашкан кебек булды. Китәләр, димәк. Бик әйбәт. Шул юлга чыгасы булыр. Юл буйлап авылга таба чыгар. Гөлкәй аяк-кулларын тыңлата алмый гаҗиз булды. Алга барырга кирәк – аяклары сулга атлыйлар. Туры барырга кирәк –

күз алдында агачлар бутала башлый. Юлга чыкканчы, урман эче тагы да яктыргандай булды. Юл пычрак иде, машина эзеннән бара алмыйча, Гөлкәй берничә тапкыр таеп егылды. Хәле бетте, күз аллары караңгыланды. Бераз утырып ял иткәннән соң, тагы алга атлады. Бүген ул Казанга кайтып китәчәк. Ул башка бу авылда тора алмый. Ул бу авылның явыз кешеләрен, явыз йола-гадәтләрен күралмый. Аның өенә кайтасы килә, әнисе белән җылы мунчага кереп, юынасы-чистарынасы килә... «Кызым, Мансур Ибраһимович кем ул сиңа?» – «Мин аны бик яратам шул, әни. Син әтине яраткан кебек яратам». – «Ярамый, кызым, мондый мәхәббәт гөнаһ ул, зур гөнаһ!» – «Ә кешене урлап китеп, үзе теләмәгән кешегә мәҗбүриләп кияүгә бирү гөнаһ түгелмени?!» – «Гөнаһ, кызым, гөнаһ...» Гөлкәйнең уйлары бутала, күз алдында әллә нинди сурәтләр пәйда була... «Мансур Ибраһимович, мин сезне өзелеп яратам. Мин башка беркемнеке дә булмаячакмын, бары сезнеке генә, мин җирдә сезнең өчен генә яшим...». – «Мин дә яратам сине, гөлем-гөлкәем, бик яратам... Мең тапкыр, миллион тапкыр яратам... Син белмисең минем ничек ярatканымны!..» – «Беләм, Мансур Ибраһимович. Әгәр мине яратмасагыз, төшләремә кермәс идегез». Ниһаять, урманнан чыкты бугай, кинәт ачылып киткән күк йөзе күзләрен камаштырды. Аяклары атламас хәлгә килде, тәне уттай кызышып янды. «Мин Казанга, Мансур Ибраһимович янына кайтып китәргә тиешмен. Миңа авылга кайтып җитәргә кирәк». Гөлкәй бертуктаусыз шушы сүзләрне кабатлады. «Казанга кайтып җитәргә тиеш... Җитәргә тиеш». Авылга ерак калмаган да иде, Гөлкәйнең күз алдында карасу күләгәләр сикерешә башлады. Әллә басу баганалары булды ул, әллә үзенә таба чабышып килгән кеше гәүдәләре иде... Аңламады. Соңгы адымын атлаганда иреннәре «Мансур Ибраһимович» дип пышылдый иде әле...

* * *

Әллә нишли бүген укытучының күңеле: урамда салмак кына яуган көзге яңгыр шулай моңсулатамы аны, әллә кичә Розалия белән әйтешеп алган кечкенә генә сүз боткасымы, әллә инде, гомумән, дөнья үзе шундый күңелсезгә әйләндеме... Һич аңлый алмый. Нидер җитми сыман, кемнедер күрәсе, эшләмәгән нindидер эше калган

кебек. Югыйсә һәрнәрсә үз урынында. Лекцияләре укылып бетте, консультация бирде, тик барыбер өйгә кайтып китә алмый, кафедрада нәрсәдер язган булып утыра.

– Мансур Ибраһимович, сезне телефонга чакыралар.

Лаборант кызның тавышына укытучы сискәнеп китте. Кызның сүзләрен бик яхшы аңласа да, кабатлап сорады:

– Минеме?!

– Әйе, Мансур Ибраһимович.

Телефон эчке бүлмәдә иде, укытучы, язып утырган кәгазьләреннән аерыласы килмәгәндәй, акрын гына кузгалды, чыгып, өстәлдә яткан трубканы иреннәренә якын китерде:

– Тыңлыйм сезне.

– Мансур Ибраһимович!

Таныш тавыш. Белгән кеше шалтырата инде. Тавышы борчулы, һичшиксез, нәрсәдер булган. Җавап биргәнчегә кадәр Мансур Ибраһимович кем шалтыратканын аңлыйсы килде, тик исенә төшерә алмады. Көне буе күңелендә йөргән борчу кинәт кенә баш калкытты, йөрәге, күңелсез хәбәр әйтәчәкләрен сизгән кебек, сулыгып куйды.

– Әйе, тыңлыйм.

– Мансур Ибраһимович, сезгә икенче курс студенткасы Хәсәнова Рәмилә шалтырата. Исәнмесез. – Трубканың икенче башындагы кыз, нәрсә әйтергә белмәгәндәй, тотлыгып торды. – Мансур Ибраһимович, сез Якупованы хәтерлисез бит?

Укытучы аңламады, кайтарып сорады:

– Нинди Якупова?!

– Якупова Гөлкәй. Икенче курс студенты, Себердән.

Әйе шул, Гөлкәй... Якупова ич инде ул. Тукта, нәрсә булды икән?!

– Әйе, хәтерлим. Сез авылда булырга тиеш түгелме соң?!

Икенче башта, әйтергә кыенсынгандый, тагы тынлык барлыкка килде.

– Авылда идек... Тик... Мансур Ибраһимович... Гөлкәй авырып китте бит әле.

Мансур Ибраһимовичның аяк асты чайкалып китте, шунда ук күңеленнән «Менә нәрсә борчыган икән» дигән уй узды. Тукта, авырмый тормыйлар инде, шулай да нишләп бу студент аңа шалтырата соң әле? Гөлкәй сорады микән әллә?

– Салкын тидергәнмени? Авылдан бик күп студентлар авырып кайталар шул. Сез аны дәрескә килә алмый дип шалтыратасызмы?

Тынлык. Нәрсәдер әйтеп бетерми бу студент. Әллә әйтә алмыймы?

– Сеңлем, сез төгәл генә миңа шалтыратуыгызның сәбәбен әйтегез әле. Нәрсә булды?

Ниһаять, студент көрсенеп куйды да, тонык тавыш белән:

– Мансур Ибраһимович, Гөлкәй бик каты авырый шул, – диде. Аннары өстәп куйды:

– Реанимациягә салдылар аны. Үпкәсе ялкынсынган. Хәле бик авыр.

Мансур Ибраһимовичның күз аллары караңгыланып китте. Әйтелгән сүзләр тиз генә аңына барып та җитмәделәр.

– Ничек инде... реанимациягә?! Нәрсә булды?

Рәмилә сүзне кыска тотты:

– Аннан аңлатырмын, Мансур Ибраһимович. Сез хастаханәгә килә алмассызмы?

Укытучы теш арасыннан сөзеп чыгарды:

– Кайсы хастаханәдә ул? Ничәнче палатада?

...Имеш, ул киң елганы аркылы йөзеп чыгарга тели. Гаҗәп хәл, елгадан пар күтәрелә, суы кайнар, Гөлкәйнең тәнен пешерә. Зур, кайнап торган дулкыннар аны әледән-әле башыннан ук күмеп китәләр, авызына су тула, һава җитми башлый, сулышы кысыла. Ул, бернигә карамый, һаман йөзә дә йөзә. Йөзмичә, каршы як ярда Мансур Ибраһимович басып тора лабаса! Менә ул, Гөлкәйне чакырып, кулларын суза, нәрсәдер эндәшә. Сүзләрен аңламый Гөлкәй, шулай да укытучының кара күзләре нәрсәгәдер бик борчылалар кебек. Гөлкәйне «йөзә алмас» дип уйлый микән әллә?! Мансур Ибраһимович чакырып торганда, Гөлкәй диңгезне кичәргә дә әзер! Тик бу дулкыннар һаман авызына тулалар, сулышы кысылганнан-кысыла бара, һава җитми. Туктале, Гөлкәй – Гөлкәй түгел, Гөлкәй – бер балык лабаса! Аны ярга чыгарып ташлаганнар, аның тагы тыны киселә, авызын ача да яба, бөтен саңакларын калтыратып, суга тилмерә. Менә тагы Мансур Ибраһимович аңа карап тора, нәрсәдер пышылдап, башын чайкый. Гөлкәйне кулларына ала да елгага ыргыта. Ниһаять, Гөлкәй-балык саңакларының су белән тулуын сизә, кан юлларына, кистереп, суда эрегән һава үтеп керә...

Гөлкәй бу саташудан мәңге айный алмас кебек иде. Мендәрдә бәргәләнеп яткан кызга карап, Мансур Ибраһимовичның бәгыре телгәләнде. Вакыт-вакыт кыз күзләрен ача, тик кара тамчылар укытучыны күрмиләр, йөрәктән чыккан назлы сүзләрне кыз ишетми. Кызның куллары ут кебек кайнар. Табиблар ничә көн инде аның температурасын төшерә алмый гаҗизләнәләр. Гөлкәй көрәшә, үлем белән көрәшә... Кайчак аңга килгән сыман була, хәлсез куллар Мансур Ибраһимовичның кулларын кыскан кебек тоела. Мондый минутларда Мансур Ибраһимович Гөлкәйнең тырналып беткән йөзенә үк иелә дә, сулыш аппаратын кымшатмаска тырышып, «Гөлкәй! Кадерлем!» дип эндәшә. Аның гөле-гөлкәе терелачәк, әлбәттә, һичшиксез, терелачәк, Мансур Ибраһимович моны белә, сизә. Башкача булуы мөмкин түгел. Шулай да бу газапларны ничек кенә җиңеләйтергә соң...

...Ниһаять, иртәләрнең берсендә кызның сулышы тигезләнде, йөзенә алсулык йөгергән кебек тоелды. Тән температурасын үлчәгән шәфкать туташының кыяфәтендә канәгатьлек хисе уелып калды. Табиб та кереп, кызның сулышын тыңлады, аппаратлар язып барган кәгазьләрне өйрәнде. «Кризис үтте булса кирәк, – диде ул, тын да алмый басып торган укытучыга. – Бераздан аңга килергә тиеш». Мансур Ибраһимовичның өстеннән тау төшкән кебек булды. Табибка рәхмәт әйтте, тагы бераз сөйләшеп торганнан соң, Гөлкәйне шәфкать туташы кулларына калдырып, коридорга чыкты. Стенага терәтеп куелган кушеткада Рәмилә белән бер сары чәчле егет утыра иде. Мансур Ибраһимович сискәнеп китте. Йөрәгенең, күңеленең бер өлешендә бу егеткә карата чиксез ачу, ярсу барлыкка килде, интуициясе бу сары егетнең Рәмилә сөйләгән, Гөлкәйнең авырып китүенә гаепле булган егет икәнен белдерде. Ничек намусы җиткән монда килергә! Укытучы, ургылып чыккан ярсуын тыя алмый, кушеткадан күтәрелгән егетнең изүенә ябышты, ике куллап стенага китереп сылады. Уң кулын ычкындырып, егеткә кизәнде. Егетнең күзләре бер мизгелгә зураеп ачылдылар да шунда ук кире чытырдап йомылдылар – Әлфис ир-атның йодрыгын каршы алырга әзерләнде. Ул күптәннән кемнән дә булса, бу йодрыкны көткән иде. Үзенең гаебе йодрык ашау белән генә җиңеләйсә иде... Тик кизәнгән кулга Рәмилә килеп асылынды.

– Мансур Ибраһимович! Мансур Ибраһимович! Туктагыз! Нишлисез?!

Укытучы йодрыкларын язды, тик егетне ычкындырмады.

– Әгәр Гөлкәйгә тагы бер тапкыр кагыласың икән, әгәр аңа бер бөртек начарлык эшлисең икән – син теге дөнья кешесе, егеткәем. Аңладыңмы? – Мансур Ибраһимовичның күкле-яшелле тавышы буш коридорны яңгыратты. – Аңладыңмы, дим мин?

Егет башта агарып-күгәреп калса да, бераздан үзен кулга алырга өлгерде, изүеннән укытучының кулларын аермакчы булып тартылды.

– Мин аңа начарлык теләмәдем. Мин Гөлкәйне яратам.

Мансур Ибраһимовичның күз карашында борынгы кыргыйлык, ир җенесенә табигать биргән ирлек-гаярьлек, ярсулык кузгалды. Үз-үзен белештерми, яңадан егетне стенага китереп сылады, бармаклары Әлфиснең бугазында боҗра булып түгәрәкләнделәр. Иреннәре һәр сүзне аерып-аерып әйттеләр.

– Әгәр Гөлкәйгә кагылсаң син җирдә яшәмәячәксең. Аңладыңмы?!

– Мансур Ибраһимович! – Рәмилә баядан бирде укытучының кулларын егеттән аерырга тырыша иде. – Ай Аллам! Нишлисез соң сез? Мансур Ибраһимович!

Ниһаять, егетне кысып тоткан куллар бушады, укытучыга акылы кайта башлады. Егет тә сулу алды, бугаз тирәсен угалап:

– Сез Гөлкәйгә кем буласыз соң? – диде.

Бу сүзләр Мансур Ибраһимовичның өстенә салкын су сипкәндәй тәэсир иттеләр. Укытучы кинәт кенә кечерәеп, бөрешеп калгандай булды. Егеткә җавап бирмичә, Рәмиләгә борылды.

– Рәмилә. Гөлкәйнең хәле әйбәтләнә, диделәр. Шулай булгач, иптәшләре алдында кабат-кабат килеп йөрү миңа да, үзенә дә уңайсыз булыр. Минем монда булганны да Гөлкәйнең үзенә әйтү әһәмиятле түгел. Сине янына кертерләр, табиб белән сөйләштем. Аңга килгәч, миңа хәбәр ит, яме! Тик бу шалапай монда булмасын!

Укытучы, гаҗәпсенүле карашларны тойган хәлдә, авыр гына атлап, коридор буйлап китеп барды. Бу кинәттән барлыкка килгән кыргыйлыкның нәрсәдән икәнен укытучы үз-үзенә дә аңлата алмый иде...

...Ап-ак томан артында Рәмиләнең яшь аралаш елмайган күзләре пәйда булды. Дусты нәрсәдер пышылдый. Гөлкәй әле аның сүзләрен аңламый, шулай да томан таралганнан-тарала бара, тирә-яктагы җиһазларның сызыклары ачыклана, тәрәзәдән яктылык бөрки... Бүлмәгә кергән кара сакаллы табиб та Гөлкәйгә ягымлы елмая.

– Шундый куркыттың безне, Гөлкәй! Шулай авырырга ярыймыни инде, син нәрсә?! – Табиб чыгып китү белән, Рәмиләнең һәрвакыттагыча бераз җитди, бераз шаян тавышы кызның колак барабаннарын яңгыраткандай булды. – Синнән башка «матан»[1] буенча контроль эштән ярты төркем кырылды, безнең турыда бер дә уйламадыңмыни?!

– Син кү-че-рер-гә бир-мә-гән-сең-дер шул. – Бу кадәр озын җөмләне Гөлкәй көч-хәл белән, иҗекләп-иҗекләп әйтте. Шунда ук сулыш алуы кыенлашты, бугазына ниндидер төер килеп тыгылды. Кыз буыла-буыла ютәлләргә тотынды, күкрәк читлеген түзә алмаслык авырту биләп алды...

– Ай Аллам, ялгыштым. – Рәмиләнең, дустының бәргәләнүенә карап, коты очты. – Сөйләшергә ярамый сиңа, Гөлкәй! Ярамый!

Бераздан Гөлкәй тынычланды, авыртуы да кимеде. Елмайган булды, баш какты.

– Сөйләшмә, зинһар, Гөлкәй, үзем генә сөйлим. – Рәмилә табиб чакырырга кымшанган урыныннан кире утырды. – Синең соңгы яңалыкларны беләсең киләдер инде, шулай бит?! – Үзе, Гөлкәйнең ым кагуын көтеп тә тормастан диярлек, сүз кыстырмаслык итеп ялгап китте:

– Авылдан кайттык, укулар башланды. Яңа предметлар кирә. «Общага»да барысы да әйбәт. Кызлар сиңа сәлам әйттеләр. Укытучыларга синең авырганыңны белдердек, борчылмасын, тизрәк терелсен, диделәр.

Шунда ук Гөлкәйнең карашы җанланып китте, иреннәре кымшанганчы ук Рәмилә дустының нәрсә сораганын аңлап алды.

– Барысына да әйттек, Борис Григорьевичка да, Елена Маратовнага да, Альберт Шамилевичка да, Мансур Ибра-

---

[1] «Матан» (кыск.) – математик анализ – математика буенча вузда укытыла торган предмет.

һимовичка да, Евгений Петровичка да – барысына-барысына да. Борчылмасын, тизрәк терелсен, диделәр.

Рәмилә кызның күзләрендә ниндидер өметсезлек уйнап алганын тотып калды. Гөлкәйне кем кызыксындырганын аңлый иде Рәмилә, шуңа күрә сүзне тизрәк икенчегә борырга ашыкты.

– Беләсеңме, Фаягөл нигә килмәгән?! Кияүгә чыгып яткан бит безнең «модница»быз! – Рәмилә тавышын беркадәр әкренәйтеп дәвам итте: – Үзең беләсең бит инде Фаягөлне. Райкомдагы «абзый» белән «роман»нары тегесенең хатынына билгеле булган, ди. Хатыны, институтка килеп, тавыш күтәргән, ди. Фаягөлнең әти-әниләренә хәбәр иткәннәр, ди. Әти-әниләре исә, озак уйлап тормый, тотканнар да Фаягөлне кияүгә биргәннәр. Вәт.

Рәмилә авыр сулап куйды да дәвам итте:

– Бик кызгандык Фаягөлне. Яратмаган, җитмәсә, үзеннән өлкәнрәк кешегә биргәннәр. Үзе белдермәгән була инде. Дөресен генә әйткәндә, Фаягөл барыбер ул ир белән тормаячак кебек. Әниләре шул кияүгә чыккан исеме булсын өчен генә биргәннәр инде, аңлашыла. Фаягөл «заочно»га күчеп йөри. Аның урынына бүлмәгә Чулпан урнаша. Әйберләрен алырга Фаягөл ире белән бергәләп килгәннәр иде. Торасы кешеләрнең кыяфәтләреннән, үзүзләрен тотышларыннан ук күренеп тора ул. Ә болар... Тегесе ниндидер бер салам торхан шунда. Җүнләп исәнләшә дә белми.

Гөлкәй дә авыр сулап алды. Фаягөлдән төртмәле сүз күп ишетсә дә, бүлмәдәш кызына бер дә ачуы юк иде аның. Әнә бит, язмышы да әллә ничек кенә килеп чыккан... Яратмаган кешегә кияүгә барырга ничек риза булды икән... Гөлкәй Әлфисне күз алдына китерде. Юк, беркайчан да...

Кызның уйларын сизгәндәй, Рәмилә Гөлкәйгә сынап карады да, тәвәккәлләп:

– Беләсеңме, Гөлкәй... Бәлки, әйтергә дә кирәкмидер дә инде, барыбер әйтим инде. Әлфис бик переживать итте синең өчен...

Рәмилә дәвам итү өчен сүзләрне бик озак сайлады. Гөлкәй дә дәшмәде.

– Монда әле ул... Синең терелгәнеңне иртә-кич көтте. Гафу үтенер идем, ди. Белмим, гафу итәрсеңме, юкмы, анысы үзеңнең эшең, шулай да үкенүе хак.

Аның үкенүе белән Гөлкәй хәзер нәрсә эшләсен?! Баш-

тарак уйларга кирәк иде. Гөлкәй бит аңа ачык итеп әйтте: яраткан кешем бар, синең белән тора алмыйм, диде. Әлеге минутта Гөлкәйнең Әлфисне күрәсе килми. Кыз баш чайкады. Ә менә икенче берәүне ничек итеп күрергә икән?! Рәмиләгә әйтсә?!

Рәмилә дә Гөлкәйнең Әлфисне күрәсе килмәвен аңлый иде, соравы да шул «әйттеңме-әйттем»гә генә кайтып калган иде. Ярар, соңрак килер әле егет. Барасы җире юк: Әлфис колхоздан эштән чыгып килгән. Шәһәргә урнашмакчы. Куып та җибәрә алмады бит Рәмилә, иртәкич егет палата ишеге төбен саклады. Әлеге минутта Рәмилә дустының күзләрендә башка теләк күрде. Тойды, сиземләде. Шуңа яңадан үзе тиз-тиз сүз башлады:

– Ярар инде, Гөлкәй, миңа да китәргә вакыт җитә. Иртәгә әле безнең яңадан «сопромат»тан контроль эш. Мансур Ибраһимовичны каядыр атна-ун көнгә командировкага җибәргәннәр, аның урынына да «сопромат». Шулай булгач, бик яхшы әзерләнәсе бар. Син тизрәк терел, кирәк әйберләрең булса, әйт, яме, алып килербез. Кызларга керергә рөхсәт бирсәләр, алар да килерләр. Терел тизрәк!

Рәмилә киткәннән соң, Гөлкәйгә тагы да ямансурак булып калды. Димәк, Мансур Ибраһимович аның авырганын белгән, тик хәл белергә килмәгән... Нәрсә булган соң укытучысына, аннан башка үткәргән бер ай эчендә нишләп болай үзгәргән әле ул? Әллә инде Гөлкәйне яратмыйча, башка берәүгә күз салды микән? Хәзер бит укулар башланды, димәк, беренче курска яңа, берсеннән-берсе матур кызлар килде... Гөлкәй үз уйларыннан үзе курыкты. Колагында әнисенең сүзләре кабат яңгырагандай булды. «Кызым, син бит акыллы, тыңла әле, балам. Уйлап кара бераз. Ул өйләнгән, хатыны, балалары бар. Янында яшь кызлар кайнап тора. Шуларның берсе – син. Аңа синең башны әйләндерү берни дә түгел!» Мансур Ибраһимович хатынын яратмый, анысы төгәл билгеле. Әгәр яратса, ул Гөлкәйне үпмәс, аңа сөю сүзләре сөйләмәс иде. Шунда ук кире кагыр иде. Күрде бит Гөлкәй, укытучының күзләрендә мәхәббәт күрде. Тик мәхәббәт булды микән соң ул, әллә вакытлыча гыйшык, теләк кенә кабынып алдымы икән? Хәзер башка кызга гыйшык тотамы икән? Юк, Гөлкәй үзенең сөйгән укытучысының андый җилбәзәк күңелле булуына ышана алмый. Мансур Ибраһимовичның үзен күреп сөйләшергә кирәк. Күзләренә

карап, сөю-сөймәве турында сорарга кирәк. Әгәр укытучы аны сөйми икән, ул вакытта... ул вакытта... Нишләргә соң ул вакытта?! Белми әле Гөлкәй, бу турыда уйланылмаган. Тик барыбер башта укытучыны күрергә кирәк. Ә моның өчен тизрәк хастаханәдән чыгарга кирәк. Шулай булгач, кызлардан үзенең үләннәрен, майларын китертергә, тизрәк терелергә кирәк. ...Йокымсырап күзләрен йомганда, кызның күңелендә моннан да зур теләк юк иде...

* * *

...Тәрәзәдән җепшек кар сыланган агач ботаклары үрелә. Кемне карыйлар алар, кемне күзәтәләр? Аудитория тәрәзәләре киң анысы, бу ботаклар бүлмә эчендә барган һәр вакыйганы, театр сәхнәсендәге кебек, озак еллар буе күзәткәннәрдер. Кайсыдыр укытучы лекцияне такта янында, паркта йөргән кебек, әрле-бирле атлап, кулларын бутый-бутый укыган, кемдер өстәлгә яртылаш утырган килеш дәрес аңлаткан, ә кемдер урындыкка утырып, өстәлгә башын салган килеш сөйләгән. Укытучыларның төрлесен күргән әлеге ботаклар. Студентларның да. Кайбер студентлар лекция саен иң алгы рәткә утырып, укытучының һәр сүзен йота барганнар, кемдер лекция дәфтәренә сәгать буе рәсем төшергән, кайсыберләре, укытучы очына-очына материал аңлатканда, башка предметтан өй эше эшләп утырганнар, ә кайберләре арткы парталарда йоклап көн үткәрүдән дә тайчынмаган. Ә бүген анда икәүдән-икәү генә калып, студент кыз белән укытучы сөйләшә. Тәрәзә пыяласы аларның сүзен чит-ятларга таратмый, шулай да ботаклар кызның күзләреннән тәгәрәгән яшь бөртекләренә аптырап карыйлар. Әле бит имтихан вакыты түгел... Имтиханда гына елый кайбер чибәр кызлар. Укытучының да йөзен болыт сарган. Юк, укытучының күзләре елаган кызга, гадәттәгечә, бераз көлемсерәп, бераз кызганып карамый. Үзе, еламаса да, күбрәк газаплана сыман. Ботаклар җисемгә ия шул, сүзнең нәрсә турында барганын бик беләселәре килсә дә, тәрәзә пыяласына бәрелүдән ары китә алмадылар. Ә менә җисемсез-исемсез Җил әфәнде аудиториянең кышкылыкка ябыштырылмаган тәрәзә ярыкларыннан җитез генә шуышты да керде. Тыңлады да таң калды...

– Мин сезнең турында башка фикердә идем, Гөлкәй

Салихҗановна. Мин бит инде сезгә әйттем: минем хатыным, балаларым бар, мин гаиләдән читтә интригалар корып, мәхәббәт уены уйнап йөри торган кеше түгел. Мин – коммунист, әхлак нормаларын һәрьяклап сакларга тиешле кеше. – Укытучының бәрхет тавышы бераз тынып торды. – Әйе, җәй көне мин ялгыштым. Әгәр хәтерләсәгез, сезнең теләк белән, сезнең сүзләрегезгә ияреп ялгыштым! Моның өчен мин сезнең алда тагы бер тапкыр, мең тапкыр гафу үтенәм!

Укытучы, үз сүзләренең авырлыгын үзе күтәрә алмагандай, көрсенеп куйды, гомердә булмаганча, аскы иренен тешләде, маңгаеннан тир тамчыларын сөртте. Гөлкәй аның бу хәрәкәтләрен күрми иде, ул, башын аска иеп, парта артында утыра. Башында укытучының сүзләреннән кадак кагалар: «Мин ялгыштым! Мин ялгыштым!»

– Бәлки, мин сезгә мәхәббәт сүзләрен яшьлегемне кире кайтарасы килүдән чыгып әйткәнмендер. Хәзер мин моны хәтта аңлата да алмыйм. Ләкин мин кабатлап әйтәм: зинһар, мине тынычлыкта калдырыгыз!

– Мансур Ибраһимович... Мин бит ул чакта сезнең сүзләргә ышандым, мин башкаларны ярата алмыйм, Мансур абый...

– Гөлкәй Салихҗановна, алай түбән төшмәгез, совет хатын-кызларына тиешле булганча, үзегезне горур тотыгыз. Мине соңгы чаралар кулланырга мәҗбүр итмәгез. Әгәр аңламыйсыз икән, мин сезнең тәртибегезне һәм алга таба укуыгызны комсомол җыелышында тикшерүне сорарга мәҗбүр булачакмын.

Гөлкәй кинәт кенә башын күтәрде, күзләреннән яшьләрен сөртте. Беркадәр тынычланып, үз-үзенә ышанган хәлдә, укытучының күзләренә төбәп карады да, тын гына:

– Мансур Ибраһимович, мин сезне үлгәнче яратачакмын. Мин сезнең сүзләрегезгә ышанмыйм. Әгәр сез мине яратмыйсыз икән, күзләремә карап әйтегез, – диде.

Мансур Ибраһимовичка әлеге мизгелгә кадәр авыр булмаган икән. Алдында утырган кызның күз карашыннан кинәт кызу булып китте, күңелендә әлегәчә басылып торган яратасы-ратыласы килү хисе яңадан чишмә булып кайный башлады. Шул ук мизгелдә укытучы күзләрендә икеләнү барлыкка килде, бу күз яшьләренә чыланып беткән озын керфекләрне, бу кара күзләрне, алсу иреннәрне, бу сылу гәүдәне кочагына кысып, иркәләргә-назларга теләде. Нинди җүләр ул... Хатын-кыз үзе синең

алдыңда мәхәббәт сорап тезләнгән, ә син, имеш, балалар язмышы, тугрылык! дип лаф орасың. Тугрылыкның тамыры корыган бер заманда... сөю югалып барган бер заманда... Борынгы философның әйткән сүзләре хәтеренә килде: «Без хайваннардан шуның белән аерылабыз да инде – тугрылык саклый беләбез...» «Әти, ә болан баласының әтисе кая киткән?» Ничек дип җавап бирерсең Рөстәмеңә? Башка бер болан кызы артыннан йөгергән диярсеңме? Юк, сабый алдында, сабый исеменә атап, үз хисләреңне тыя белергә кирәк. Соң инде, соң – яратырга, сөелергә.... Мансур Ибраһимовичның иманы камил: мондый мәхәббәтнең башы булса да, азагы булмас. Шуңа күрә аның тамырын корыту хәерлерәк...

– Гөлкәй!

Мансур Ибраһимович әйтергә теләгән сүзен әйтеп бетерә алмады, аудитория ишеге ачылды, анда профессор Альберт Шамилевичның пеләшләнгән башы күренде:

– Ә, менә кайда икәнсез, Мансур Ибраһимович! Кафедрада пальтогыз эленеп тора, ә үзегез юк! Нәрсә, зачетмы әллә?

Мансур Ибраһимович әлеге профессор иптәшне бик өнәмәсә дә, бу юлы аны күрүгә әйтеп бетергесез шат иде. Шуңа урыныннан сикереп диярлек торды, Альберт Шамилевич каршына барып, кул биреп күреште.

– Ачыклыйсы сораулар калган иде. Ярар, Гөлкәй Салихҗановна, минем әйткәннәр үз көчендә кала. Тәртибегезне яхшыртырга онытмагыз.

– Ә, Гөлкәй! Бик яхшы студентка ич бу безнең, Мансур Ибраһимович! Отличница! Тәртибе начарланганмыни?! – Альберт Шамилевич аудиториядән чыгып барган Гөлкәйне ялманып диярлек озатып калды. – Аңлашыла, аңлашыла! Чибәр кызларны тоткарласаң да гөнаһ түгел!

– Авыру сәбәпле, дәресләрен күп калдырган. Шуларны тапшырып йөри. – Мансур Ибраһимович, профессорның күрәләтә ымсынулы карашын чамалап, сүзне тизрәк икенчегә борырга ашыкты. – Мине нигә эзләгән идегез, Альберт Шамилевич?

...«Ул ялгышкан... Ул мине бөтенләй яратмаган...» Әйтерсең сүз башка кеше турында бара. Күңелендә аңлатып бетерә алмаслык битарафлык, бушлык. Мондый бушлыкны гомерендә дә тойганы юк иде Гөлкәйнең. Барысы да үз урынында кебек: йортлар, агачлар, трамвайлар, урамны тутырып чапкан машиналар... Кешеләр. Бары-

сы да үз урынында. Шул ук вакытта берсе дә юк сыман. Берсе дә Гөлкәйнең күңеленә ямь өстәмиләр, дәва бирмиләр. Гөлкәй тулай торакка җәяү генә атлады. Беркемне дә күрәсе килми иде. Әле кичкә кадәр вакыт бар, бәлки, күңелендәге авырлык бераз җиңеләер, нәрсәдер үзгәрер, нәрсәдер... Гөлкәй бераз автобус тукталышында утырды, аннан икенче тукталышка кадәр тагы җәяү атлады, тагы тукталыштагы эскәмиягә аркасын терәде. Вакыт үтте, һәм ул вакыт бернәрсәне дә үзгәртмәде. Инде караңгы төште, сәгать тә кичке җидене күрсәтте. Кайтырга кирәк.

...Тулай торак каршында җепшек карны эретеп, таптанып торган озын буйлы кешедә таныш чалымнар табып, Гөлкәй башта сискәнеп китте. Әлфис икән. Әнә ул да Гөлкәйне танып алды, моңсурак елмаеп, каршысына килә. Соңгы араларда Әлфис еш кына аларның бүлмәләренә килеп йөри башлады. Рәмилә белән уртак тел таптылар, ахры. Алай дисәң, Рәмиләнең үзенең дөньясы Нияз исемле егет белән тулган. Шулай да кичләрен Әлфис килү белән Рәмилә, җыенып, уку залына төшү ягын карый, Әлфис тә аның белән төшә. Гөлкәйгә Әлфиснең болай үзләренә килеп йөрүе борчу тудырмады. Әлфис аңардан инде мең кат гафу үтенде, Гөлкәй дә аны кичерде. Нишлисең, яшьлек-җүләрлек, уйланылмыйча эшләгән эш, әбисе әйтмешли, узган эшкә салават. Шулай да бу «узган эш» кайчакта Гөлкәйне ялыктыргыч ютәлгә сала әле...

– Исәнме, Гөлкәй. Соң кайтасың икән, кичләрен йөрергә курыксаң, каршы алыр идем. Әйт кенә.

Гөлкәй авырсынып елмайды.

– Рәхмәт, Әлфис. Бүген генә шулай туры килде, башка көннәрдә вакытында кайтам мин...

Гөлкәй, артыгын сөйләшми, ишеккә таба атлады. Кинәт нәрсәдер, ниндидер көч аны әйләнеп карарга мәҗбүр итте. Әлфис һаман, шул ук урында басып, Гөлкәй артыннан карап тора, кымшанмый да. Күзләре очраштылар. Гөлкәй егетнең ачык соры күзләрендә үзендәге кебек үк бушлык күрде. Дөньяга битарафлык күрде. Күрде дә, баскан урыныннан кымшана алмый, torаташтай катып калды. Йа Хода... Элек игътибарга алмаган иде. Егет тә бит Гөлкәй кебек үк бәхетсез икән. Аның да бит күңелендә бушлык, гамьсезлек икән. Күңеле тулы авырту, газап икән. Нишләп әле без кешеләргә җиңел генә авыр сүзләр әйтә алабыз, аларның авырлыгын үзе-

безгә әйләнеп кайткач кына тоябыз соң?! Әлфисне кире какканда Гөлкәй бер дә газапланмаган иде. Инде менә үзен кире кактылар... Кыз, юатырлык сүзләр эзләп, Әлфискә таба атлады. Тапмады.

– Әлфис, син ашыкмыйсыңмы? Әйдә, якыннан гына әйләнеп киләбез.

Әлфис бу сүзләрне әллә аңламады, әллә аларга ышанмады.

– Кибеткә керергә онытылганмы? Сөт беткән, якындагысында мин булдым инде. Еракта булса гына.

Гөлкәй моңсу елмайды. Ничек аңлый ул хәзер Әлфисне.

– Юк, Әлфис. Кибеткә керергә кирәкми. Болай гына, йөреп килик, дим. Син эшкә урнаштым, дигән идең, ахры?

Әлфис, үз колакларына үзе ышанмый, Гөлкәйгә иярде. Кайчакта могҗиза була бит... Могҗиза күргән кешенеке кебек иде аның кыяфәте.

– Әйе, эшкә дә, тулай торакка да урнаштым. Ипи заводында машина йөртүче хәзер мин. Тик анысы вакытлыча дип уйлыйм. Әле тагы рабфакка укырга кердем ич.

Гөлкәй монысын ук белми иде. Чыннан да, гаҗәпләнеп сорады:

– Кайчан өлгердең, Әлфис? Кая, кайсы институтка?

– Сезнең институтка. Рәмилә булышты инде.

Гөлкәй, шаккатып, Әлфискә карады. Ничә яшь икән бу егеткә? Утыздан ким түгелдер...

– Котлыйм, чын күңелдән котлыйм, Әлфис. Институтка кабул ителергә, яхшы укырга, тәмамлап чыгарга насыйп булсын.

Әлфис тә җанланып китте, көлеп үк җибәрде.

– Әле тумаган тайны иярлибез булып чыга инде анысы. Кереп булырмы, юкмы – кем белгән. Шулай да тырышырга исәп. Аю – беләгенә ышаныр, кеше – йөрәгенә ышаныр, диләр бит. Заочнога керергә исәп, көндезге өчен мин карт инде – егерме алтыны тутырдым. Рәмилә бик булыша, аңа өметләнәм.

Гөлкәй читенсенеп китте. Әнә Рәмилә егетнең кайгысын күптән күреп алган, ә ул дәрвишләрчә сукыр икән... Болай ярамый.

– Мин дә булышырмын, Әлфис. Син ничек дигән идең әле? Мин җырлыйм, син уйныйсың – шулаймы?!

Гөлкәйнең исәбе егетне көлдерү иде. Уйламыйча әйткән икән. Әлфис, киресенчә, шунда ук үз эченә йомылган кебек булды, йөзе караңгыланды.

– Гафу ит, Гөлкәй... Нәрсә уйлаганмындыр ул чакта!

Гөлкәй, ашыгып, иренен тешләде. Ничектер сүзләре сүзгә ябышмый. Аның яңадан әлеге күңелсез хәлләргә әйләнеп кайтасы килми иде. Шуңа барган җиреннән капыл гына туктады да, Әлфискә ике әйтмәслек итеп:

– Әйдә, Әлфис, онытыйк без ул турыда, – диде. – Минем күңелемдә сиңа карата ачу юк. Мин сине аңлыйм. Шуңа күрә башка бу турыда сүз башламыйк.

Әлфис тә Гөлкәйдән күзен ала алмады.

– Мин үземне кичерә алмыйм, Гөлкәй. Әгәр шул вакытта, урманда ятканда, синең белән берәр хәл булган булса? Әгәр син авырудан терелә алмый үлеп китсәң? Ничек шул турыда уйламаганмын мин?

Егет, үзен яңадан газапларга теләгәндәй, кабат-кабат көрсенде, кулы белән маңгаен уды. Күрәсең, бу сүзләр инде күптән тынгы бирми иде аңа.

– Үлмәгәнмен бит әле менә, исән калганмын. – Гөлкәй дә, ямансулап, көрсенеп алды. – Бәлки, үлгән булсам, теге дөньяда мин сиңа тезләнеп рәхмәт әйткән булыр идем...

Егет, кайнарланып, Гөлкәйнең кулларын учына кысып тотты.

– Алай димә, Гөлкәй. Мин сине аңлыйм. Башта авыр була, аннан үтә ул. Тормыш дәвам итә. Мәхәббәт, бер булса да, ике йөрәктә яшәргә тиеш. Бер йөрәктә генә яшәгән мәхәббәт ярты гына була. Димәк, икенче яртысын башка йөрәктән эзләргә кала. Бер йөрәктә мәхәббәт булса, икенчесен дә кабыза ала.

Гөлкәй аңламады.

– Әллә ни сөйлисең, Әлфис, аңламыйм, – дигән булды, үзе кулларын егетнең учыннан ычкындырды. – Әйдә, бу турыда сөйләшмибез, яме!

Алар тагы бераз урам әйләнделәр. Егет үзләренең авылы турында, абый-энеләре турында сөйләде. Әти-әнисенең инде вафат икәнлекләрен әйтте. Туган нигезенең тәрәзәләрен кадаклап чыгып китүе бик авыр булганын аңлатты. Гөлкәй шушы сәгатьтә бер әйбергә төшенде: дөньяда бик, бик күп кеше яши икән ләбаса. Аларның һәркайсының үзенең язмышы, борчу-газаплары бар икән. Нишләптер элек бу турыда уйламый иде. Элек үзенең дөньясы, үзенең Мансур Ибраһимовичка булган мәхәббәте белән генә яшәгән икән. Кинәт кенә йөрәгендәге бушлыкның бер өлешен Әлфиснең сагышы, тагы җир йөзендәге алты миллиард кешенең бәхете-бәхетсезлеге биләп

алды. Әлбәттә, моңа карап Мансур Ибраһимовичка булган мәхәббәте кимемәде, киресенчә, укытучының да шул алты миллиард арасында үзенең бәхете-бәхетсезлеге бар икәне ачыкланды. Тулай торак бүлмәсенә кайтканда, Гөлкәй күңелендәге «мин һәм минем җавапсыз мәхәббәтем» темасы беркадәр артка чигенеп, күңеле йомшарып калган иде. Әлфискә рәхмәтле иде кыз...

* * *

...Мансур Ибраһимович бүген дә йоклый алмады. Янындагы Розалиянең тигез сулышын шактый озак тыңлап ятканнан соң, кухняга чыгып, ут кабызды, кәгазьләрен алып, өстәл артына утырды. Төн уртасы узып бара. Эшләргә дип чыкмаган иде ул. Яңадан торып, кухня тәрәзәсе янына килеп утырды, башын салкын пыялага терәде. Әнә йорт ишегалдында, яңа явып киткән ап-ак карның салкынлыгын сизмичә, лампа уты яктысында бер пар басып тора. Егетнең куллары кызның билендә, кыз егетнең иңенә башын салган. Бер-берсенең йөрәк тибешен сизеп, тын гына басып торалар. Бәхетле мизгелләре. Яшьлекләре. Мансур Ибраһимович күзләрен йомды, шунда ук алдында Гөлкәйнең күз яшьләренә чыланган йөзе пәйда булды. Бүген дә, алдагы дәрестә тә рәнҗетте аны Мансур Ибраһимович. Рәнҗеткәнен аңлап, махсус рәвештә рәнҗетте. Шулай кирәк иде. Гөлкәй аны күралмаска тиеш. Йөрәгендәге мәхәббәтен күралмаучанлык белән алыштырырга тиеш. Укытучының төсен, битен, кыяфәтен мәңге күңеленнән кырып-юып алырга тиеш. Ә моның өчен Мансур Ибраһимовичны усал, гаделсез, начар холыклы, ялганчы, җилбәзәк, коточкыч эгоист итеп истә калдырырга кирәк. Мансур Ибраһимович бу хакта мең тапкыр уйлады инде. Гөлкәй әле яшь кыз гына, ул үзенең чын мәхәббәтен табар. Яшьлектә кем укытучыга гашыйк булмаган да кем гыйшык утларында янмаган. Онытыр. Мансур Ибраһимовичның Гөлкәй тормышын җимерергә хакы юк. Укытучы күңелендә дә бу мәхәббәт татлы, ләззәтле бер хис булып кына калыр. Ул да онытыр. Себернең коеп яуган яңгыры астында үткәргән һәр мизгеле берәм-берәм, татлы-газаплы төш булып, үткәнгә китеп югалыр. Кара күзләрне, озын керфекләрне, сусыл иреннәрнең ымсындыргыч тәмен онытыр. Бу вакытта инде ул сиксәннән өстә булыр. Ә аңа кадәр... Аңа кадәр һәр

көн кич кухня тәрәзәсенә башын терәр дә, күзләрен йомып, күңеле шул тормышта бер генә була торган Себер яңгырына, Гөлкәй исемле гүзәл кочагында эреп юкка чыккан мизгеленә әйләнеп кайтыр...

* * *

...Учак яна. Ялкын телләре, төн караңгылыгын ертып, күкне үбеп калырга ашыгалар. Очкыннарның аксыл-кызгылт төсенә йолдызлар көнләшеп җемелдәшә. Учак кырыена җыелып утырган яшьләр, балыкка җим сипкән кебек, ара-тирә утка кәгазь битләре ташлыйлар, канәгать учак очкыннарын яңадан йолдызларга суза. Студентлар диплом яндыралар[1]. Әледән-әле тынлыкны яңгыраткан гомуми уен-көлеш, шаян сүзләр ишетелә. Биш ел буе укыткан укытучыларның исемнәре телгә алына, кемнедер хөрмәткә күмәләр, кемнедер каһәрлиләр... Менә учак яктысыннан ике күләгә аерылып китте, салмак атлап, тулай торак кырыенда үскән агачлыкка юл алды.

– Кайчан мин дә сезнең кебек диплом яндыру бәхетенә ирешермен инде.

– Ничә ел калды дисең, Әлфис? – Тавыш тыенкы, беркадәр моңсу булса да, ягымлы.

– Күп әле! – Егет, көлеп, бармакларын санады. – Бер, ике, өч, дүрт. Дүрт ел бар әле минем.

– Үтә ул. – Моңсу тавыш бу сүзләрне үз-үзенә бик ышанып әйтте. – Үтә ул, Әлфис. Элек мин дә бу укуның очы-кырые күренми дип уйлый идем. Бөтен нәрсә мәңгелек дип уйлый идем. Үтә икән. – Кыз көрсенеп куйды. – Хәзер менә нишләргә дә белгән юк. Направление[2] буенча ниндидер күз күрмәгән, колакларым ишетмәгән Әгерҗе районына җибәрәләр.

– Ә синең Казаннан китәсең килмиме?

Кыз бераз уйланып торды. Аннан тагы үз-үзенә ышанып җавап бирде:

---

[1] Бишенче курс студентларының имтиханнарны биреп, диплом эшен яклаганнан соң уздырыла торган йола-гадәтләре. Нигездә, диплом эшенең караламасы (черновигы) һәм кирәкмәгән лекция дәфтәрләре утка ташлана.

[2] Совет елларында вуз бетергән белгечләрне юллама буенча вуз һәм партия билгеләгән урыннарга эшкә җибәргәннәр. Анда өч ел эшләү мәҗбүри таләп ителгән.

– Юк, китәсем килми, Әлфис. Мин бу шәһәргә ияләндем инде. Яраттым дияргә була.

– Ә син китмә. Кызларга монда калу җиңелрәк. – Егет ышанмыйча гына, икеләнеп әйтте. – Теләгәннәргә инде, әлбәттә.

– Син шулай дип уйлыйсыңмы? Ә ничек монда калырга була соң?

– Әйтсәм, ачуланмыйсыңмы?

– Нишләп ачуланыйм инде? Әйтергә ярамаган сүз түгелдер бит?

– Кызлар, Казан кешесенә кияүгә чыгып, шәһәрдә кала алалар. Кызларга җиңелрәк. – Егет, бераз тын торгач, беркадәр уфтанып өстәп куйды: – Димәк, Казан егетенә кияүгә чыксаң, монда каласың дигән сүз.

– Кияүгә чыгарга дисеңме? – Моңсу тавыш тагы да моңсулана төшкән кебек булды, сүзләрне сузыбрак әйтте. – Кияүгә чыгарга. Әйе. Күрәсең, кияүгә чыгарга да вакыт инде. Бер генә сорау кала – кемгә?

– Синең кебек чибәр кызга андый сорау биреп торырга туры килмидер лә.

– Ә син мине кияүгә алыр идеңме?

Егет атлаган җиреннән туктап калды, бераз тынып торгач:

– Юри әйткәнеңне аңлыйм инде. Тик алай шаярма, зинһар. Авырткан урынга кагылуың бар.

Кыз да җитдиләнеп китте.

– Син хәзер мине яратмыйсыңмы инде, Әлфис?

Егет төн каралыгыннан кызның күзләрен эзләде: тавыштан гына шаярумы, түгелме икәнен аерып булмый иде. Юк, алдамыйлар да, көлмиләр дә кебек. Шулай да егет ышанмады, җавап бирмичә, тын гына басып тора бирде.

– Әлфис, әгәр мин сиңа кияүгә чыгарга риза булсам, син инде мине кире кагар идеңме?

Егет үзенең күкрәгенә назлы, җылы тәннең килеп уралганын тойды, битенә кызның битләре кагылды. Бу назга каршы торуы авыр, мөмкин түгел иде. Егет кинәт кенә акылдан язгандай булды, кайнарлык белән кызның сылу гәүдәсен кочакларына яшерде, йөрәге урыныннан атылып чыгардай булып типте.

– Гөлкәй... Нигә болай газаплыйсың бүген син мине? Ничә еллар өзелеп яратканымны беләсең ич! Көләсеңме тагы?

Иреннәр. Болары да йомшак, тик Мансур Ибраһимовичның иреннәре суыра торган чоңгыл иде. Башка иреннәрне белми Гөлкәй. Мансур Ибраһимович кочагында эрегәнен хәтерли, акылын югалтканын белә... Ә бүген барысы да икенче төрле. Юк, алай ук начар дип әйтмәс иде. Элеккеге күңел кайтаргыч тәмәке исе дә юк, аракыны Әлфис бөтенләй авызына алмый бугай. Киресенчә, затлы одеколон исе борынын кытыклый, җылы, талгын рәхәтлек сизә, Әлфиснең җиңелчә калтыравын, аның хисләрен, теләгән тоя, тик үзендә шул хисләргә җавап юк. Аңы үз урынында, дөнья әйләнми, уйлары да буталчык түгел. Кайсыдыр профессорның сүзләре искә төште әнә: «Тулаем алганда, уңай тәэсир калдыра». Уңай тәэсир. Кем уңай тәэсир белән тормыш итеп булмый дип әйткән?

– Мин көлмим, Әлфис. Әгәр син мине яратсаң һәм кияүгә алырга риза булсаң, мин сиңа барыр идем. Тик өч шартым бар.

Кыз егетне үзеннән читкәрәк этәрде. Әлфис бераз вакыт тынын җыеп торгач, Гөлкәйнең кулларын иреннәренә китереп үпте.

– Нинди генә шартлар булса да, мин аларны үтәргә әзер. Миңа кияүгә чыгарга риза бул, Гөлкәй!

– Ашыкма, Әлфис.

Кыз да бераз тынып, әйтергә теләгән сүзләрен тәртипкә китерде.

– Иң авыр шартым: миннән мәхәббәт таләп итмә, Әлфис. Яраткан кешем барлыгын күптән беләсең. Мин аны беркайчан да оныта алмамын кебек. Гаилә булып торганда, сиңа хыянәт итмәм. Иң тугры хатын булырмын, балалар үстерербез. Тик мәхәббәтем чакырса, мин синнән китәчәкмен, Әлфис. Иң авыр шартым шул.

Әлфис дәшмәде. Шактый озак тын торды. Аннан көрсенеп куйды, яңадан учларына Гөлкәйнең кулларын кысты.

– Хәтерлисеңме, мин сиңа бер тапкыр әйткән идем: мәхәббәт бер генә була, тик ул ике йөрәктә яши. Минем мәхәббәтемнең яртысы синеке булыр, Гөлкәй. Мин синең беренче шартыңа риза.

– Икенче шартым: мин аспирантурага укырга керергә телим.

– Монысына мин һәрвакыт риза! Ирләр укыган хатыннарны бик яратмыйлар инде, шулай да мин сиңа кулдан килгәнчә ярдәм итәрмен. Бу шартыңны да үтәргә мин әзер.

– Алайса, өченчесе бөтенләй җиңел инде: Әлфис, мин чәчләремне кистерәчәкмен.

Әлфис аһ! итте. Шунда ук Гөлкәйнең кара толымнарын учларына чылбыр ясап менгезде, сыйпады, үпте.

– Гөлкәй! Ни сөйлисең син! Синең чәчләрең бит дөнья бәясе тора, нишләргә уйлыйсың?!

– Әлфис, мин сиңа кияүгә чыксам да, чыкмасам да, чәчләремне кистерәчәкмен. Бәлки, хәзер үк түгел, бераздан соң булса да, мин чәчләремне кистерәчәкмен.

Бер үк сүзләрне үҗәтләнеп кабатлаган кызга Әлфис аптырап карады. Бу аның өчен иң авыр шарт иде. Нәрсә булган Гөлкәйгә?!

– Бу шартымны кабул итмәсәң, гафу ит, Әлфис. Димәк, мин сиңа лаеклы түгел.

– Гөлкәй... Мин риза. Нишләтәсең син мине, аһ, гөлемгөлкәем...

Гөлкәй сискәнеп китте. Бу сүзләр тик аныкы, Мансур Ибраһимовичныкы гына иде. Әлфис кагылырга ярамаган урынга кагылды. Үзе сизмәстән кагылды.

– Дүртенче шартым калган: мине беркайчан да алай дип атама! Оныт ул сүзләрне! Оныт!

Гөлкәй яшь аралаш кычкырды. Берни аңламаган Әлфисне этеп җибәрде дә төн каралыгына йөгерде. Учак янына, дус кызлары янына йөгерде. Их, узганнарга да шулай йөгереп кенә кайтып булса икән...

# ЭПИЛОГ

Идел ярында тал елый. Бу талларны кем утырткандыр – билгесез. Алар инде озак еллар буе шулай, кәүсә-тамырларын кисеп кергән асфальт-бетон кантарларны сизмәгәнгә салышып, су буенда әкрен генә шаулап утыралар. Җилсез, яңгырсыз кызу көннәрне таллар елый. Тал яшьләре, тып-тып итеп, Идел дулкыннарына тама. Һәрвакыт хәрәкәттәге, һәрвакыт шаян һәм шук дулкыннарга бу күз яшьләренең баллы тәме беркадәр гаҗәп тоела. Кемне сагынып елыйлар икән бу таллар? Ерак түгел генә Идел портына таба йөзеп баручы теплоходлар сузып-сузып кычкырталар. Аларның моңсу тавышына яр буенда аякларын суга салындырып утырган ике хатын-кыз сискәнеп китә.

– Еллар үтәләр дә үтәләр, Рәмилә. – Кара чәчләре җилкәләренә төшкәне авыр сулап ала. – Картаябыз бугай.

– Әй, юкны сөйләмә әле, Гөлкәй. Кая әле безгә картаерга? Яши башладык кына лабаса!

– Әллә минем генә күңелем картая микән? Озакламый утыз ике яшь тула бит инде миңа...

– Ә миңа күпме дип уйлыйсың? Миңа да утыз ике тулды! Тик картаерга уйламыйм да. Гомумән, сиңа да болай моңсуланып утыру килешми, дустым! Исемең бар, дәрәҗәң бар, нинди урында эшлисең бит әле – у-ни-вер-си-тет-та!!!

Гөлкәй авыр сулап куйды.

– Китәм мин, Рәмилә. Университеттан китәм.

Рәмилә Гөлкәйнең сүзләренә артык гаҗәпләнмәде булса кирәк.

– Димәк, мәхәббәттән качасың алайса. – Рәмилә дустының иңнәреннән кочып алды. – Мансур Ибраһимовични әйтер идем инде! Алай интектерерлек булгач, нишләп үз янына чакырып алгандыр сине!

Гөлкәйнең болай да кара төн кебек күзләре зураеп ачылдылар, Рәмиләне йотардай булып, кызга текәлде:

– Син белә идеңмени?

Рәмилә көлеп куйды.

– Нишләп белмим инде, Гөлкәй. Бергә яшәдек ич. Мансур Ибраһимовични күргән көнне чәеңә тоз салып бутаганны хәтерлисеңме? Бернинди башка шаһзадәң юк иде бит синең. Ә Мансур Ибраһимович авырганда? Үзеңнең тилелегеңне читтән күрсәң иде!

Гөлкәй дә елмайды.

– Мин аны һаман яратам, Рәмилә. Яшьлектәге хисләрем бер бөртек кимемәде, һаман, аны күргән саен, артыннан йөгерердәй булам. Тик хәзер инде итәктән тарталар шул.

– Әйе, Әлфисең, Таңгөлең бар.

– Мин алар булуга мең рәхмәтле. Сиңа да теге елларда Әлфисне кеше арасына чыгаруыңа рәхмәт! Син ярдәм итмәсәң, без бергә булмаячак идек бит.

Рәмилә хәйләкәр елмайды.

– Башкалар арасында Әлфис иң кулай кандидат булып тоелды. Бары шул гына. Читтән күбрәк күренә бит ул.

Гөлкәй җанланып китте.

– Беләсеңме, мин үзебезнең туган туфракка, әби-бабаларым авылына килен булып төшкәнмен бит, әй! Кайчандыр минем әби килен булып төшкән авылга! Әни Себердән Әлфисләргә туйга кайткач, үзе ышанмады хәтта. Барысы да дөрес, авыл кешеләре дә хәтерләделәр.

– Гаҗәп. Менә язмыш юк диген инде, әйеме?!

– Күрәсең, «йөртә безне язмышлар» дип җырлаулары хактыр инде. Әтинең «туган җиребезгә кайт» дигән аманәтен үтәдем, шуңа күңелем тыныч. Югыйсә Әлфис урлаган төнне мин ул авыл кешеләрен күрәлмас хәлгә җиткән идем.

Рәмилә дә, еракта калган вакыйгаларны искә төшереп, бераз тын утырды.

– Беләсеңме, ул вакытларда әйтә алмый калган бер сүзем бар сиңа. Ничә еллар «әйтәм, әйтәм» дип йөрдем, әйтә алмадым.

Рәмилә туп-туры Гөлкәйнең күзләренә карады.

– Син хастаханәдә ятканда, Мансур Ибраһимович яныңнан китмәде бит. Терелгәнгә, аңга килгәнчегә кадәр. Хатынына ничек дип аңлаткандыр – анысы миңа караңгы. Ярата ул сине, Гөлкәй. Аннан соң дәресләрдә сине җәберләве дә шул синең күңелең суынсын өчен генә булгандыр дип уйлыйм.

Гөлкәй авыр сулап алды.

– Мин дә беләм яратканын. Хәтерлисеңме, мине ачулана башлаганда гел дәрескә әзерләнми йөри торган Альбинага карап кычкыра иде? Үзе мине ачулана, янәсе. Галәсен мәхәббәттән өстен күрде ул. Шуның өчен мин аны бик хөрмәт итәм. Андый ирләр музейларда гына инде хәзер. Үзем җүләр идем.

Рәмилә кулын селтәп алды.

– Синең тәүге мәхәббәтең булгандыр ул, Гөлкәй. Шуңа оныта да алмыйсың инде.

– Әгәр аның яратуына ышанычымны югалтмаган булсам... Кияүгә чыкканымны әйткәч, син аның йөзен күрсәң иде, Рәмилә! Лекциясен укымыйча каядыр чыгып йөгерде. Ә мин шундый үкендем кияүгә чыкканыма! Авырлы идем инде... Мин бит аның өчен университет аспирантурасын тәмамладым, кайчакта, ерактан гына булса да күреп йөрермен дип, күрше кафедрада укытырга калдым...

– Ә хәзер нәрсә булды, нигә китәм дисең?

– Китәм, Рәмилә. Быел Мансур Ибраһимовичка илле яшь тулды. Зур улы инде университет бетерде, кечкенәсенә дә күп калмагандыр. Хатыны белән аерылганнар, икенче кешегә кияүгә чыккан икән, диләр. Үз-үземнән куркам, Рәмилә. Ымсынырмын, баламны әтисеннән мәхрүм итәрмен дип куркам. Җитмәсә, быел Әлфис үзенең фирмасын ачып җибәрде, аңа булышырга кирәк.

– Ә мәхәббәт?! Ничә еллар буе йөрәгеңдә йөрткән сөйгәнең белән кавышырга мөмкинлек табылгач кына качасың түгелме соң?

– Әй, Рәмилә! Үгетләмә, ымсындырма! Йә акылымны югалтырмын!

– Ярар алайса. Үзең беләсең инде, Гөлкәй. Гашыйкка кеше киңәше – искән җил генә. Тик берүк иртәгәсе очрашу хакында гына онытма!

Гөлкәй моңсурак итеп елмайды.

– Онытмыйм инде, нишләп онытыйм ди... Институт бетергәнгә ун ел узган диген, ә? Ышанасы да килми хәтта!

– Узган инде, узган. Замана да ничек үзгәрде! Туксан җиденче ел бара... Өч елдан коммунизм каршыларга тиеш кешеләр идек югыйсә...

Ахирәтләр шактый вакыт тын утырдылар. Идел дулкыннары аякларын кытыклый, көньяктан искән җылы җил чәчләрен тузгыта, кояш нурларын читкә алып китә...

– Группадашларны күптән күргән юк. Кызлар турында хәбәрләр килә килүен, тик үзләре белән кара-каршы утырып сөйләшмәгәч, күңелле түгел инде ул. Иртәгә кемнәр килер икән диген син?

– Якындагыларга да, ерактагыларга да әйтелде. Үзебезнең бүлмә кызлары килер, шәт. Алай дисәң, син дә мин инде. Зөлфия авылда, бала үстереп ята, ул килер; Гөлүсә хәзер бизнеска чумган диделәр, ул да килергә тиеш; Чулпан үзләренең якларында, нишлидер, белгән юк. Син дә Мәскәүнең үзендә кайныйсың, ә, Рәмилә?

Рәмилә көлде.

– Әй, безнең татар башы кайда гына югалмаган! Элек тә мин банклар системасы белән кызыксына идем ич, мөмкинлек булгач, китеп бардым инде. Аллага шөкер, зарланмыйм.

– Менә Фаягөлне генә табып булмады. Аны инде өченче иреннән дә аерылган дигәннәр иде, хакмы икән?

– Кем белгән. Беренче ирдән бәхетеңне тапмасаң, йөз иргә җитсәң дә юктыр ул, Гөлкәй. Йөз дә беренчесе бәхет китерер дип уйламыйм.

– Сезнең дә Нияз белән юлларыгыз аерылды...

– Нияз өчен мин артык мөстәкыйль идем шул. Безнең татар ирләре хатыннарның мөстәкыйльлеген кичерә алмыйлар. Алар үзләре солтан булып, хатынны олтан итеп яшәргә күнеккәннәр.

– Әлфис андый түгел кебек.

– Синең Әлфисең юлыңда очраган бер асылташ ул. Кадерен генә белмисең.

– Беләм, Рәмилә, беләм... Тик хисләргә белем кирәкмени!

– Шулай инде. Кайтыйк без, Гөлкәй. Казанны бик сагынган идем, тик бу Казан минеке түгел. Бу, күрәсең, киләчәк буын Казаны... Элеккеге кыйшайган асфальтлы Бауманда йөрисе килә...

...Кафедра мөдире бүлмәсенең ишеге ачык. Ишек тә, тәрәзәләр дә ачык, бүлмәдә талгын җил уйнап йөри. Вакытның соң булуына карамастан, профессор Мансур Ибраһимович китмәгән әле, димәк. Гөлкәй, үкчәләрен бик шакылдатмаска тырышып, бүлмәгә керде, ишекне тавышсыз гына япты. Күрәсең, Мансур Ибраһимович эчке бүлмәдә. Әнә ул тәрәзә янына кулларын артка куеп баскан да җилдә уйнаган чыршы ботакларына онытылып карап тора. Кара дулкын чәчләре дә шул ук, тик чигәләре генә көмешләнгән. Маңгаена еллар буразналар салган. Менә Гөлкәйгә таба борыла. Танымый инде әллә? Күзләрендә – аптырау, чиксез гаҗәпләнү.

– Гөлкәй?!

– Мансур Ибраһимович, исәнмесез!

Гөлкәй кулындагы төргәкне якында торган урындыкка сөяп, эчке ишекне дә япты.

– Гөлкәй! – Укытучы, шашкан кешедәй, Гөлкәйгә якын ук килеп, куллары белән ханымның чәчләрен туздырды. – Гөлкәй, нишләттең чәчләреңне? Кайда толымнарың?

Гөлкәй кыска чәчләрен тузгыткан кулларны кысып тотты, Мансур Ибраһимовичның күзләренә карады.

– Мин хушлашырга кердем, Мансур Ибраһимович.

Укытучы ишетми аны. Беркадәр үпкәле тавыш белән һаман бер үк сүзләрне кабатлый:

– Гөлкәй, чәчләреңне нигә кистең?

– Мин китәм, Мансур Ибраһимович. Шуңа күрә сезнең белән хушлашырга кердем.

Ниһаять, Гөлкәйнең сүзләре укытучы аңына барып җитте, күрәсең, күзләрендә аңламау, сорау барлыкка килде.

– Мин университеттан, Казаннан, сездән, яшьлегемнән, сөюемнән китәм, Мансур Ибраһимович.

– Ни сөйлисең син, Гөлкәй? Ничек инде китәсең? Кая китәсең?

– Мансур Ибраһимович...

Гөлкәй башка түзә алмый. Укытучының, сөйгәненең шулкадәр якынлыгы аны шаштыра, уйларын бутый, әйтәсе килгән сүзләрен җилгә очыра... Болай булса, ул беркайчан да араны өзә алмаячак. Ул хәл итте инде, артка юл юк.

Гөлкәй, укытучыны үзеннән беркадәр читләштереп, урындыкка куйган төргәген алды, сүтеп җибәрде. Гади генә рамкаларга утыртылган картина иде бу. Бер якта Камышлы күлнең ярсу дулкыннары кояшта чайкалалар, икенче яктан, тоташ стена булып, яңгыр явып килә. Очы көеп каралган каенның ботаклары тузгыган...

– Тормышымдагы иң бәхетле көнне мин сезгә бүләк итәм, Мансур Ибраһимович. Истәлегем булсын.

Мансур Ибраһимовичның йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. Кулларын пешереп торган рәсемне тизрәк өстәлгә куйды, Гөлкәйгә якын килеп, сак кына кочып алды, иелеп, колагына пышылдады:

– Мин истәлекләр белән озак яшәдем, Гөлкәй. Сине дә, үземне дә газаплаганмын. Гафу ит... Миңа син кирәк, гөлем-гөлкәем. Китмә...

Гөлкәй Мансур Ибраһимовичның җилкәләренә башын салды. Күзләреннән яшьләр агып төште. Кеше гомере шулай төзәтеп булмый торган ялгышлардан тора микән әллә? Кайда ялгыш ясаганыңны ничек белергә? Кайчандыр, күп еллар элек, Мансур Ибраһимович ялгышты микән, әллә бүген Гөлкәй ялгышамы? «Илаһидан мәҗүсигә – бары бер мизгел...»

– Хушыгыз, Мансур Ибраһимович!..

* * *

...Әй, вакыт! Син һәрвакыт ашыгасың, әйтерсең без мәхлукларның газапларын күрмисең дә. Күрсәң, ялгышларыбызны төзәтергә кушар идең. Кайтарып булмый торган ялгышлар була, дияр идең. Төзәтеп булмый торган ялгышлар була, дияр идең. Якын кешеләр янда булганда аларның кадерен белегез, дияр идең. Сөйгән ярларны яшьлектә эзләгез, дияр идең. Әй, вакыт! Син үзең бер дә ялгышмыйсың микәнни соң? Синең һәр мизгелең үз урынында микәнни? Нигә безне шулай бер дә ялгышмыйча яшәргә өйрәтмисең син? Әллә безгә ялгышларның ачысын татып, күңелебезнең керләрен әнә шул ялгыш ачысы белән кырып-кырып юу кадерле микән? Әллә кешегә шунысы да кирәк микән?

*2004*

## ЭЧТӘЛЕК

ЯШӘҮ МОҢЫ

4

АСЫЛЪЯР

118

Литературно-художественное издание

**Ширман** Халиса
(**Кузьмина** Халиса Хатиповна)

**ОТ СУДЬБЫ НЕ УБЕЖИШЬ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Ширмән** Халисә
(**Кузьмина** Халисә Хатыйп кызы)

**ЯЗМЫШЛАРДАН ЮК ЛА УЗМЫШЫМ**

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 27.07.2009.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 15,12. Тиражы 2000 д. Заказ В-496.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.